# Казан
# УТЛАРЫ

ЯНВАРЬ № 1
1966

*Яңа ел котлы булсын,*
*хөрмәтле иптәшләр!*

# КАЗАН утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

*КЫРЫК БИШЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

1

ЯНВАРЬ

1966

## Бу санда:

**ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ**

**А. Шамов.** Бер кичәдә . . . . . . . . . . . 3

**ХИКӘЯЛӘР, ПОВЕСТЬ, ШИГЫРЬЛӘР**

**Г. Әпсәләмов. Поши баласы.** Хикәя . . . . . . . . 15
**Ә. Ерикәй.** Лирик шигырьләр . . . . . . . . . 25
**Ә. Еники. Әйтелмәгән васыять.** Хикәя . . . . . . . 29
**Г. Афзал.** Яңа шигырьләр . . . . . . . . . . 60
**Р. Гатауллин.** Яңа шигырьләр . . . . . . . . . 63
**Г. Гобәй. Коръән серләре.** Повесть . . . . . . . 67
**К. Фәсәхов.** Яңа шигырьләр . . . . . . . . . 102
Редакция сорауларына язучыларның җаваплары . . 16—41

**ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ**

Ф. Әмирхан хатлары . . . . . . . . . . . 103
**Ш. Байчура. Татар яшьләре хәрәкәте һәм Ф. Әмирхан** . . . . . . . . . . . . . . 114
**М. Бәдәйли. Барысы да хәтердә** . . . . . . . . 123

**ОЧЕРКЛАР**

**Р. Беляев. Америкада егерме ике көн** . . . . . . 126

**СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ**

**Д. Гыйм ранова. Юлның дәвамы һәм зур хыяллар** . 132

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## ТӨРЛЕСЕННӘН

Г. Саттаров. Шагыйрьнең исеме кем? . . . . . 135
К. Петров. Чуваш журналистикасы Казанда туган . 140
Д. Тумашева, Г. Якупова. Тюркологлар киңәшмәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141

## САТИРА һӘМ ЮМОР

Ш. Галиев. Сөзгәк үгез маҗаралары. Поэма . . . . 142

## УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

Тагын да яктырак янсын . . . . . . . . . . . . 149
Б. Урманчы. Ле Корбюзье вафат . . . . . . . . . 153
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . . . 156
Зыя Ярмәки. Некролог . . . . . . . . . . . . . 159

*Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый*

---

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Афзал Шамов

# БЕР КИЧӘДӘ

*(Истәлек)*

1923 ел.

Казан дәүләт университетында һәм аның рабфагында укучы татар студентларының культура советы 14 апрельдә күңел ачу кичәсе ясарга һәм бу кичәгә күренекле язучыларны, шагыйрьләрне, кайбер җәмәгать эшлеклеләрен чакырырга булды. Кичәне сый-хөрмәт белән үткәрергә карар бирелде. Хәер, ул елларда күңел ачу кичәләре чәйсез үткәрелми иде дисәм, ялгыш булмас.

Кичә Г. Тукайның үлгәненә ун ел тулу көннәрендә үткәреләчәк булганга, анда, язучылар һәм җаваплы работниклар белән очрашудан тыш, бөек шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында да зуррак, төплерәк бер чыгышны тыңларга, әгәр мөмкин булса, бу турыда фикер алышырга кирәк табылды.

Ул елларда матбугатта Г. Тукай турында ике төп караш яши иде: берәүләр аны вак буржуа шагыйре дип, ә икенче берәүләр халык шагыйре дип атый иде. Беренче караштагы кешеләр дә, икенче караштагы кешеләр дә үз фикерләрен шагыйрь иҗатындагы мисаллар белән раслыйлар иде. Моннан тыш, тагын өченче караш та туып, башын калкытып килә иде: сул киселгән кайбер тәнкыйтьчеләр яисә үзләрен тәнкыйтьче дип атап йөргән, әмма «тәнкыйтьләре» теге я бу язучының үзен һәм аның иҗатын матбугатта сүгүдән, хурлаудан, аңа кара мөһер басудан узмаган шәрә политиканнар, Г. Тукайның үлгәненә ун ел тулу уңае белән, аның иҗатын «тикшергән» булып, урыны туры килүдән файдаланып, «Тукай — безнең шагыйрь түгел, аның социаль революциягә дә, пролетариатка да мөнәсәбәте юк, ул либераль буржуа шагыйре, ул аларга хезмәт итте», дип, төрле урыннарда сафсата сатарга керешкәннәр иде. Әгәр бу караш сул киселгән хәсрәт «тәнкыйтьчеләрнең» үз фикерләре булып кына калса, алар аны урам чатларында, театр фойеларында, тәмәке тарту бүлмәләрендә такылдап йөрмәсәләр, һичбер нигезе булмаган бу зарарлы фикерләре белән укучы яшьләрне агуламасалар, бер хәер иде, түзәргә, игътибар итмәскә мөмкин булыр иде, ләкин әдәби мирасыбызны ярлыландыруга, аның алтын фондыннан иң талантлы әдипләрне, шагыйрьләрне, аларның иҗатларын сызып ташлауга алып барган бу зарарлы караш бер төркем студентлар арасында җирлек таба башлады. Мәсәлән, дәүләт рабфагы студентлары апрель аенда, Коммунистлар клубында, Г. Тукайны искә алуга багышланган зур әдәби кичә үткәрергә йөриләр иде. Аңа әзерлек башланганын ишетеп, әлеге зарарлы фикергә бирелеп өлгергән, Тукай әсәрләрен бервакытта да укымаган, укыган булсалар да, аның әһәмиятен белмәгән, аңламаган кайбер татар студентлары, суллык шаукымына бирелеп:

— Буржуа шагыйрьләрен искә алырга, аларга багышлап кичәләр үткәрергә ирек бирмәбез! — дип тавыш куптара башладылар.

Кыскасы, бөек шагыйрь иҗатына булган мондый начар мөнәсәбәт татар әдәбиятын һәм культурасын яратучы студентларның күңелләрен бик әрнетә, борчый иде.

Студентлар кичәгә, башка язучылар белән бергә, Тукайның замандашы һәм якын дусты булган Фатих Әмирханны да чакырырга булдылар. Ул Г. Тукай иҗаты һәм аның әһәмияте турында доклад ясарга ризалык бирде.

Бина турында артык борчылырга туры килмәде. Тиз табылды. Ул елларда татар студентлары аз һәм бик кадерле булганлыктан, мондый кичәләрне үткәрү өчен аларга шәһәрдәге теләсә кайсы клубны яисә берәр мәктәпне түләүсез бирәләр иде. Кирәк булса, кичәне үткәрергә кайбер учреждениеләрдән акча да алып була иде. Мәгариф халык комиссариаты гына түгел, хәтта уку-укыту эшенә бертөрле дә бәйләнеше булмаган башка учреждениеләр дә ярдәм иткәлиләр иде. Бу юлы без бер каян да акча сорамаска булдык. («Булдык» дип, ялгышмый әйтәм, чөнки мин культсоветның дәүләт рабфагыннан сайланган члены идем.) Кунакларны үз акчабызга чакыруны яхшырак таптык. Культсоветның мондый эшләр өчен билгеләнгән беркадәр акчасы бар иде. Ул кышкы каникул вакытында үткәрелгән «шәрык кичәсе»ндә билетлар сатудан, американский лотереялардан, кичәдәге буфетларны нэпманнарга арендага бирүдән, бары студентлар фантазиясе генә уйлап чыгара алган башка чаралар белән җыелган акча иде. Шуның өстенә кичәгә катнашучы студентлар үзләре дә билгеле күләмдә акча кертергә тиеш иде. Тик кунаклардан гына түләтмәскә булдык.

Шул елларда язылып барган көндәлек дәфтәремдә кичәгә керү билетының бәясе турында түбәндәге сүзләр бар: «Күңел ачу кичәсенә катнашырга теләүче һәр студент билет ала. Билет бәясе биш миллион сум».

Биш миллион сум!

Бүгенге яшьләр, бу сүзләрне укып, бәлки, бик гаҗәпләнерләр: «Әй, ул заманда студентлар нинди бай булганнар икән!» — дип уйларлар. Гаҗәпләнмәгез! Бу — айлык стипендиянең кечкенә бер өлеше генә. Ә без ала торган стипендия, никадәр кысып, саклап тотсаң да, башка килерең булмаса, айныкы айга җитми иде. Ачыграк итеп әйткәндә, көненә бер тапкыр кайнар аш ашап, иртә-кич кара ипи белән шикәрсез чәй эчәргә такы-токы җитсә дә, уку әйберләре һәм башка шуның кебек кирәк-яракларны юнәтер өчен өстәмә акча табарга кирәк иде.

Ул көннәрдә биш миллион сумга нәрсә алырга мөмкин булгандыр, — хәтерләмим.

1923 елда акча курсы искиткеч тизлек белән түбән тәгәри иде. Аның ни дәрәҗәдә тәгәрәвен, сатып алу көчен югалта баруын бүгенге тизлекләрнең берсе белән дә чагыштырырга теләмим. Ничек кенә чагыштырсам да, аны яшь укучыларга аңлатып бирә алмам кебек. Тик шуны гына әйтәм: мин рабфакта алтын акча исәбе белән аена 15 сум стипендия ала идем. Халык кулындагы кәгазь акча белән исәпләгәндә, миллионнар белән санала иде ул. Аны без, сатып алу көче кимеп, әрәм булмасын өчен, саклык кассасына сала идек. Стипендияне кулга алу белән үк, унга-сулга карамыйча, көчебездән килгән хәтле тизлек белән саклык кассасына йөгерә идек. Дөньяда йөгерек аяклар без генә түгел иде, билгеле. Башкалар да шулай йөгерә иде... һәм саклык кассасында һәрвакыт зур чират була иде.

Кайчак җил сыман атылып йөгереп барган арада яисә чиратта торганда, алтын белән йөртелгән бер сумның яңа курсы, ягъни шул заманда кулда йөргән кәгазь акча белән билгеләнгән яңа бәясе турында дәүләт банкысыннан хәбәр килеп куйгалый иде (һәр көнне билгеле бер сәгатьтә хәбәр итәлә иде). Әле дә хәтеремдә: бернәрсә сатып алмаган, хәтта төргәләп тыккан акчаңны кесәңнән кузгатып карамаган булсаң да, әлеге 15 сумлык стипендияң кинәт кими, я 14 сум 50 тиенгә, я 14 сумга, я аннан да кимрәк сумга әверелә иде.

Кичәне үткәрү өчен Зур Мещан урамындагы, ул чакта Гаспринский исеме белән йөртелгән татар мәктәбен алдык (хәзер Нариман урамындагы 76 нчы мәктәп). Башлану сәгатен кичке алтыга билгеләдек. Ул елларда халыкның кичәләргә, спектакльләргә соңга калып килү гадәтен исәпкә алып билгеләү иде бу. «Сәгать алтыга килүен килмәсләр, шулай да билгелик. Бәлки, бераз җыелсалар, сәгать җидедә башлап җибәрербез», — дидек.

Килергә тиешле кешеләр бары сәгать сигез тулганда гына җыелды. Анда да барысы да җыелып бетте дип әйтеп булмый. Кайсылары кичә уртасында гына килеп керделәр.

Күренекле язучылардан шәһәрдәгеләрнең барысы да диярлек чакырылган иде.

Билгеле, башта яшь язучылар килде. Алар төрле уку йортларында укыйлар иде.

Студентлар берәм-берәм күренә башлагач, кепкасын шул еллардагы яшьләрнең гадәте буенча бер якка тартып, салындырып кигән, соргылт кара төстәге демисезон пальтосының якасын күтәреп җибәргән Г. Кутуй белән зур малахай бүрекле, бүреге

төсле үк коңгырт пиджаклы Ф. Әсгать килеп керде. Алар, икесе ике институтта укысалар да, еш кына бергә йөриләр, хәтерем ялгыштырмаса, ул елны алар икесе Академический урамда (хәзер Вишневский урамы), бер фатирда торалар иде, шикелле. Килеп керү белән үк кичәдәге укучылар белән аралашып киттеләр. Г. Кутуйның кешеләр белән бик тиз аралашу, сүз башлап җибәрү, гомуми тема табу һәм кешене ничектер үзенә җәлеп итә белү сәләте бар иде. Әйләнә-тирәдәге кешеләр кемнәр генә булмасын, зур дәрәҗәле кешеләрме алар, әллә гади кешеләрме, барыбер, Кутуй алар белән сөйләшергә теләсә, һич тә икеләнмичә, яннарына бара, исәнләшә, күрешә һәм әллә кайчангы танышлары сыман сөйләшә башлый. Бу гадәте өчен аны утызынчы елларда, кыерсытылып йөртелгән чагында, кайберәүләр җыелышларда төрле сүзләр белән хурладылар да: имеш, «ул дәрәҗәле кешеләр белән аралашырга, аларга үзен күрсәтергә, шулай итеп, нииндидер шикле багаж әзерләргә маташа», дигән булдылар. Болар барысы да ул көннәрдә Кутуй өстенә һичбер нигезсез һәм сәбәпсез ташланган, аның кешелек дәрәҗәсен кимсетүгә, таптауга юнәлдерелгән яла иде. Кутуйның кешеләр белән тиз аралашуында, аларга кушылып китүендә, үз кеше булып әверелүендә саф күңеллелектән, яхшы нияттән башка бернәрсә дә юк иде. Кутуй ачык йөзле, киң күңелле кешеләрнең берсе иде. Соңыннан, сугыш алды елларында, элек тә аның өстенә ташланган ялалар, кемнәрдер тарафыннан уйлап чыгарылган төрле гаепләр алынып ташлангач, ул да барлык язучылар белән тигез хокуклы бер кешегә әверелгәч, аның бу аралашу сәләте безне Язучылар союзындагы кайбер мәҗлесләрдә, зур кунаклар кабул иткәндә, шактый уңайсыз хәлләрдән коткара иде һәм без аңа, телебез белән әйтмәсәк тә, бу сәләте, егетлеге өчен күңелебездән рәхмәтебезне әйтми калмый идек.

Яшь совет әдәбиятына зур өметләр вәгъдә итеп аяк баскан, заманы өчен берничә матур хикәя, нәсерләр иҗат иткән, кызганычка каршы, безнең арабыздан туберкулез авыруы белән бик иртә китеп барган, тулы, түгәрәк битле, ягымлы күзле Ф. Әсгатьнс Кутуй кебек аралашу сәләтле дип санап булмый иде. Кешеләр белән тиз үзләшеп китә алмый иде ул. Әгәр үзләшсә, яхшы, күңелле мәҗлестәш була белә иде. Шуның белән бергә, бу яхшы күңелле егеттә кайбер кешеләрнең, бигрәк тә үзенә ошамаучыларның тискәре якларын оста тотып ала белү һәм моны, аларның үзләренә сиздермичә, ирония белән бик тапкыр әйтеп кую гадәте дә бар иде.

Озакламыйча Шамил Усманов, Һади Такташ күренде. Беренчесе, мәктәп залының шактый салкын булуына карамастан, килеп керү белән шлемын, шинелен салып, каешын, гимнастеркасын рәтләп, матур, төз буе белән яшьләр арасына кереп китте, бер төркемнән икенче төркемгә күчеп йөри башлады. Бу вакытта Ш. Усманов Казандагы Берләштерелгән татар-башкорт хәрби мәктәбе комиссары иде. Аның да кешеләр белән аралашу, алар белән сөйләшергә гомуми тема табу сәләте зур иде. Тик ул бер урында яисә бер төркем кешеләр янында озак басып тора алмый, кайчакларда, башлаган сүзен сөйләп бетермичә яисә үзе белән сөйләшеп басып торучы иптәшенең сүзен тыңлап бетермичә, икенче урынга, башка кешеләр янына күчеп китә торган гадәте бар иде. Бу китү белән ул иптәшләрен, танышларын үпкәләтми, аларга моны бер-ике сүз белән һәм кул хәрәкәте белән оста гына аңлата да китеп бара. Иптәшләре дә аның бу гадәтен беләләр. Кайчакларда син бу китүнең мәгънәсен аңлап та өлгермисең, ул синең янга яңадан әйләнеп кайта, яңадан дусларча, моннан берничә минут элек башланган, бераз өзелеп торган сүзне, бертөрле дә бүленеп тормагандай, оста ялгап алып китә. Кыскасы, терекөмеш сыман хәрәкәтчән кеше иде ул.

Һ. Такташ әле ул елда, замандашларының хәтерендә калганча, шомарып беткән кәкре башлы таягын таянып йөрми, кыш көннәре өстендә дә «Тун трагедиясе»н язарга мәҗбүр иткән бүре тун түгел, ә бик гади, язын, көзен, кышын өстеннән төшми торган демисезон пальто иде. Ул да аны заманча якасын күтәреп кия иде.

Ул чакта күпләр кышын да көзге пальто киеп йөри иде. Көзге пальтоны яратканга түгел, ә кышкы пальто алырга мөмкин булмаганга кияләр иде. Хезмәт хакы, газета-журналлардан бирелә торган гонорар бик кечкенә иде. Мәсәлән, берничә елдан соң, совет акчасының курсы тәмам ныгыгач, червонецлар чыккач, Казандагы бер газета Һ. Такташ шигыренең юлына бары сигезәр тиен генә түли иде. Әдәби гонорар озак еллар күтәрелми торды. Бары утызынчы елларның урталарында гына беркадәр күтәрелде, һәм түләү системасы рәткә салынды. Аңа кадәр иң талантлы татар язучылары да басылган әсәрләре өчен алган акча белән генә тормышларын алып бара алмыйлар.

берәр урында хезмәт итәргә тиешләр иде. 1923 елда исә бу турыда уйларга да, хәтта хыялланырга да мөмкин түгел иде.

Бераздан татар коммунистлар университеты укучысы Габделхак Шаһиәхметов күренде. Бу иптәш — хикәяләре, мәкаләләре белән укучыларга билгеле булган, күтәрелеп барган Г. Толымбайский иде. Кайчакларда ул Г. Толымбай дип тә, Гумир дип тә кул куя иде.

Аның килеп кереше хәзергедәй күз алдымда. Озын буйлы, эре сөякле, кыска кара чәчле. Башында тушкырыла төшкән кара кепка, өстендә хлястигы салынып торган иске соры шинель, аягында үкчәләре шактый ашалган, ремонтта булган хәрби ботинка. (Бераздан ул, «Татарстан» газетасының җаваплы секретаре булгач, бик яхшы киенә башлады. Кыш көннәрендә инде ул каракүл якалы драб пальто, озын каракүл бүрек киеп йөри, аягында да яхшы, яңа ботинка иде.) Бик сул фикерле яшьләрнең берсе иде ул. Матбугатта да, җыелышларда да каты әйтә, берәү белән дә исәпләшеп тормый. Бу кичәдә дә ул, формалы фуражка, ялтыравык төймәле куртка кигән кайбер студентларны күреп (андый киемдә йөрүче студентлар юк түгел иде әле), аларга булган тискәре мөнәсәбәтен, сүзе белән булмаса да, күз карашы, ирониялe елмаюы белән бик ачык сиздерде.

Ул елларда коммунистлар университеты һәм рабфак укучылары иске формалы студентларның килешмәс дошманнары иде. Формадан йөрүчеләр киемнәре белән генә түгел, дөньяга карашлары, психологияләре, тормышлары, көнкүрешләре белән дә иске заманның калдыклары булып тоелалар иде. Бу бик беркатлы, балаларча садә караш иде, билгеле. Кешенең үзенә, кемлегенә, нинди хисләр, нинди идеаллар белән яшәвенә, ничек уйлавына игътибар итүдән элек, аның тышкы күренешенә, кием-салымына карап, шуның нигезендә аның турында хөкем чыгару авыруы бик көчле иде әле ул заманда. Мәсәлән, Илгиз псевдонимы белән шактый төшенке шигырьләр язгалаган, 1921—24 елларда дәүләт рабфагы студенты булган, Казандагы «футуристларның» берсе булып саналган Хуҗа Рәфиков, ул заман теле белән әйткәндә, буржуаз студентларга охшамас өчен, үзенең пролетар студенты икәнен басым ясап күрсәтер өчен, җиңе, якасы, биле сүтелгән кыска сары тунын ямамыйча, хәтта аны тагын да сүтәерта төшеп, билен ремень белән түгел, ә ниндидер бер иске бау белән генә буып йөри иде. Ул да кичәдә иде. Бу коммунист студентның формалы егетләргә, кызларга сизелеп торган нәфрәте булмаса да, ул өстендәге кием-салымы белән аларга үзенең протестын әйтергә тели иде шикелле. Бу иптәш рабфакны тәмамлаганнан соң Казан педагогия техникумының директоры булып эшләде, аннары, Ленинградтагы көнчыгыш телләре институтын бетереп, озак еллар Кытайда совет илчелегендә хезмәт итте.

Күп еллар үткәч, миңа Х. Рәфиков белән берничә мәртәбә очрашырга, студент чактагы беркатлы карашларыбызны искә төшереп, чын күңелдән көләргә һәм «заманы шулай иде шул» дип, күңелебезне тынычлатырга туры килгәне бар.

Халык җыелып бетәрәк, Галимҗан Ибраһимов белән Фатих Сәйфи-Казанлы күренде. Алар белән бергә Абруй Сәйфи дә килеп керде.

Ф. Сәйфи, Г. Ибраһимов белән нәрсә турындадыр сөйләшеп, шактый кызу бәхәсләшеп керде кебек. Бәлки, бәхәсләшмәгәндер дә, нинди дә булса гади, көндәлек мәсьәлә турында гына сөйләшүе булгандыр. Бик ихтимал. Хәзер күп еллар үткәч, барысын да дөрес, ачык итеп хәтергә төшерүе читен. Әмма шунысы бик ачык: бу хәрәкәтчән, ашыгучан әдипнең берәр кеше белән иң гади мәсьәлә турында сөйләшүе, җыелышлардагы һәр чыгышы безгә, яшьләргә, еш очракларда бәхәсләшү кебегрәк тоела иде. Кызу һәм бәхәсчән сөйли иде ул. Сөйләгәндә каударлана, сүзләре өелешеп чыга, бик кызып китсә, хәтта нәрсә әйткәнен дә аңлап бетереп булмый иде дисәм, аның рухына күләгә төшерү булмас дип уйлыйм. Кызып сөйләгән чакларда дикциясе җитәрлек ачык булмый иде аның. Әмма аның бик яхшы бер гадәте бар иде: әйтәсе сүзен ул, боргалап-сыргалап тормыйча, ни дәрәҗәдә ачык һәм каты булуына карамастан, кешенең йөзенә карап, туп-туры әйтә иде. Гәрчә мондый минутларда дикциясе җитәрлек ачык булмаса да, аның тәнкыйтенә эләккән кешеләр аның нәрсә әйткәнен, ничек әйткәнен, хәтта әйтеп бетермәсә дә, нәрсә әйтергә теләвен бик яхшы төшенәләр иде.

Г. Ибраһимов, үзенең дәрәҗәсен белеп, ләкин моны хәрәкәте, сүзе, үзен тотышы белән сиздермичә, аңа басым ясамыйча, бик гади һәм тыныч кына килеп керде, өстен салгач, артка таба кайтарып тараган озын кара чәчен ике кулы белән бераз рәтләде

дә, кешеләргә орынырга, аларны борчырга теләмәгән бер җыйнак хәрәкәт белән алгы рәткә китте, таныш-белешләре белән исәнләшеп, күрешеп, урындыкларның берсенә утырды.

Зал кешеләр тыны белән бераз җылынды. Пальтоларын салмый утырган кешеләр, урыннарыннан торып, чишенделәр, киемнәрен элеп куйдылар.

Язучылардан Фатих Әмирхан гына килеп җитмәгән иде. Күп тә үтмәде, ул да килеп керде... «Килеп керде» түгел, аны студентлар күтәреп керделәр, тар, кысрык зал буенча алып китеп, түргә, аның өчен махсус әзерләнгән урынга утырттылар. 1907 елда ук аның ике аягына да паралич булган, шул көннән бирле ул читләрнең ярдәменнән башка беркая бара алмый иде. Өендә дә махсус эшләнгән коляска белән генә бер урыннан икенче урынга күчеп йөри иде. Урамга исә, аны күтәреп алып чыгалар, коляскасына утыртып, барасы җиренә этеп алып баралар. Шул хәлендә дә ул спектакльләрдә, зуррак әдәби кичәләрдә, әдәбият һәм культура мәсьәләләре каралырга тиеш булган шәһәр күләмендәге мөһим җыелышларда булгалый.

Мин аны җәйге матур, кояшлы көннәрдә, билгеле сәгатьләрдә, хәзерге Ленин бакчасында, китап укып яисә узган-барганнарны тамаша кылып, ял итеп утырганын еш күрә идем. Бу бакчаны ярата иде булса кирәк ул.

Аны кайда гына очратма, бакчадамы, театрдамы яисә берәр кичәдәме, барыбер, аның янында һәрвакыт я таныш-белешләре, я аның иҗатын ихтирам итүчеләр җыелган була. Алар аның янында төркемләшеп басып торалар, сөйләгәнен кызыксынып тыңлыйлар. Бакчада аның янында өлкән агайларны күбрәк очратырга туры килсә, театрларда, кичәләрдә яшьләрне, аеруча кызларны очратасың. Аның янына хатын-кызларның җыелуы бик табигый иде. Чөнки ул Бөек Октябрь революциясенә кадәр атаклы әдип булып кына түгел, ә кыерсытылган, рәнҗетелгән, хокуксыз татар кызларын бөтен әдәби-публицистик көче белән яклаучыларның берсе һәм иң күренеклесе булып та танылган иде. Шуның өстенә, ул теләсә нинди мәсьәлә турында оста, матур һәм тирән эчтәлекле итеп сөйли белә иде.

Ф. Әмирхан үзенең бераз соңга калуы өчен гафу үтенде. Аны алырга барган студентларның берсе соңга калуның сәбәбен әйтте: ат булмый торган икән.

Кичәне медицина факультеты студенты Кашшаф Казаков ачып җибәрде, нинди максат белән җыелганлыкны кыска гына аңлатып бирде. Сабыр холыклы, кешеләргә игътибарлы, мохтаҗлыкка яисә берәр бәлагә дучар булган иптәшләренә чын күңелдән ярдәм итәргә әзер торучы, авыру чырайлы, ләкин матур кыяфәтле бу коммунист студент ул елларда иң актив җәмәгать эшлеклеләренең берсе иде. Культсоветның председателе дә ул иде. Соңыннан ул, медицина факультетын бетергәч, Казандагы I нче шәһәр больницасының баш врачы булып хезмәт итте, гомеренең иң соңгы көннәренә чаклы җәмәгать эшен ташламады.

Г. Тукай турындагы кереш сүз белән кичәне башлап җибәрү өчен Фатих Әмирханга сүз бирелде. Студентлар аны, урындыгы белән күтәреп алып, халыкка каршы борып утырттылар. Ул үзенең ихтыярына буйсынмаган, студентлар күтәреп алгач, ничектер бераз селкенеп, өстерәлгән сыман тәэсир калдырган аякларын, ике кулы белән тезләреннән тотып, төзәтеп куйды да, зур, акыллы күзләре белән залны, анда утыручы кешеләрне, егетләрне, кызларны, үзенең замандашларын сөзеп карап чыкты. Аның исемен ишетү белән кул чабып, бераз шаулап, гөрләп алган зал тынып калды, урын җитмәгәнлектән, ишек төбендәрәк басып торган, алдагы бушрак урынга күчәргә теләкләре булган студентлар да баскан җирләрендә тындылар, урыннарыннан кузгалмадылар.

Әдип гомуми тынлык урнашудан канәгать калды булса кирәк. Сүз башлар алдыннан, гадәте буенча, ниндидер бер билгесез ноктага күзләрен текәп, бер мизгел уйланып торды, тик шуннан соң гына көр һәм тыныч тавыш белән ашыкмыйча сөйли башлады.

Хәзер, бик күп еллар үткәннән соң, аның бөек шагыйрь турында ничек һәм нинди сүзләр белән башлап китүен, ничек дәвам итүен стенографик рәвештә төгәл, тулы итеп хәтергә китерү, бигрәк тә моны укучыларга сөйләп бирү мөмкин түгел. Әмма аның нәрсә сөйләве, сөйләгән сүзләренең мәгънәсе, эчтәлеге, барыннан да бигрәк, шул эчтәлек нәтиҗәсендә туган хисләрне, көндәлек дәфтәремдәге язмалардан чыгып, билгеле дәрәҗәдә ачып итеп сөйләп бирергә мөмкин.

Беренчедән, мине әдипнең салмак кына агылып чыккан тавышы, бу тавышның тыңлаучыларга тәэсире, ишетү хисләребезне сыйпагандай тыныч яңгыравы, сөйләү манерасы, сүзләрне оста сайлавы, бер әйтелгән фикерне икенче кабатламавы, логикасының үскәннән-үсә баруы җәлеп итсә, икенчедән, аның үзен тотышы, тынычлыгы, кулларын кирәксезгә хәрәкәтләндермәве, хәрәкәтләндерә икән, моны инде әйтә торган сүзенең эчтәлеге, аһәңе белән яраштыруы барлык игътибарымны үзенә тартты.

Зал тын. Шылт иткән тавыш юк... Әдип кай секундларда, сүзеннән туктап, уйланып, тынып тора, яңа сүзләр, яңа гыйбарәләр, яңа мәгънәләр сайлый һәм, гадәте буенча, шактый калын, әмма җәядәй матур булып сузылып килгән кызгылт иреннәрен суыргалап, чылатып ала, аннары яңадан сөйләргә керешә, яңадан тыңлаучыларны үз ихтыярына буйсындыра, аларны күңелләре белән Тукай яшәгән, ул йөргән җирләргә алып китә, аның даирәсенә алып керә, аның тормышы, хисләре, хыяллары, шатлыклары, кайгылары белән таныштыра... Һәм син сизми дә каласың: зал да, залда утырган кешеләр дә, түшәмнән салынып, тоныя кына янып торган лампалар да, тыштагы салкын җилле төн дә, барысы да, барысы да каядыр югала, синең күз алдыңда бары Тукай гына, халык рухын, аның шатлыгын, кайгысын, матур хыялларын җырлаган, халыкның бөек талантлы баласы булган һәм аның белән мәңге бергә яшәячәк бөек шагыйрь генә кала...

«Зал тын. Шылт иткән тавыш юк...» дигән идем. Чыннан да, шагыйрьнең тормышы, шатлыклары, кайгылары турында сөйләгәндә шулай булды, әмма Тукай халык рухын җырлаучы, халык баласы, халык шагыйре дигән фикерләр әйтелә башлагач, залдагы яшьләрнең моңа риза булып, бирелеп тыңлап утырулары сизелгәч, шагыйрьнең замандашларыннан кайберләре, пышылдашып, тынычсызланып алдылар. Ф. Сәйфи исә:

— Фәтхи Бурнаш белән бер үк җырны җырлыйсың, — дип, шактый каты кычкырып, реплика ташлады.

Докладчы җавапны көттермәде. Ф. Сәйфигә тыныч кына карап алып:

— Әгәр Фәтхи минем караштa икән, бу аңа зур мактау, — диде һәм, тынычлыгын югалтмыйча, сөйләвендә дәвам итте.

Чыннан да, Ф. Бурнаш, Ф. Әмирхан кебек үк, Тукайны халык шагыйре дип атый иде.

Залдагы кешеләр бераз шаулашып, гөрләшеп алдылар. Бу шаулашу реплика ташлаучының фикере белән килешмәүчеләрнең залда шактый күп икәнен күрсәтеп тора иде.

Ф. Сәйфинең, күңелендәге фикерен боргалап-сыргалап тормыйча, туп-туры әйтә торган гадәте барлыгын искә алып үткән идем. Аның бу яхшы гадәте белән бергә мәҗлес тәртибен, аның тынычлыгын тиешенчә саклый торган гадәте дә юк түгел иде. Һәм бу гадәте белән ул кайчакларда шактый уңайсызлыклар тудыра иде: я репликалар ташлап утыра, я үзенең фикерен башкаларга ишеттерерлек итеп, борылып, күршесенә сөйләргә керешә, докладчының сүзен тыңларга комачаулый; кискен сыйнфый мәсьәләләр тикшерелгән чакта, берәрсенең чыгышы белән килешмәсә, үзенең килешмәгәнлеген белдереп, аңа яны белән борылып утыра. Бу юлы борылып утырмаса да, шулай да репликалары белән тынычлыкны шактый бозды.

Ф. Әмирхан сөйләп бетергәннән соң Ф. Сәйфи сүз алды. «Сүз алды», — дип әйтсәм генә ул замандагы кызу бәхәсләрне кайбер темпераментлы ораторларның ничек башлап җибәрүләрен аңлатып бирә алырмынмы икән? Ф. Сәйфи бик темпераментлы кешеләрдән иде. Ул урыныннан сикереп торды, урындыгын ике кулы белән тоткан килеш йөзе белән халыкка таба борылды да, гадәтенчә, кызып, кычкырып сөйләргә кереште:

— Фатих Әмирханнар һәм аның иптәшләре миңа никадәр ачулансалар да, Габдулла Тукайны коррективсыз, шартсыз — халык шагыйре дип кабул итә алмыйм, — диде ул. — Тукайның үзенә карап түгел, язган шигырьләренә карап, ул хезмәт иясенең генә хәсрәтен, аһ-фәганен җырлаучы шагыйрь дип кабул итү — буташтыру. Тукай әсәрләренең сыйнфый төсен югалту булыр иде. Тукай шигырьләрендәге мотив — сыйнфый көрәш мотивы түгел, бәлки вак буржуаз милләтчелегенең мотивы. Ул — вак буржуа шагыйре. Ул аллага, аның яратучы булуына ышана. Иң дөрес дин коръәндә күрсәтелгән ислам дине, ди. Ул шигырьләрендә аңа гына хас булган берәр фәлсәфә мәктәбен дә калдырмады, халыкларның миләрен шөгыльләндерерлек зур идеалларны да

күтәреп чыкмады. Шуның белән бергә ул татар халкының туксан тугыз процентын тәшкил иткән крестьян тормышыннан да күзгә күренерлек бернәрсә дә калдырмады... — дип, Тукай иҗаты турында сөйләвендә дәвам итте.

Зал тынычсызлана башлады, кайберәүләр, урыннарыннан тордылар, мәҗлеснең түренә, бәхәсләшүчеләр янына якынлаштылар, кайберәүләр исә, үз фикерләрен исбат итәргә теләп булса кирәк, кулларын кызу-кызу селкештергәләп, күршеләре белән сөйләшергә керештеләр. Түрдә генә түгел, залда да ике фикернең бәхәсе, тартышы бара иде. Асылда бу бәхәс Ф. Әмирхан белән Ф. Сәйфи бәхәсе генә түгел, ә Г. Тукай иҗатына, аның татар әдәбияты тарихында, киңрәк итеп алганда, татар халкы тарихында тоткан урыны, әһәмияте турындагы ике капма-каршы позициянең бәхәсе иде, билгеле.

Зал беркадәр шаулап, гөрләп торды, тынычсызланды. Ләкин бәхәснең сәбәпчесе һәм башлап җибәрүчесе булган Ф. Әмирхан тыныч иде, залдагы гөрнең бер өлеше, күбрәк өлеше, аның ягында, ягъни Тукай ягында икәнен сизә һәм шуңа шатлана иде. Бәхәстә ул бик көчле, тирән логикалы, үткен телле иде, теләсә, каршы якны образлы мисаллар, ышандыргыч дәлилләр белән кысрыклап, үз урынына утырта белә иде. Хәер, Ф. Сәйфи дә бәхәстә сыртны җиргә салучылардан түгел иде. Тик аның сабырлыгы, такты, логикасының көче, тирәнлеге җитешеп бетми иде. Барыннан да бигрәк, кызу характерлы иде ул. Ләкин Ф. Әмирхан аңа бик тыныч җавап бирде, ике арадан кара мәче йөгереп үтәрлек артык бер сүз дә әйтмәде. Г. Тукай яшьләр күңелендә халык шагыйре булып калды. Ф. Әмирхан өчен бары шул кирәк иде.

Ф. Сәйфинең тагын бер матур гадәте бар иде: ул каты бәхәсләшсә дә, кызып, каршы якның исеме белән бәйләп шактый кискен сүзләр әйтсә дә, җыелыш беткәннән соң, аның янына барып, көлә-көлә, дустанә дип әйтерлек дәрәҗәдә сөйләшә белә иде. Ә кайчакларда үзенең каршы ягы белән тәнәфес вакытларында да бәхәсләшә иде.

Без Г. Ибраһимовның да Тукай турында үз фикерен әйтүен көткән идек. Ләкин ул бәхәснең башыннан алып ахырына кадәр тыныч утырды, сүзе белән дә, хәрәкәте белән дә бер якка да кушылмады. Аның бәхәскә кушылмавы, үз фикерен әйтмәве, билгеле, укучыларны бик кызыксындырды. Алар, аны бәхәскә алып кереп китәргә теләп, берничә омтылыш ясадылар. Чөнки аның «Татар шагыйрьләре» исемле китабы, Г. Тукай иҗатына булган тискәре карашы күбебезнең хәтерендә иде әле. Тукай шигырьләрен бик яратучы, аны күңеленнән белүче студент Фәхри Басыйров, безнең арада яше белән шактый өлкәннәрнең берсе, соңыннан балалар авыруы буенча күренекле врач, урыныннан торып, Г. Ибраһимовның Тукай турында үз фикерен әйтүен бер-ике тапкыр сорады, әдип һәр юлы, үзенә хас тактны саклап, моның өчен миңа Тукай иҗатын яңадан карап, тикшереп, өйрәнеп чыгарга кирәк, хәзергә әле аңа вакытым һәм мөмкинлегем юк, дигән кебек сүзләр белән чикләнде. Билгеле, әдипнең бу сүзе укучыларны канәгатьләндермәде. Алар аның фикерен бүген, Бөек Октябрь революциясеннән соң, ишетергә теләгәннәр иде.

Югарыда мин Ф. Әмирханның Г. Тукай иҗаты турындагы фикерләрен бары аның чыгышыннан туган тәэсоратым белән генә биреп тә, аңа каршы чыккан Ф. Сәйфинең сүзләрен исә, ул менә нәкъ шулай әйтте, болай әйтте дип, төгәл китерүем, укучыларны гаҗәпләндерүе, һәм бу сүзләрнең дөреслеге турында бераз шик тудыруы мөмкин. Ләкин мин шуны ачык итеп әйтәм: бу сүзләр, бу фикерләр башыннан алып ахырынача Ф. Сәйфинең үзенеке. Монда минем тарафтан өстәлгән бер генә сүз дә, бер генә фикер дә юк. Шул заманда Ф. Сәйфи Тукай иҗаты турында ничек сөйләгән булса, дөресрәге, ничек язган булса, шул хәлендә алынды.

Тагын икенче мәсьәлә. Әдәбиятыбызга шактый өлеш керткән, егерменче-утызынчы елларда әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге белән киң танылган әдип һәм тарихчы Ф. Сәйфи, әгәр бүген исән булса, Г. Тукай иҗатына булган карашын үзгәртер идеме? Үзгәртер иде, билгеле. Ул да, нәкъ Ф. Әмирхан, Ф. Бурнаш һәм башкалар кебек, Г. Тукайны бөек халык шагыйре дип атар иде. Чөнки ул чактагы аның карашы — шул заманда тамыр җәеп килгән, хөкем сөргән вульгар социологизм методының гарип бер күренеше иде.

Бу истәлегем белән мин күңел ачу кичәсенең соңга калган отчетын язарга җыенмыйм. Әгәр җыенсам, шуны максат итеп алсам, кичәдәге художество өлешенә туктап,

Такташның, Кутуйның һәм башкаларның яңа шигырьләрен укуын, Абруй Сәйфинең һәм шул заманда күтәрелеп килгән артисткаларыбызның ничек җырлауларын тәфсыйл-лап язып үтәр идем. Аңа керешмим. Кунакларыбызны чәй бүлмәсенә алып керү белән генә чикләнәм.

Зур бер бүлмәдә өлгер студенткаларыбызның һәм шул заманда мондый кичәләрдә ярдәм итәргә, булышырга әзер булып, җиңнәрен сызганып торучы, сәнгатьне, әдәбиятны яратучы сөйкемле ханымнарның кулы белән әзерләнгән сый өстәле заманы өчен йөзне кызартырлык түгел иде. Мәҗлестә студентлар белән бергә, Г. Ибраһимов та, Ф. Әмирхан да, Ф. Сәйфи дә, Ш. Усманов та, һ. Такташ та бик рәхәтләнеп, бу утырудан эчке бер ләззәт табып утырдылар, табынны, аны әзерләүчеләрне чын күңелләреннән мактадылар. Менә монда инде мин өстәлдәге сыйларның шул заман өчен хас булган бер сыйфатына тукталмыйча булдыра алмыйм. Табында ашау әйберләре күп булса да, спиртлы эчемлек юк иде. Аның юклыгын сизмиләр, кирәклеген тоймыйлар иде. Мәҗлес болай да күңелле, матур иде. Ул заманда студентлар гына түгел, партия-совет хезмәткәрләре дә эчмиләр иде. Зуррак бәйрәмнәрдә эчсәләр дә, белеп, тоткан урыннарын, халык алдында, намуслары алдында җаваплылыкларын аңлап, кешелек горурлыгын саклап, аны бер минутка да исләреннән чыгармыйча, әдәпле эчәләр һәм син, аларның төсләренә, кыяфәтләренә карап, эчкәнлекләрен сизми дә идең. Бар иде шундый заманнар!

Чәйдән соңгы уеннарны, җырларны, шуның белән күңел ачуларны да язып тормыйм. Пианино янына барып утырган Солтан Габәшинең музыкаль бармаклары астыннан төрле милли көйләр агылып чыкса да, укучылар шул көйләргә ияреп җырласалар, уйнасалар, биесәләр дә, парлашып танцевать итүчеләр булмады. Хәер, С. Габәши дә танец көйләрен уйнарга кирәк тапмады. Әгәр уйнаса, егетләр, кызлар парлашып танцевать итәргә керешсәләр, кем белә, бәлки, мәҗлеснең бөтен яме киткән, зур скандал чыккан булыр иде. Рабфак студентлары пианиноны урамга чыгарып ыргытмасалар да, барып, аның капкачын ябарлар, уйнаучыга да, танцевать итүчеләргә дә каты ачуланып: «Әфәнделәр, ташлагыз әле буржуазиянең черек гадәтләрен!» — дип кычкырырлар, кычкырмыйча калмаслар иде. Чөнки ул елларда барлык танцылар буржуазиянең черек гадәтләре булып санала һәм бу гадәтләр совет яшьләрен мораль бозылуга алып бара дип уйлый идек. Танцыларның гына түгел, хәтта галстукның, эшләпәнең дә дошманы идек без. Аларны да буржуазия атрибутлары итеп саный идек. Менә шундый сәер заманнар да бар иде.

Төнге уникене тулырга унбиш минут калгач, сүрән генә янып торган электр лампалары, исегездә тотыгыз, озакламыйча сүнәбез дигәндәй, өч тапкыр күзләрен кысып алдылар һәм, чыннан да, сүзләрендә тордылар. Бераздан лампалар ялгыз елтырап яткан утлы күмер кисәге төсле генә җемелди башладылар, аннары бөтенләй сүнделәр. Өлгер кызлар керосин лампаларын әзерләп куйганнар икән. Аларны кабызып җибәрделәр. Караңгылыкка чумган зал яңадан бераз яктырып китте.

Укучылар да, кунаклар да акрынлап тарала башлады. Өлкән язучылардан Ф. Әмирхан гына калды. Ул, яшьләрнең уйнауларын, шаяруларын кызыксынып күзәтеп, мәҗлеснең ахырына чаклы утырды, аннары төнне безнең белән бергә салкын залда таңга кадәр уздырды.

Кешеләр кимегәч, мәктәп эче кинәт моңаеп, күңелсезләнеп, салкынаеп китте. Ф. Әмирхан инде күптән пальтосын аркасына салган иде. Шәфкатьле кызларның берсе үзенең пальтосы белән аның тезләрен томалады.

Бу бинада без берничә кеше таңга кадәр Ф. Әмирхан янында калдык: һ. Такташ, Г. Кутуй, Ф. Әсгать, Г. Толымбайский, журналист Габдулла Әхмәдиев һәм тагын берничә кеше. Егетләр, кызлар. Ш. Усманов та калган иде. Тик ул тынгысыз җан, үзенә урын таба алмыйча, бүлмә буйлап арлы-бирле сызгыргалап йөрде дә, бу мәҗлескә ничек җиңел килеп кергән булса, шундый ук җиңеллек белән, шинелен киеп, башына шлемын элеп, чыгып китте.

Мәктәп сторожының киптерергә кертеп куйган утыны бар икән. Аны мичкә тутырдык, кабызып җибәрдек. Берничә минуттан ул күңелле генә чатнап яна башлады.

Ф. Әмирханны, урындыгы белән күтәреп, мич янына, ут каршына китереп утырттык. Үзебез дә аның әйләнәсенә җыелдык.

Янybызга унлы лампаны алып килеп куйган идек. Әдип аны, бераз басып, читкә алып куярга киңәш итте:

— Мич каршында лампасыз гына утыру ничектер күңеллерәк, серлерәк, — диде ул һәм кулларын ут җылысына сузды. Аның кичләрен янган мич каршында ялгыз уйланып утырырга ятратканлыгы күзләреннән, йөзенә чыккан сизелер-сизелмәс елмаюыннан күренеп тора иде.

Без инде бу кичәдә әдипкә күнегеп, ияләшеп өлгергән идек (барыбыз да түгел, билгеле). Үзара сөйләшеп утыру табигый һәм җиңел башланып китте. Моңа, бердән, Ф. Әмирханның укучы яшьләрне яратуы, алар белән аралашырга теләве сәбәп булса, икенчедән, Г. Кутуй белән Ф. Әсгатьнең сүзчәнлеге дә ярдәм итте.

Ф. Әмирханның моңача матбугатка чыкмаган көндәлек дәфтәре бар. Ул СССР Фәннәр академиясенең Казан Тел, әдәбият һәм тарих институты архивында саклана. Шул дәфтәрдә әдип үзенең укучы яшьләрне яратуы турында түбәндәге сүзләрне яза (сүз бер кичәдә яшьләр белән очрашуы турында бара): мин «югары мәктәп шәкертләре... өстенә хосусый бер дикъкать белән карыйм. Алар да миңа карыйлар, йөздән туксаны сәламле бер караш белән карый. Таныш икәнлекләреннән хәбәрем булмаган бик күпләр күз вә баш белән сәламләп уза. Шулардан берничә таифә[1] кешеләр аркылы минем белән танышу тәшәббесенә[2] керәләр... Шул кыйсым яшьләр белән сөйләшү, үз-үземнән яшерергә хаҗәт юк, миңа һәрвакыт зур оптимизм бирә», ди.

Без аңа бу төндә, шаулы күңел ачу кичәсеннән соң шыр һәм күңелсез булып калган салкын бүлмәдә, чатнап янып торган мич каршында сөйләшеп утырганда, омтимистик тәэсир иттекме икән, юкмы икән, — анысын белмим, әмма ул безнең белән бу кичтә бик рәхәтләнеп, яратып сөйләшеп утырды кебек. Һәрхәлдә, бездә шундый тәэсир калды. Вакыт соң булуга карамастан, кайтып китәргә теләге барлыгын әйтмәде һәм сиздермәде.

Барыннан да бигрәк, безне аның нинди яңа әсәрләр өстендә эшләве, «Хәят»ның дәвамы, бүгенге әдәбиятка һәм яшьләргә карашы кызыксындырды. Шул турыда без аңа сораулар бирдек.

Әдипнең иҗат планы шактый кызыклы икән. Мин аны үз сүзләрем белән тәфсыйлләп язып торуны кирәксез санап, аның югарыда телгә алынган көндәлек дәфтәрендәге, бу очрашудан бер ел ярым чамасы элек үз кулы белән язган юлларны китерү белән генә чикләнәм:

«Былчырак көз көне, өстән юеш кар явып тора, — дип яза ул. — Яратмыйм мин җылак көзне. Мин, авырудан яңа бераз терелеп, язуга утырырлык булып киләм. Язасы килә, башта төрле-төрле мәүзуглар[3] йөри. Хәзер минем шәхси тормышымда шушы ашарга юнәтү, өйгә утын юнәтү белән тулы,.. соң дәрәҗәдә вак мещанлык (гаҗәп түгелме?) интересына гына мәхсур итеп[4] калдырылган көндәлек тормышымны онытып, баштан чыгарып, язасы иде. Шул язуда, творчествода бер ял итү, бер хәл җыю табасы иде. Ә ниндидер шәраит җитми, рәхәтләнеп язарга тотынып китә алмыйм: менә әле яртылай язылган хикәям («Ситдыйк мәхдүм») соңгы авыруыма кадәр язылып калган җирендә терәлеп тора. Вәхаль минем аннан башка да быел кыш язарга тиешле мәүзугларым башта чуалып йөриләр: «Үлем» — мин моны соңгы авыруым вакытында үзем бик яхшы хис итеп уздырдым бит. Күптән инде «Карт кыз» мәүзугысы башта өстерәлеп йөри, аның ялгызлык хисе белән җәфа чигүе, аның бу социальный революцияне дошман тотуы, үз-үзен зәминсез[5] хис итүе. Быел кыш азагында, шул ике мәүзугыны язып, хикәя рәвешендә тәмам итәргә тиеш бит мин...»

— Язылган һәм язылмаган, әмма бөтен сюжеты, образлары, детальләре башымда эшләнеп беткән, тик кәгазь өстенә төшерәсе генә калган сигез хикәям бар, — диде ул безгә. — Ләкин мин бу хикәяләремне тиз бастыра алырмын дип өметләнә алмыйм. Сәбәбе: кәгазь кытлыгы, нәшриятыбызның бик акрын аякка басып килүе. Хәзер татар

[1] Берничә таифә — берничә төркеме.
[2] Тәшәббесенә — чарасына.
[3] Мәүзуглар — темалар.
[4] Мәхсур итеп — чикләнеп.
[5] Зәминсез — җирлексез.

язучысына бердәнбер чара: рус матбугатына чыгу. Хикәяләремне рус теленә тәрҗемә иттерәсем бик килә...

Әдип «Хәят» повестеның дәвамын шактый эшләгән икән, тик тәмамлый алганы гына юк. Тәмамлап, укучыларга бирергә теләге зур икәнен әйтте.

«Хәят»ның беренче китабы 1911 елны «Юл» нәшриятында басылган иде. Аннан бирле күп еллар узды, ләкин китапның дәвамы күренмәде. Укучылар аны бик көтәләр, авторның язу-язмавы белән кызыксыналар иде. Кичәдә дә аңа бу турыда бернича сорау бирделәр. Кызганычка каршы, автор, бу әсәрен тәмамлап, матбугатка чыгара алмады. Шулай итеп, «Хәят» беренче китап белән генә калды.

Мич яна. Ф. Әсгать аңа ара-тирә яңа пуләннәр өсти. Пуләннәр, янарга теләмәгәндәй, күз яшьләрен чыгарып, пыскып, бераз чыжлап торалар да, нәрсә соң киреләнеп маташабыз, барыбер янарга, күмергә, көлгә әверелергә бит дигән сыман, кинәт дөрләп кабынып китәләр, җылы нурларын Ф. Әмирханның хәрәкәтсез аякларына, алдына, күкрәгенә төшерәләр, ә кай мизгелләрдә, әдип мичкә таба иелгән арада, аның йөзен, киң маңгаен, кыска итеп алдырган кара чәчен яктыртып алалар. Әдип ялкынга һәм мич тирәсендә, аның янында, иңнәренә шинельләрен, туза төшкән пальтоларын салып утырган, күзләрен аңа текәгән яшьләргә караштыргалап ала-ала, ашыкмый гына сөйли. Кай секундларда туктап, күзләрен ниндидер билгесез ноктага текәгән хәлдә уйланып тора, безне узган көннәргә, хәзер инде тарих булып саналган елларга, шул заманның яшьләре арасына алып керә, аларның тормышлары, күңел кичерешләре, хыяллары белән таныштыра һәм яңадан безнең арага, салкын бүлмәгә, әле генә булып узган кичәгә кайта:

— Мин кичәнең башыннан бирле сезне күзәтеп карап тордым, — ди ул. — Сез миңа, яшегезгә караганда, бер ун яшькә картрак тоелдыгыз. Күңелләрегез карт сезнең. Без яшь чакта, сезгә караганда, шатрак, күңеллерәк, дәртлерәк уйный идек. Бәлки, безнең җилкәләребездә дөнья мәшәкате ул кадәр булмагандыр... Шулай да сез бәхетле яшьләр. Авыр заманның бәхетле яшьләре сез... Заманның кадерен белегез. Сезгә бөтен мәктәп ишекләре ачык. Ә безнең заманда бу бәхет юк иде. Бөтенләй юк иде. Белегез, бу бары бүгенге шартларда, совет власте хакимлек иткәндә генә мөмкин. Башка власть моны һич тә бирмәгән һәм бирә дә алмаган булыр иде. — Ул, сөйләвеннән туктап, безгә карап, тагын уйланып тора, тагын иреннәрен суыргалап, чылатып ала һәм сорый: — Кәрим Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» исемле драмасын күргәнегез бармы сезнең? Күргән булсагыз, андагы геройларны хәтерли торгансыз? Кәрим ул заманның шәкертләр арасыннан чыккан алдынгы яшь кешесен бик дөрес биргән. Аттестат зрелостига әзерләнәбез дип, шулай азапланалар, ач яшиләр, бөтен мохтаҗлыкларны кичерәләр, кан косалар иде безнең заман яшьләре, шулай да максатларына ирешә алмыйлар, югары мәктәпләргә керә алмыйлар иде. Кабул итмиләр иде аларны. Шуның өстенә, татарның карагруһлары бу яшьләрне бөтен җаннары-тәннәре белән дошман күрәләр, хурлыйлар, мыскыллыйлар иде.

Ф. Әмирхан үзе дә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен ташлап чыкканнан соң, бик тырышып русча укырга керешә. Аны да бу эше өчен карагруһлар дошман күрәләр, сүгәләр, хурлыйлар. Менә шул турыда ул безгә үз башыннан узган бер кызык вакыйганы сөйләде.

Аны да мин үз сүзләрем белән язып тормыйм. Ф. Әмирхан аны үзе 1926 елда, исенә төшереп, көндәлек дәфтәренә язып куйган икән. Шуннан гына күчерәм.

«Минем бик җәдитләнеп, бик динсезләнеп, халыкка бик «тәрәкъкый кертеп» йөргән чакларым, — дип яза бу вакыйга турында ул. — Миңа русча укыр өчен Болак күпере аркылы шәһәрнең рус бүлегенә йөрергә туры килә. Көннәрнең берсендә, Болак күпереннән үтеп барганда, минем тарафтан һичбер сәбәп булмаган хәлдә, шул күпер өстендә дәвами тора торган фахишәләрнең берсе мине сүгәргә тотына: иң кабахәт, иң оятсыз сүзләр белән сүгә; артымнан йөри-йөри сүгә; минем һичбер җавап кайтармавыма карамастан, сүгә. Бу эш бер көн дәвам итә, ике көн дәвам итә, өч көн дәвам итә, дүрт көн дәвам итә... Бу эштән гаять туйгач, мин йөрешемне икенче күпер аркылы ясый башлыйм. Ләкин өч-дүрт көннән соң теге фахишә, ул күпергә күчеп, үзенең сүгенүен дәвам иттерә. Фахишә белән нишлисең: миңа көндәлек бу сүгенүне башымны иеп тыңлап китүдән башка бер чара калмый.

Казанның иң фахиш, иң хулиган байларыннан берсе шул көннәрдә Печән базарында бер хәбәр тарата:

— Чукындырдым бит теге Зариф мулланың чукынчыгын; ул кяфергә хәзер Болак күпереннән үтеп йөрергә дә калмады инде,— ди».

Әдипнең көндәлек дәфтәрендәге бу юлларны укыганнан соң, 1923 елдагы кичә, мич яны, хәзер инде берсе дә исән булмаган андагы иптәшләр, Ф. Әмирханның үзе, аның бу вакыйганы ниндидер бер әчке әрну һәм нәфрәт белән сөйләве, безнең гаҗәпләнеп тыңлавыбыз һәм шул заманда яшәвебезгә чын күңелдән шатлануыбыз, барысы да, барысы да күз алдыма җанланып, бүгенгедәй килеп басты. Хәтта, алай гына да түгел, әдипнең ашыкмый гына сөйләгән тыныч тавышын да ишетәм мин, аның сүзләрен күңелемнән кабатлыйм:

— Сез халык балалары, халык арасыннан чыккан яңа кешеләр,— дигән иде ул безгә.— Халыктан беркайчан да аерылмагыз, аңа хезмәт итегез. Аның туксан процентын тәшкил иткән хезмәт ияләренең мәдәни, икътисади һәм сәяси күтәрелеше — минә сезнең барыгыз өчен дә уртак кыйбла!

Сүз татар әдәбиятының бүгенге торышына, яңа бөреләнеп килүче футуризм, символизм һәм имажинизмнарга, шул «измнар»га ияреп язылган, ул вакытлардагы газета-журнал битләрен шактый чуарлаган шигырьләргә күчте. Бу темага күчкәнче мәҗлесебез шома, матур, бәхәссез барган иде, әдипнең үз сүзләре белән әйткәндә, кыйблабыз бер юнәлештә иде. Бу темага күчкәч, Ф. Әмирхан модалы «измнар»га ияреп язылган мәгънәсез, эчтәлексез шигырьләрне шигырь дип санамавын әйткәч, формализмны заманның вакытлы бер чире дип атагач, әдәбиятта бары реализм методы гына яшәргә тиеш дип сөйли башлагач, ничектер мәҗлесебезнең рухы үзгәрде, юлыбыз сикәлтәләнә төште, чәкүшкәләр дә бәрелешеп алды. Ф. Әмирхан мондый сөйләшеп утырулар вакытында тактны, әдәпне саклаучылардан, мәҗлестәшләренең рухына, аларның үз-үзләрен ярату хисләренә тукынмаучылардан иде. Шулай да нәрсәдер булды, әдипнең бу сүзләре кай ягы беләндер һ. Такташка ошамады. Ул урыныннан торды, төн уртасы булуга карамастан, китәргә җыенды һәм, кул бирмичә генә саубуллашып, чыгып китте. (1931 нче елны, һ. Такташ вафат булганнан соң, «Яңалиф» журналының 12 нче санында аның Ф. Әмирхан турында язган «Ул безнең өчен үле иде инде» дигән кыска гына истәлеге басылып чыкты. Шагыйрь бу истәлеген 1926 елда, Ф. Әмирханның үлүе уңае белән язган икән, ләкин ул вакытында басылмаган, архивында сакланган. Истәлекнең эчтәлегенә караганда, һ. Такташның студентлар кичәсеннән ни өчен чыгып китүе ачык аңлашыла: әдипнең «совет язучыларына булган ачы көлү карашы, шуңа юнәлтелгән сүзләре әле дә хәтеремдә», — ди ул. Әгәр шагыйрь, мәҗлеснең ахырына чаклы утырып, Ф. Әмирханның соңгы сүзләрен ишеткән булса, бәлки, бу истәлеген икенче рухтарак язган булыр иде.) Г. Толымбайский да, урыныннан торып, бүлмә буйлап әйләнеп килде, ләкин үз урынына кайтмады, ә бер читкә, анда да мәҗлескә яны белән утырды (бу елларда ул да, форма белән бик мавыгып, шигырьләр язгалый башлаган иде). Тик Г. Кутуй, Ф. Әсгать, Г. Әхмәдиев һәм башкалар гына урыннарында калдылар, әдипнең сөйләвен кызыксынып тыңлауларында дәвам иттеләр.

Ф. Әмирхан Такташның һәм Толымбайскийның урыннарыннан торуын, берсенең чыгып китүен, бу чыгып китүнең серен төшенде, билгеле. Ләкин ул аңа әһәмият бирмәде, сөйләвендә, безнең белән сөйләшүендә, тормышыбызны, укуларыбызны, планнарыбызны сорашуында дәвам итте, хәтта кайберләребезнең, бигрәк тә иңнәренә шинель салып утыручыларның биографияләре белән дә кызыксынды. Ул үзе сөйләү белән генә чикләнми, башкаларны да сөйләтә, сөйләгәннәрен оста һәм кызыксынып тыңлый белә иде.

Мичебез инде күмерләнеп, сүнеп бара иде. Төн буе каралып, шыксызланып торган тәрәзәләр дә таң нуры белән агара башлады. Без әле һаман утырабыз...

Ф. Әмирхан сәнгатьтә реализмны яклаучы, сәнгать һәм әдәбият бары реалистик нигездә генә үсәргә, дәвам итәргә тиеш дип санаучы язучылардан иде. Бу кичәдә дә ул реализмны яклап сөйләде.

— Дөньяда зур әдәбиятлар, зур язучылар бар, — диде ул. — Рус әдәбиятын мин шундый зур әдәбиятларның берсе итеп саныйм. Аның сүз художниклары, даһилары реалистик нигездә дөнья күләмендәге әдәби җәүһәрләрнең иң гүзәл үрнәкләрен бирделәр. Безнең яшь язучыларыбыз, үз әдәбиятыбызны ныклап, бик тырышып өйрәнү белән бергә, шул җәүһәрләрне дә белергә, өйрәнергә, алардан үрнәк алырга тиеш дип

табам мин, — диде һәм бу сүзләргә ул аеруча басым ясады, шикелле. Хәтеремдә бүгенгәчә шулай сакланган. — Дөньяда Пушкин иҗаты бар, Толстой, Тургенев, Чехов һәм Максим Горький иҗаты бар. Алар бөек язучылар һәм бөек реалистлар. Аларның реализм принципларына нигезләнгән иҗатлары мәңге калыр, мәңге яшәр, ә бүгенге футуристлар һәм башка шуның кебекләр бик тиз онытылыр, халык гаммәсе күңелендә тамыр җәя алмас дип уйлыйм, чөнки алар заманның вакытлы чирләре генә. Чир уза, халык бәдәне ныгый, тазара, матурлана... — диде ул һәм безгә тагын бер сынап карап алды.

...Ф. Әмирханны «барабыз»га чыгарып утыртканда таң аткан, көн яктырган, урамда хәрәкәт башланган иде инде. Без аны артсыз чанага, «барабыз»чының салам түшәгенә уңайлап утырттык, аякларын өйдән алып килгән келәме белән урадык. Әдип янына, аны өенә күтәреп кертер өчен Ф. Әсгать һәм тагын бер студент утырды. Чанасының түренә аягүрә баскан «барабыз»чы, дилбегәсен кагып, чөңгереп җибәрде, туры алаша урам буйлап, шәһәрнең югары ягына, әдип квартирасына таба ашыкмый гына юыртып китте. Апрель иртәсе булуга карамастан, көн шактый суык, җилле, аяк асты катырган, кичәге гөрләвекләрнең өсләре бозланган, бизәкләнгән иде.

Без дә таралыштык. Бераз сөйләшмичә генә бардык. Г. Кутуйның көндәлек кайбер вакыйгаларны киләчәктән торып карый торган гадәте бар иде. Бу юлы да ул күңел ачу кичәсен, язучыларның җыелуын, Ф. Әмирхан белән төн буе сөйләшеп утыруны киләчәккә күчереп карады:

— Кем белә, бәлки, әле без бу кичәне кайчан булса да бер исебезгә төшерербез, — диде. — Күңелле кичә булды. Рәхәтләнеп сөйләшеп утырдык. Сиздегезме, Ф. Әмирхан үзенең авыруыннан зарланмады, теленә дә алмады. Әйтерсең, таза, исән кеше. Менә нинди ул!

Г. Кутуйга бу кичәне искә төшереп язарга насыйп булмады. Безнең арабыздан ул бик иртә китте. Мин, шул кичәдә катнашучыларның берсе, аның кайбер моментларын күңелемдә дә, көндәлек дәфтәремдә дә саклаганлыктан, бу турыда язып чыгарга, узгандагы хисләремне укучылар белән уртаклашырга кирәк таптым.

*Габдрахман Әпсәләмов*

# ПОШИ БАЛАСЫ



*Хикәя*

Күкнең төбе тишелгәндер, валлаһи, яңгыр бер туктаусыз коя да коя. Ике-өч көн генә яуса, сүз әйтер иденме, яз яңгырсыз булмый, язгы яңгыр — көзге муллык. Ләкин һәр нәрсәнең чамасы бар бит. Тоташтан бер ай коя башласа, туйдыра, теңкәне корыта. Ә язда, картлар әйтмешли дә, фән әйтмешли дә, көннең генә түгел, сәгатьнең дә кадерен белергә кирәк, чөнки язның бер көне елны туйдыра. Ә монда көннәр генә түгел, атналар, айлар үтә! Нинди генә гөнаһ шомлыгы булды икән? Югыйсә быел игенчеләрнең язгы чәчүне бик кыска тотарга исәпләре бар иде, механизаторлар эшне дүрт-биш көндә төгәллибез дип кыш буе әзерләнделәр, өйрәнделәр. Яңа техника да, элекке еллар белән чагыштырганда, шактый күп кайтты, халыкның кәефе дә шәп иде. Кыскасы, һәр игенче эшкә жилкенеп тора иде, шундый чакта, мә сиңа пәрәмәч! Ай буе тоташтан коя, май бетеп килүгә карамастан, чәчүлек җирләренең шактый өлеше жылбыр-жылбыр килеп торган яңгыр сулары астында ята...

Язгы чәчүне пычракка булса да чәч, ди борынгы халык мәкале. Пычрагы игенчене куркытмый, чәчәр иде, әмма тракторларны кырларга ничек чыгарасың? Чыккан берсе, нәкъ сазлыкка кергән кебек, бата да кала бит. Райком секретаре Нурислам Гатин әле яңа гына шундый тракторларның берсе янына туктаган иде. Шундый баткан, кабинасына чак пычрак тулмый. Элекке танк механигы Нурислам үзе рульгә утырып карады, кая ул! Икенче трактор китереп сөйрәтеп чыгармасаң, тәмам пычракта күмелеп калачак.

Үзе дә пычракка буялып беткән, атна буе рәтләп йокы күрмәгән, ял итмәгән, колхоздан колхозга, басудан басуга чапкан Нурисламның ачуы килде. Ләкин бу ачуны кая орырга?! «Күзең чыкканмы әллә, кая керәсең!» дип тракторчыны җан тиргә батырып әрләргәме, яки тракторчыга кырга чыгарга боерык биргән бригадирны, агрономны яки колхоз председателенме тетеп салырга (үзе бер минутны да әрәм итмәгез дип ашыктырып, тикшереп, булышып йөргәндә!), яки синоптикларны якаларыннан тотып селкергәме? Бу тирәдә синоптиклар дүртәү: берсе Удмур-

## *УЙЛАР, ПЛАННАР, ТЕЛӘКЛӘР*

*«Казан утлары» редакциясе яңа ел уңае белән үз авторларына шундый сораулар белән мөрәҗәгать иткән иде:*

*1. 1964—65 еллар Сезнең өчен нәрсәләр белән истәлекле булды?*

*2. 1966 елда нинди әсәрләр язачаксыз?*

*3. «Казан утлары» журналына 1966 елда нәрсәләр тәкъдим итәргә уйлыйсыз?*

*4. Бөек Октябрьның һәм Татарстанның 50 еллыгына Сезнең иҗат планнарыгыз?*

*Без түбәндә шул сорауларга алынган кайбер җавапларны урнаштырабыз.*

## *Фатих Хөсни:*

●



**Минем кызым кияү күргән нәрсәме, дигәндәй, мин соң интервьюлар биреп өйрәнгән кешеме! Редакция куйган сорауларны укыгач, бераз башны кашып калдым. Әлбәттә, уйландыра торган мәсьәләләр булды, бар. Иҗтимагый-политик планда алганда да, миңа аеруча якын мәсьәлә — әдәбиятны алсак та...**

**Узган 1965 ел илебезнең эчке тормышында, бигрәк тә, КПСС Үзәк Комитетының март, сентябрь Пленумнарында карап тикшерелгән мәсьәләләре белән минем игътибарымны җәлеп итте. Бу сөйләшүләрнең бөтен әһәмияте, минемчә, барыннан да элек шунда: безнең идарә итүче даирәләребез көн саен, сәгать саен яңаданяңа материаль байлыклар тудырып торучы кешеләргә, асылда илнең тоткаларына, якынрак килү, аларны**

тиянеке, икенчесе Киров өлкәсенеке, өченчесе Татарстанныкы, дүртенчесе Башкортстанныкы. Дүртесенең авызыннан рәтле сводка чыкмый, гел «явым да явым» дип торалар. Бу яклар, гадәт буларак, Казан синоптикларының хәбәрләренә караганда Ижевскиларныкына күбрәк колак салалар, ник дисәң, Ижевск моннан кырык-илле километрда гына, ә Казан берничә йөздә. Әмма тегеннән дә, моннан да күңел юаткыч бер хәбәр юк.

Бераз чистарынгач, Нурислам яңадан үзенең шоферы янына күчеп утырды һәм радиоалгычны тоташтырды. Ләкин вакыт бик иртә булганлыктан, Киров та, Ижевск да, Уфа да, Казан да сөйләми иде әле. Нурислам, выключательне кире борып, яңгыр сулары тәгәрәшкән юеш пыяла аркылы күңелсез һәм моңсу кырларга карап бара башлады. Башында аның кара кепка, өстендә ябык якалы фуфайка һәм кара плащ, аягында күн итек. Тыштан ул бик сабыр, тыныч сыман күренә, дөньясына аз гына да исе китми кебек. Хәтта борын эченнән җырлап та ала, кайчакта шоферына берәр шаян сүз әйтеп тегене шаркылдап көлдертә дә. Әмма кашлары өстенә үк төшерелгән козырегы астыннан төбәп караган конгырт күзләрендә шундый әрнү, күңелендә шундый каты киеренкелек, йөрәгендә шундый авыр тойгы, — илнең икмәксез калу куркынычы бу синең шәхси кайгың гына түгел инде! — эчендәге кайсыдыр тамыры менә-менә шартлап өзелер кебек. Була бит кеше белән шундый хәл: ул артык бер генә минут та бу киеренкелеккә чыдый алмас кебек, чыдаса, йөрәге ярылыр, сулышы киселер кебек. Мондый чакта аңа нәрсәдер — нәрсә икәне артык мөһим түгел — ләкин нәрсәдер эшләргә, бәрергә, сугарга, торып йөгерергә, тәмәке тартырга я булмаса кемгәдер кычкырырга кирәк. Кызурак холыклы кешеләр мондый чакта дуамаллык та эшләп ташлыйлар. Фронтта шундый адәм чыдый алмаслык киеренке минутларның берсендә Нурисламның танк белән таранга баргасы бар. Фронт шартларында бу, ихтимал, акланган дыр да, әмма хәзер кемгә таран ясыйсың? Күкне таранламассың бит!

Кинәт Нурислам башын чайкап алып, кычкырып көлеп җибәрде:

— Бригадир бәхил булсын дип әйттеме әле тракторчы? Әнкәсе белән, хатыны белән бәхилләшми, бригадиры белән бә-

хилләшә! Ха, ха! Ә син, Кәбир, кем белән бәхилләшер идең? Минем беләнме? Әллә командующиеңа чабып, башта киңәш сорар идеңме?

Сугыш елларында да шофер булган һәм ниндидер бер армиянең командующиен йөрткән Кәбир җае туры килгән саен үзенең командующие белән мактанырга ярата торган иде. Янәсе, аннан да батыр, аннан да акыллы кеше дөньяда булмаган, пәйгамбәрләр, әүлиялар кебек барысын да алдан күргән, һәр очракта бердәнбер дөрес киңәш бирә торган булган.

— Минем командующием мондый чакта солдатның канатын каерып китмәс, кыен ул солдат хезмәте дип әйтер иде,— дип җавап бирде Кәбир секретарьның көлүенә каршы.— Кешедә душа бар, душасына кагылырга ярамый аның.

— Ә мин кагылдыммы әллә? — дип кискен итеп сорады Нурислам.

Кәбир аның соравын ишетмәгәндәй, үзенекен дәвам итте:

— Кешенең хәленә керсәң, аның душасы тынычлана. Ә кешенең душасы тынычланса, ди торган иде минем командующием...

— Карабрак бар әле, душабыз белән түпер астына очмыйк.

— Язмаган булса, очмабыз әле.

— Ә синең Гегельны укыганың бармы, Кәбир? — дип кинәт сорады Нурислам, һәм аның коңгырт күзләрендә шаян очкын кабынды.

— Гегельны? Юк, очрашырга туры килмәде. Кем соң ул?

— Синең кебек бер фәлсәфүн. Душа турында сөйләргә яраткан.

— Ә... Душа турында сөйләүчеләр күп, әлбәттә.

Кыяфәте белән татардан бигрәк удмуртка охшаган Кәбирҗан аксыл чәчле, зәңгәр күзле, утыз биш-кырык тирәсендәге ир; чандыр гына, озын гына, бер атна кырынмаса да, йөзендә сакал-мыегы сизелми. Өстендә карага манган хәрби китель, галифе чалбар, аякта күн итек, башта шулай ук карага манган фуражка. Сөйләшкәндә көлемсери төшеп, әкрен тавыш белән сөйләшә һәм шушы көлемсерәгән чакларында аның үткенлеге дә, мутлыгы да, эчкерсезлеге дә бик ачык чагылып китә кебек.

Алар иң элек тракторы баткан колхозга кагылдылар. Нурислам идарәгә кереп китте, ә Кәбир кабинага кырын ята тө-

тирәнтен кызыксындыра торган стимулларны хәрәкәткә китерү юнәлешендә уйланыбрак, тормышчарак эшли башладылар. Бу — бик сөенечле факт. Әлбәттә, сөйләшү, карар кабул итү — шул юнәлештә барысы да эшләнде дигән сүз түгел әле. Ләкин күмәкләшеп һәм һәрберебез үз урынында, бу эшнең әһәмиятен тирәнтен аңлап, җиң сызганып тотынсак, монда җиңеп чыкмаслык кыенлыклар булмастыр кебек.

Дөнья күләмендә алганда да игътибар казанырдай күп кенә вакыйгалар булды. Аларын хәзергә дөнья күләмендә сөйләргә өйрәнгән «дәү абыйлар»га калдырып, шулай да минем игътибарны аеруча җәлеп иткән бер фактны китерәсем килә: Англиянең лейбористлар партиясендә илле бер ел член булып торган галим-философ, мәгълүм җәмәгать эшлеклесе Бертран Рассел шушы партиянең узган ел булып узган съездында демонстратив рәвештә үзенең членлык билетын ертып ташлады һәм бу партия белән арасын өзгәнлеген бөтен дөнья алдында ачыктан-ачык игълан итте. Сәбәбе: Америка империалистларының кечкенә генә Вьетнамда, инде күпме вакытлардан бирле, рәхимсез сугыш алып баруы һәм Англиянең идарәче лейбористлар партиясенең, халык таләбенә каршы килеп, шулай ук сайлау алды программаларында биргән вәгъдәләренә каршы килеп, шушы гаделсез сугышны яклавы. Күренә ки, акны карадан аера белүчеләр торган саен күбәя бара һәм алар акны карадан аерып кына да калмыйлар, «кара»ны алып килүчеләрнең юлына киртә булып та басалар. Бәләкәй генә бер факт кебек, ә үзе күтәрелеп килүче бер хәрәкәтне яктырта.

Конкретлыгы белән шундый ук бер факт — бусы инде әдәбият дөньясыннан. Узган ел безнең совет язучысы Михаил Шолоховка халыкара бүләк — Нобель премиясе бирелде. Минем бу фактка шулай ук игътибар итәсем килә. Беренчедән, «Тын Дон», «Күтәрелгән чирәм» романнары авторы булган бу зур әдипне, кеше рухының башкалар үтеп керә алмаган «карурманнарына» иркен үтеп керүче художник буларак, чын-ихластан яратканлыгым өчен. Икенчедән, бу фактта мин совет әдәбиятының дөнья күләм авторитеты үсә барганлыкны күрәм. Әбиеңә сәлам әйт, бабаң утырмага килсен, юк инде, капиталист әфәнделәр, бу сезгә ялангач кул белән тотып алып ташлый торган «пропаганда» гына түгел!

Тагын бер игътибарга лаек әдәби факт — бусы моның «өй эчебездә» — үзебезнең республикабызда булган хәл. Сөйләшә торгач, ниһаять, Тукай исемендәге әдәбият-сәнгать бүләген

«үз урынына» куйдык. Моның өчен КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм Татарстан хөкүмәтенә язучылар исеменнән рәхмәт әйтәсе килә. Татар әдәбиятына, сәнгатенә һәм, гомумән, мәгърифәтчелек хәрәкәтенә караган башка мәсьәләләр дә бездә юк түгел. Тукай премиясен уңай хәл итү — әлеге мәсьәләләргә якынрак килүдә уңышлы бер адым булсын иде.

Тагы нәрсә? Узган мең тугыз йөз алтмыш бишенче ел үземә нәрсә китерде?

Иң элек шуны әйтим: коточыргыч баш авырту бәласе китерде. Ахрысы, узгандагы йокысыз төннәр, иҗади тынгысызлыклар, сөенечләр һәм борчылулар, яңадан барысы бергә тупланып, минем бәләкәй генә башымда «пәри туе» ясап утмәкчеләрдер. Нишләмәк кирәк, үзем эстәп алган «пәри туе»! Шулай да узган елда моңа чаклы татымаган әр-яңа иҗади сөенечләрем бер дә булмады дисәм, дөрес булмас иде. Башның авыртуын онытып торып, кайбер яңа хикәяләр яздым, үзәктәге әдәби матбугатта әдәбиятның кайбер актуаль мәсьәләләре буенча чыгышлар ясадым. Тамашачы һәм тәнкыйть фикере тарафыннан уңай каршыланган «Бертуган Таһировлар»ны да шундыйлар рәтенә кертәсем килә.

Алда тагы ниләр кырмакчы булам? Баш авырту бәласе белән юкка гына «мактанмадым», иптәшләр. Бик күпне вәгъдә итә алмыйм. Минем тагы кешегә бик үк әйтергә ярамый торган яшерен бер фәлсәфәм — үз фәлсәфәм бар: вакытында туктый белү — ул үзе бер сәнгать. Арыган-алҗыган башны нигә артык көчләргә? Көчләгәнгә карап аннан рәтле нәрсә чыгамы? Ә чын сәнгать бары тик «рәтле нәрсә»не генә, көчәнмичә-көчләмичә тудырган нәрсәне генә кабул итә. Шулай да бөтенләй үк тик ятып булмас. «Язмыш шуклыгы» дигән башлаган бер нәрсәм бар. Өстәлемне бик сагынган һәм баштагы «пәри туе» басылып торган араларда шундагы геройлар янына килеп утырам, алар белән иске һәм мәңге бетми торган әңгәмәне башлыйм. Кечерәк бер повесть кисәге булып чыгар кебек. Ел урталарына журналга шуны тәкъдим итә алмаммы дип уйлыйм.

Бөек Октябрьның һәм Татарстанның 50 еллыгына карата да бик матур планнарым бар. Аерым алганда, революция һәм интеллигенция мәсьәләсе мине күптәннән уйландыра. Бөтен катлаулылыгы һәм эчке драматизмы белән шуны драматургиядә бер чагылдырып карыйсы килә. Уйланам, ләкин кайсы ягыннан «тешләп карарга?» Хәл итеп җиткерә алганым юк.

шеп күзләрен йомды: кайда туктаса, түшәге-мендәре үзе белән шоферның, кош йокысы белән черем итеп алырга да өлгерә.

Иртәнге бишләр чамасы иде, бу вакытта авылда инде йокламыйлар. Кәбир дә, күзен йомса да, йоклап китә алмады, ничектер үзеннән-үзе тормыш җебе сүтелә башлады. Командующийдан соң ул тагы бер дәү генералны йөртә. Әмма ул озын гомерле булмый, Кәбир белән икәү машинада барганда бомбежкага эләгәләр. Кыйпылчык тиюдән генерал үлә, Кәбир үзе дә бик каты яралана, машина тәмам янып бетә. Армиядән кайткач, Кәбир Казанда Татарстан Верховный Советы президиумы председателе Гали абзыйны йөртә. Гади халык кебек простой Гали абзыйга Кәбирҗан бик нык ияләшә һәм аны шулхәтле ярата, Гали абзый үлгәннән соң Казанда кала алмыйча, районга китеп бара һәм райком секретарен йөртә башлый. Райком секретарен йөртү кебек аерата тынгысыз бер эштә генә ул үзенең кайгысын беркадәр оныта. Аннары Нурисламга да ияләшеп китә, аны да ярата башлый, чөнки аңарда да Гали абзый сыйфатларын күрә. Бигрәк тә аңа Нурисламның халыкка булган мөгамәләсе ошый: төчеләнми дә, койрык та болгамый, ялагайланмый да, әйтәсен дә әйтә, шулай ук халыктан качмый да, сүзе үтәрдәйләрнең сүзен тыңлый белә, акыллы киңәшкә һәрвакыт колак сала, эреләнми дә, тәкәбберлек тә юк. Шуңа күрә, кая барсалар да, безнең Нурислам килде дип кенә торалар.

Менә машина яңадан пычрак ерып ялангач кыр буйлап бара, тәрәзә пыяласы өстеннән яңадан эре-эре яңгыр тамчылары тәгәри. Кәбир чак кына башын бора төшеп Нурисламга карап ала: аның күзләрендә сагыш ярылып ята. Өйдән чыгып киткән чагында бәләкәй кызы авырып калган иде. Шалтыратып хәлен дә сорый алганы юк. Ә кайтып керүе белән кызы муенына сарылып:

— Әткәем, поши баласын күрдеңме?— дип сорар.

Арганлык, йокысызлык үзенекен итте, Нурисламның башы күкрәгенә салынып төште. Шунда ук төш тә күрә башлады. Күк йөзе тәмам чистарган, имеш, бер болыт калмаган, саф зәңгәр күктә таң сызылып килә, офык буен алсу нурга манып кып-кызыл кояшның бер кырые күренә, имеш. Әнә ул югарырак күтәрелә, бөтен

тирә-як, кырлар, болыннар, әрәмәлекләр, су буйлары яктыра, ямьләнә, әллә кайда биектә-биектә, баш турысында, тургай сайрый, имеш. Кайдандыр бик тәмле ис тә аңкый кебек. Чәчәк исеме әллә? Нурислам кулына чәчәк тотканмы? Юк, авылда туган, авылда буразнада аунап үскән, балачактан тырма тырмалаган, сука сукалаган, кырык ел гомеренең нибары дүртесен — сугыш елларын — читтә үткәргән Нурислам, ата-бабадан калган гадәт буенча кулына парланып, жылынып торган бер уч туфрак алган да шуны борынына китереп исни, имеш...

Кинәт машина сикереп куйды, каты бәрелүдән Нурислам күзен ачты һәм бер минут чамасы аңына килә алмыйча торды: ал тан да, тургай тавышы да, учына тоткан жылы туфрак та юк, кулында бары тик әвәләнеп беткән папирос кына. Кырлар да әүвәлгечә соры, күңелсез, болытлар да җиргә сыдырылып кына агыла сыман. Нурисламның иркенәеп киткәндәй тоелган күңелен тагын түзә алмаслык авыр тойгы сарды, яңадан башны әйләндерә, акылны җуя торган, бер секунд эчендә үзеңне дә, бүтәннәрне дә сындырып ташлаттыра торган ачу аны калтырата башлады һәм юл чатын күргә шоферга:

— Кая барасың, Алмалыга бор!— дип кычкырды.

Рульгә чатырдап ябышкан Кәбир моңа каршы берни әйтмичә көлемсерәп кенә куйды.

— Нәрсә иренеңне кыйшайтасың? — дип сорады Нурислам кырыс кына.

— Бу вакытта паромчылар буламы соң анда, — диде ул, дөресен әйтмичә. — Кунак кызы да йоклый торгандыр әле.

— Йокласа, тәрәзәсен чиертеп уятырбыз. Анысы синең кайгың түгел.

Җәй көннәрендә яшел бөдрә таллар арасыннан күзгә күренмичә диярлек тын гына ага торган елга быел бер галәмәт җәелгән. Аргы як чак күренә. Районның байтак кына колхозлары әнә шул елга аръягында. Ләкин бит Нурислам Пушкин исемендәге колхоз идарәсе урнашкан Салагызга дип әйтмәде, Алмалыга диде.

Алар килеп җиткәндә яр буе, чыннан да, буп-буш иде, анда бер генә җан иясе дә күренми иде. Нурислам белән Кәбир машинадан төшеп, яр якасына килделәр дә кулларын авызларына куеп: «Паааромммм!!! Паааромммм!»—дип кычкыра башладылар, ләкин аргы якта кыймылдаган

*Әхмәт Ерикәй:*

●



Җәйге көннәрдә сахраларга чыккан саен тамчылы талларга күз төшерәсең. Синең күңелеңне алар нигәдер дулкынландыра. Менә, гүяки хәзер генә җәйге җылы яңгыр явып, талларның озын чәчләрен чылатып үткән; әнә тамчылы таллар су буена тезелеп утырган да, сихри толымнарын сүтеп, кояшта киптерә. Әнә соңгы мода буенча киенгән кызлар төсле каеннар үзән буйлап суда йөзеп килгән сыман күренәләр. Гүя алар суга чылатудан куркып, күлмәк итәкләрен күтәргәннәр, ап-ак аяклары күренеп тора. Урманга керсәң, я ул тып-тын, я шау-шулы. Я кошлар моңы анда, я агачлар чайкалу тавышы ишетелә. Урман һәм, гомумән, табигать нәкъ кеше кебек. Я ниндидер шатлыклар, я ниндидер кайгылар, әрнүләр, сызланулар кичереп яши.

Син бакча буйлап барасың. Яз. Түтәлләрдә тюльпаннар тантанасы. Күз явын алырлык ничаклы матурлык, йөрәкне назлап җылыта торган ничаклы нәфислек. Син сокланасың аларга, син гашыйк. Матур чәчәкләргә сокланып, аларның хуш исләренә исереп, рәхәтләнеп йөргәндә, күзләреңә зәгыйфьләнгән, имгәнгән, таптalган чәчәкләр чагыла. Ниндидер тупас җаннар нәфислеккә кул яккан, матурлыкка аяусыз һөҗүм иткән, кеше шатлыгын мәсхәрәләгән. Син рәнҗетелгән чәчәкләрнең иңрәвен ишетәсең. Пошынмыйча, тынычсызланмыйча кала алмыйсың.

Мин табигатьнең матурлыгына хәйран булып яшим. Әгәр илемнең табигатен сөйми торган бер адәм булсам, бәлки, шагыйрь дә булмас идем. Минем хыялымда табигать. Кошлар тавышын мин йокыда да ишетәм, кө-

**меш суларның челтерәвен, шомыртларның шау чәчәктә чагын төшләремдә күрәм. Туган илемнең матур табигате минем өчен бетмәс-төкәнмәс дәрт чишмәсе; лирик әсәрләр, күтәренке рухлы җырлар язарга мине шул илһамландыра.**

**1966 елда да мин туган илемнең сокландыргыч табигате белән мавыгып, «җенләнеп» яшәячәкмен. Кыска шигырьләр һәм җырлар жанрын дәвам иткән хәлдә, аларны заман турында уйлануларга, совет кешесенең тойгыларына, кичерешләренә, хезмәт шатлыгына, дуслык-мәхәббәт проблемаларына багышларга тырышачакмын.**

**Шулай ук киләчәктә мемуар жанрында эшләүне дә дәвам итәргә уйлыйм. Минем кебек олы яшьтәге кешеләрнең үтеп киткән һәм сагынылган кадерле минутлары яңадан кайтып, элеккедән дә матуррак, кадерләрәк булып хәтер тәрәзәләренә чиртеп торалар. Биографиям андый коннәргә ярлы түгел. Мин — тормыш юлымда онытылмаслык вакыйгаларны очраткан, данлы кешеләрне күрү һәм алар белән аралашу бәхетенә ирешкән кеше. Ул вакыйгаларны язып, яшь буынга калдырмасам, аның алдында үз бурычымны үтәмәгән кеше булып саналачакмын.**

## *Атилла Расих:*

●



**1964 һәм 1965 еллар истә калырлык бик күп мөһим вакыйгалар чоры булды. Мин аларның барысын санап чыгарга да батырчылык итмим. Инде әдәби хәрәкәт мәсьәләләренә һәм хосусән үземнең иҗатыма килгәндә, ул еллар минем өчен «Ике буйдак» исемле романымның дөньяга чыгуы белән истәлекле. Алтмыш дүртенче елда ул роман журналда басылды, ә алтмыш бишенче елда аерым китап булып чыкты.**

кеше күренмәде. Бары тик яңгыраш кына елга аръягындагы урман буйларыннан кире әйләнеп кайтты. Ә дымлы, салкын җил, нигә монда килдегез дигәндәй, аларның чабуларыннан тарткалады, яңак очларыннан чеметкәләде. Әгәр учак якмыйча шунда бер ярты сәгать басып торсаң, кәбестә күчәне кебек катарсың.

— Бар, кабинаңа кереп йоклап ал,— диде Нурислам Кәбиргә, — ә мин көймә эзләп карыйм. Шунда булырга тиеш Әхмәтша агайның көймәсе.

— Туңарсың, әзрәк көтик, — диде Кәбир. Ләкин Нурислам аны тыңламыйча яр буендагы әрәмәләр арасына кереп югалды. Бераздан инде аның көймә белән су киңлегенә чыгып барганы күренде. Кәбир тагын бер-ике минут карап торды да кабинасына кереп утырды. Биредә җылы иде.

— Йөрәгенә чыдый алмый, — дип уйлады ул, сыңар ишкәк белән ишеп, һаман ераклаша барган Нурисламга карап. Теге якта да аны күреп алдылар, ахрысы, паром тирәсендә кыймылдаша башладылар. Әмма паром килеп райком секретаренең машинасын алганчы байтак вакыт үтте, Кәбир черем итәргә дә өлгерде. Ә инде ул машинасы белән аргы як ярга барып төшкәндә, Нурислам учак янында ике кулы белән тез башларын кочып, утка карап утыра иде. Ул гүя оеган, әмма арка сөягенең торышы, беләкләренең кабаруы аның һаман коточкыч киеренкелектә булуын сөйли иде. Кәбир аны кызганып куйды. Язга чykканнан бирле шулай бит. Бу киеренкелекнең кайчан бетәсе дә билгеле түгел, һәм, гомумән, бетәме икән ул райком секретаре тормышында. Көн саен ак икмәк ашаучы кешеләр икмәкнең никадәр кыенлык белән үстерелгәнлеген бер уйлыйлармы икән?! Йөрәк маен суырып үсә бит ул икмәккәй!

Борчулы кешенең йокысы бервакытта да рәтле булмый, күзен йомдымы, хәзер әллә нинди саташулы төш күрә башлый. Кайчагында саташу да булмый, бәлки, кайчандыр булып узган хәлләр гаҗәп бер ачыклык һәм төгәллек белән хәтердә кабатланалар. Менә Нурислам, башка райком секретарьлары белән бергә, Өлкә комитеты бюросында, имеш. Өстәл өстенә күкрәге белән ята төшеп утырган секретарь, күзләрен зур итеп ачып, астан өскә таба карап, аягүрә баскан райком секретареннан:

— Туп-туры итеп әйт: ике мең пот өстәмә ашлыкны ике көннән бирәсеңме, юкмы? — дип сорый.

Район инде планны да тутырган, өстәмәсен дә, өстәмәсенең өстәмәсен дә тапшырган, тагын кайдан алырга? Әмма бу турыда секретарьга авыз ачарга да бирмиләр. Тагын ике мең пот таләп итәләр. Ул уйлап карарга бераз вакыт сорый — вакыт та бирмиләр. Райком секретареның йөзеннән шабыр тир ага.

— Тырышырмын, — ди ул.

— Юк, син тырышма, — дип бүлдерәләр аны, — әйт: буламы, юкмы!

Булмый дип әйтеп кара! Ләкин бирәм дисәң дә вай. Ике мең пот бит! Миллионнарны тапшыру берни түгел, менә кырып себереп алганнан соң мең потны түгел ун потны табуы кыен. Шуңа күрә райком секретаре туры җавап бирмичә:

— Бөтен чараларны күрермен, — дип әйтеп карый.

— Анысы безне кызыксындырмый, ике меңне ике көннән бирәсеңме, юкмы? Шуны әйт! — дип тагын почмакка китереп кысалар. — Я партбилетыңны өстәлгә чыгарып сал диләр...

Төше шул җиргә җиткәч, ничектер барысы да буталып китте. Кайдадыр, кемдер аңа хәзер ул заманнар үтте инде, хәзер барысы да үзгәрде дип кычкыра башлады кебек... Юк, берәү дә кычкырмады, Нурислам үзе Мәскәүдән, Үзәк Комитет Пленумыннан кайткач, партактивта яңа үзгәрешләр турында сөйли, имеш.

Бераздан Нурислам белән Кәбир машинада баралар иде инде. Урманны чыгып, Кәбир машинаны авылга таба бора башлагач, Нурислам:

— Урап, урап бар! — дип кычкырды.

Кәбир шунда ук машинасын авыл артыннан уза торган юлга борды. Бу хәйләне фәлсәфүн Кәбир кирәгеннән артык яхшы белә иде. Райком секретарен райкомнан яки Өлкә комитетыннан эзләсәләр, колхоз һәм авыл советы председательләре барлык юл чатларына кешеләр чыгарып куялар һәм райком секретареның газигы кайда гына күренсә дә, аны тотып алып, телефонга китерәләр. Бүген, күрәсең, Нурисламның беркем белән дә сөйләшәсе килми, шуңа күрә машинаны ындыр артларыннан уратып алып бардыра. Шоферга ни, кайсы юлдан кушалар, шул юлдан алып бара. Кәбир Нурисламны яхшы аңлый, ил кайгысы ир иңендә дип әйтәләр дә, ил кайгысын

**Үзебезнең «Казан утлары»на 1966 елны «Каһарманнар юлы» исемле яңа романымны тәкъдим итәчәкмен.**

**Иҗат планнарым шактый. Октябрьның 50 еллыгы бәйрәменә мин башлыча ялкынлы революционерыбыз Хөсәен Ямашев образын тудырырга телим. Мин аны шул бөек датага багышлап язам да. Драматургия өлкәсендә көч сынап каравымны да дәвам иттерәчәкмен. Режиссер Ширъяздан Сарымсаков белән бергәләп, минем прозаик әсәрләрем мотивлары буенча, ике сәхнә әсәре өстендә эшлибез. Берсе аның «Ике буйдак», ә икенчесенең әле исеме юк. Бары шул кадәресен әйтә алам, анысы авыл яшьләре тормышыннан. Сүзне тагы да дәвам иттерергә булыр иде. Ләкин теләкләр әз генә дә тормышка аша башламаган килеш алдан ук лаф ору уңайсыз.**

## *Рафаил Төхфәтуллин:*

●



**1965 елда минем «Тамчылар ни сөйли» дигән яңа повестем аерым китап булып басылып чыкты. Ләкин иҗади елымның тагын да истәлеклерәк бер хәтирәсе бар әле. 1965 елда мин, кайбер каләмдәш дусларымның сәерсенеп җилкә сикертеп куюларына карамастан, тоттым да, драматургиядә дә каләм тибрәтеп алдым: «Гашыйклар урамы» дигән лирик комедия яздым. Яңа жанр җиңел генә бирелмәде, әлбәттә. Әйтергә кирәк, пьесаның беренче вариантын Язучылар союзының үзебезнең Әлмәт бүлегендә укып карагач, чәчләрем үрә торырлык тәнкыйть уты яуды өстемә. Чәчләр үрә торса торды, әмма дөрес тәнкыйть, дусларча тәнкыйть, яхшылыкка әйтелгән тәнкыйть иде бу. Кызарган яңаклардан кайнар тирне сөртеп ташлап, җиңнәрне тагы да**

**ныклабрак сызганырга туры килде. Пьеса белән Әлмәт дәүләт драма театры да кызыксынды. Юк, кызыксынып кына калмады. Театрның баш режиссеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Габдулла ага Юсупов үзенең бай тәҗрибәсе белән миңа зур ярдәмгә килде. Әнә шулай иҗади хезмәттәшлек нәтиҗәсендә туган спектакль тиздән Әлмәт дәүләт драма театры артистлары башкаруында сәхнәгә менәчәк.**

**Киләчәк планнармы? Иң беренче — язылa башлаган әсәремне төгәлләү. Ул хәзергә әле шартлы рәвештә «Агым су» дип атала һәм һәр бүлеге аерым хикәя дә була алырлык бер бөтен повесть булачак. (Һәрхәлдә, шундый композицион мөкәммәллеккә омтылам.) Бу әсәремдә кара алтын да таба торган, иген дә үстерә торган нефть ягы авылы кешеләрен күрсәтергә тырышачакмын. 1966 елда «Казан утлары»нда шушы әсәрем белән катнаша алсам иде.**

## *Гали Хуҗиев:*

●



**Үсмер чакның шундый хатирәсе һич онытылмый: безнең Кайбыч якларында гектарның биштән бер өлеше чамасын «ярымбиш» дип йөртәләр иде. Син шул ярымбишне сөреп бетергәч, җир башына басып, маңгай тирләрен сөртә-сөртә, уйланып торасың: бу җир быел безне нәрсә белән сөендерер, безнең хуҗалыкка купме уңыш бирер?..**

**Ул заманнар инде ерак калды. Вакыт оча да оча... Дөнья мәшәкатьләре, иҗат өметләре белән мавыгып йөри торгач, тагын бер ел үтеп китте, гомер кырыбызның тагын бер ярымбишен сөреп бетердек. Иҗат мәйданыбызны — поэзиябез кырын күздән кичерәбез: аның быелгы уңы-**

күтәреп йөрүләре кыен шул! Дөньяга күтәрелеп карамас минутлары да булгалый аның. Ә менә Нурисламның кунак кызын — ягъни бозаулар фермасындагы поши баласын карарга йөрүен, кайчагында хәтта ерак юлны якын итеп анда баруын ул һич аңлый алмый. Поши баласын бер тапкыр карау Кәбирнең үзенә дә кызык булды, икенче, өченче тапкырында кызыгы калмады инде. Ә Нурислам һаман шул поши баласы янына бара, барып кына да калмый, ул аны ярата. «Булса да була икән кешенең сәер яклары», дип уйлый фәлсәфүн Кәбирҗан үз алдына.

Поши баласының кечкенә тарихы болай: Камада боз киткәннән соң, шундагы исәпсез-хисапсыз утрауларның берсендә, ничектер, бер поши баласы бүленеп калган. Мескенкәй ныгып җитмәгән аяклары белән әле анда чаба, әле монда, — әйләнә-тирәсе су. Ялварып-ялварып, моңлы һәм кызганыч тавыш белән әнкәсен чакыра. Ә әнкәсе юк, күрәсең, харап булган, югыйсә бозлы суны ерып булса да баласы янына килмичә түзмәс иде. Моннан берничә ел элек баласын югалткан ана пошиның язгы ташкыннарда Каманы ике тапкыр йөзеп чыгып, бозаулар фермасы янына килгәнлеге турында сөйләделәр. Күрәсең, бозаулар тавышын ишетеп килгән ул. Утраучыкта бүленеп калган поши баласын умарталыкка баручы колхозчылар күреп алганнар. Көймә белән утрауга төшеп, поши баласын тоталар да ярга алып чыгалар, аннары мотоцикл арбасына салып бозаулар фермасына — Алмалыга алып кайталар. Шуннан бирле бу иркә урман кызы бозаулар белән бергә яши. Ул алардан әллә ни аерылмый, тик авыз-борын тирәләре генә бераз зуррак, бозауларныкы кебек нәфис түгел, аннары бик куркак, һәр кыштырдаган тавышка колакларын торгыза.

Ферма янында Нурислам машинадан төште дә туп-туры бозаулар аранына юнәлде. Бозаулар караучы олырак яшьтәге хатын белән ягымлы гына исәнләште.

— Кунак кызы ни хәлдә, Мәһирә апа-у? — дип Нурислам поши баласы торган почмакка узды.

— Тәмам ияләште инде, Нурислам. Сөтне дә әйбәт кенә эчә, яфрак, печән дә чемчи. Кызым дисәм, артымнан ияртә.

Нурислам иелеп поши баласын кочагына алды да уртага, иркен җиргә бастырып, башыннан, сыртыннан сыйпый

башлады. Поши баласы бөтен гәүдәсе белән калтырый иде.

— Курыкма, юләркәй, тимим бит. Нурислам абыеңны танымыйсыңмыни? Һәй, юеш авыз, зур күз. Әнкәсе күренмиме, Маһирә апа?

— Юк шул, күренми, Нурислам, — диде Маһирә апа көрсенеп. — Исән түгелдер, югыйсә ана йөргә килми түзмәс иде.

— Шешәңне бир әле, Маһирә апа.

Бозау караучы хатын башына имезлек киертелгән сөтле шешә алып килеп, Нурисламга сузды:

— Вакытлы-вакытсыз имезеп, режимын бозасың, Нурислам.

— Мин дә иркәләмәсәм, минем райком секретаре икәнемне каян белер ул, Маһирә апа? Алмалы кызлары кебек, ускәч, сәлам дә бирмәс әле. Һай, назлыбикә түгел икән үзе, кара ничек суыра,— диде Нурислам һаман да бер кулы белән бозауның башыннан сыйпый-сыйпый. — Маһирә апа, бу кызың, мин әйтәм, модадан бер дә калышмый икән,— кызлар малайларга, ә бу колынга охшап бара. Сыйраклары нечкә, торыгы озын. Ә күзләре? Пешкән кара сливамыни! Әллә инде сөрмә тартырга да өйрәтәсең әзрәк, Маһирә апа,— дип көлде Нурислам.

— Я инде, әйтерсең, Нурислам. Бик мактама әле, я күз тидерерсең сылуыма.

— Кара, кара, Маһирә апа, безнең сөйләшкәнне аңлый бит, колакларын ничек торгыза. Тыңла, тыңла, чибәркәй, кеше усал түгел ул, кешедән курыкма, кешедән качма... Маһирә апа, элек аның күзләрендә кара курку гына иде бит, хәзер нур балкый башлаган, сөенеч нурыдыр инде, ә?

— Я, житте инде, Нурислам, — диде хатын, Нурислам кулыннан буш шешәне алып. — Әйдә әле, кызым, ял итик. — Һәм поши баласы райком секретарена борылып та карамыйча, апасы артыннан иярде.

Бозаулар аранынан чыккач, Нурислам Кама ярына таба китте. Кама моннан нибары йөз-йөз илле метрда гына ага иде. Нурислам текә һәм биек ярга басты да елга киңлегенә карап тора башлады. Яңгыр туктаган иде. Офык буенда аз-маз ачыклыклар да күренгәли. Җил шактый көчле. Димәк, озакламый болытларны да туздыра, таркатa башлар. Райком секретареның күңелендә дә ерактан, бик ерактан әлегә чак сизелеп торган сөенеч тойшы нинди? Аңа һәркайсыбыз күпме өлеш өстәде?

Илебез Совет властеның илле еллыгын билгеләп үтәргә әзерләнә. Шул уңай белән, мин Туган илебезне «Планетабыз күгендә салават күпере» дигән шигыремдә гәүдәләндерергә омтылдым. Язгы яки җәйге җылы яңгырдан соң пәйда булган салават күперенә сокланып карап та туймыйсың, ул инде, акрын-акрын сүнеп, юкка да чыга.

> Бар бит аның сүнми торганы да,
> Ильич күңеле аша кабынган;
> Тора күренеп бөтен планетага,
> Карасаң да кайсы ягыннан.

Владимир Ильичның тууына озакламый йөз ел тулачак. Юлбашчыбыз турында яңа поэтик фикер әйтергә теләп, үткән ел мин аны күреп белгән кешеләрне эзләп табарга тырыштым. Татарстанның Чаллы районы, Биклән авылында карт коммунистка Нурдидә апа Бухарметова яши икән. Ул Советларның II Бөтенсоюз съездында һәм В. И. Ленинны күмүдә катнашкан. «Күңел яктысы» исемле әсәремдә мин аның шул көннәрдә күргәннәрен, кичергәннәрен, юлбашчыбыз турындагы уй-фикерләрен чагылдырдым.

Илебез 1966 елга экономика һәм культура төзелеше өлкәсендә гаять зур уңышлар белән, яңадан-яңа үрләр яулап алырга ялкынлы омтылыш белән керә. Яңа елга безнең дә үз иҗат планнарыбыз һәм өметләребез бар. Журнал укучыларына билгеле булганча, мин, күп еллардан бирле, Юлиус Фучик турында «Вөҗдан сүзе» исемле поэма өстендә эшлим. Аның лейтмотивы:

> Ярата идем мин сезне,
> Кешеләр, уяу булыгыз! •

Үткән ел, каләмдәш иптәшләрнең тәнкыйть фикерләрен искә алып, әсәрне яңадан эшләп чыктым. Кирәк була икән, быел тагын ныгытып эшләргә әзер торам.

Моңардан тыш, журналда яңа шигырьләр белән катнашырмын дип өметләнәм.

## *Ибраһим Салахов:*

●

Күптән түгел генә Целиноградтан кайттым, ничектер үтә куанып, канатланып, язасым килеп кайттым. Анда Казагыстан язучылары җыелган иде.

Гасырлар буенча йокымсырап яткан Казагыстан даласы уянды. Миллионлаган гектар җәйләүләр иген басуларына әйләнде. Ул далада хәзер йөзләгән калалар күтәрелде. Бу —



**Коммунистлар партиясенең чакыруы буенча далага килгән совет кешеләренең хәләл көче һәм фидакарьлеге. Менә шушы гади кешеләрнең бөек хезмәтен без үзебезнең әсәрләрдә тулысынча чагылдыра алдыкмы соң? Әдәбиятта югары художестволылык нәрсә? Социалистик реализм бездән нәрсәне таләп итә?**

**Язучылар ике көн буенча, дулкынланып, янып-көеп, әнә шул һәм башка сорауларга җавап эзләделәр, бәхәсләштеләр һәм фикер алыштылар. Бик кызыклы һәм файдалы булды бу сөйләшү.**

**Инде иҗат планнарым турында. Көндезләрен мин кооперация эшендә. Иҗатка бары төн һәм ял көннәре генә кала. Утырырга-утырырга, туктаусыз язарга кирәк. Хәзер берьюлы өч әсәр өстендә эшлим. Беренчесе — Күкчәтау турында лирик шигырьләр циклы. Икенчесе — Колыма алтын прискалары турында повесть. (Мин анда үзем биш ел буена алтын эзләдем бит.) Өченчесе — Күкчәтау якларында гражданнар сугышы чорын чагылдырган романга материал җыям. Билгеле, бу бик зур, катлаулы һәм шуның белән бергә гаҗәп тирән сюжетлы тема. Уйлаганча очлап чыга алсам, бу әсәр Октябрьның 50 еллыгына иҗади бүләгем булыр иде.**

**Минем Сафа җизнинең атасы — Фәхретдин Мифтахетдин углы шагыйрь булган. Аның «Шаһмаран» һәм «Сал-сал» исемле героик поэма дастаннары 1900 елларда Казан университеты басмаханәсендә басылып чыга. Моннан башка аның дөньяга чыкмаган бик күп шигъри әсәрләре була. Билгеле, күбесе кулдан-кулга йөреп югалган. Ләкин бу әсәрләрнең берникадәресе улы Сафа җизнидә, кызы Зәйнәп апада саклана. Татар әдәбияты өлкәсендә байтак хезмәт күрсәтеп, әлегә кадәр үзенә тиешле урынны ала алмаган, бөтенләй онытылган шагыйрь Фәхретдин турында тарихи материал әзерлим.**

**Шулай ук Галимҗан ага Ибраһимовның соңгы көннәре турында язылган истәлегем бар. Мин бу әсәрләрне «Казан утлары»на тәкъдим итәргә уйлыйм.**

гысы кузгалды, күңелен зынҗырлап торган салкын киеренкелек гүя йомшара төште, ул башын күтәреп, түбәсе турысына карады. Чү, тургай сайрый түгелме?! Быел бит аның тургай сайравын да ишеткәне юк. Тургай сайрамыйча, яз яз була димени.

Нурислам җитез адымнар белән машина янына килеп кабинага кереп утырды да көр тавыш белән:

— Пушкин хәзрәтләре янына! — диде. — Тукай ничек әйткән әле, Кәбир. Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай өч йолдыз ул, дигәнме?

Хәзер яңадан Нурисламның күңелендә таулар актарырлык көч бар иде. Ә райком секретаре йөрәгендәге көч һәм дәрт озакламыйча колхоз председательләре, бригадирлар, механизаторлар йөрәгенә күчәчәк, йөзләгән тракторлар, чәчкечләр тавышы булып яңгыраячак һәм алар бергәләп табигатьнең барлык капризларын җиңеп чыгачаклар, илгә менә дигән мул уңыш үстерәчәкләр.

Нурислам радиоалгычны тоташтырды. Казан соңгы хәбәрләр тапшыра иде. Республикада язгы чәчүләрнең барышы турында сөйлиләр. Үз районының исеме әйтелгәндә Нурисламның колаклары үрә торды. Соңгы көннәрдә, диде диктор, һава шартларының начар булуына да карамастан... районы механизаторлары республикада аеруча яхшы эшләделәр, алар... мәйданда...

Калганын Нурислам үзе дә белә иде. Ул елмая башлады, аңа карап фәлсәфүн Кәбир дә елмая башлады.

— Кунак кызын сөт белән сыйладың, бу шуның изге теләгедер, мөгаен,— диде ул шаяртып һәм нәкъ шул чакта һава торышын әйттеләр. Бүгеннән башлап республикада яңгырлар туктый...

— Һай, авызыңа бал да май! — диде Нурислам һәм шуның артыннан ук Галия Гафиятуллина «Бормалы суны» сузып җибәрде, әйтерсең, зәңгәр күктә тургай сайрый башлады. Ә юл чатында «хәзрәти Пушкинның», ягъни Пушкин исемендәге колхоз председателенең зур гәүдәсе күренде. Ул райком секретарен каршыларга чыккан иде.

1965

●

## *Әхмәт Ерикәй*

●●●

**М**ин кешегә бүләк биргән кебек,
Шатлык бүлеп бирәсем килә;
Әллә нигә моңсу караш түгел,
Нурлы йөзләр күрәсем килә.

Башкаларның урыны җайсыз булса,
Тәкъдим итмә миңа җайлысын;
Үземә дә җиңел була төсле
Җиңеләйтәлсәм кеше кайгысын.

Шатлыгымны илдән яшермим мин,
Яшерен төенчеккә төрмим мин,
Кешеләргә уңыш юллаудан да,
Зуррак бәхет барын белмим мин.

1965

●●●

**Я**кты йөзең, гадел сүзең өчен
Көн бирмәсә сиңа көнче күршең,

Синең өметләрең сүлмәсыннар,
Иптәшең бар синең, сердәшең бар...

Дус-ишләрең сиңа хыянәт итсә,
«Якын» дигәннәрең читкә типсә,

Юлларыңда мине юлдаш ит,
Уйларыңда мине уйдаш ит.

Уйдырмалар корып йөдәтсәләр,
Түр урынына ишек күрсәтсәләр,

Кил яныма, йөрәгемә сыен,
Тартынмыйча таты йөрәк сыен.

Яхшы барса эшең бөтен яктан,
Сәлам бирсә һәркем бик ерактан,

Чик булмаса синең даныңа,
Килмәсәң дә ярый яныма...

1965

●●●

Нинди давылларга каршы бардың,
Нинди күкрәү булып күкрәдең;
Нинди ялкыннардан ялкын алдың,
Нинди сафлык били күкрәгең?

Кояш — кояш түгел балкымаса,
Ышыкланса болыт артына;
Егет — егет түгел эше белән
Иш булмаса туган халкына.

Син бәхетле түгел, ашкынмасаң
Ил бәхетенә бәхет өстәргә;
Тик көрәштә өстен кеше генә
Юмарт була нечкә хисләргә.

1965

●●●

Оныгым белән чыгам бульварга
Чәчәк иснәргә, һава суларга.

Оныгым белән бакчада йөрим,
Сүзләрнең аңа асылын сөйлим.

Дөнья турында сөйлим мин аңа,
Соклана белсен якты дөньяга.

Якты дөньяны ярата белсен,
Яңарта белсен, яңрата белсен.

Ул уйный белсен һәм көлә белсен,
Ил арбасына җигелә белсен.

Мин сөйлим аңа, ул тыңлый әле,
Бәхәсләшергә тотынмый әле.

Эндәшәм аңа иркәләп кенә,
Мин — сары яфрак, ул — бәбәк кенә.

Ул — хыялымның саф күбәләге,
Мин кичәге көн, ул — иртәгәге.

1965

●●●

Заман җырын, дөнья матурлыгын
Яшьләр җырлый яшел аланда;
Күздән яшь китерә торган сүзләр,
Йөрәк өзгеч моңнар бар анда.

Тыңлап торам яңа җырларны мин,
Бер шатлана күңел, бер тула;

Әллә ниләр төшә исләремә,
Әллә кая йөрәк омтыла.

Тыңлап торам яңа җырларны мин,
Нидер зыңлый төсле күңелдә.
Шуннан зуррак бер теләгем дә юк,
Җырым калса яшьләр телендә.

1964

●●●

Саф йөрәкле кеше мәңге гашыйк
Табигатьнең якты көченә;
Суын яңгыр гөлгә биргән кебек,
Яшәү бирсен кеше кешегә.

Ни әйтсәң дә, кеше хәлләренә
Фәкать кеше генә төшенә;
Кояш нурын җиргә биргән кебек,
Җылы бирсен кеше кешегә.

Яшәгәндә яшә колак салып
Туган җирнең йөрәк тибешенә.
Җир дөньяга дәрман биргән кебек,
Ярдәм бирсен кеше кешегә.

●●●

Күзләрдән коелган яшь сыман
Яфраклар коела, коела;
Саргайган яфраклар коела,
Күңелгә ямансу тоела.

Еракка, Дарданелл буена
Торналар кунакка җыена.
Яңага юл биргән шикелле
Искергән яфраклар коела.

1965

●●●

Борчылмыйм мин, әгәр сандугачлар
Сайрамаса урман буенда,
Кешеләрнең елмаюлы йөзен
Очратасым килә юлымда.

Тамашачыларның алкышлары
Илһам биргән кебек җырчыга,
Нурлы йөзләр канат бирә төсле,
Дәрман бирә төсле юлчыга.

Аякларым минем тигез баса,
Аякларым минем еш баса,
Авырын белмим юлның, озынын белмим,
Елмаюлы йөзләр очраса.

Мөмкин түгел эшне башкарырмын,
Карап калса дуслар елмаеп,
Юлда миңа уңыш теләсәгез,
Озатмагыз, зинһар, моңаеп!..

1965

●●●

Җилләр алып килә болытларны
Күз яшьләре белән елатып,
Сиреньнәрнең ефәк яулыкларын,
Хатфә күлмәкләрен чылатып.

Кара болыт китә тау артына,
Ерганаклар һаман ярсыйлар.
Каеннарның юеш чәчләреннән
Тамып кала көмеш тамчылар.

Сафлана һәм зәңгәрләнә һава,
Юган төсле зәңгәр күлләрдә.
Яңгырдан соң сулыш җиңеләя
Игеннәргә, җиргә, гөлләргә.

Яңгырдан соң сулыш җиңеләя,
Төрле яктан хуш ис бөркелә.
Табигать бит кеше шикелле ул —
Бер яшь түгеп елый, бер көлә.

1964

●●●

Мин һәрвакыт гашыйк зур ташкынга.
Аккан саен ташкын ишәя;
Алга барган саен чистара ул,
Алга барган саен көчәя.

Син дә, йөрәк, ташкыннарга тартым,
Ашкынасың һәрчак каядыр;
Ташкын кебек ашкынасың икән,
Син дә, димәк, шактый чаядыр.

Артка карап түгел, еракларны,
Туар таңны күреп тип, йөрәк;
Тыңгы түшәгенә караганда,
Юлдагы таш безгә иплерәк.

Мин борчыла башлыйм, әгәр дуслар:
«Тыныч кына ял ит!» дисәләр...
Агачлар да кояш юлын күреп,
Күккә таба үрелеп үсәләр.

1965

Әмирхан Еники

# Әйтелмәгән васыять

Хикәя

*Баязит Бикбайга*

Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй бит-тән сөя... Рәхәт, һай рәхәт тә соң!.. Һәм ямансу. Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып җылыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!

Әнә көмешләнеп дулкынланган кылганнар арасында ак яулык бөркәнгән, алъяпкыч бәйләгән, күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырган кечкенә буйлы, арык кына бер әби кизәк җыеп йөри. Сул беләгендә аның иске чиләк, уң кулында нечкә таяк. Шул таягы белән ул кизәкне чирәмнән куптарып әйләндерә дә, аннары иелеп алып, чиләгенә сала. Тагын як-ягына каранып эзләп китә. Тагын кизәкне чирәмнән куптарып, чиләгенә алып сала... Шулай да бу авыл кырындагы чирәмлектә хәзер кизәк аз табыла, колхоз терлекләре монда йөрмиләр, ә бәләкәй генә авылның үз бозаулары салып калдырган «беленнәр» күпме генә соң ул! Далада утын дигән нәрсә бик кадерле булгач, ялгыз әби ике-өч көндә бер чыгып, иске чиләге тулыр-тулмас шул «беленнәрне» җыеп кайта. Борыннан килгән бер гадәт. Аннары кизәк казан астына бик килешә, ашны әкрен генә кайната, ә үз җае белән әкрен генә кайнап пешкән аш бик тәмле була ул. Әйтерсең, чирәм исе керә ашка.

Тик соңгы вакытта әбинең хәле шәптән түгел әле. Картлыгы житкәнме, берәр чир зәхмәтеме шунда, ләкин гел менә бөтен тәне авыраеп, кул-аяклары сызлап, йөрәгенең хәле китеп тора. Ара-тирә өшетеп тә җибәрә, яки тиктомалга яндыра да башлый. Үзенчә мәтрүшкәсен-ниен эчкәләп, ятып караса да, бер дә юнәеп китә алмый. Менә бүген дә, кояш шактый нык кыздыруга карамастан, аның зәгыйфь тәне, эчендә боз яткандай, гел туңып тора, аркасы буйлап әледән-әле салкын кымырҗау йөгереп уза, шул ук вакытта күз төпләре яна, иреннәре бөрешеп кибә, һәм ул гер таккандай авыраеп киткән аякларын көчкә генә сөйрәп йөри... Булмас ахрысы, кайтырга кирәк, ди ул үз-үзенә иренеп кенә һәм, чиләге кизәк белән тулмаса да, авылга таба борыла.

Читән буйларында котырып кычыткан үскән тар тыкрыктан узып, бәбкә үләне белән түшәлгән киң урамга килеп чыккан чакта гына аңа Миңлебай карт очрый. Торна шикелле нечкә, озын аяклы, какланып беткән бу чандыр бабайны авылның иң карт кешесе диләр. Туксанның өстендә үк түгел микән, хәер, тәгаен ничә яшьтә булуын ул үзе дә белми. Былтыр гына аның җитмештән узган Миңнегәрәй исемле улы үлеп киткән иде. Хәзер бабай Миңнегәрәйнең зур улы Миңнегалидә тора.



Миңнегалинең дә өйләнгән улы, кияүгә чыккан кызлары бар. Миңлебай карт менә шуларның балаларын, ягъни үз токымының дүртенче буынын күрде. Дүртенче буын әкәмәт икән ул, бер дә бабай дигәнчә түгел. Ул хәтта аларның исемнәрен дә отып ала алмый: Вилне Вилдан дип, Эмманы Әсмабикә дип тик йөртә бирә...

Дөньяда чамасыз озак яши торгач, кайчандыр паровоз тавышын да ишетмәгән бабай тракторын да күрде, автомашинасын да, самолетын да, радиосын да күрде, алар аның авылына һәм өенә килеп керделәр, ләкин картның берсенә дә исе китмәде. Чөнки бу заманның барышына ис китеп өлгерерлек түгел иде. Ләкин былтырмы икән, өченче ел микән, кемнәрнеңдер бу тирәләргә очып килеп, самолеттан бүре атып йөрүләрен ишеткәч, картның моңа шулай да исе китте. Кара син аны! Бүрене самолеттан гына «сугалар» диген, ә?.. Кайчандыр, бик күптән инде, ул үзе ир-егет чагында камчат бүрек, ак чикмән киеп, билен кызыл билбау белән буып, камыт күрмәгән, сөлектәй яшь айгырга атланып далага чыгып китә иде дә, йөри-йөри бүренең эзенә төшкәч, аны уктай сузылып очкан бурзаеннан өсләтеп, ун-унбиш чакрым куа барып, озын саплы чукмары белән сугып ала торган иде. Менә бу ичмасам бүре сугу иде! Ә хәзер һавадан атып йөриләр, имеш. Моның ни кызыгы да ни комарлыгы бар? Юк, әллә нишләде бу замана! Машина да машина, ә кешенең үз йөрәгенә, үз кулына ни кала?!

Миңлебай картның дөньяда да, колхозда да хәзер бер эше дә юк. Ул какланып беткән тәнендә бары җан асрый. Алдына куйганны утырып ашый, ястыгын тәгәрәтә дә ятып йоклый, шулай итеп гомерен суза да суза. Аның хәзер бер генә эше бар,— ул ялан таптарга ярата. Һәркөнне иртәнге чәйдән соң ул озын карагай таягын тотып, торнаныкыдай нечкә аякларын сыгылдырып кына буш урамнан уза, кырга чыга һәм күзе караган якка таба юлсыз-нисез китеп бара. Берәр түбә җиргә менгәч, озын таягын ике учлап, ерак кырларга тик кенә һәм озак кына карап тора. Бу күз җитмәс Юлкотлы яланының бөтен ягын, андагы түбәләрнең, үзәннәрнең, чокырларның бөтенесен карт исемнәре

белән белә. Хәзер инде ул исемнәрнең күбесе онытылып бара. Хәзер, мәсәлән, Каракош басуы яки Атчабар кыры дип түгел, ә фәләненче бригаданың да тегәненче бригаданың участогы дип кенә йөртәләр. Юлкотлы яланнарын тоташтан сөреп бетерделәр. Иске чикләр, иске исемнәр барысы да күмелеп калды шунда...

Карт түбәдән төшеп китә, үзәнлекләрдән уза, иген басуларын буразна буйлап кисеп чыга, шулай итеп әллә никадәр җир әйләнеп, күп вакытта авылның икенче очыннан кайтып керә. Юлында очраган кешегә үзе башлап дәшми, ә берәрсе: «Саумы, Миңлебай бабай?» дип дәшсә, «Ару әле» яки «Шөкер!» дип кенә узып китә. Ни уйлап, нәрсә карап йөри торгандыр карт — белүче юк.

Менә бүген дә карчык, йөзгә-йөз очрашкач дәшмичә китүне килештермичә, үзе башлап аңа:

— Нихәл, арумы, Миңлебай агай? — диде, авызын учы белән генә каплый төшеп.

— Ә синмени әле бу, Акбикә килен? Шөкер! — диде карт, тукталып. Җитмештән узган карчык аның өчен һаман да «килен» иде әле, һәм «Акбикә» дип тә бары ул гына дәшә, югыйсә авыл халкы карчыкны күптән инде «Акъәби» дип кенә йөртә.

— Каян кайтып киләсең болай? — диде карт.

— Менә кизәк җыярга чыккан идем.

— Ә ярый, ярый... Казан астында утның өзелмәве яхшы. Йә, үзең ару гынамы соң?

— Шөкер иде әле, тик менә бу көннәрдә генә әллә нишләп хәлем китеп тора, — диде карчык һәм тирләгән битен яулык очы белән сөртеп алды.

— Авырма инде, син — ялгыз кортка, карар кешең юк.

— Алладан вакыт җитмәгән булса, үтәр әле.

— Үтәр, алла боерса, үтәр, бик күпне үткәрдек, — диде карт, ияк очында гына ябышып торган берничә бөртек апак кылдай сакалын селкетеп. — Ярый, кортка, юлыңда бул! — Һәм карт, озын аякларын сыга биреп, китеп тә барды. Ул карчыклар белән күп сөйләшеп торырга яратмый иде.

Акъәби, үзенең җил капкасына җиткәч, туры читән алачыкка узды. Бу тыштан балчык белән сылаштырылган җир

## *УЙЛАР, ПЛАННАР, ТЕЛӘКЛӘР*

### *Гамил Афзал:*

●



Мин шушы елның октябрь аенда «Өянкеләр моңы» исемле шигырьләр җыентыгымны тәмамлап, нәшриятка тапшырдым. «Өянкеләр моңы» соңгы елларда язылган лирик һәм сатирик әсәрләрдән тора. Лирика бүлегендә совет халкының рухи байлыгын, тормышның матурлыгын һәм катлаулылыгын, Ватан, Ленин образларын чагылдырырга тырыштым.

Ә юмор-сатира дигәнендә, тискәре күренешләрне тәнкыйтьләдем.

Бөек Октябрьның 50 еллыгын яңа җыентык белән каршы алам. Әле исеме куелмаган яңа китабымда гражданлык лирикасына киң урын бирелә. Анда Ленин, революция, халык күңеленең матурлыгы, коммунизм төзүче кешеләрнең җиңелмәс рухы тасвирлана. Бу яңа китабым 1967 ел урталарында дөньяга чыгар дип өмет итәм.

### *Шәүкәт Галиев:*

●

Университетның фольклор экспедициясе белән ике ел рәттән Пермь һәм Курган өлкәләрендә булдым. «Сөзгәк үгез маҗаралары» исемле, ун әкәмәттән торган яңа юмористик поэманың ачкычын әнә шул сәяхәт — халык иҗатының үзенчәлекле яңа үрнәкләре белән танышу бирде. Әсәрне журналга тәкъдим иттем, яңа ел башларында, ихтимал, укучылар кулына керер.

Соңгы вакытта мин күбрәк юморсатирага тартылдым, бугай. 1965 елгы «Уйларым-серләрем» исемле ки-



тапта, юмордан тыш, лирик парчалар, шигырьләр дә урын алса, «Уеныны бергә» исемлесе (1966 елда чыгачак) — бөтенләй диярлек юмор-сатира.

Балалар өчен яратып язам. 1965 елда «Шәвәли» исемле, Г. Огородниковның мәзәк рәсемнәре белән бизәлгән шаян шигырьләр китабым да дөнья күрде. Яңа елда балаларга бүләгем — «Шаян каләм» булыр. Мәскәүнең «Балалар әдәбияты» нәшрияты юмористик шигырьләрне русча чыгара.

Заман, чордашлар турында лирик парчалар да язылгалый тора. Аларны туплап журналга бирермен дип уйлыйм.

## *Гариф Ахунов:*

●

1964 елда минем тәрҗемәмдә М. Шолоховның «Тын Дон» романының дүртенче китабы басылды. Шул ук елны «Хыялый Хәйрүш егетләре» диган повесть тәмамладым. Октябрь азакларында Мәскәүдә үткәрелгән татар әдәбияты атналыгында катнаштым. 1965 елның май башында Әлмәт дәүләт драма театры «Утлар яна учакта» исемле драмамны сәхнәгә куйды. Моны иҗат тормышымдагы иң шатлыклы вакыйгаларның берсе дип саныйм.

1965 ел минем өчен тагын да бер ягы белән аеруча истәлекле булды: Язучылар союзының Әлмәт бүлеге тәкъдиме буенча, Мәскәүдә ике айлык курсларда укып кайттым. СССР язучылар Союзы тарафыннан, Бөек Октябрьның 50 еллыгына һәм В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышлап, әдәби институт каршында оештырылган бу курсларның максаты тарихи-революцион темага язучы авторларның эшенә ярдәм итү

идәнле алачыкта аның барлы-юклы савыт-сабасы да тора, шунда аш-суы да пешә иде. Җирдән аз гына күтәртеп салынган, калай морҗасы туры гына кыектан чыгарылган учагы алдына карчык кизәкләрен бушатты. Казанына өч-дүрт чүмеч су салды да учагына күп кенә итеп чыбык-чабык сындырып тыкты, ут төртеп җибәрде. Чыбыклар күмерләнеп төшкәч, алар өстенә иплән кенә кизәкләр өештереп куйды. Аның исәбе башта су җылытып, табак-савытын юу, аннары әзер казанда үзенә бер-ике генә уҗау буш умач пешереп алу иде. Нигәдер күңеле бүген сызык йөгерткән буш умачны корот катып кына ашарга теләп тора иде. Ләкин карчык сизә, пешерә дә, ашый да алмас төсле; хәле бөтенләй бетеп бара, көчкә генә йөреп азаплана, гәүдәсе менә гел ятарга гына сорап тора... Ахырда түзмәде, казан астыннан кизәкләрне алгарак тартып, учагын сүрелтә төште дә бераз ятып торырга булды. Алачыктан өенә узышлый күрше ишек алдында йөргән яшь хатынга читән аша гына дәште:

— Гарифә, дустым, минем казан астын гына кереп караштыра тор әле, әз генә ятып алмакчы булам, бер генә дә хәлем юк.

— Ә ярый, ярый, Акъәби, карармын, борчылма, ят! — диде уңган хатын, әбинең төсе качкан чыраеннан авыру булуын шунда ук чамалап.

Акъәби урам тәрәзәләре ябык, әрем себеркесенең исе аңкыган салкынча өенә керде, сәке түренә бөкләп куйган ястыгын җәйде дә, бисмилласын әйтеп, сырган юрган белән ябынып, бөгәрләнеп кенә ятты. Аның бик җылынасы килә иде. Ятып күзләрен йомуга, ул салкын бер чонгылга баткандай башта туңып китте, кымырҗып, акрын гына калтырана башлады. Күпмедер вакыттан соң бераз гына җылынган кебек булды, ләкин тәмам эреп, изерәп китә алмыйча ярым уяу, ярым йокылы хәлдә һаман бөрешеп кенә ята бирде. Бераздан Гарифә кереп хәлен белде, ашыйсың-эчәсең килмиме дип сорады. Әби локма да кабасым килми, кайнар чәй генә эчәр идем, диде. Гарифә алачыктан утлы көл өстендә генә пешергән куе чәй китереп, чынаягына карлыган кагы салып, шуны сыек бал белән генә аңа эчерде. Әбинең җыерчыклы ябык куллары һәм кипкән иреннәре калтырый иде. Шулай да ул тәлинкәне үз кулы белән тотып эчте, Гарифәгә күп итеп рәхмәт әйт-

те, тирләп бер йокласам, иртәгә, алла боерса, аякка басармын, диде, тик бүген инде көтү кайткач, кәҗәсен савып, сөтен баз өстенә генә куярга кушты. Гарифә барысын да эшләргә булды, тыныч кына ятарга кушты һәм карчыкның өстен әйбәтләп ябып чыгып китте.

Ләкин карчык икенче көнне дә, өченче көнне дә аягына баса алмады. Күрәсең, авыруы аның болай бер-ике көн генә ятып үткәзеп җибәрерлек түгел иде. Ниндидер җитди чиргә охшый. Карчык үзе алай дип уйларга тырышмаса да, әллә ходайдан вакыт җитүе шушы микән дип, шомланып куйгалый иде.

Күршеләре кереп, аның хәлен һаман белә тордылар, Гарифә исә ашау-эчүен кайгыртып, йорт-җирен һаман карый йөрде. Шулай да карчыкның хәле бер дә алга бармагач, аңа әллә улларыңа, кызларыңа хәбәр итикме, болай яту ярамас бит, дия башладылар. Ләкин Акъәбинең өмете зур иде әле, ерак каладагы балаларын бер дә борчыйсы килми иде. Аннары болай да берәрсе кайтып китмәсме дигән өмете дә юк түгел иде. Кайткалыйлар иде әле аның уллары яки кызлары, инәләрен онытып бетермиләр иде, исән генә була күрсеннәр инде.

Карчыкның соңгы еллардагы гомере шул балаларының кайтып китүләрен көтеп яшәү белән генә уза башлады. Дөрес, моннан ун ел элек карты үлгәннән соң, балалары карчыкны калага тартып караганнар иде дә каравын, ләкин ул гомер иткән нигезен ташлап китәргә теләмәде инде. Шушы Юлкотлыда туган ул, үскән ул, шушы Каһарман карт өенә килен булып төшкән, шушында илле биш ел яшәгән, уллар-кызлар үстергән. Шушы Юлкотлы туфрагында аның атасы, анасы, күпме туганнары, яшьли үлгән сабыйлары, гомер иткән карты ята — йә, ничек шуларның барысын да ташлап китәсең?.. Күп торасы да калмагандыр, ят җирнең туфрагына барып ятканчы, шушында үзенең ата-анасы, карты, сабыйлары янында булыр, — шулай уйлаган иде карчык ул чакларда. Һәм, һичнигә карамастан, хәзергә чаклы ул шушы ниятендә нык торды.

Шулай да карчыкка җиңел түгел иде. Туган туфрак никадәр генә үзенә бәйләмәсен, авыл артындагы канау белән әйләндереп алган зиратта ятучы әрвахлар никадәр генә якын булмасын, әмма болар гына аның тормышын тутыра, ялгызлы-



иде. Иҗат эшебезгә кагылышлы махсус лекцияләрдән тыш, без, Советлар Союзының төрле ягыннан җыелган 35 язучы (Татарстаннан Атилла ага Расих һәм мин), Мәскәүнең күп кенә музейларында, архивларда булдык. Революция бишеге Ленинградка сәяхәт кылып, 10 көн буена тарихи-революцион урыннарны карадык. Легендар «Аврора», Разлив һәм Ленин шалашы, Смольный, Эрмитаж, Пушкино шәһәре, Петропавловский крепосте, Бөек Ватан сугышы чорындагы Ленинград оборонасы һәм Кронштадт күңелдә зур тойгы калдырдылар, туган илебезгә, аның тарихи үткәненә ихтирамыбызны тагын да көчәйттеләр. Шул ук вакытта күңелдә икенче бер уй да кузгалды: шулай да без, Татарстанның яшьрәк буын язучылары, тарихыбызны начар беләбез икән. Моңар, безнең үзебездән тыш, өлкән иптәшләребез дә гаепле булса кирәк. Язучылар союзы идарәсе революцион теманы аз кузгата, шуңа күрә бүгенге көнгә кадәр көнчыгышның бөек революционеры Мулланур Вахитов турында да роман язылмаган әле. Гражданнар сугышы чорындагы татар командирлары һәм татбригада турында да гаҗәеп материаллар бар икән ләбаса! Кыскасы, Мәскәү бездә революцион ут кабызды. Казанның үзендә һәм, бигрәк тә, читтә яшәүче авторлар өчен шушындый ук курсларны безнең үз союзыбыз оештырганда да шәп булыр иде. Беренче империалистик сугышларны ук күргән Идрис ага Туктарлар, Совет властеның беренче елларыннан поэзия сафына баскан Хәсән Туфаннар һәм Нәкый Исәнбәтләр яшь язучыларда шундый ялкынны кабыза алырлар иде.

Октябрьның 50 еллыгына мин Татарстан турында документаль повесть тәмамлап киләм. Бу әсәр урта яшьтәге мәктәп балаларына адреслана һәм Мәскәүнең «Детгиз» нәшрияты заказы буенча языла. Бая әйткән ике

**айлык курсларда булу — повестьны язуга күп ярдәм итте. Моңардан тыш, Октябрьның 50 еллыгына «Кайсыгыз комиссар?» исемле пьеса язам.**

**1966 елда «Юлдаш» исемле романымны язуны дәвам итәрмен дип уйлыйм.**

**Язылып бетеп, «комын сеңдерергә» куйган өч хикәям бар. 1966 елда «Казан утлары»на шул хикәяләремне, нефтьчеләр турында очерклар һәм, элекке гадәтемне искә төшереп, берничә әдәби тәнкыйть мәкаләсе бирергә ниятем бар.**

## *Мөхәммәт Гайнуллин:*

●



**Берничә еллар XX йөз башы татар әдәбияты һәм публицистикасына караган материалларны өйрәнү өстендә утырдым. Мине, бигрәк тә, 1905 ел революциясе тәэсирендә мәйданга килгән вакытлы матбугат һәм аның әдәбиятыбыз үсешенә ясаган йогынтысы кызыксындырды.**

**1964—65 елларда Татарстан китап нәшриятына әдәбиятыбызның бөтен жанрларын (публицистика, әдәби тәнкыйть, поэзия, драма, проза) эченә алган «Татарская литература и публицистика начала XX века» исемле бер хезмәт тапшырдым. Ул хәзер производствода, ел башларына басылып чыкса кирәк. Мин бу китапта шул чор әдәбиятыбыз букетының розаларына гына түгел, аерым кечерәк чәчәкләргә һәм букет бәйләмен тулыландырып торган яшел үләннәргә дә игътибар һәм урын бирергә тырыштым. Мәгълүм булганча, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимовлар янәшәсендә талантлары буенча алардан түбәнрәк дәрәҗәдә торган йөзләрчә язучыларыбыз бул-**

гын жиңеләйтә алмыйлар иде. Ялгыз башын монда асраса да, күңеле белән ул һаман шул балалары янында иде. Шуларны уйлап, шуларны сагынып, шыксыз озын көзләрне дә, салкын кышларны да уздырып җибәрә, сабыр гына җәйне көтеп ала, ә җәен берәр улымы яки кызымы балалары белән кайтып китәргә тиеш аның... Шулай көйләнде инде карчыкның тормышы: асылда җәйнең бер атна-ун көне өчен генә яши ул һәм ел буе диярлек тик шуңа әзерләнә. Маен-күкәен дә шул көнгә дип җыя, итен-казылыгын да балаларым өчен дип каклый, шомыртын, эремчеген, коротын да шулар өчен киптереп куя. Бигрәк тә оныкларын бик сагына карчык. Шулар кайтса инде куанычы эчены сыймый, бөтен дөньясын оныта, үзе дә бер бәйрәм итеп ала, бичара. Тик бу бәләкәчләрнең эти-энриләре карчык янына гадәттә бик кыска вакытка гына кайталар. Алар, ни хикмәттер, гел ашыгалар. Кайсының эше көтә, кайсының курортка китәсе була, аннары балаларыбыз авыл җирендә авырып-нитеп китә күрмәсен дип куркалар да булса кирәк, кыскасы, берәр атна торгач та карчыкның бик тилмереп соравына карамастан, юатыр өчен кулына мул гына акча тоттырып, вәгъдәләр биргән булып, китеп тә баралар. Шулай итеп ел буе көтеп алган санаулы көннәр төш кебек үтә дә китә. Аннары тагын шул кыска гына тансык төшнең яңадан иңүен көткәндәй озын йокыга охшашлы ялгыз гына яшәү башлана.

Нишлисең, заманасы шулай туры килде инде. Акъәбинең сабый чактан исән калган балалары үсә тордылар, күрше авылның урта мәктәбен бетерә тордылар, һәркайсы канат чыгарган кош кебек Юлкотлыдан еракка оча торды. Хәзерге вакытта бер улы белән бер кызы Өфедә яшиләр. Тагын бер кызы, врач булып чыкканы, Пермь өлкәсендә тора, ә иң кече малае, авиация институтын бетергәч, Казахстанга җибәрелгән иде, шунда, исеме дә билгесез яшерен бер җирдә, кемдер булып эшли.

Өфедәге иң зур улы Суфиян — хәзер инде отставкага чыккан полковник, ә кызы Гөлбикә фәнни институтларның берсендә гыйльми эштә, кияве исә аның, Чакмагош башкорты, зур, җаваплы урында утыра. Кыскасы, барысы да зур кешеләр булып беттеләр. Кайсы галим, кайсы инженер, кайсы врач... Борын заманда бер ата-анадан түгел, бөтен өя-

зеннән бу кадәр укымышлы башкорт чыкмагандыр. Акъәби үзе кыз чагында башкорттан яки татардан доктор барлыгын ишеткәне дә юк иде. Әле дә хәтерли, әлек авылда берәрсенең теше сызласа, моннан унсигез чакрымдагы чуваш авылына тәмәке алып кайтыр өчен, ат мендереп, кеше чаптыра торганнар иде. Булган заманнар. Юк, аның балаларына килде инде бәхет, килде, әйтәсе дә түгел!

Тик менә бик бәхетле булып киткән балалары аңардан ничектер шактый ераклаштылар шикелле. Зарланса язык булыр, карыйлар, ярдәмнәреннән ташламыйлар, рәхмәт үзләренә, тик шулай да карчык борчылып уйламыйча булдыра алмый: туган җирләрен дә, кечкенә Юлкотлыны да, аталарыннан калган нигезне дә алар бөтенләй онытып бара лар кебек. Уйлары да, күңелләре дә бүтәндә булса кирәк... Менә зур улы Суфиян. Күпме ил гиздe, нинди зур дәрәҗәгә иреште, олайды, үзенең дә ул-кызлары үсеп җитте, инде хәзер беркая да эшләми, зур пенсия ала, машинасы бар,— аңа бит Юлкотлыга ешрак кайтса да була хәзер... Ләкин, нишләтәсең аны, һаман вакытым юк дип зарлана, ниндидер комиссияләрдә эшләп йөри, кышын берике айга курортка китә, йә булмаса үзе кебек погоннарын салган полковниклар белән төннәр буе карта сугып утыра, ә җәйгә чыккач, машинасына хатынын, бала-чагаларын утырта да йә Кырымга, йә хатынының урыс туганнарына — Саратовка китеп бара. (Суфиян сугышка чаклы ук әле, Саратовта хезмәт иткән чагында, марҗа кызына өйләнгән иде, һәм Акъәбинең ул чакта моңа күңеле бик тә сыкранган иде.) Ә каладан йөз егерме чакрымда гына торган Юлкотлы читтә кала, әнисе-карчыкның алар өчен генә дип саклаган казлары келәтендә шул килеш эленеп тора, — полковникның кереп, туган авылын күрергә һәм әнисен куандырырга вакыты да, җае да табылмый. Ничек моңа күңел сыкранмасын ди!

Шулай да былтыр җәй Суфиянның җиткән улы Геннадий үзләренең машинасында «бабушканы» күрергә дип кайткан иде. Өч көн торды, өч көн Акъәби бер кәлимә башкортча белмәгән оныгы алдына барлык сыйларын куйды, сүзсез генә аңа моңсу һәм назлы итеп карап утырды. Егет җирән чәчле иде, таза иде, физкультурник иде, урам буйлап чыгып киткән чакларында карчык аның чуар

ган, һәм культурабыз үсешенә алар да аз өлеш кертмәгәннәр бит.

Һәр халыкның әдәбияты башка милли әдәбиятлар белән тыгыз бәйләнештә үсә. Менә бу тема күптәннән җәлеп итеп килә. «Горький и татарская литература», «Толстой һәм татар әдәбияты», «Чынлык көче» кебек мәкаләләрем шул юлдагы беренче башлангычлар иде. Мин хәзер Идел-Урал буе халыклары әдәбиятларындагы үзара бәйләнеш мәсьәләсе өстендә эшлим. Халыклар дуслыгының һәм үзара ярдәмләшүнең әдәбиятта чагылышын күрсәтү һәм шул хәлнең безнең коммунизм төзүче халыкларыбызны интернационализм рухында тәрбияләүдә тоткан урынына басым ясау — куелган төп максат менә шул.

Шулар белән бергә, мине татар әдәбиятында һәм сәнгатендә Ленин образы дигән яңа бер тема бик кызыксындыра. Өлкән язучыларның һәм хәзерге иптәшләрнең әсәрләреннән шул темага караган өзекләр, бөек җитәкчене үзен күреп белгән кешеләрнең (Г. Ибраһимов, С. Сәетгалиев, Б. Мансуров, В. Бахметьев һ. б.) истәлекләрен, халык җырларын, татар композиторлары әсәрләрен, Татарстан художникларының картиналарын да кертеп, бер әдәби җыентык әзерләдем. «Безнең Ильич» дип исемләнгән бу җыентыкның татарчасы 1966 елда, ә рус телендәгесе юлбашчының тууына 100 ел тулу көненә басылып чыгар дип өметләнәм.

1966 елда «Казан утлары» журналына бер-ике мәкалә бирермен дип ышанам. Шулардан, беренче чиратта, мәгърифәтче Хөсәен Фәезхановның үлүенә 100 ел тулу уңае белән, кечерәк мәкалә һәм аның казакъ мәгърифәтчесе Чокан Вәлихановка һәм күренекле тарихчыбыз Шиһап Мәрҗәнигә язган хатларын, Тукайның 80 еллыгы уңае белән, «Тукай иҗатында ода жанры һәм татар совет әдәбиятында аның традициясе» дигән темага мәкалә бирергә планлаштырам.

## *Ибраһим Нуруллин:*

●

Такташка ерак киләчәк булып күренгән «илле еллык»ның без бусага төбендә. Табигый, тормышны, эшне, иҗат планнарын шушы дулкынландыргыч зур датага бәйләп карыйсы килә.

Нинди хезмәтем белән каршы алырга уйлыйм соң Октябрьның илле еллыгын? Хәзер мин татар әдәбиятында критик реализмның яралуы, үсеп-ныгып китүе турындагы монография өстендә эшлим. Моны мин тарихка чуму, заман таләпләреннән читкә ки-



ту димәс идем. Үткәнен тикшерүдән башка, әдәбиятның бүгенге хәлен аңлау, киләчәк юлын күз алдына китерү мөмкин түгел. Олы бәйрәмгә бу хезмәт китап булып чыгармы, белмим, әмма ул нәшрият кухнясына барып керер дип өметләнәм.

1964—65 еллардан зарлану гөнаһ булыр иде. «Образлар дөньясында» исеме астында әдәби-тәнкыйть мәкаләләре җыентыгым, «Тукай иҗаты» дигән китабым чыкты. «Тукай Петербургта» исемле пьеса һәм «XX йөз башы татар әдәбияты» дип атала торган зур китабым яңа елга кадәр дөнья күрер дип ышанам.

Иҗат планнары? Безнең эштә план бик үзгәрүчән бит ул. Шулай да чама белән әйтергә мөмкин. Төп эш, әлбәттә, югарыда телгә алынган монография. Моннан тыш журналга мәкаләләр белән катнашырга уйлыйм. Әдәби иҗатка да кул кычыткалап тора. Тукай турында хикәяләр циклы язган идем. Кайберләре белән укучылар таныш инде. Вакыт мөмкинлек биргән дәрәҗәдә шул эшне дәвам иттерергә исәп бар. Сер итеп кенә әйткәндә, Тукай турында зуррак «тоташ» әсәр язу хыялы да юк түгел. Анысы әле киләчәк эше.

*Нил Юзиев:*

●

1. Уралда үткәрелгән бер әдәби кичә ничектер күңелгә тирән эз калдырып, уелып калган. Казан дәүләт университеты студентларыннан оештырылган фольклор экспедициясе вакытында без әдәби кичәләрне аз оештырмыйбыз. Ләкин Муса Җәлил колхозында булып узганы (Пермь өлкәсе, Кунгур районы) аеруча истәлек-

күлмәк кигән киң аркасына читән аша гына карап кала иде. Егет бер көн эчендә Юлкотлының бөтен тирә-ягын йөреп чыкты, машинасына ыбыр-чыбыр балаларны төяп, әллә кайлардан үзләрен йөртеп кайтарды, аннары колхоз келәтендә аунап яткан ике потлы гер ташын табып кайтты да иртә-кич гел шуны күтәрепчөеп уйный башлады.

Кечкенә авылда егеткә аралашыр өчен үз тиңнәре бөтенләй юк диярлек иде,— кызлар җәйләүдә яталар, егетләре каядыр таралышып беткәннәр,— һәм Акъәбинең монда бик эче поша иде. Оныгының күңелен табар өчен ул әледән-әле аңа башкортча нидер әйткән була, ләкин Геннадий берни аңламыйча «бабушкасына» бик юмарт елмаеп карый, җавапсыз калмас өчен генә:

— А, да-да, точно! — дип, баш кагып куя иде.

Әби белән оныг арасында бер кызык хәл дә булып алды. Шулай иртәнге чәй янында оныгын сары майда гына йөзгән эче коймак белән сыйлаган чакта Акъәби «безнең башкорт халкы...» дип нидер сөйли башлаган иде, Геннадий шуны үзенчә аңлап булса кирәк, көтмәгәндә генә баш бармагы белән күкрәгенә төртеп:

— Я — башкир, бабушка, башкир! — диде һәм житмәсә әле «борчылма!» дигәндәй әбисенә күз дә кысып куйды.

Акъәби уйчан гына аңа карап торды, үз алдына гына күрсенгәндәй итте, аннары моңсу-назлы итеп кенә елмайды: нишлисең, бу җирән чәчле егеттә аның каны, башкорт каны, ага иде шул!

Менә шулай Акъәби — ялгыз башы — шушы көнгә кадәр уллары, кызларын көтеп, оныкларын сагынып, алар турында үзенең күңелле һәм күңелсез уйларын эченнән генә уйлап, исән-имин генә яшәп килде. Җәйгә чыгу белән аның һәрвакыт өметләре уяна торган иде, бәйрәм көннәрен көткәндәй рухланып, шуңа бер дә иренмичә тырышып әзерләнә башлый иде. Әмма быел, ходайдан вакыты житкәнме, җәйгә аяк басу белән үзен начар сизә башлады һәм бирешмәскә тырышып йөрде-йөрде дә ахыр чиктә менә урынга ук ятарга мәҗбүр булды.

Башта торып китәрмен дигән өмет белән ятты, күршеләренең калага улларына хәбәр итик дигән сүзләрен дә кире какты, әмма ләкин хәле аның отыры начарлана барды. Биш-алты көн эчендә ул

күзгә күренерлек булып суырылды, саргайды, ашаудан калды. Күршеләре карчыкның болай начарлана баруын күреп, хәвефкә төштеләр, нишлик икән дип үзара киңәшеп тә алдылар, ахырда Юлкотлыдагы колхоз бригадиры Сәетгалигә хәбәр итәргә булдылар.

Колхоз идарәсе моннан алты чакрымдагы Сыртлан авылында иде, шунлыктан Сәетгали кечкенә Юлкотлыда бердәнбер хуҗа һәм баш кеше. Һәр көнне иртән иртүк ул мотоциклының сиртмәле биленә атланып, такыр юлдан пырылдап, тирбәлә-тирбәлә Сыртланга китеп бара, ә кич белән тагын шулай җен кебек машинасында тумырылып кайтып җитә иде. Гарифә барып әйткәч тә Сәетгали икенче көнне үк, Сыртланга узышлый, үзенең мотоциклында пырылдап, Акъэбинең капкасы төбенә килеп туктады. Акъэби шунда ук кем килгәнен белеп алды һәм ни өчен икән бу дип борчылып уйлап куйды. Ул арада ишектән иелә биреп, тузанлы күн итекләрдән, бригадирлар белән председательләр өстендә генә очрый торган, капчыкланып беткән зәңгәр пинҗәктән Сәетгали үзе дә килеп керде.

— Саумы, Акъэби? — диде ул, таза кешегә дәшкәндәй юри кычкыра биреп.— Бәй, ни булды, әллә авырып калдыңмы?

— Авырыйм шул, Сәетгали,— диде карчык, гаепле кешесыман итеп.

— Куй, юкны сөйләмә, гомер дә авырмаганны... Синең кебек корткага килешәмени ул!

Сәетгали килеп, сәке кырына гына утырды, карчык юрганын үзенә таба җыя төште.

— Килешми дә бит, нишлисең, ходайдан вакыт җиткәч...

— Җиткән ди сиңа... Болай гына, салкын-фәлән генәдер әле... Кай җирең авырта соң?

— Авырткан җирем дә юк кебек... Тыным кысыла, сулавы авыр...— диде Акъэби, бугазын һәм күкрәген сыйпап.

Сәетгали карчыкның суырылган, саргайган йөзенә беравык сынап карап торды.

— Йә, нишлибез, Акъэби, доктор чакыртыйкмы?

— Кирәкмәс, Сәетгали улым, иншалла болай да үтәр әле...

— Үтә күрсен! — диде Сәетгали, карчыкка тагын да сынабрак карап; юк, шулай да карчыкның хәле бер дә шәпкә охшамый, йөзе лимон кебек сары, күзлә-



ле булды. Шагыйрь Шәүкәт Галиев (ул соңгы елларда безнең экспедициянең даими члены булып китте), мин һәм бер төркем студентлар билгеләнгән вакытка Кәнәбик авылына килеп җиткәч, халыкның күплегеннән сөендек тә, бернадәр аптырабрак та калдык. Клуб шыгрым тулы булып чыкты, урамга күп санлы машиналар тезелгән, ә алар янында тагын бернечә клубка сыярлык бәйрәмчә киенгән халык төркеме. Җыйнаулашып уйлый торгач, колхоз председателе бер оригиналь фикер әйтеп ташлады:

— Әллә сабан туй мәйданында үткәрикме? Күрше авылларны да кире борып җибәрү килешмәс бит, агайэне. Берсенең дә Казан хәтле Казаннан килгән кунакларны күрмичә, сүзләрен ишетмичә кайтып китәсе килмәс.

Сабан туй мәйданы әдәби кичә өчен, чыннан да, бик кулай булып чыкты. Төнге күктә — поэзиянең аерылмас юлдашлары ай, йолдызлар. Якында гына биек таулар тезмәсе күтәрелгән, тау аслап безнең яннан гына елга агып ята. Ә алда — халык, халык. Әйтерсең лә, сабан туй. Күрше авыллардан килгән машиналар да эшкә ярап куйды. Икесен бергә янәшә куеп, бортларын төшереп, «сәхнә» ясадылар. Өч машина өч яктан фаралары белән «сәхнә»не яктыртып җибәрде. Көрәшчеләр көч сынаша торган мәйданга бу юлы шигырь чыкты. Шигырьне дә, көрәшне карагандай ук, кызыксыну һәм ярату белән тыңладылар.

Башка авылларда мондый ук шигъри тамашага тап булмасак та, без һәр авылда халыкның әдәбиятка шундый тирән омтылышы белән очраштык. Ерактагы Урал авылларында да бүгенге язучыларның әсәрләрен яратып тыңлыйлар, артистларны,язучыларны сагынып көтәләр. Әмма бу көтүләр

еш кына нәтиҗәсез булып чыга. Артистлар онытканда бер генә килеп чыгалар, язучыларның да без йөргән Пермь һәм Курган як авылларында моңача булганнары юк иде. Бездә соңгы вакытларда районнарда әдәби атналыклар үткәрү йолага кереп китте. Менә шундый әдәби атналыкларның берничәсен Урал өлкәләрендә дә үткәреп аласы иде. Дөрес, язучылар шәһәр-авылларда никадәр еш булмасыннар, алар барыбер барлык укучылары белән очрашып бетерә алмаячаклар. Шушы уңай белән минем тагын бер тәкъдим кертәсем килә: җырчы артистларның җырларын, композиторларның симфоник, инструменталь музыкаларын грампластинкаларга язып алган кебек, аерым язучыларның тавышларын грампластинкаларга язып таратырга иде. Әйтик, Г. Бәширов, Н Исәнбәт, И. Гази яки Г. Әпсәләмовның үз әсәрләренең язылу тарихы турында сөйләве, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Р. Төхфәтуллиннарның үз хикәяләрен укуы, Х. Туфан, С. Хәким, Ш. Маннур, Ә. Давыдов, Н. Дәүли һ. б. шагыйрьләрнең үз шигырьләрен башкаруы укучы өчен нинди кызыклы һәм мавыктыргыч күренеш булыр иде.

Граммафон пластинкаларына язу күптән үйлап чыгарылуга карамастан, безнең оятыбызга каршы, Г. Тукайның да, С. Рәмиев, Ф. Әмирханнарның да, һ. Такташ, Г. Ибраһимовларның да, хәтта алай гынамы әле, М. Җәлил, Г. Кутуй, Ф. Кәрим кебек XX гасыр урталарына хәтле диярлек яшәгән атаклы әдипләребезнең дә тавышларын язып кала алмаганбыз. Бу өлкәдәге ваемсызлыкка 1966 елда, ниһаять, чик куелсын иде. Ерак тайгада яки чирәм җирләрендә яшәгән, котыпта яки экваторда йөзгән әдәбият сөючеләр Горький, Маяковский, Куприн тавышларын ишетү белән бергә, бүгенге татар әдипләрен дә тыңлау бәхетенә ирешсеннәр иде.

2. Үткән еллардагы кызыклы эшләрнең берсе — ул архивларда «казыну» булды. Эзләнә торгач, үзең өчен дә, әдәбият тарихы өчен дә әһәмиятле документларга очрап куясың. Алар тәге яки бу язучыны яңа яктан ачып җибәрәләр. Мәсәлән, Мәхмүт Галәүнең үз кулы белән язган автобиографиясен мин әнә шундый кызыклы һәм әһәмиятле документларның берсе дип саныйм. Бу автобиографик язма М. Галәү тормышының һәм иҗатының моңача аз билгеле якларын ачыклый, язучының татар иҗтимагый фикер үсешендәге һәм әдәби процесстагы ролен тагы да югары күтәрә. М. Галәү үзенең 1905 — 1907 елларда социаль-демократлар партиясендә член булып торуы, Астрахань большевикларының яшерен түгәрәгендә эш алып баруы, революцион «Туп» журналы чыгаруда актив катнашуы, исемсез брошюра-

ре тоныкланып тора.— Әллә, мин әйтәм,— диде бригадир сак кына,— калага хәбәр итикме? Суфиян агай, йә булмаса, Гөлбикә апай килеп китсә, зарар итмәс... сөйләшерсез...

— Юк, кирәкмәс, сабыр итик әле, алар да эшле кешеләр,— диде карчык, эченнән генә үзенекен уйлап.

— Анысын куй,— диде Сәетгали, урыныннан торып,— бер әсәйләре өчен вакыт табарлар әле. Ярый, идарәгә баргач, мин Гыйльман агай белән сөйләшермен. Берәр чарасын күрербез. Ә син, кортка, тыныч кына ят. Терел.

— Иншалла... Рәхмәт керүеңә, Сәетгали улым.

Сәетгалигә ияреп, Гарифә дә өйалдына чыкты. Алар анда пышын-пышын гына нидер сөйләшеп тә алдылар. Аннары мотоциклның каты гына пытыр-пытыр итеп кузгалып китүе ишетелде, һәм озак та үтми аның тавышы ераклашып, ниһаять, бөтенләйгә тынды.

Ә берничә көннән соң Сыртлан ягыннан Юлкотлыга таба тузан уйнатып килгән өр-яңа яшел «Волга» машинасы күренде. Һәм озак та үтми, киң урамның күк үләнендә ярылып яткан кара эз калдырып, Акъәбинең капкасы төбенә килеп тә туктады. Машинадан җәйге габардин пальто, күк эшләпә кигән зур, таза гәүдәле бер ир белән ефәк плащ кигән, зәңгәр косынка бәйләгән озын буйлы ябык кына бер хатын чыктылар. Болар Акъәбинең кызы белән кияве иделәр.

Алар урам тәрәзәләре ябык караңгырак өйгә килеп кергәч һәм кызының «Әсәем!» дип дәшүен ишеткәч, йокылы-уяулы хәлдә яткан Акъәби сискәнеп күзләрен ачты, бер мәлгә өнемме, төшемме бу дигәндәй аптырап, каушап калды, аннары куанычыннан онытылып китеп, капыл гына урыныннан тормакчы булды.

— Кызым, Гөлбикә—диде ул, өзелеп.

Кызы шунда ук килеп, аның өстенә иелде, маңгаеннан үпте, һәм алар тотынышып икесе дә елап җибәрделәр. Мәһабәт кияве дә килеп, карчыкның кипкән ябык кулын зур, таза кулларына алды, иелә төшеп, күтәренке тавыш белән: «Нихәл, әби җаным, авырып киттеңмени? Ничева, ничева, берни дә булмас!» диде, һәм пальто чабуын кайтарып, аз гына читкәрәк, сәке кырыена утырды. Кызы да чажлап торган плащы белән әнисенең аяк очына чүкте. Алар икесе бер тавыштан карчыкка кузгалмаска

куштылар. Ләкин карчыкка кияве белән кызы алдында болай авырып ятуы гаҗәп уңайсыз иде, һич нигә карамыйча аның тизрәк торасы, кадерле кунаклары өчен әүвәлгечә бөтерелеп йөрисе килә иде, әмма тик, нишләсен, ятарга чарасыз мәҗбүр иде. Шулай да ул түшәк өстенә торып утырды һәм Гарифәгә урам тәрәзәсен чыгып ачарга, тизрәк самовар куярга кушты.

Тәрәзә капкачы ачылгач, өй эче яктырып китте. Акъәби шәһәрчә бик пөхтә киенгән кадерле кызы белән кадерле киявенең чиста, шома йөзләрен күрде. Күрде дә үз хәленнән тагын бер уңайсызланып, елыйсы килеп, авыр сулап куйды. Үз нәүбәтләрендә алар да бик ябыккан, тәмам кечерәеп калган әниләренең зәгыйфрандай саргайган, сулган йөзен күрделәр. Күрделәр дә, сүзләрен оныткандай, бер мәлгә тынып калдылар һәм яшерен генә карашып алдылар. Болай ук булыр дип көтмәгәннәр иде алар. Хәер, колхоздан калага шалтыраткач та алар карчыкның чынлап авырып китүен белеп, башта ук тәгаен бер ният белән юлга чыкканнар иде. Хәзер исә ике төрле сүз булырга мөмкин дә түгел. Эшләре тыгыз, вакытлары юк, шуңа күрә сүзне озынга сузмыйча карчыкка шул ниятләрен әйтергә булдылар.

— Әсәем,— диде кызы, әнисенә үрелеп.— Без сине үзебез белән алып китәргә дип килдек. Калада докторларга күрсәтербез, әйбәтләп карарбыз, анда тизрәк терелерсең.

Кияве дә шунда ук өстәде:

— Дөрес, әби, бездә сиңа әйбәтрәк булыр, монда доктор да юк, караучы да юк, ялгызың нишләрсең!

Карчык тиз генә җавап кайтара алмады, аның кинәт күңеле тулды, шул ук вакытта нигәдер бик борчылып та куйды.

— Рәхмәт инде, балалар! — диде ул, бераздан әкрен генә.— Юкка мәшәкатьләнгәнсез, үз өемдә дә терелер идем әле, ходай насыйп итсә.

— Юк, әсәем, сине монда хәзер калдырып китеп булмый,— диде кызы, кабаланып.— Алып китәбез. Яхшылап дәваларга кирәк сине...

— Өй ялгыз кала бит.

— Калсын, берни дә булмас, күршеләрең карый торырлар.

Карчык бүтән бер сүз дә әйтмәде, сулап кына куйды, монда доктор каравыннан башка, мәтрүшкә-фәлән эчкәләп

ларның авторы булуы турында, охранка тарафыннан эзәрлекләнүе турында яза. М. Галәү «Кармак» журналында эшләгәндә дингә каршы язган бер мәкаләсе өчен 1916 елны Оренбург округ суды тарафыннан бер елга иркеннән мәхрүм ителүгә дә хөкем ителә. Болар барысы да М. Галәү иҗатын ныклабрак тикшерүне һәм яңачарак бәяләүне сорый торган яңа фактлар. Шушы уңайдан М. Галәүнең иҗат мирасына салкынча карашның 20 — 30 елларда гына түгел, әлегәчә яшәп килүен әйтәсе килә. М. Галәү әдәби мирасы комиссиясенең ул вакыттагы исән членнары Ә. Фәйзи, М. Максудлар әдипнең татарча өч томлыгын бастыру турында әллә кайчан ук инде эш кузгатканнар иде. Ләкин бу эш башланган килеш торып калды. Вакытында М. Галәү романнары А. М. Горький ярдәмендә рус телендә дөнья күргәннәр иде. «Канлы тамгалар»кебек атаклы романы татарча әлегәчә басылганы юк. Татар иҗтимагый-политик фикер хәрәкәте тарихында, әдәбият мәйданында тирән эз калдырган бу язучының исемен Октябрьның 50 еллыгына багышлап чыгарылган әсәрләр арасында очратасы килә. Бу бәйрәмне әзерләүдә терееләр генә түгел, үзләренең олы эшләре белән үлгәннәр дә катнаштылар түгелме соң?!

Әхмәт Фәйзинең сеңелесе Зәйнәп апа белән бергә миңа Әхмәт Фәйзи әсәрләренең өченче томын әзерләүдә катнашырга туры килде. Бу соңгы томга язучының драматик әсәрләре һәм публицистикасы урнаштырылырга тиеш иде. Томга материаллар туплау барышында миңа Ә. Фәйзи драматург буларак бөтенләй яңадан һәм яңа яктан ачылып китте. Без Ә. Фәйзине басылган берничә пьесасы буенча гына беләбез икән. Ә аның 30, 40, 50 елларда язылган драма әсәрләренең күпчелеге беркайда да басылмаган булып чыкты. Аларның байтагы бүгенге репертуарда да урын алырлык чын сәнгать әсәрләре. Либреттолары турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Менә, мәсәлән, «Зөлхәбирә» либреттосы. Ул гаҗәп матур шигъри тел белән, драма һәм музыка законнарын тирән тоеп, халык иҗаты әсәрләреннән файдаланып язылган. Шагыйрь либретто өстендә озак вакытлар эшләгән,кат-кат тәзәткән. Опера сәхнәсе һәм композитор өчен бу зур табыш саналырлык әсәр. Сораша торгач, аңа 40 елларда ук Мансур Мозаффаров тарафыннан музыка язылганлыгы мәгълүм булды. Миңа композитор өендә булып, либреттога сылтау ителеп, чирек гасыр үле капитал булып яткан шушы операның бер шкаф тулы клавирларын да күрергә туры килде. Нинди байлык нича еллар буе әрәм ята! Операның либреттосы үзенең идея эчтәлеге,

сәнгатьчә камиллеге ягыннан һич тә шик уятмый. Әгәр музыка да шул югарылыкта язылса, бу әсәр безнең опера сәнгатен бизәүче әсәрләрнең берсенә әверелер иде. Композиторлар союзы һәм М. Җәлил исемендәге татар опера һәм балет театры татар хатын-кызларының Октябрьга кадәрге фаҗигале язмышлары турында сөйләүче бу операга кабат әйләнеп кайтып, аны сәхнәдә җанландыру турында тиешле чаралар күрергә тиешләр дип уйлыйм.

Укучыга билгесез мондый әсәрләр Ә. Фәйзи архивында гаять күп. Җыя һәм сайлый торгач Ә. Фәйзинең драма әсәрләре үзләре генә өч томлык күләм алды. Сайлый торгач аны ике томлык күләмдә нәшриятка тапшырдык. Рецензент та аларны тулы килеш чыгару фикерен куәтләде. Ләкин... хәзер ул драма әсәрләренең байтагы кабат архивта торып калды. Шулай ук бай публицистикасы да бу өч томга сыймады. Теләк итеп әйтәсе килә: киләчәктә нәшрият Ә. Фәйзинең бу өч томга керми калган әйберләрен дә укучыга җиткерү турында уйласын, чараларын күрсен иде.

## *Газиз Мөхәммәтшин:*

●



Узган елны мин РСФСР язучыларының II съездында катнаштым. Андагы сөйләшүләр миндә күп кенә уйлар тудырды. Үзебез иҗат иткән әсәрләргә никадәр җаваплы карарга кирәклеген һәм халкыбыз алдындагы бурычларыбызның никадәр олы икәнлеген тагын бер тапкыр исемә төшерде.

Мин шул съездан кайткач ике җыентык төзедем. Аларның беренчесе — «Кояш кызы». Бу җыентыкка унбиш яңа хикәя керде. Икенчесе балалар өчен. Исеме — «Бурзайлар команда-

кенә терелеп китмәсен үзе дә аңлый иде булса кирәк. Аннары япа-ялгыз яту да аны шомландыра иде. Ә тегендә, калада, бөтен балалары диярлек, ходайдан вакыт җитеп, алай-болай булып китсә, алар аның янында булачаклар. Әмма шул ук вакытта нәкъ менә шушы «алай-болай булып», ягъни үлеп китүен уйлап, ул үзенең гомер иткән почмагыннан чыгып китәргә дә теләми иде. Чит җирдә үлү, чит җир туфрагында ятып калу аны һәрвакытта куркыта иде. Юк, аның шушында, карты җан биргән кечкенә өендә үләсе, авылдашлары кулы белән кечкенә авыл зиратына — карты һәм яшьли үлгән сабыйлары янына куеласы килә иде. Ләкин ничек итеп менә хәзер ул алырга дип килгән кызы белән киявенең ихтыярына каршы тора алсын? Чыкмаган җанда өмет бар дигәндәй, бәлки, алып китеп, чынлап та терелтеп, аякка бастырып кайтарырлар,— шуның өчен килгәннәр бит... Юк, авыр иде карчыкка бу төенне чишү, бик авыр иде!

Чәй урынын карчык янына, сәке өстенә әзерләделәр. Карчык, яткан җиреннән генә, Гарифәгә кушып, үзенең сыйларын — баздан сөтен, маен, чоланнан кәрәзле балын, каклаган казылыгын табынга китертте. Ярлырак та бит, нишлисең, таза чагы булса үзе тиз генә берәр кайнар аш та өлгертер иде, ә болай кешегә кушып кына буламыни ул. Аннары кызы белән кияве дә: «Борчылма, әсәй, бик әйбәт, бик җиткән»,— дип кенә торалар. Ашыгалар, күрәсең. Алып китәргә дип килгәч, алар үзләре дә бу юлы күчтәнәчләр төяп кайтмаганнар иде. Шулай да кызы берничә лимон белән бер кап шоколад конфетлар китергән икән, шуны табынга чыгарып куйды. Лимон авыру карчыкның нәфесе бик теләп торган нәрсәсе иде, ул аңа бик сөенде, хәтта кулына алып иснәп-иснәп тә карады.

Табын әйләнәсенә утырыштылар. Гарифә чәй ясый башлады. Карчыкка берьюлы рәхәт тә, күңелле дә булып китте. Менә, ходаның рәхмәте, көтмәгәндә генә ул иң кадерле якыннары белән бер табында утыра бит әле. Аның өчен елына бер генә килә торган бәхет бит бу, гел шуны көтеп яши иде бит ул, тик менә, кызганычка каршы, урын өстендә каршы алырга туры килде үзләрен. Шуңадыр ахры, бу минутта аңа никадәр генә рәхәт булмасын, нечкәргән күңеле нидер сизенгәндәй ирексездән ямансулап та, шомла-

ныл та куйгалый иде. Хәерлегә була күрсен инде...

Чәй янында сүз дә гел китү белән бәйләнгән эшләр турында барды. Карчыкка авыр иде бу сөйләшү, китүенә бер дә ышанасы килми иде шикелле, шуңа күрә күбрәк кызы бу турыда кайгыртып утырды. Аның соравы буенча Гарифә карчыкның кәҗәсе белән тавыкларын карап торырга булды. Келәтнең үз йозагы бар икән, өйне бикләргә дә бер иске богау йозагы бар икән әле, Гарифәгә шуның белән өйне бикләп, ачкычын үзендә сакларга куштылар. Боларны тыңлап утырганда карчыкның рухы акрынлап һаман сүнә барды. Ахырда түзмәде, өзелергә торган тавыш белән еламсырап әйтте:

— Ходаем, гомер иткән өемә йозак салып китәрмен дип уйлаган идеммени мин...

— Әсәем, бу ниткән сүз? — диде кызы, гаҗәпләнгән булып.— Бөтенләйгә ташлап китмисең бит, менә тиздән терелеп, үзең дә кайтып җитәрсең.

Карчык, «юат инде, кызым, юат!» дигәндәй, үз алдына моңсу-зәгыйфь кенә көлемсерәп куйды, әмма кайтарып бүтән бер сүз дә әйтмәде.

Чәйдән соң юлга да әзерләнә башладылар. Кияү кеше ашыга иде, аңа ниндидер бер кечке жыелышка кайтып җитәргә кирәк икән. Ул машинасы янына чыгып китте. Тузан кунган яшел «Волга»-ны бала-чага сырып алган иде. Аягына чак тәпи басканы да ава-түнә килеп җиткән. Зурраклары машинаның бөтен ялтыткән нәрсәләрен тотып-сыйпап, әйләнеп йөриләр, тик түбәсенә генә менеп китмиләр. Зур, таза абзый чыккач, алар башта чыпчыклардай куркып читкә сибелделәр, ләкин тиз үк яңадан машина тирәсенә җыела башладылар. Аларның тынгысыз елтыр күзләре бу шәп агайга, машинасында бер йөртеп килмәсме дигән яшерен өмет белән, гел чекрәеп карап кына торалар. Хәтта бер кап-кара башлы малай әрсезләнеп һәм юмаланып сорап та куйды:

— Агай, әгаем, безне анавы очтан гына бер йөртеп килсәң ине!

Мәһабәт агай башын кагып, телен шартлаткан булды:

— Юк шул, малайлар, булмый хәзергә, ашыгабыз. Менә Акъәбиегезне

сы». Китапларның икесе дә быел Татарстан китап нәшриятында басылып чыгачак.

«Казан утлары» журналына быел «Кояш кызы» дигән зур хикәямне һәм «Изге Галиәкбәр» исемле юмористик хикәямне бирәчәкмен.

Бөек Октябрь Социалистик революциясенең 50 еллыгына багышлап нинди әсәр язармын — әлегә билгесез. Чөнки башта берничә тема йөри, хәзергә кайсына да тукталa алганым юк. Ә язасы килә һәм язарга кирәк.

*Эдуард Касыймов:*

●



Сөекле халкыбыз һәм аның эчендә җанлы бер валчык булган мин дә җиңел сулап куйдык: иҗади хезмәт юлына аңсыздан куелган кирталәрне үткән ел партия җимереп ташлады. Кешеләрнең күз карашында ышану һәм өмет чаткылары артты, алар җиргә хуҗаларча нык басып йөри башладылар һәм шул куанычка кушылып мин дә... Шөбһәсез, партиянең бу карарлары кырыс тарих битләренә иң күркәм хәтирәләрнең берсе булып керер.

Бу ел көннәрем республика нефтьчеләренең тиңдәшсез тырыш хезмәтен чагылдыруга багышланган повесть язу белән үтәр дип уйлыйм.

Журналга ике-өч хикәя, очерк һәм тирән нефть ятмаларына юл салучы бораулаучылар, геологлар турында язылган пьесамны (җәйге айларда) тәкъдим итәргә исәплим. Өлгерсәм, ел азагында повестьны да тапшырырга ният юк түгел.

Бөек азатлык революциясенең һәм Республикабызның 50 еллыгын зуррак күләмле проза әсәре һәм тугандаш халыклар дуслыгын сурәтләгән хикәяләр циклы белән каршылау теләген хыялымда һәм күңелем түрендә тотам.

китерә килгәч, мин сезне рәхәтләнеп бер йөртеп кайтарырмын, ярыймы!

Малайлар Акъәби дигәнне ишеткәч шунда ук тындылар, артык бәйләнеп тормадылар. Кайчагында алар мәсьәләнең җитдилеген зурларга караганда да тизрәк аңлый беләләр иде.

Шул арада читтәге капка төпләрендә җыелышып торган корткалар, хатын-кызлар да акрынлап килә башладылар. Акъәбине алып китәләр дигән хәбәр кечкенә авылга бик тиз таралып өлгерсә дә, хатын-кызлар әбинең каладан кайткан кадерле кунакларына ашап-эчкәндә комачауламас өчен шулай әдәп саклап, көтебрәк торганнар иде. Хәзер инде менә килделәр, олыраклары өйгә үк кереп киттеләр. Акъәби аларга бик якын кеше, гел бергә яшәгәннәр, аңа бик ияләшкәннәр, шуңа күрә аны ерак юлга, билгесез сәфәргә озату алар өчен шактый зур вакыйга иде. Үзләре дә аларның җитди-уйчан иде, нидер сизенәләр иде ахрысы, һәркайсында корткабызны яңадан инде күрә алмабыз дигән уй ята иде шикелле... Гаҗәп бит ул,— кеше берәүнең дә үлүен теләми, әмма шул ук вакытта ничектер ихтыярсыздан шул үлемнең буласын сизеп, көтеп тә тора кебек.

Бераздан кара бишмәтен, оек-калушын кигән, чәчәкле зур шәлен ябынган Акъәбине кызы белән Гарифә ике ягыннан култыклап, акрын гына өйдән алып чыктылар. Алар артыннан бер хатын зур мендәр күтәреп чыкты.

Кияү машина ишеген ачты. Карчыкны ипләп кенә утырттылар, мендәрен таяныр өчен янтыгына салдылар. Кызы янәшәсенә кереп утырды. Машина тәрәзәсенә хатын-кыз башлары иелде.

— Акъәби, җаным, хуш-сау бул инде!

— Акъәби, бәгъерем, терелеп кайта күр!

— Хуш, безне онытма, без көтәбез сине! — диделәр аңа.

Ә таякка таянган бер кортка:

— Хуш, яшьтәш, бәхил бул, ахирәттә күрешергә насыйп итсен! — диде, бик тыныч, әмма чын күңелдән бик ихлас итеп.

Гөлбикә иренә тизрәк кузгалырга кушты. Машина — алдында торучыларга кыска гына бер гудок бирде дә шома гына кузгалып китте.

Аз гына китүгә, Акъәби кинәт урыныннан кузгалып:

— Һай, кәфенлегемне онытканмын лабаса! — диде, нишләргә белмәгәндәй бик борчылып.

Кызы бу көтелмәгән сүздән сискәнеп киткәндәй булды һәм чыраен сытып:

— Куйсана, әсәй! — диде, үпкә катыш рәнҗү белән.— Таптың искә төшерер нәрсә!

Карчык дәшмәде, күзләрен йомып, хәлсезләнеп башын гына иде.

Яшел машина, йомшак кына тирбәлеп һәм тузан уйнатып, Юлкотлыдан зур калага таба чыгып китте. Кечкенә өйнең капкасы төбендә җыелышып калган хатын-кызлар бөтерелеп тузан сузылган юл буена, машина күздән югалганчы, тик кенә карап тордылар.

## II

Менә Акъәби ялгызы кечкенә бер бүлмәдә, сиртмәле тар караватта, ак түшәмгә карап һәм каяндыр түбәннән тонык кына иштелгән зур кала гөрелтесенә колак салып, тыныч кына ята. Урыны йомшак, астында чип-чиста ак җәймә, өстендә сатин юрган — арык-җиңел гәүдәсенә аның иркен, рәхәт. Рәхмәт инде киявенә дә, кызына да,— аны менә шулай кадерләп, аерым бүлмәгә урнаштырдылар. Дөрес, ул аларны бер дә тыгызлыйсы килмәгән иде килүен, ләкин кияве белән кызы бу хакта авыз да ачырмадылар. Хәтта элек бу бүлмәдә торган асрау кызларын

да кухняга чыгардылар. Тик бераздан гына сизде карчык: монда авыру кешенең яткан җире генә түгел, ашаган-эчкән савыт-сабасы да аерым булырга тиеш икән.

Гомумән карчыкка башта игътибар бик зур булды. Беренче көнне ук шәһәрнең икенче читеннән отставкадагы полковник улы белән марҗа килене дә аны күрергә килеп җиттеләр. Чүкечтәй нык, базык гәүдәле, зур йомры башлы, кыска имән муенлы полковник Суфиян, әйтергә кирәк, кәкре аякларындагы тар кунычлы хром итекләре белән генә түгел, бөтен кыланыш-гадәтләре белән дә чын «янарал» булырлык, беткәнче хәрби бер кеше иде. Кычкырып, кырт кисеп сөйләшә ул, берәүдән дә тарсынмыйча киерелеп, шаркылдап көлә һәм, иң мөһиме, үзен бик хаклы рәвештә дөньяның хуҗасы санап, бернигә исе китмичә рәхәтләнеп яши иде. Квартир менә дигән, машина бар, пенсия җитәрлек, шуның өстенә аучылар җәмгыятендә нидер эшләп тә шактый төшергәли, кыскасы, әле чак иллесен тутырган полковникның тормышы бал да май, ал да гөл иде.

Әнисе карчык янына күрешә килгәч тә ул карлыккан тавыш белән бүлмәне яңгыратырга тотынды:

— Һай, әсәй, әсәй, әсәем! — диде, әнисенең кипкән кулын каты учларына алып.— Ни булды сиңа, авырып киттеңмени, ике күзем?.. Ну, ничево, түлке син паникага бирелмә. Безнең генерал әйтә торган иде: солдатны пуля түгел, паника үтерә дип...

— Нәрсә соң ул... пәникә дигәнең, улым?

— Улмы, ул ни... курку, әсәем!

— Мин бер дә курыкмыйм, улым,— диде карчык, тыныч кына.— Тәкъдирдән узмыш юк, барысы да алла кулында.

— Һи, әйттең тагын! Барысы да безнең кулда! — диде полковник, һаман шаулап.— Менә мин сиңа докторның иң шәбен үзем алып килермен, әсәй!..

— Рәхмәт, улым, рәхмәт!

Карчыкның килене — өч башкорт бичәсенә торырлык юан, мәһабәт, ап-ак Мария Васильевна — кайнанасы белән ике куллап, бик җитди итеп күреште. Карават кырыена урындык алып утырды да, авыруның хәленә керергә теләгәндәй, аңа чын кызгану белән карап тора башлады. Юрган астында бала шикелле сизелер-сизелмәс кенә яткан бу кайнана дигән сап-сары йөзле карчыкка аның нидер әйтәсе дә, кайгыртып нидер сорыйсы да килде, ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, тел юк,— карчык бер кәлимә русча, ә килен бер авыз башкортча белми иде. Шулай да Мария Васильевна ире аркылы булса да берничә сорау бирде.

— Әсәй, килененң менә синнән: «Кай җирең авырта?» — дип сорый.

Карчык уйчан-моңсу гына әүвәл улына, аннары килененә карады.

— Тыным кысыла,— диде ул, күкрәген күрсәтеп.— Хәлем бер дә юк.

— Күптәнме?

— Тыным бетүен кыштан ук сизә башладым. Ә хәлсезләнүем күптән түгел...

Суфиян карчыкның сүзләрен русчага әйләндергәч, Мария Васильевна иреннәрен мәгънәле генә кысып, башын селкеп торды. Аннары ашыкмыйча гына нидер әйтте.

— Әсәй, килененң әйтә,— диде Суфиян,— опасный берни дә булмас, бронхлары ниткәндер, борчылмасын, ди.

Карчык дәшмәде, тик күзләре белән генә рәхмәтен белдереп, килененә бер тутырып карап алды.

Икенче көнне карчык янына күрешергә дип Суфиянның зур улы Геннадий да килде. Геннадий инде Юлкотлыга барып, әбисендә кунак булып кайткан егет, шуңа күрә ул карчык белән бик үз булып, «Ха, бабушка!» дип шатланып күреште һәм урындык алып, караваты янына

утырды. Акъәби сөенеп-яктырып, башкортча: «Улым, килдеңмени, рәхмәт төшкерем!» — диде, ә егет аның ни әйткәнен аңлагандай, елмаеп башын какты. Әйе, карчык бу дәү, сары егетне, үз нәселенә һич охшамаса да, чынлап ярата иде,— барыбер аның токымы ич, аның каны!.. Нишлисең, якын шул, бик якын!.. Тик егет үзе «бабушкасының» йөрәгендә аңа карата нинди тирән һәм газаплы мәхәббәт ятканын сизәме икән?.. Юк, сизәргә тиеш, әнә килгән бит әле ул, әнә елмаеп әбисенә нидер әйтә дә бит әле... Ах, бу тел юклыгы!.. Карчыкның тел өйрәнер вакыты күптән үткән шул инде, әмма ник бу Суфиян, юньсез, балаларына, ичмасам, әбиләренә дәшә алырлык кына үзебезчә берничә дистә сүз өйрәтмәде икән соң?!

Егет әдәп кушкан кадәр утырганнан соң кузгала башлады, торып, әбисенең кипкән ябык кулын сыйпады һәм «Пока, бабуся!» дип баш какты да чыгып китте. Карчык аңардан бик шат, риза булып калды.

Шул ук көнне тагын Суфиянның өч кызы — Татьяна, Светлана, Рита — белән кече малае Борис та әбиләре янына килделәр. Кызлары да суеп каплагандай әниләренә охшаганнар, әниләре кебек барысы да эре сөякле, җирән чәчле, зур соры күзлеләр... Тик Боря (Борис) кына атасына охшаган, атасы кебек зур башлы, зур битле, арыш чумарыдай кап-кара бер малай иде. Бусын инде бер дә икеләнмичә Суфиян малае Шәяхметов дип йөртергә була.

Кызлар әбиләрен сырып алдылар, шаулап: «Здравствуйте, дорогая бабушка!» дип күрештеләр, алып килгән чәчәкләрен караватъ янындагы тәрәзә төбенә утыртып куйдылар, урындыгына шоколад конфетларын салдылар һәм, инде ни әйтик дигәндәй, күзләрен елтыратып, әбиләренә карап тора башладылар. Шушы икән инде ул папаларына мама тиешле әби-карчык! Үзе кечкенә, үзе арык, өстенә киң җиңле әкәмәт кенә күлмәк кигән, башына вак кына чәчәкле сары яулык бәйләгән,— вообщем, типичная башкирка икән.

Ә Акъәби үз нәүбәтендә бу җитеп килгән таза, зифа кызларга уйга калып, исе китеп, селкенмичә карап ята. Аннары зәгыйфь кенә елмая, иреннәрен кыймылдатып куя — нидер әйтергә тели ахрысы... Менә ул күзләрен Боряга төби, әкрен генә кулы белән ымлап, аны якынрак килергә чакыра. Боря курыккандай башын сөзеп, каш астыннан гына карап, кузгалмыйча тора, тик апалары: «Иди, иди!» — дип аркасыннан этәргәч кенә әбисенә якынлаша. Карчык бердән яктырып, малайның аркасыннан сөеп: «Бәбкәчем,— ди,— зур егет бул, алла тәуфикъ бирсен үзеңә!» — ди... Малай берни аңламыйча кызарып, әбисеннән тизрәк китә, ә кызлар нидер әйтеп, шаулап көлешәләр... Карчык исә һич үпкәсез, әмма боек-сагышлы итеп, тирән генә бер сулап куя. Әйе, бу балалар, никадәр ят-сәер күренмәсеннәр, аның үзенеке шул, үзенеке!.. Улының кемгә өйләнүенә, ничек яшәвенә бәгъре күпме генә сызланмасын, әмма оныклары аңа бик якын, бик газиз шул!.. Минем байлыгым дип кенә йөртә ул аларны...

Бер-ике көннән соң кызы Гөлбикә доктор чакыртып китерде. Урта яшьләрдәге таза, мөлаем хатын-доктор Акъәби белән бик ачык сөйләште, күп сорашты, аннары күкрәген алдан да, аркасыннан да әйбәтләп тыңлады, тик ни өчендер карчыкның үзенә авыруы турында бер сүз дә әйтмәде. Кызы белән залга чыгып, шунда икәүдән-икәү генә сөйләштеләр.

Тагын берничә көн үтте, һәм менә шул ук хатын-доктор олы яшьтәге озын, чандыр, күзлекле бер ир кешене ияртеп китерде. Моны шәһәрнең бик атаклы профессоры дип әйтәләр. Үзе татар икән... Шул профессор карчыкны игътибар белән тыңлады, сорашты, вакыт-вакыт иреннәрен кысып, авыруга озак кына уйланып карап та торды, аннары яңадан сорашты, яңадан тыңлап карады. Карап беткәч, тураеп һәм сүзләрен үлчәп кенә: «Әби, үпкәгездә авыру бар, ләкин ул картлык бе-

лән бәйләнгән булырга тиеш, без биргән даруларны эчеп, тыныч кына ятыгыз!» — диде. Шуннан соң барысы да залга чыгып, үзара тагын нидер сөйләштеләр.

Акъәби күңеленә ни генә килсә дә сабырлыкка өйрәнгән гадәте буенча артык борчылмыйча, шомланмыйча тыныч кына ята бирде. Ләкин докторларны озатканнан соң янына кергән кызының бик җитдиләнеп киткән йөзенә карап, ул эшнең серен сизенгәндәй булды. Дөрес, кызы аңа берни әйтмәде, әмма бу киеренке хәрәкәтсез чырай, бу юри аңа карамаска тырышкан борчулы күзләр хәлнең ничек икәнлеген һәр төрле сүздән дә ачыграк әйтеп торалар иде кебек... Ә хәлләр чынлап та бик шомлы-куркыныч иде: докторлар карчыкның үпкәсендә яман шеш (рак) таптылар. Алар фикеренчә, җитмештән узган карчыкка операция ясап торудан мәгънә юк, иң яхшысы — үзенә әйтмичә юатып, тыныч кына яткыру да авыру газабын төрле дарулар белән җиңеләйтергә тырышу — бары менә шуны гына эшләргә мөмкин. Хәер, үзенә әйтмәсәләр дә, карчык бу авыруның әҗәленә тигән авыру булуын күптән инде сизеп тора иде. Күпме яшереп маташмасыннар, монда ул бары вакытлы мосафир гына...

Докторлар килеп киткәннән соң карчыкка игътибар һәм тәрбия тагы да көчәя төште. Кызы белән кияве генә түгел, улы белән килене дә башта әсәйләренә бик йомшак булдылар, гел кайгыртып кына тордылар. Кирәк даруларын да табып китерделәр, кәефе теләгән ризыкны да алдыннан өзмәделәр. Гүя алар көннәре санаулыга калган әсәебез алдында соңгы бурычыбызны үтик дип тырышалар иде. Һәм шушы хәл үзе генә дә инде карчыкка күп нәрсә турында сөйли иде кебек... Билгеле, ул балаларыннан бик риза, күңеленнән аларга рәхмәтен укып кына тора, әмма шулай да аларның бу соңгарак калган яхшылыклары вакыт-вакыт карчыкка аны фани дөньядан юатып озатыр өчен генә эшләнгән шикелле булып тоела, шуңа йөрәге сызланып куя һәм, чыкмаган җанда өмет бар дигәндәй, иң элек бер алласына сыенып, тыныч кына ята бирә иде.

Акъәби калага килеп урынга яту белән Казахстандагы кече улын һәм Пермь өлкәсендәге зур кызын чакырып язуны үтенә башлады. Аны менә язабыз, инде язабыз дип гел юатып тордылар, ләкин шулай да язарга ашыкмадылар. Бу шактый читен мәсьәлә иде. Карчыкның кече малае кайтып-китеп йөрмәслек үтә яшерен бер җирдә эшләгәнгә күрә, аны гомумән чакырып маташудан мәгънә юк иде. Ә зур кызы Пермь өлкәсенең эчкәре бер районында балалар врачы булып эшли, җәй көне эше аеруча тыгыз була, шуңа күрә аны да вакытлы-вакытсыз борчырга ярамый иде. Кыскасы, карчыкның хәле бер көерәк торган чакта чакыру белән ашыкмаска булдылар.

...Көннәр үтә, гүя алар зур каланың түбәндәге шау-шуы кебек тоныкына гүләп, читләтеп үтә. Колакка сеңгән бу шау-шуның башы-ахыры булмаган кебек, үтеп торган көннәрнең дә исәбе һәм билгесе юк. Ә рәхимсез авыру карчыкны астыртын гына кимерә, акрынлап кына ул эри-сыза...

Озакка сузылган өметсез авыруның бик күңелсез бер ягы бар: авыручы үзе дә, аны караучылар да акрынлап ялыга башлыйлар. Бигрәк тә соңгылар өчен бу бик читен хәл: алар үз-үзләренә икърар итәргә курыксалар да, ничектер ихтыярсыздан «ахырын» көтә башлыйлар. Акъәби моны әле сизми иде, элекке кебек игътибар да бар, карыйлар да үзен, әмма шулай да нәрсәдер, җан җылысымы, борчылып торумы, кимеде кебек. Һәрхәлдә кайгырту-карау гадәткә кергән мәҗбүри бер мәшәкать төсен алды шикелле. Аннары кызы да, кияве дә бик эшле кешеләр, һәркөнне үзләренең хезмәтләренә йөриләр, шулай булгач, аларның авыру әсәйләренә бөтен игътибарларын биреп бетерә алмаулары бик табигый иде.

Карчыкның берәүгә дә зары юк, ул барысын да аңлый, һәммәсеннән риза-канәгать, тик ул көне буе ялгыз ятудан бик туя һәм берәрсенең кайтып керүен зарыгып көтә. Кеше тансык, кеше кирәк аңа. Бигрәк тә кызының ике баласын — алты яшьлек Равиле белән дүрт яшьлек Гүзәлне бик сагына иде ул. Аларны балалар бакчасына йөртәләр — иртән илтеп куялар, кичкә табан алып кайталар. Алар кайткач, зур квартира тулып, җанланып киткәндәй була. Бүлмәдән-бүлмәгә йөриләр, таќы-токы нидер сөйләнәләр, һәм Акъәби ишектән күзен алмыйча аларны көтеп ята. Равиле — малай кеше — әбисе тирәсендә күп чуалырга яратмый, керсә дә тизрәк чыгып китү ягын карый, әмма Гүзәле, кыз бала булганга ахры, авыру әбисеннән бер дә ятсынмый, аңа гел сырпаланып кына тора. Бары шушы бала гына аңа бик матур, бик мөлаем итеп: «Әбекәем!» дип дәшә. Бичара карчыкның күзләре яшь белән тулып китә бу җанга якын, тансык, кадерле «әбекәем»не ишеткән чакта. Бик ярата, өзелеп ярата ул шушы төп-түгәрәк битле, кап-кара күзле йомшак, пакь, татлы оныгын! Үз йөрәгедәй якын ул аңа.

Хуҗаларга кунаклар да еш кына килгәлиләр иде. Өйдә, билгеле, ыгы-зыгы башлана. Гөлбикәнең кадак үкчәле туфлиләрдә шак-шок басып, ашыгып йөргәне ишетелә, тәлинкә, чәнечке-пычак, рюмкалар чыңлавы ишетелә, шуннан залдагы кунакларның шаулап сөйләшүләре, көлүләре ишетелә башлый. Карчык шуларның барысын да ничектер балаларча кызыксынып тыңлап ята.

Кызы Гөлбикә, вакыты тыгыз булса да, кергәләп, «Әсәй, хәлең ничек, бер-бер нәрсә кирәкмиме?» дип сорап чыга. Карчык күңеле булып:

— Рәхмәт, кызым! Кунакларыңны кара, кунакларыңны! — ди аңа.

Ә залда мәҗлес матур гына дәвам итә. Сөйләшеп-көлешеп аргач, берәрсе пианинода уйный башлый, аңа кушылып, кемдер җырлап та җибәрә. Ә кайчагында исә кунакларның тавышы бөтенләй тына, аның урынына ят бер хатын-кызның ашыгыбрак сөйләгән ясалмарак тавышы ишетелә. Бу инде телевизор дигән нәрсә булырга тиеш. Карчыкның аны әле күргәне юк, ләкин шундый әкәмәт бер әйбер барлыгын, өйдәгеләрнең аны бик көтеп, бик яратып карауларын ул инде белә. Вакыт-вакыт шул «тилевәзир» дигән нәрсәдән бик моңлы курай тавышы да, бик борынгы башкорт җыры да яңгырый... Шул чакта карчык ишекләрне ачарга куша һәм җанына тансык бу җыр-моңны тәмам эреп, хыялларга китеп тыңлый. Гүя ул ефәк кылганнар йөгерешкән даласына, авыр чулпыларын чыңлатып йөргән кыз чакларына кайткандай була.

Әмма кайвакытта бу «тилевәзир» бик әкәмәт нәрсәләр дә күрсәтеп куя ахрысы. Шундый әкәмәтләрнең берсен өйдәгеләр «футбул» дип атыйлар. Нәрсәдер инде ул «футбул» дигәннәре, ходa белсен!.. Ләкин шуны күрсәтә башласалар, хуҗалар да, килгән кунаклар да ашауэчүләрен дә, дөньяларын да оныталар. Бервакытны шул хәерсез «футбул» аркасында Акъәби бичара чак җаныннан аерылмады. Тик кенә уйланып ятканда залдагы бер ханым кинәт:

— Керде! — дип чинап җибәрде.

— Гол! — дип үкереп салды җитмәсә тагын бер ир кеше.

— Әстәгыфирулла, тфү, тфү! — диде карчык, тәмам агарынып.

Кунакларның күбесе читтәге кечкенә бүлмәдә авыру карчык ятканын белмиләр дә иде шикелле... Һәрхәлдә авыру бар дип борчылучы яки аның хәлен белергә керүче булмый диярлек,— утыралар, көләләр-шаулыйлар, ашыйлар-эчәләр дә таралышалар... Шулай да ешрак килеп йөрүче бер кунак Акъәби янына кергәли торган иде. Бу — тәбәнәк буйлы, ашыкмыйча елмаеп кына сөйләшүче, исеме шактый билгеле булган, олы яшьтәге бер шагыйрь иде.

Залда кунаклар шаулап утырган чакта гына ул карчык янына мыштым гына килеп керә, керә дә: «Саумы, әбекәем?» — дип ике куллап күрешә, аннары урындык алып, карават кырыена утыра. Ул күп сөйләшергә яратмый иде, күбрәк тезләренә таянып тик кенә утыра һәм ара-тирә берәр хикмәтле сорау гына биреп куя торган иде. Карчык аның әчкәнме-түгелме икәнен дә аера алмый, чөнки шагыйрь һәрвакытта гел бер төсле була торган иде. Ләкин, ничек кенә булмасын, ул бу уйчан-сәер кешене кәтеп ала иде. Ничектер алар аз сөйләшсәләр дә бер-берсенә бик тиз ияләшеп киттеләр.

— Акъэби, Акъэби! — ди шагыйрь үз алдына әйткәндәй әкрен генә.— Ә ни өчен Акъэби, ни өчен Караэби түгел?

— Минем исемем Акбикә,— ди карчык, бу көтелмәгән сорауга бераз пошынып.— Кыз чагымда мине Аксылу дип йөртәләр иде, кияүгә чыккач Аккилен булдым, аннары Акжингә, ә хәзер менә Акъэби...

— Димәк, син гомерең буена ак кеше булгансың икән. Ак күңелле, пакь күңелле кеше... Менә миңа да шундый әсәй кирәк иде.

— Ни сөйлисең, улым, синең үз әсәең бардыр бит?!

— Юк шул, юк... Күптән оҗмахта инде ул... Ә әсәйсез авыр, әсәй сабый балага гына түгел, менә минем кебек сакалы агарган кешегә дә кирәк икән ул!

— Рәхмәт, улым! — ди карчык, нигәдер ирене калтырый башлап.

Шагыйрь тезләренә таянган килеш бераз уйланып утыра, аннары тагын сорап куя:

— Юлкотлыны сагынасыңмы?

— Сагынам, улым!

— Әйе, халык матур уйлаган, авылына, җиренә, суына матур исемнәр бирә белгән. Юлкотлы! Юлың котлы булсын, Акъэби! — дип әйтәсе килеп тора.

— Безнең ерак бер бабаебызның исеме Юлкотлы булган диләр. Аның кышлавын «Юлкотлы кышлавы» [1] дип йөрткәннәр. Тора-бара авылга да шул исем күчкән.

— Ә шулаймыни? — ди шагыйрь кызыксынып һәм карчыктан иплән кенә аның кыз чакларын, кайчан, ничә яшендә кияүгә чыгуын, туйларның ул заманда ничек узуын, шул чактагы йолаларны, уеннарны, җырларны сорашырга тотына. Акъэби, еш кына тыны кысылса да, үзенең истәлекләрен, күргән-белгәннәрен иренмичә сөйли, ә шагыйрь аны бик игътибар белән тыңлап утыра... Карчык сөйләп беткәч тә әле ул ни дә булса әйтергә ашыкмый, тик бераздан гына үзенең берәр әчке уен раслагандай әйтеп куя:

— Ийе, узган гомер кире кайтмый, сулар үргә акса да!.. Шулай ди җыр, сулар үргә акса да ди, усал әйтә! Берсе дә — узган гомер дә, үтеп киткән тормыш та кире борылып кайтмаячак. Син дә, әбекәем, моның белән килешә torгансыңдыр?

— Килешмичә нихәл итәсең инде...

— Юк, син дөресен әйт, син олы кеше, бәлки борынгы тормыш сиңа кадерлерәктер, син аны сагына торгансыңдыр?..

— Хәзергесе начар булса, сагыныр идем, — ди карчык уйланып кына. — Хәзергесе, аллага шөкер, әйбәт бит әле.

Шагыйрь аңа күзләрен тутырып карый.

— Шулаймы?!. Син дөньяны таный беләсең икән, әбекәй, яшә, яшә!.. Ләкин сагыныр нәрсәләр дә юк түгел бит. Әнә шул син сөйләгән халыкның матур йолалары — бәйрәмнәре-туйлары, уеннары-җырлары — берсе дә онытылмаска тиеш, минемчә... Халыкның буыннан-буынга күчеп килгән рухи байлыгы бит алар барысы да... Дөрес, яңа заман

[1] Кышлау дип борын күчмә башкортларның җәйләүдән соң кыш уздырыр өчен туктаган җирләренә әйткәннәр.

яңа байлыклар тудыра, ләкин искенең дә яхшысын саклый белергә кирәктер ләбаса!

— Борчылма, улым,— ди карчык, сабыр гына.— Халыкныкы халыкта саклана, югалмас, алла бирсә!

— Гаҗәп сүз әйттең, әсәй бәгърем гаҗәп сүз!.. — Һәм дәртләнеп киткән шагыйрь кинәт кенә тураеп, бер аягы белән идәнгә акрын гына суга-суга җырлап та җибәрә:

— Ап-ак микән, йомшак микән йәнкәемнең куллары,
Салават күпере кү-ү-үк суга барган юллары.

Онытып кара син бу җырны, онытып кара, мөмкинме соң!..

Шагыйрь тавышы өзелгәндәй шулай ук кинәт кенә тынып кала, башын артка чөя һәм күз төбендә аның тәгәрәп төшә алмаган яшь бөртекләре күренә. Тик бераздан тынычлангач кына гафу үтенгәндәй әйтеп куя:

— Син мине тилегә санама инде, яме!.. Нишлим, мин шагыйрь кеше, халык җырын, бөек Тукай әйтмешли, рәсүлнең тырнагыдай йөрәгемдә саклап йөртәм.

— Ә мин Тукайны беләм, — ди карчык, һич көтмәгәндә.

— Китче! — ди шагыйрь шаккатып. — Кайдан беләсең син аны?

— Суфияннар мәктәптә укыган чакларында «И туган тел, и матур тел» дип бер җыр ятлап йөриләр иде, шуннан хәтеремә кереп калган.

— Суфиян агай туган телне җырлап йөрдеме?.. Кызы-ык!—Һәм шагыйрь бөгелә төшеп, тавышсыз гына көләргә тотына:— Их, генерал, генерал!..

Ләкин Акъәбинең җитдиләнеп китүен күргәч, ул көлүеннән шунда ук туктый, иелеп чәчләрен сыпыра, аннары баладай юаш кына әйтә:

— Син мине кичер инде, әсәй, синнән бер нәрсәмне дә яшерә алмыйм шул...

— Бик яхшы, улым, — ди карчык, тыныч кына. — Күңелең кешеләргә көзгедәй һәрвакыт ап-ачык булсын!

— Рәхмәт, әсәй, рәхмәт!.. Җиңел, рәхәт миңа синең янда... Тик күп лыгырдап ялыктырам бугай үзеңне... Ярый, кузгалыйм булмаса, син дә ял ит инде, ял ит, безгә карама, без — эрсез кунаклар!.. — Һәм шагыйрь торып, карчыкның юрган өстендә яткан сап-сары кулын йомшак кына сыйпый да исерә төшкән кешедәй аз гына чайкала биреп чыгып китә.

«Сәер кеше! — дип уйлана карчык, аның артыннан, — ләкин әйбәт кеше үзе, кече күңелле, тик күңелендә ниндидер сызлавыгы бар шикелле, җанына урын таба алмыйча шуңа сызланып йөри, ахрысы, бахыркаем!»... Һәм күп вакытта ул аны ятим баладай күреп, чын ихластан кызганып кала торган иде.

... Бер ике-өч атна үтүгә карчыкның хәле шактый авыраеп китте. Бик ябыкты ул, тамагына бер нәрсә капмас булды, шуның өстенә тавышы да бетә башлады. Янадан врачлар килде, карадылар, юаткан булдылар, тагын ниндидер яңа дарулар язып калдырдылар. Хәер, карчык өчен боларның берсе дә кирәкми иде инде. Ул барысын да белеп ята. Шулай ук аның хәлен уллары-кызлары да бик яхшы белеп торалар... һәм эчләреннән генә куркып, шомланып үлемне көтәләр. Карчык хәзер моны сизә, карчыкның сизгәнен алар да беләләр. Ләкин шуңа карамастан һаман: «Әсәй, борчылма, үтәр, терелерсең!» дип аны да, үзләрен дә алдарга тырышалар.

Карчык соңгы көннәрдә бик уйлана башлады. Көндезләрен барысы да хезмәтләренә китеп беткәч һәм асрау кыз да, карчыкның өстеннән бикләп, базарга китеп баргач, Акъәбигә ялгызы ак түшәмгә карап, теләсә күпме уйланып ятарга мөмкин иде. Уйлар күп, уйлар төрле-төрле,

өзлексез килә торалар, китә торалар... Башта ул чынлап та Юлкотлысын сагынып йөдәде. Бөтенесе — яланы-кыры, авылы-урамы, кешеләре-маллары — бер генә минутка да исеннән чыкмый... Бөтенесе — өе, алачыгы, келәте, кәҗәсе, тавык-чебешләре — күз алдында тора, бөтенесен ап-ачык ишетә-күрә... Менә кәҗәсе көтүдән кайткач, ишек төбенә килеп, Акбикәне дәшкәндәй, тавышын калтыратып, кычкыра торгандыр. Җавап булмагач, тык-тык басып, өйалдына ук керә башлыйдыр... Тавыклары да тибенеп йөргән җирләреннән туктап, «Нигә әле безнең әбиебез күренмиҗ» дигәндәй, башларын кырын салып, желт-желт карана торганнардыр. Казлары да күл буеннан кайткач, ишек алдында озак кына кангылдаша торганнардыр да, чыгучы, дәшүче булмагач, чирәмгә боек кына чүгәләшеп, башларын сыртларына салып, йокыга талалардыр... Әйе, алар барысы да әбинең юклыгына гаҗәпләнә торганнардыр, күңелсезләнеп, боегып, моңаеп йөри торганнардыр... Шуларны уйлагач, Акбикәгә гаять авыр булып китә, алар да, үзе дә аңа бик кызганыч булып тоела һәм ихтыярсыздан кайнар яшьләре мөлдерәп агып төшә. Юк, күрмәс инде ул аларны, — туып-үскән Юлкотлысын да, гомер иткән өен дә, күршеләрен дә, терлекләрен дә — берсен дә яңадан күрә алмас инде!

Шушы котылгысыз аерылышуны сизеп торганга күрә булса кирәк, карчыкның күңеленә еш кына башка уйлар — житдирәк, тирәнрәк уйлар да килә башлады. Әйе, аның көннәре санаулы, соңгы сәгате якынлаша... Ул курыкмый, ул тыныч көтә бу серле, рәхимсез сәгатьне, тик бер ходаеннан җан биру газабын җиңеләйтүне генә сорый... Ул әзер булып торырга тиеш, әйе, зиһене ачык, теле бар чакта ул үзенең соңгы теләген, соңгы васыятьләрен әйтеп калырга тиеш. Аннары инде... китәргә дә була.

Иң элек аның уен, билгеле, үлгәннән соң ничек итеп күмәрләр дигән нәрсә гел борчып тора. Ул белә: кайда, кемнәр кулында ятуын, әмма ул — гомере буена башыннан яулыгын салмаган мөселман карчыгы, — алла хозурына барам дип ышана, шуңа алдан әзерләнеп килгән һәм бөтен керсез күңеле белән үлгәннән соң гәүдәсен бары мөселманча итеп җирләүләрен тели. Ул инде мулла-мәзин чакырып, тәхлил әйттерү кебек зур мәшәкатьле эшне сорамый да, анысын эшләмәсәләр дә ярый. Әмма ләкин аның гәүдәсен әйбәтләп юып, ак кәфенгә төреп, ләхетле кабергә куйсыннар иде. Аннары берәр карттан гына булса да баш очында коръән укытсыннар иде... Күп түгел, күп сорамый ул... Авылында булса аны шулай күмәрләр дә иде, аның алып куйган кәфенлеге дә, чачеме өчен җыеп торткан тәнкәләре дә, гәүдәсен ләхеткә куючылар өчен саклап килгән сөлгеләре дә бар иде, ләкин, нихәл итмәк кирәк, барысы да сандыгында торып калды шул... Ничек кенә булмасын, улы-кызы аның бу үтенечен тыңларга тиешләр. Үзләре ышанмасалар да, кирәксез нәрсә дип тапсалар да, ул кушканча эшләргә тиешләр, — бу бит газиз аналарының соңгы васыяте! Васыятьне үтәмәү мөмкинме соң?!

Һәм кызы бер кичне аның хәлен белергә кергәч, Акъәби аңа якынрак килеп утырырга кушты.

— Гөлбикә кызым, сиңа сүзем бар, — диде ул, чак ишетелерлек зәгыйфь тавыш белән. — Алладан вакыт житә шикелле, шулай сизәм... Менә исемдә чакта әйтеп каласым килә... — Аңа сөйләве авыр иде, әледән-әле тыны кысыла, авызы белән көчкә генә өзеп-өзеп сулышын ала. — Ух, ух, тәңрем җиңеллек бир... Э-э, әйе... кызым, ишетәсеңме, мин үлгәч гәүдәмне бер ук...

Гөлбикә, кызганудан йөзен чытып, шунда ук аның сүзен бүлде:

— Әсәй, әсәем, нигә ул хакта сөйлисең әле... Куй, кирәкми, борчылма, уйлама ул турыда...

— Һай, кызым, ничек уйламыйсың ди, килә бит ул әҗәл, килә, күрмисеңмени?.. Ух, уф... Соңгы сүземне әйтеп калыйм...

— Әсәем бәгърем, ярамый сиңа сөйләшергә, — диде кызы, кат-кат башын селкеп. — Хәлең юк, тавышың беткән, нигә үзеңне азаплыйсың... Тыныч кына ят, кирәгеңне генә сора!..

Карчык бераз күзен йомып торды, аннары ничектер хәл кергәндәй тыныч кына әйтте:

— Мин, кызым, нәкъ менә иң кирәген сорыйм да шул... Сез яшьләр, шәригать йолаларын белмисез, үзем әйтеп калдырмасам, кем мине мөселманча җирләр?.. Яшниккә салырсыз да илтеп куярсыз...

Кызы урыныннан ук торды, — ул гадәтенчә каядыр ашыга иде.

— Юк хәсрәт төшкән башыңа, әсәй!.. Ярар, бу хакта сүзне бетерик... Врачлар киңәшен тыңларга кирәк. Хәзер менә шушы даруыңны эч, бераздан Фатыйма кайнар чәй кертер... Онытма, ямьсез уйларга бирелеп яту синең өчен бик зарарлы ул... Ярый хәзергә, сөйләшербез, минем барып киләсе җирем дә бар иде...

Карчык дәшмәде, тик «бар!» дигәндәй башын гына каккандай итте. Һәм бик озак ул күзләрен йомып, берни уйламагандай, тын гына ятты. Әмма аның зиһене бер генә секундка да эшләүдән туктамаган иде. Нәрсәнедер, үзе өчен бик мөһим, бик яңа бер хакыйкатьне аңларга тырышып ята иде кебек... Алай, әнә ничек икән ул!.. Үләсе кеше белән каласы кеше тиз генә уртак тел таба алмыйлар икән! Бик кыен икән аларга сөйләшүе... Ни өчен соң бу шулай? Бөтенләй кирәксез, юк нәрсә турында кайгыртып ятамыни ул, дөньядан китәсе ана кеше? Балалары белән аның арасы шулай бик ераклашты микәнни? Алай дисәң, карыйлар, дәвалыйлар, кызганып, борчылып та торалар кебек, ә менә әсәйләренең соңгы сүзен, соңгы үтенечен тыңларга, йөрәген аңларга теләмиләр. Нидән соң бу болай?

Әлбәттә, карчыкка моның җавабын табу бик читен иде. Тик ул күңеле белән генә сизенә: балалары аның — бүтән кешеләр, бик нык үзгәргән кешеләр. Авыр аңа, ямансу аңа, ничектер кинәт бик ятим, бик ялгыз калгандай хис итә ул үзен... Ләкин шулай да аның балаларына үпкәлисе, рәнҗисе килми. Җанлек үзенең ярасын ялап төзәткәндәй, ул да җәрәхәтле йөрәген сабыр акылы белән тизрәк тынычландырырга, юатырга ашыга: ярамый болай, язык булыр, ди, балаларымны бәхилләп, ризалыкларын алып китәргә тиешмен, ди. Шәт, алар да мине аңларлар, сүземне тыңларлар, кадерләп озатырлар... Әйе, аның өмете зур һәм әйтер сүзе дә күп әле, күп...

Җитмеш алты ел бу дөньяда яшәгән карчык бит ул. Гомер иткән нигезе бар, нужа белән тапкан күпме-азмы мал-мөлкәте бар, яшь килен чагыннан ук саклап килгән, үзе өчен бик кадерле кием-салымнары бар,— шуларның барысын да ул бик теләп, бик куанып балаларына калдырып китә. Өен, абзар-курасын, кәҗә-сарыкларын соңыннан теләсә нишләтсеннәр — колхозга бирәләрме, сатып акчасын бүлешәләрме — алар эше.

Ләкин кайбер бик кадерле нәрсәләрен ул балаларына исемләп атап, биреп калдырырга тели. Сатар өчен дә түгел, чит кешеләргә бирер өчен дә түгел, ә аның төсе итеп, саклап тотар өчен бүләк итәргә тели. Мәсәлән, үзенең ак ука тоткан, якут каптырмалы сары бәрхет камзулын Гөлбикәсенә, вак мәрҗәннән җыеп эшләнгән, әдрәс астарлы кашмау белән чәчкабын Пермьдәге олы кызы Сылубикәсенә, картыннан калган камчат бүрекне улы Суфиянга билгеләп тора. Аннары бик борынгы тәңкәләр һәм төрле төстәге ташлар белән бизәлгән бөяте (хәситәсе) бар, шуны, кабул итсә, марҗа килененә бүләк итәр иде. Улының хатыны булгач, ул аңа да якын бит, бәлки Мария килен дә кайнанамның төсе дип бөятне үзендә саклар иде.

Билгеле, кызы кашмауны, килене бөятне киеп йөрмәсләр — ул кадәресен генә Акъәби аңлый инде. Ләкин бит аларны бер әсәйләре генә түгел, әсәйләре кебек бик күп башкорт кызлары, башкорт җиңгәләре

кигәннәр. Шуның өчен генә булса да, алар ул киемнәрне ничектер сакларга тиешләр. Югыйсә бетә бит инде барысы да, югала, онытыла... Ярый, шушы көнгә кадәр ул, Акъәби дигән кортка, яшәп килде. Ул мәнә аларны моңарчы туган җирләре белән, андагы тормыш, андагы кешеләр белән бәйләгән бердәнбер җеп булды. Хәзер шушы бердәнбер җеп тә өзелә инде... Нишлисең, тәкъдирдән узып булмый шул, узып булмый!.. Ләкин, ни кызганыч, тере җеп өзелү белән бергә туган-үскән илгә юл да киселәчәк. Кылганлы далада утырган Юлкотлы үзе дә, аның кешеләре дә акрынлап онытылачак. Әмма киселергә тиешме соң, ходаем, туган илкәйгә юл, онытылырга тиешмени соң ата-бабадан килгән андагы тормыш, андагы кешеләр? Юк, Акъәби үзе мондый хәл белән һич тә килешә алмый. Аның өчен туган ил — туган туфрак дигән сүз. Шул туфракта ата-бабаларының сөякләре ята, шунда аның гомердәшләре Миңлебай картлар, Миңҗиһан корткалар, шунда аның күз алдында үсеп җиткән яшь ирләр, яшь киленнәр, шунда аның тирәсендә чуалган бала-чагалар һәм ул аларны, кая гына китмәсен, актык сулышына чаклы онытачак түгел. Менә шул хакта аның үз балаларына да бик нык әйтеп каласы килә:

— «Суфиян улым, Гөлбикә кызым, балакайларым! Сез икегез дә укыган, белемле, дәрәҗәле, зур кешеләр булдыгыз. Икегезнең дә түгәрәк кенә семьягыз бар, бер-бер артлы балаларыгыз үсеп килә, үзегез дә инде олыгаеп барасыз. Хак тәгалә барыгызга да тигез гомер биреп, шул балаларыгызның игелеген күрергә насыйп итсен! Амин!.. Ләкин сезнең дә сабый чакларыгыз бар иде. Сез Аслы күл әйләнәсендәге киң, тигез далада утырган Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылында тудыгыз. Сөттәй йомшак, көмештәй саф сулы Аслы күл Юлкотлыдан өч кенә чакрымда... Аның шифалы суында коендырыр өчен атагыз мәрхүм сезне арбага тезеп утыртып, еш кына шунда алып бара иде. Ә Аслы күлнең Нора тавына менсәң, шуннан инде еракта ялгыз утырган, нәкъ түбәсенә куш каен үскән Балкан тавы да күренә. Сезнең «Зыятүләк белән Сусылу» экиятен ишеткәнегез бар инде, шул көзгедәй уйнаклап яткан күл белән еракта басып торган биек таудан туган экият ул, ә тауның түбәсендәге куш каенны Зыятүләк белән Сусылуның кабере диләр, каеннар төбеннән бәреп торган чишмәне Сусылуның озын кара толымнарыннан саркып чыккан су диләр.. Әнә шулай экиятләргә кергән гаҗәеп якты, иркен, матур җирләр бит ул безнең Аслы күл яклары! Һи, ниләр генә сөйләп булмас иде безнең башкорт илләре, башкорт җирләре турында!..

...Мин бераз читкәрәк киттем шикелле, балалар! Әйтәсе килгәнем бүтән иде... Зиһенемне азрак җыйыйм әле... Әйе, менә шул... Сез Юлкотлыда тудыгыз, аның киң урамында чабышып йөрдегез, чирәмендә ятып аунадыгыз... Үсә төшкәч, сез Юлкотлының ак кылганлы яланнарында, тау-чокыр буйларында йөрдегез, — бозау көттегез, кизәк җыйдыгыз, әрлән кудыгыз... Бүтәннәрдән бер аермагыз да юк иде, бүтәннәр шикелле үк сез дә ситса күлмәк, бөрмәле ыштан киеп, ялан тәпи йөрүче кап-кара балалар идегез — үскәч кенә менә кем булып киттегез!

...Җиде-сигез яшегездән Юлкотлының кечкенә мәктәбенә сабакка төштегез. Шунда тел ачкычы таптыгыз, шунда күңел күзегез ачылды... Икешәр-өчәр көн рәттән котырган кышкы бураннарда үзем сезне җитәкләп мәктәпкә илтә торган идем... Атагыз Әлшәй базарыннан, куенына кыстырып, сезгә китаплар, дәфтәрләр алып кайта торган иде... Бик иплe, бик бала җанлы кеше иде ул, мәрхүм!.. Бервакытта да сезнең теләгегезгә каршы килмәде... Юлкотлы мәктәбен бетергәч, Сыртлан мәктәбенә йөреп укыдыгыз... Аны да бетергәч, калага китәбез дидегез,— каршы тормадык. Гәрчә сезне бер-бер артлы яныбыздан җибәреп тору авыр булса да, уку изге эш, без күрмәгәнне балаларыбыз күрсеннәр, безгә насыйп булмаган аларга насыйп булсын дип, хәлебез җиткәнчә

һәркайсыгызның өс-башын юнәйтеп, акчасын да аннан-моннан табып, сезне ерак юлга озаттык. Сездән аерылгач, безгә бик ямансу була иде, атагыз, ир кеше, сиздермәсә дә, минем ашарга утырган саен кашыгыма яшьләрем тәгәрәп төшә иде... Сез киттегез, әмма ул чакларда әле сез Юлкотлыны онытмый идегез, Юлкотлыны сагына идегез, бала кошлар шикелле очып-очып кайткалый идегез... Ләкин ни өчен сез аны соңыннан оныттыгыз?.. Чакырып-дәшеп тә еллар буе кайтмый башладыгыз. Ике сүзнең берендә «туган ил!» дисез, ә Юлкотлы нәрсә соң? Туган илнең сезгә иң якын, иң кадерле бер өлеше түгелмени ул?..

...Сез бик еш кына «халык» дисез, ләкин Юлкотлыдагы кешеләр дә халыктыр бит инде. Бер тамырдан чыккан, бер ыругдан үрчегән халык, шуңа күрә ул сезгә якынрак та, туганрак та булырга тиештер ләбаса!.. Кайчандыр сезнең башыгыздан сыйпап узган агайларның, апайларның кайберләре хәзер дә әле исәннәр. Менә кайтып, шулар белән ике куллап бер күрешсәгез, олылап бер җылы сүз әйтсәгез, күпме сез аларны сөендерер идегез. Һәм күпме рәхмәт, күпме изге теләк сез алардан ишетер идегез. Һай, ярата безнең халык зур, укыган кешенең кече күңелле булуын, мактап бетерә алмый, ә тәкәббердән кача, тәкәбберга бервакытта да йөзен дә, телен дә ачмый ул...

Яки атагыз мәрхүмне исегезгә төшерегез. Ул да бит халыкның бер бөртеге... Сезгә җан биргән, сезнең өчен тир түккән, сездән күпме өметләр көткән ата кеше бит әле ул сезгә! Йә, сез аның алдында бер дә бурычлы түгелмени соң?.. Авыл читендәге канау белән генә әйләндереп алган кечкенә зиратта аның гәүдәсе ята. Баш очында ташы юк... Аның каберен мин дә, тагын берничә авыл карты гына белә. Бездән соң белүче булмаячак, кабер җир белән тигезләнәчәк... Йә, сезнең күңелегезне бер дә борчымыймыни бу нәрсә?.. Машиналар сатып алырга хәлегездән килә торып, атагызның кабренә бер ком таш кына яздырып куярга сезнең кулыгыздан килмимени? Килә, бик килә, тик күңел саранлыгыннан котылырга кирәк, тик кемгә бурычлы булуыгызны онытмаска кирәк!.. Имештер, яшь чагында көтү көткән, соңыннан бик баеп киткән Өфенең бик зур бер куписы үзенең шул кайчандыр киеп йөргән иске чабаталары белән озын чыбыркысын намаз бүлмәсендә генә элеп тоткан ди. Күрәсез, ул да, бахыр, намаз укыган саен шуларга карап, элек кем булуын онытмаска тырышкан. Менә сезгә гыйбрәт!

Әйе, сез зур кешеләр булдыгыз, илгә, дәүләткә кирәкле, файдалы кешеләр булдыгыз, хәзер шуның әҗерен күрәсез, рәхәтен чигәсез!.. Ләкин сезне менә без, Сәлимҗан белән Акбикә дигән гади башкорт кешеләре, дөньяга китердек, Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылы сезне үзенең туфрагында үстерде, башкорт халкы сезне бүгенге югарылыкка күтәрде, — сез шуны онытмагыз, балаларым, ишетәсезме? Сезнең онытырга хакыгыз юк, аңлыйсызмы?.. Бу минем күңелем түреннән чыккан иң кайнар, иң зур, иң соңгы васыятем сезгә!»

Һәм шушы васыятен әйтеп калырга Акъәби берничә тапкыр омтылып карады. Бу аның өчен бик тә кирәк иде, әйтмичә китәсе килми иде, хәтта үлгәннән соң да әйтә алмыйча калган васыяте өчен каберендә борчылып ятар кебек иде. Ләкин күпме генә теләмәсен, күпме генә сүз башларга омтылып карамасын, васыятен әйтеп калу аңа насыйп булмады. Авызын ачты исә: «Һәй, әсәй, юкка борчылмале син, кирәкмәгән нәрсәләр уйлап ятмале», — диделәр. «Сиңа күп сөйләргә ярамый, врачлар кушмадылар», — дип тыйдылар һәм аны юатыр, тынычландырыр өчен тамчылап даруын эчерделәр, лимонлап чәен китерделәр, тәлинкә тотырып алмасын, чиясен китереп куйдылар.

Аптырап-уйланып ята торгач, кайчагында, Акъәбинең үзе янында сырпаланган кечкенә Гүзәлгә нидер әйтәсе килә, бик сак кына, бик гади сүзләр белән генә күңелендәгеи шул сабыйга аңлатасы килә. Шул ук вакытта баланың йөрәгенә шом салмыйм дип тә курка ул... Ничек кенә



дип әйтергә аңа? Бераз икеләнеп ятканнан соң, баланың аркасыннан сыйпап, гүя болай гына әйтеп куйган була:

— Бәләкәчем, мин тиздән китәрмен инде...

— Китәсең... Кая китәсең? — ди бала, зур күзләре белән әбисенә тутырып карап. (Ә берни сизә, берни төшенә белмәгән, бары тик ышана яки курка гына белгән сабый күзләреннән дә бәгырьне телгәләрлек нәрсә бар?!)

— Ни инде... үзебезнең Юлкотлыга, — ди карчык, көчкә генә телен әйләндереп.

— Юк, китмисең, китмисең!.. — ди бала, шунда ук үпкәли дә башлап.

Акъәби үксеп җибәрмәс өчен иреннәрен кыса һәм озак кына дәшә алмыйча тора. Бары бугазына килгән төер кире киткәч кенә тагын әйтеп куя:

— Мин сиңа, кошчыгым, аннан бүләк җибәрермен.

— Бүләк? Нинди бүләк, әбекәем?

— Сиңа билгеләп куйган бик матур чулпыларым бар, шуларны җибәрермен.

— Ә нәрсә ул чупы? Нигә син аны алып килмәдең?

— Онытканмын.

Бала ышаныргамы, юкмы дигәндәй әбисенә карап тора-тора да нидер сизенгәндәй башын селкеп куя.

— Син алдыйсың, — ди ул, сузып кына. — Бездән китәр өчен генә әйтәсең...

Акъәби үзен тизрәк читкә бора. Юк, булмый, сөйләү мөмкин түгел... Сабыйның күңеленә кагылырга ярамый, аярга кирәк аны, аярга!.. Кем белә, бәлки соңыннан бу әйткәннәрне исенә төшереп, әнисеннән: «Әбекәем кая китте, нигә миңа чупы җибәрми?» дип сорап йөдәтер. Һәм карчык, сабыйны тынычландырыр өчен, аның күңелендә бернинди шик-шөмлану калдырмас өчен, көлгән булып, баланы юатырга ашыга:

— Юри генә әйттем, бәбкәем, юри генә! Сине калдырып китәммени соң?.. Юк, юк, беркая да китмим, күз нурым!..

...Гаҗәп хәл! Бала белән шушы гөнаһсыз гына сөйләшүдән соң Акъәби, гомумән, васыятьләрен кемгә дә булса әйтергә тырышудан шактый вакыт тыелып торды. Әллә ничек шунда, һич нәрсәгә исе китмәстәй, һич нәрсә турында уйлыйсы килмәстәй булып калды. Тик өзлексез җанын борчыган бер генә нәрсә аны һаман уйландыра иде. Һәм бары шуны гына ул үз янына ашыгып кына кереп чыккан улы Суфиянга ишетелер-ишетелмәс тавышы белән тагын бер тапкыр әйтеп карады:

— Улым, үтенәм синнән, мине зинһар үзебезчә, мөселманча җирли күрегез инде.

Улы Суфиян уйлап та тормыйча:

— Һи, әсәй, обязательно шулай эшлибез аны! — диде гаҗәеп бер җиңеллек белән. — Менә әйтте диярсең, мөфти хәзрәтнең үзен чакыргам янына... Только син, әсәем, үләргә ашыкмале, яме! Торыйк әле, торыйк, алласына, мулласына үч итеп дигәндәй...

— Кәфер сүз сөйләмә, улым! — диде карчык, сабыр, җитди генә.

Ләкин Суфиян авыру кешегә бердәнбер кирәк нәрсә — ул да булса (үз сүзе белән әйтсәк) бодрость дип белә иде. Шуңа күрә ул һәр сүзне уенга бора, үзенчә шаяртмакчы-көлдермәкче була. Һәм күп вакытта утырып та тормыйча, авызына ни килсә шуны сөйләп, бүлмәне бер шаулатып, тизрәк чыгып та китә иде. Ә карчык, бичара, ни уйларга да белмичә аның артыннан башын гына чайкап кала. Чынлап әйттеме ул, юри генә әйттеме, нигә утырып, әйбәт кенә сөйләшмәде соң, кая ашыга, кая чаба ул? Гаҗәп бу шәһәр халкының гадәте — барысы да каядыр ашыгалар, ашыгалар, ашыгалар!..

Үлем дә ашыга иде шикелле... Соңгы көннәрдә карчыкның хәле бөтенләй начарланып китте. Тын алуы бик авырлашты, кислород мендәреннән бер дә аерылмас булды. Бала шикелле тәмам кечерәеп калды, күзләрен дә инде йөртә алмый башлады.

Врачлар кызы белән киявенә карчыкның тиздән өзелеп китү ихтималын әйттеләр, — торса, тагын бер атна-ун көн генә тора алыр, диделәр. Бу хәбәр аларда зур борчылу тудырды. Димәк, әсәй карчык китә!.. Һәм бик ачык, котылгысыз булып алларына килеп баскан бу гаять авыр, хәсрәтле үлем аларны тәмам аптырауга төшерде. Хикмәт шунда, үлем дигән нәрсә аларның өенә беренче мәртәбә керә әле, моңарчы аларның мондый фаҗигале хәлне күргәннәре дә, кичергәннәре дә юк иде әле... Борчылмыйча, уйланмыйча һич мөмкин түгел. Иң элек карчыкның үлеме балаларга бик авыр тәэсир итәчәк, куркытачак бу нәрсә аларны... Аннары мәетне юу бар, җыештыру бар, озату бар, ә алар үзләре бу эшләрнең тәртипләрен һич белмиләр. Кемнән эшләтергә, ничек эшләтергә боларны? Түбәндәге дворник хатыны Сәрбиҗамал апага әйт-

сәң, ул бик теләп боларның барысын да оештырыр иде.... Юарга, кәфенләргә карчыкларын да табар иде, бәлки мулласын да чакырып китерер иде. Ләкин болар барысы да гаять мәшәкатьле эш бит, әллә ничек күңелсез эш. Кияве бу хакта сүз чыкса, теше сызлагандай, чыраен сыта башлый. Мөселманча булсын дип әллә нинди карчыкларны, муллаларны үзенең квартирасына бер дә китерәсе килми аның... Килешми аның хәлендәге кешегә бу нәрсәләрнең берсе дә. Ничектер бүтән юл, бүтән чара табарга кирәк бу положениедән чыгар өчен...

Кияве белән кызы арасында шушы хакта берничә көн буена сүз барды. Гаять четрекле мәсьәлә турында алар мөмкин кадәр әдәп, такт саклап сөйләштеләр, ләкин шулай да ара-тирә үпкәләшеп, талашып та киткәләделәр. Хәер, асылда аларның фикерләре бер иде: карчык квартирада үлсә бик авыр, бик күңелсез булачак.

Ахырда кияве әйтте: «Гөлкәй, бүтән чара юк, әбине больницага салырга кирәк,— диде.— Больницада әле аңа яхшырак та булыр, урынҗире чиста, врач көн дә карап тора, сестралар һәрвакыт янында, үзебез дә чиратлашып янына баргалап торырбыз... Нишлисең инде, үләргә булгач кайда да барыбер... Аның каравы, балалар кадерле әбиләренең үлемен күреп, тетрәнеп калмаслар, куркып елашмаслар иде... Аннары больницада мәетләрне әйбәтләп юындырып, киендереп озатучы махсус кешеләр дә бар. Ә без үзебез монда нишли алабыз?.. Юк, иң яхшысы — больницага салу инде...»

Гөлбикә бу эшнең күңелгә авыр, оят, килешмәгән ягын сизсә дә, уйлый торгач ахырда риза булды. Шулай сөйләшеп килешкәннән соң алар үзләренең бу карарларын, уңайсызланыбрак булса да, Суфиян белән Мария Васильевнага да әйттеләр. Башта Суфиян бик кайнарланып каршы төште:

— Што сез, — диде кычкырып, — кадерле әсәебезне өйдә үлмәсен өчен генә больницага илтеп салмакчы буласыз! Оятын ничек күтәрерсез, хурлыгын кая куярсыз?.. Юк, юк, мин моңа асла риза түгел!

Ләкин кияү кеше кызмыйча гына, мәгънәле итеп кенә, әйбәтләп кенә аңа төшендереп бирде:

— Кайнагай, оят мәсьәләсендә синең безгә бер сүз әйтергә дә хакың юк. Әсәебезне авылдан без барып алдык, без аны өебездә ай ярым буена кулыбыздан килгән кадәр тәрбияләдек, карадык, терелмәсме дип бөтен чараларны күрдек... Әсәй үзе дә моның өчен безгә рәхмәтен әйтер, дип ышанабыз. Инде больницага салу мәсьәләсенә килгәндә, бу синең өчен авыр икән, тотасың да үзеңә аласың... Синә да ана бит ул!.. Әмма мин әсәйнең үлгән чагын балаларга күрсәтеп, аларның йөрәкләрен җәрәхәтләргә теләмим.— Һәм шунда ук кайнагай тагын дулап китмәсен дип булса кирәк, иплән, йомшартып кына әйтте:—Без, Суфиян, дәү кешеләр, мәсьәләгә айнык карарга тиешбез. Авыруны больницага салуның һичбер гаебе юк. Беркем бер сүз әйтмәячәк. Инде анда үлеп китә икән, без әсәебезне шуннан гына бик әйбәтләп, бөтен шартын җиткереп, соңгы юлына озатырбыз. Ә өйдән мәет озату бик авыр, бик мәшәкатьле эш ул — син безнең хәлебезне аңларга тиешсең, Суфиян!

Һәм Суфиян аңлаудан да бигрәк, бу эштә үзенең көчсезлеген сизеп, ниһаять, риза булды.

Инде моны карчыкның үзенә җиткерергә кирәк иде. Кияү, билгеле, бу эштән читтә калырга теләде, чөнки ул нинди генә якын кеше булмасын, карчыкның үз баласы түгел... Шуңа күрә улы белән кызы әйтергә тиеш булдылар: «Әсәй җаным, — диделәр алар аңа иплән кенә, — докторлар сине бер атна-ун көнгә больницага салып торырга куштылар, анда дәвалап карамакчы булалар. Син борчылма бер дә, хәлең яхшыргач та кире алып кайтырбыз үзеңне...»

Акъәби моның чын сәбәбен сизгәндерме-юктырмы, әмма «болнис»

дигән сүз үзе генә дә аның котын алды, бәгырен телгәләп җибәрде. Тәмам куркып, рәнҗеп һәм ялварып ул: «Балакайларым, зинһар кузгата күрмәгез, шушы җылы урынымда тыныч кына үлим, миңа берни дә кирәкми, вакытым житте, аңлагыз шуны!» — диде.

Ләкин улы белән кызы, ташка әйләнеп булса да, аны үгетләп, юатып. хәтта азрак кына көчләп тә урыныннан кузгаттылар, киендереп чыгардылар һәм «Волга» машинасына кырын яткырып, алдан кияве сөйләшеп куйган бер больницага илтеп салдылар.

... Өч тәүлек үтүгә төнлә белән Акъәби шул больницада вафат та булды. Җан биргәндә янында кеше булмаган. Берәүне дә борчымыйча күбәләктәй тавыш-тынсыз гына киткән дә барган. Әйтерсең, үзенең Юлкотлысына...

Иртән иртүк әбинең үлгәнен телефон аша кызына хәбәр иттеләр. Кызы белән кияве шунда ук машинага утырып больницага киттеләр. Алар барганда Акъәбине үлекләр ята торган цемент идәнле таш бүлмәгә төшереп куйганнар иде инде. Тиздән улы Суфиян белән килене Мария Васильевна да килеп җиттеләр. Ак җәймә астында яткан әсәйләренең йөзен ачып карадылар, — йөзе бер дә бозылмаган иде, киресенчә, ничектер авыр газапларыннан котылып, тынычланып калган кебек иде. Әмма күзләрендә ни торып калгандыр, анысын күрмәделәр, — күзләрен кемнеңдер бармагы сак кына йомдырып куйган иде.

Аннары больница бакчасына чыгып, шунда гына карчыкны ничек итеп җирләү турында үзара киңәш корып алдылар. Мулла чакыру, җиназа укыту кебек нәрсәләрне эшләмәскә булдылар. Шулай да әсәйләренең аллага ышанган карчык кеше булуын исәпкә алып һәм аның үзенең дә бик үтенеп соравын исләренә төшереп, гәүдәсен кәфенгә төреп күмәргә булдылар. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, больницадагы мәетне юып, киендереп озатучы марҗалар кәфен дигән нәрсәне бөтенләй белмиләр дә икән. Ә читтән кеше чакыртып, дини йолага бәйләнгән нәрсәләрне эшләтү монда рөхсәт ителми икән. Шулай итеп, чарасыздан, Акъәбине «заманча гына» әзерләргә мәҗбүр булдылар. Бер чиста күлмәген китереп өстенә кидерделәр, башына «мөселманнарча» итеп ак батис яулык бәйләделәр, шуннан соң гәүдәсен кечкенә кызыл табутка салдылар. Табут әйләнәсенә чәчәкләр тезделәр, күп итеп ислемай сиптеләр, һәм Акъәбиебез хәйран матураеп китте. Ул, бичара, хәтта көлемсерәп яткандай күренә башлады.

Зиратка табутны машинага куеп илттеләр. Озата баручылар күп түгел иде; иң якыннары да аларның кайбер дус-ишләре, һәм шулар арасында әлеге кечкенә буйлы шагыйрь дә бар иде. Ләкин ул бүген дә кызмача иде шикелле.

Табутны кабергә төшергәндә кызы Гөлбикә бик каты елады, килене Мария Васильевна да елады, аның кызлары да «бабушкаларын» кызганып елашып алдылар... Ләкин ирләр түзделәр... Кияве иреннәрен кысып, читкәрәк китте. Ә улы Суфиян әсәен озату шәрәфенә бөтен орден-медальләрен өр-яңа кителенә тагып килгән, башына соры папахасын сындырыбрак кигән полковник кабер кырыенда таш сындай басып торды. Үлемне күп күргән, елауны күптән оныткан кеше булуына карамастан, аңа бу минутта яшьләрен йотып калу гаять авыр иде шикелле.

... Күмеп бетергәч тә борылып китү ничектер кыен иде, шуңа күрә шагыйрь ак балчык өеме янына басып, мәрхүмә турында берничә сүз әйтергә булды:

— Кадерле дуслар, без менә шушы биек тау башындагы, инде үләннәре дә корган, чәчәкләре дә шиңгән җир куенына Акъәбиебезне бирдек, — диде ул, ашыкмыйча салмак кына. — Ак күңелле, пакь күңелле әсәебездән мәңгегә аерылдык... Әйе, ул барыбызның да уртак әсәебез иде. Алай гына да түгел, мин һич икеләнмичә аны башкорт халкының изге җанлы анасы дияр идем... Әмма нәрсә беләбез без аның хакында?..

Күрә белдекме без аның шул изге җанын, пакь күңелен, ак уйларын!.. Менә сез, аның уллары, кызлары, кияүләре, нәрсә генә әйтә аласыз гомере буе сезнең өчен өзелеп яшәгән бичара әсәегез турында?.. Юк бит, әйтә алмыйсыз бит...

Шунда ук Суфиян кычкырып аның сүзен бүлде:

— Син ни сөйлисең, ә?! Ташла, кирәкми...

— Безобразие бу! — диде кияве дә кызарып-бүртенеп.

Шагыйрь аларга һич исе китмичә тагын нидер әйтә башлаган иде, шул чакта кемдер аны беләгеннән эләктереп, кабердән җилтерәтеп читкә алып китте. Телгә батыр булса да, гәүдәгә бик җиңел иде шагыйрь...

Бу күңелсез тамаша аркасында озата килүчеләр яңа гына кабергә куелган Акъэбине ничектер онытып җибәрделәр. Берәүләр шагыйрьне тиргәргә тотындылар, икенчеләр, киресенчә, аңа әһәмият бирмәскә, сүзне уенга борырга тырыштылар. Һәм үзара сөйләшә-шаулаша кабер яныннан тарала да башладылар. Иң ахырдан кузгалган Гөлбикә зират капкасы төбендә утыручы карт-корыларның учларына тиз-тиз генә акча салып чыкты...

Киттеләр... Агыйдел, Дим буйларына караган биек тау башында Акъэби берүзе генә торды да калды.

* * *

Әмма ләкин Акъэби, биек тау башындагы зиратта әнә шулай ялгызы гына торып калса да, үзенең фани дөнья белән аерылып бетмәвен тагын бер тапкыр балаларының исенә төшерде. Хикмәт шунда, кызы Гөлбикә Юлкотлыда карчык өен карап торучы әлеге күрше хатыны Гарифәгә кыска гына хат язып, әсәйләренең август ахрында вафат булуын хәбәр иткән иде. Озак та үтми Гарифәдән дә Акъэбинең үлүенә бик хәсрәтләнеп, күрше тирәнең аны бик кызганып елауларын әйтеп, инде бахырның өе ятим калды, аны нишләтергә уйлыйсыз, дип борчылып язган хат килә. Хат артыннан ук, колхоз машинасына салып җибәргән, карчыкның иске яшел сандыгы да килеп төшә. Күрәсең, яхшы күңелле Гарифә үзенчә бер изгелек эшләргә теләгәндер инде, ләкин монда ул сандыкны берәү дә әле көтми иде. Яңа гына кичергән кайгы-мәшәкать аркасында гомумән Юлкотлыда калган өй-нигез турында да, башкасы турында да уйлашырга өлгермәгәннәр иде. Инде менә әсәйләренең үзе белән бергә картайган, буявы да уңып беткән иске сандыгы: «Мин сезнеке, мине нишләтәсез?» дигәндәй Гөлбикә квартирына килде дә керде. Гөлбикәгә бу сандык бик таныш иде, кайчандыр аның шушы сандык өстендә курчак уйнаган чаклары бар иде, кинәт күргәч, әллә нишләп китте, бер мәлгә аптырап-каушап калгандай булды. Аннары исенә килеп, тиз генә агасы Суфиянга шалтыратты. Шул ук көнне кичкә табан агасы белән җиңгәсе Мария Васильевна, зур уллары Геннадийны да ияртеп, аларга килеп тә җиттеләр.

Барсы да җыелып беткәч, сандыкны идән уртасына куеп ачтылар. Ачып җибәрүгә алар өстә генә яткан ак бәз кәфенлекне күрделәр. Һәм күреп, берәр сүз әйтү түгел, хәтта бер-берсенә күтәрелеп карарга да ничектер кыймадылар, тик ак материяне сак кына бер читкә алып куйдылар. Аннары бөкләп салган кием-салымнарны чыгарырга тотындылар. Менә әсәйләренең тәнкәле кара җиләне, читләренә ука тоткан сары хәтфә камзулы, алтынга манган тәңкәләр һәм төрле ташлар тагылган бөяте (хәситәсе), вак мәрҗәннән эшләнгән кашмавы белән чәчкабы, беләзек, муенса, чулпылары, кыз чагында үз кулы белән чүпләп суккан кызыл башлы сөлгеләре килеп чыкты. Шулай ук аталарының кызыл сәдәпле кара казакие белән камчат бүреге дә килеп чыкты, — карчык шушы көнгә кадәр аларны да саклап торган икән, бичара!.. Актарына торгач, тагын бер хикмәтле әйбер табылды: бу аталарының яшь

чагында тотып йөргән кыска саплы, күн чуклы, өч япьле, һәр ябенең очына көмеш пластинка бөкләп кидерелгән бик шәп камчысы иде.

Хикмәтле камчы шунда ук барысын да бик кызыксындырды.

— Һай, атаемның төлке куганда тотып чапкан камчысы бит бу! — дип кычкырып ук җибәрде Суфиян һәм элмәгеннән киеп селтәнеп тә, бот буена сугып та карады.

— Да-а, менә бу ичмасам реликвия! — диде кияве дә сокланып. — Тик кем саклар аны?

— Ә аның хуҗасы бар, — диде Суфиян катгый рәвештә һәм, улы Геннадийга борылып, тантаналы итеп әйтте: — Мә, улым, Гена, ал бабаңнан калган чуклы камчыны... Белеп тот, Шәяхметовлар кулында йөргән камчы булыр бу!..

Һәм Геннадий Шәяхметов баш кагып, елмаеп кына өч япьле камчыны кулына алды.

...Инде калган әйберләрне нишләтү, ничек бүлешү мәсьәләсе кузгалды. Белгәнебезчә, әсәйләренең бу хактагы теләген алар тыңламыйча калдылар. Шулай да һәркайсы үзенә ошаган нәрсәне алырга хаклы иде. Ләкин бу тәңкәле җилән, хәтфә камзул, бөят, кашмау, чәчкаплар белән алар нишләрләр икән?.. Төс итеп кенә саклаудан башкага ярамый инде боларның берсе дә, аунап йөри торгач череп-тузып кына бетәрләр... Шул чакта кияүләренең башына бик шәп бер идея килде. Ул болай диде:

— Менә нәрсә, Гөлбикә, кайнагай! Без бу әйберләрне бүлешеп, әрәм-шәрәм итеп бетермик. Барыбер файдаланып булмаячак бит... Без лучше тотыйк та бөтенесен театр гардеробына тапшырыйк. Анда мондый нәрсәләрне саклый беләләр, борынгы тормышны уйнап күрсәткәндә киеп файдаланырлар, ә безнең тарафтан театрга бу бик әйбәт бер бүләк булыр. Чын, уйлагыз әле!

Бу фикергә шунда ук Мария Васильевна да кушылды:

— Бик дөрес әйтәсез, Сәхип Карамович, безгә нигә алар, артистлар кисеннәр.

Ләкин Суфиянга да, Гөлбикәгә дә мондый тәкъдим белән тиз генә килешүе авыррак иде. Ничектер күңелләре тартып бетерми иде. Әллә ничек менә әсәйләреннән яхшы түгел кебек, — алар өчен саклаган, аларга дип калдырып киткән бит әле ул... Инде тот та бөтенесен кочагы белән театрга илтеп ташла! Килешерме, оят булмасмы?

Шул ук вакытта кияүләренең сүзендә дә дөреслек бар: бүлешеп алсалар әрәм-шәрәм булып кына бетәчәк, нишлисең, тәңкәле җиләннәр, укалы камзуллар заманы үтте шул инде!.. Ахырда, уйлаша торгач, башта Суфиян, аннары Гөлбикә дә яшел сандыктан чыккан бөтен киемсалымны театрга илтеп тапшырырга риза булдылар. Гөлбикә шулай да әсәенең төсе итеп уртасына кызыл якут куеп, саф көмештән челтәрләп эшләнгән ике зур чулпыны үзенә алып калды.

Көннәр уздылар. Хәсрәт иртәнге томандай бик тиз таралды. Эш, мәшәкать белән тулы, иркен мул тормыш үзенең иске эзеннән ашыгып һаман алга таба тәгәрәде. Акъәбинең балалары өчен бу кызу чапкан тормыш бик тансык та һәм бик мавыктыргыч та иде.

* * *

Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә... Куыша-куыша йөгергән кылганнар арасыннан, озын карагай таягын җир үлчәгәндәй алга ташлап, Миңлебай карт кайтып килә. Ыштан балагын эчкә тыгып кигән ак оекларына аның чәчәк тузаны кунып, билчән уралып, бакыра сырышып беткән, — әйтерсең, Юлкотлы яланнарын үзе белән ияртеп кайта ул...

Авылга кереп, Акбикәнең тәрәзәләре кагылган өе янына җиткәч, карт күрше Гарифәдән гел кычкырып, сорап уза:

— Аккилен кайтмадымы әле?

Гарифә ни диеп җавап бирергә дә белми, — ул бит инде аңа былтыр ук берничә мәртәбә Акъәбинең калада вафат булуын әйткән иде. «Балалар акылы керә башлаган ахрысы бу картка», — дип уйлый ул эченнән генә, һәм, аптырагач, ачулана биреп әйтә:

— Куй, Миңлебай бабай, үлгән кеше кайтамыни, ничек телең барып сорый?

Ләкин карт аның сүзләрен гүя колагына да элми.

— Алдама, — ди ул, таягының башын селкеп. — Аккилен үлмәде ул, китте генә... Китте генә... Кайтыр насыйп булса, кайтыр... Ә син учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен.

Һич аңламассың, әллә чынлап, әллә үчекләп, әллә саташып әйтә бу бер нигә исе китми торган, әҗәлгә дә күптән кулын селтәгән, ялан таптаучы йөз яшәр Миңлебай карт!

1965 ел, август.

■ ■ ■

*Гамил Афзал*

## Шагыйрь язмышы

*Муса Җәлилгә*

Шагыйрьләрне атып үтергәннәр,
Төрмәләргә яшереп суйганнар;
Җырын сагынып искә төшергәннәр,
Каберенә чәчәк куйганнар.

Шагыйрь егет балта астына яткан
Кылыч үтмәс җыры хакына;
Газиз җанын өзеп утка аткан
Нуры төшсен диеп халкына.

## Идел ага

*Сибгат Хәкимгә*

Идел ага кыйбла якка карап,
Ак болытлар ага күгендә.
Көпшәләрен кара ләмгә кадап,
«Фердинанд»лар ята төбендә.

Илне иңләп Идел агып үтә,
Дулкыннары ярда сулкылдый;
Еллар үтә,
Чал гасырлар үтә —
Бары да үтә — берни онытылмый.

...Идел ага,
Дулкыннары кага.
Сары сусар уйный таллыкта.
Идел буйлап Таһир агып бара,
Таһир агып бара сандыкта.

Төнбоеклар сыгыла моң-сагышка,
Лашманчылар сузган тавышка.
Стеньканың җитез көймәләре
Ышыкланып тора камышта.

...Кымыз эчә ханнар кырын ятып,
Айбалтаны элеп югары.
Тыгыз янбашларын уйнаклатып,
Суга төшә Болгар кызлары.

Идел ага,
Дулкыннары кага
Вышкалар утырган ярларга.
Каракашлар, Алтынчәчләр серен
Таң җилләре сөйли талларга.

...Ишкәкчеләр ишеп Идел кичә,
Дулкынына иелеп су эчә...
Ишкәкчеләр җыры искә төшә,
Идел буйлап җилләр истисә.

Чуваш кайры алган юкәләрне
Теплоходлар карап үтәләр.
Мари морда салган урыннарда
Шау-гөр килеп ГЭСлар үсәләр.

Удмурт урманының уйчанлыгы
Йөзендәге зәңгәр күзгедә.
Зифа наратларның күләгәсе
Бизәк булып төшкән биленә.

Идел ага,
Таулар карап кала,
Озатып бара кырлар киңлеге.
Ерак җәелеп диңгез каршы ала,
Күтеп ала Каспий диңгезе.

Анда инде Идел Идел булмас,
Максатына җиткәч югалыр.
Ярдан ярга чаклы йөз мең колач
Шаулап-үкереп торган су калыр.

Айлы кичтә көзгесенә иелеп
Каен шәүләләре уйнамас.
Нигә шаулыйсың син,
Кайдан килеп,
Кем дулкыны?—беркем сорамас.

Ә киң Идел һаман ага бирер,
Үтәр чорлар,
Үтәр гасырлар;
Үз вакытында көзләр, язлар килер,
Кошлар китәр,
Кошлар кайтырлар...

Бозлар ката,
Эреп бозлар китә.
Бөек Идел инеш булалмый.
Патшалыклар бетә,
Яулар үтә,
Таулар иңә — Идел югалмый.

## Уй

Тау артына китеп кояш бата.
Күреп туймас яшел җәй тора.
Өстәлемдә бер бит кәгазь ята,
Бер стакан салкын чәй тора.

Миңа илләр, еллар сере ачык,
Төсен беләм акның, караның,
Титаннарның иңсәсенә басып
Заман түрләренә карадым.

## Язмышлар

Кара син болынлы бу якны:
Болында чәчәкләр ни чаклы!
Болында үләндәй төрлеләр
Гомерләр,
гомерләр,
гомерләр.

Карыйсың уңга да, сулга да:
Гүяки балыклар елгада,
Гүяки тирбәлгән камышлар —
Язмышлар,
язмышлар,
язмышлар.

Ни чаклы тапталган нахакка,
Ни чаклы киселгән сабакта
Баш тарткан хуш исле бөреләр
Тереләр,
тереләр,
тереләр.

●●●

Бөтен дөнья күз алдында горур басып,
Яши кеше дуслашып һәм дошманлашып,
Уйный-көлә синең белән,
минем белән;
Бер ялгызы очраша тик үлем белән.

*Рәдиф Гатауллин*

## Җилкән

Җилкәннәрне ефәк җил күтәрде,
Тын ярларны инде калдырам...
Авыр миңа,
гүя гомерлеккә
Ай, кояштан бүген аерылам.

Тиргәмәгез мине сөйгән дуслар,
Тиргәмәгез — ерак киткәнгә.
Сезгә, бәлки, утрау күбрәк ошый,
Диңгез кирәк ләкин — җилкәнгә.
Җилкәннәрне тагын җил күтәрде,
Җилгә — җиңел... ә соң күңелгә?!
Бик еракта инде тын яр булып,
Малай чагым минем күмелә.

Диңгезләргә илтә тагын юлым,
Мин күрмәгән ерак җирләргә.
Ярдан һаман ерагайган саен
Җиңелрәк икән
җилкәнгә!

●●●

— Сезнең өчен бер кеше мин.
Минем өчен, дуслар, сез — мең.
Шатлык сезгә минем гомер.
Үлсәм — кайгы, меңгә ул бер...
Мөмкинме тик, дуслар, үлү?!
Мең дуска — мең кайгы булу?!
Мең дуска — дус булып һаман,
Шатлык булып җирдә калам.

## Чакыру

Кайтыгыз,
минем сөюнең
Былтыргы бураннары!
Югыйсә, бушанып калды
Күңелнең урамнары.
Кайтыгыз, җилне-давылны
Тынычтан артык күргән,
Тын йортның ишеген ватып
Урамга чыккан көннәр.
Кайтыгыз, йолдызлы төннәр,
Беркатлы өметләрем,

Кайтыгыз, кыш үскән гөлләр,
Йокысыз минутларым.
Кайтыгыз, былтыргы карлар,
Кайтыгыз, сезгә карыйм!
Гөнаһсыз чакның карына
Гөнаһлы исемен языйм.
Кайтыгыз, минем сөюнең
Былтыргы бураннары!
Киңәеп, бушанып калды
Күңелнең урамнары!

## Кайт—кире!..

Син киткәнсең.
Үткән яз кире кайтмый.
Бер өзелгән гөл дә чәчәк атмый,
Елга кирегә акмый,
Ә син — кайт кире.

Мәңгегә киткәннәр кайтмый,
(Истәлекләр әле кайта).
Еласаң да хәтта,
(Үткән өчен елау, бәлки, хата?)
Яшьлек, иң беренче сөю кайтмый.

Кайтмый — үткәннәр,
Кайтмасын белдереп, әйтеп,
Мәңгегә киткәннәр.
Ә син — кайт кире!

Син кайтырга тиешсең!—
Киткән чакта, син —
Китүеңне әйтмәгәнсең;
Кайтып шуны әйтергә тиешсең.
Кайт — кире!

* * *

Алар ничә еллар буе инде,
Берсен-берсе сөйде.
Ләкин, кичә юктан гына күккә
Кара болыт килде.
Төнен йокламады,
                    үртәлде кыз.
Йокламады егет.
...Бүген, кичен килештеләр алар;
Берни дә юк кебек;
Күңел — күгенә килгән ул болытны
алып ташладылар.
Тик, ни гаҗәп?
                    Элек күктә булган
Айны тапмадылар.

* * *

Назыйм Хикмәт турында мин уйлыйм
бүген.
Диңгез шавы —
колагымда.
Акчарлаклар уйнаклыйлар
төшеп монда.
Ярга килә дулкын арты
дулкын тавы.
Кинәт диңгез тып-тын калды.
(Назыйм Хикмәт турында мин уйлыйм бүген)
Күз алдымда —
бер йөрәк; ул
Бар дөньяны урап чыккан.
Йөрәк — алма,
ачлар аны кулына тоткан,
авыз иткән.
Кызыл алма...
арыган да, хәзер ярга
тукталган ул —
бары ялга.
(Назыйм Хикмәт турында мин уйлыйм бүген)
Кипарислар һәм топольләр,
Ак каеннар, кызыл таллар —
Көньяк белән төньяк бергә кушылганнар.
Алда — Кеше,
бер кулында җирне тоткан,
саклап тора.
Икенчесе белән бөек табигатьнең
Чәчен сыйпап, назлап тора.
...Назыйм Хикмәт турында мин
уйлыйм бүген.
Тыңла, сөя белгән
Назыйм Хикмәт турында мин сөйлим бүген.

* * *

Дулкынга син тездән атлап кергән идең
Кояш судан яңа чыгып килә әле.
Су чәчрәттең,
үзең көлдең...
Һәм шул мәлне
Ишеттең син:
— Борыл, кызый!
(Әнием бугай?!)
Дулкынга син билдән кереп баскан идең:
Алга төбәп карашларың,
Толымнарың сүтеп, суга син
ташладың.
— Эчкә керәм, барыбер йөзәм.
Кемдер әйтте:
— Борыл, кызый!
(Әтием бугай?!)
Дулкынга син күкрәгеңнән
күмелеп кердең.

Тагын көлдең:
— Алга, алга...
Әнә анда —
Бәхетем минем, алгы ярда.
Киттең!
Һәм ишеттең:
— Хәерле юл!
Ярга җитми борылма, кызый! —
Кем соң әйтте шулай?!
Яшьлек бугай.

* * *

Кеше!
Бар бит синең иң-иң матур чагың —
Япь-яшь егет — Артур чагың.
Тормыш сиңа Монтанелли вәгазедәй,
Джемманың күзләредәй матур, якын.
Бу — беркатлы,
тик бәхетле малай чагың!

Һәм,
бар синең
нык характерлы,
Кырысланган йөзле
Овод чагың.
Тормыш — гүзәл! — дисең.
Яралары,
кыйнавы да аның якын.
Тормыш — шулай...
Яшь Артурны
Җитди Овод алыштыра...
Ләкин нигә —
аңламыйм мин —
акыллыны
һәм геройны —
Акылсыз чак,
беркатлы чак сагындыра?
Кеше нигә үткәннәргә якын тора?!

*Гариф Гобәй*

# Коръән серләре

## *Беренче бүлек*

«Минем динем хакыйкатькә ышануда.
Ышанам мин, иманам мин фәкать шуңа».
*Әбү-Гали-Сина.*

1

**АЛЛА ДӨНЬЯНЫ НИЧЕК ЯРАТКАН?
ҮГЕЗГӘ РӘХМӘТ ИНДЕ...
ЙОЛДЫЗ АТЫП ҖЕН КУУ.
АНЫСЫ «ВАК» МӘСЬӘЛӘ.**

Борын-борын заманда, бик тә борын заманда, алла бер үзе генә була. Кешеләр белән хайваннарны әйткән дә юк, Җир дә, күк тә, Кояш, Ай, йолдыз кебекләр дә булмый әле, фәкать бер караңгы бушлык кына бар. Коръәндә алланың бу бушлыкта ничек яшәве, нишләп йөрүе турында сүз юк. Ә риваятьләр төрлечә сөйлиләр. «Дөнья яратылганчыга кадәр алла шул караңгы бушлыкта очып йөргән», ди берсе. Икенчесе болай ди: «Дөнья яратылганчы алла «Таң нуры» дигән балык сыртына атланып йөзеп йөргән». Арада шундый бер мәзәге бар: «Башларына мондый көфер сорау килүчеләрне салып суктыру өчен, алла, имештер, урманда чыбык кисеп яткан».

Чыбык кисеп яту үзеннән үзе төшеп кала. Чөнки урман юк бит әле. «Таң нуры» сыртына атланып йөзү дә төшә. Чөнки әле «Таң нуры» түгел, бер шыртлака да яратылмаган...

Ә нишләп кенә яткан соң? Мәңге бит. Бу сүзне әйтүе генә тиз. Миллион еллар, миллиард гасырлар мәңге янында диңгездән бер тамчы кадәр дә юк. Шулхәтле вакыт бер үзе нишләп яткан? Дөнья күреп йөргән дияр идең, башта әйткәнебезчә, дөньяның «д» сы да юк бит әле, зиһен җыеп, дөньяны ничек-ничек ясау турында уйланып утырган дияр идең, бу алланың башта ук бетмәс-төкәнмәс акыл иясе икәнен, чикләнмәгән кодрәт иясе икәнен инкарь итү булачак... Ах, нигә



инде шунда үзенең Коръәнендә ике генә сүз белән булса да әйтеп бирмәгән... Әллә болай итте микән?.. Кирәк түгел, әйттем исә кайттым... Әйдәгез, юкны юрап гөнаһлы булганчы, анысы турында онытып торып, миллион елларны, миллиард гасырларны сикертеп үтеп, үзебезнең эраның 7565 нче елына күчик. Бу алланың тормышында бөек үзгәрешләр елы. Нәкъ шул елда инде алла дөньяны ярата, үзебезчә итеп әйтсәк, ясый.

«Имде ошбу 1900 сәнәгә кадәр дөнья яратылганнан бирле 7.500 ел кадәр вакыт кичтеке Риваять кылынмактыр».

*(«Әнбә-эл-әнбия» китабы, Галәм вә дөнья булеге, 3 бит.)*

Бу уй капылт кына ничек исенә төште икән? Монысы да Коръәндә һ. б. дини китапларда юк. Күрәсең, тик торудан туйган, берәр шөгыль кирәк миңа дигән дә җиң сызганып эшкә керешкән.

Алдарак үзегез дә күрерсез, алланың кодрәте чикләнмәгән. Әгәр ул берәр нәрсә эшләргә теләсә, «Бул!» гына ди, теге нәрсә күз ачып йомганчы була да куя.

*(Коръән, «Ясин» сүрәсе, 82 аять.)*

Шик юк, әгәр теләсә, ул без яши торган дөньяны, бөтен галәмне, күз ачып йомганчы әвәләп куйган булыр иде. Ләкин «ашыккан — ашка пешкән» дигәндәй, алай эшләми. Шул ук вакытта бик үк сузмый да. Һичбер төрле ару-талу белмәстән, ниятләгән эшен алты көн эчендә башкарып чыга.

*(Коръән, «Каф» сүрәсе, 37 аять.)*

Алты көндә бер дөнья! Тик менә көннәрнең нинди икәне әйтелмәгән. Ул көннәр без белгән 24 сәгатьлеме, әллә алланың үз көннәреме? Ә аның көннәре уһу нинди!.. Һәрберсе безнең мең елга тора.

*(Коръән, «Хаҗ» сүрәсе, 46 аять.)*

Ә «Баскычлар» сүрәсенең 4 нче аяте алланың бер көне Җирдәге көннәрнең 50.000 елы хәтле, ди.

Алла шулай ди. Ә соң кеше боларның кайсына ышанырга тиеш икән соң? Икесенә дә. Әйе, икесенә дә. Чөнки бу хакта алла безне кисәтеп, менә нәрсә ди:

«Шулай итеп, сез Коръәннең бер җиренә ышанып, икенче җиренә ышанмас идегезме икәнни? Андый кешеләргә кыямәт көн җәза яман каты булачак».

*(«Коръән, «Сыер» сүрәсе», 79 аять.)*

Димәк, әгәр син хак мөселман икәнсең, мең дигәндә шул меңгә, 50 мең дигәндә 50 меңгә ышанырга тиешсең. Көлке? Әйе, көлке. Аның каравы Коръәнчә, алла кушканча...

Димәк, алла дөньяны безнең исәп белән 6.000 елда һәм 300 мең елда ясаган булып чыга. Хәер, дөнья хәтле дөнья өчен анысы әллә ни күп түгел. Тик бу мәсьәләдә «Фәсаләт» дигән сүрәнең 8—11 аятьләре безне аптырашта калдыра. Фәсаләт — ачыклау дигән сүз. Ләкин ул ачыкламый, киресенчә, мәсьәләгә буталыш кертә:

«Син әйт аларга, — ди алла Мөхәммәт пәйгамбәргә, — җирне **ике** көндә яратучы аллага ышанмыйсызмыни? диген... Алла **дүрт** көн буена фатиха бирде, бөтен сораучылар өчен тигез итеп ризык бүлеп чыкты, шуннан соң күккә ашты да **ике** көн эчендә җиде катлы күк ясап куйды, диген». 2 + 4 + 2 = 6 түгел, 8 була, шулай ич? Хәер, анысы «вак» мәсьәлә. Сүрәнең хикмәте менә кайда: әүвәле күккә менә, аннары күкне ясарга кирәшә. Кеше теленә күчереп әйтсәк: башта өйгә кереп утыра, аннары өйне салырга керешә!..

Тагын төгәлсезлек, тагын хикмәт... Аның кебекләр алда күп очрар әле. Без андый «вак-төякләргә» күз йомыйк та, алланың дөньяны ничек-ничек итеп ясавы турында укып карыйк.

Әүвәл башлап, алла боламык сымаграк бер матдә изә. Нәрсәдән? — Юктан. Ничек? Шулай. Тели, «Бул!» ди. Матдә, ходайның рәхмәте, була да куя. Бу боламык сыман матдә эчендә өч төрле нәрсә бар: җир, су, күк. Алла шунда ук аларны сортын сортка аерып ташлый. Шуннан соң җирне түши. Игътибар итегез: ике кәррә түши җирне. Беренчесендә ул аны бала бишеге төсле итеп ясый. Аннан, ошатып бетермиме, бер тапкыр ясаганын онытып җибәрәме, — янәдән ясый. Бу юлы идәнгә келәм җәйгән кебек итеп җәеп сала.

*(Коръән, «Пәйгамбәрләр» сүрәсе, 31 аять; «Бизәкләр» сүрәсе, 9 аять, «Сыер» сүрәсе, 20 аять һәм башка бик күп сүрәләр, бик күп аятьләр.)*

Җәеп сала да, әле кешене ясарга өлгермәгәнен онытып, янында адәм заты бар төсле итеп мактанып куя:

«Күр, без нинди уңган төзүчеләр! Җирне ничек матур итеп җәйдек».

*(Коръән, «Таркатучылар» сүрәсе, 48 аять.)*

Ә ул җирне нәрсә өстенә җәя, җир ничек караңгы бушлыкка төшеп китми, диярсез. Китми шул. Чөнки алла моның хәстәрен алдан күргән була. Әлеге боламык сыман матдәдән аерып алган суны ялт җирнең астына китереп куя, шундук суга зур бер балык җибәрә, балык сыртына, күз ачып йомганчы, бер бик шәп үгез менгезеп бастыра [1].

Соң, җан ияләрен ясамады бит әле; балык белән үгез каян килде? — Анысы да «вак» мәсьәлә. Үгезнең зирәклегенә исең китсен синең. Балык сыртына менеп басуына җирне мөгезләре белән китереп тери. Бердән, ышанычлы булды, нык булды, икенчедән, күрер күзгә матур. Ә үгез ашарга иелгәндә, койрыгы белән чебен-черки куганда, кашынып куйганда җирне ялгыш аударып җибәрмәсен өчен, аннары бер урында гына торсын өчен, **алла җирне таулар белән әйбәтләп кадаклап куя.**

*(Коръән, «Балкортлары» сүрәсе, 15 аять, «Кырмыскалар» сүрәсе, 62 аять һ. б. бик күп сүрәләр, бик күп аятьләр, тагын «Фазаил шөһүр», Рабгузи, «Рисаләи газизә» китаплары.)*

Шуннан соң алла җир йөзен төрле-төрле хайваннар: сыер, сарык, кәҗәләр, атлар, ишәк, дөяләр вә һәртөрле җәнлекләр белән тутыра. Төрле-төрле кош-кортлар, бөҗәкләр ярата, безнеңчә әйтсәк, ясый. Шуннан соң алла җирдә төрле үләннәр, агачлар ярата, безнеңчә әйтсәк, үстерә.

Алары өчен рәхмәт. Бакчы, бөтенесе ярап куйды. Ләкин менә бүре белән аю һ. б. меңнәрчә төрле ерткычларны нигә ярата ул? Елан, күсе, тычкан, бака, юеш таракан, кырыгаяк, кандала, бет-борча кебек хәшә-

[1] Мондый әкиятләр бүтән халыкларда да бар. Диңгез буйларында тереклек итүче кайбер халыкларның ерак бабалары җирне өч кит балыгы сыртында тора дип уйлаганнар, һинд кешеләре фил күтәреп тора дип белгәннәр.

рәтләрнең кемгә һәм нигә кирәге бар? Тагын хәрәмнең дә хәрәме, шакшының да шакшысы каты борын — дуңгызның?.. Бөтен җир йөзен баскан кырыкмаса-кырык төрле чүп үләнен: билчәнен, кычытканын, тигәнәген, шайтан таягын ни дип ярата? Күпме интегә кеше алардан, күпме зыян-зәүрат күрә! Нигә ярата алла боларның барысын да? Ярата да, безгә аларны мактый-мактый тәкъдим итә бит әле:

«Күрдегезме, без яраткан нәрсәләр бөтенесе нинди гүзәл?»

*(Коръән, «Сәҗдә» сүрәсе, 6 аять.)*

Гүзәл генә түгел, Коръәнгә ышанган кеше бу хәшәрәтләрне Җирнең бизәкләре итеп тә танырга тиеш. Алла әнә нәрсә ди бит:

«Без җирдәге нәрсәләрнең бөтенесен җирнең бизәге итеп яраттык».

*(Коръән, «Мәгарә» сүрәсе, 6 аять.)*

Безнең хәзрәт мәрхүм, чебен пычраткан көзге бозып күрсәтә, калебе бозык кеше дә шулай: аның күзенә яхшы — яман, яман — яхшы булып күренә, ди торган иде. Бәлкем, биредә шундый хикмәттер, хәшәрәтләр безнең кебек калебе бозыклар күзенә генә шулай шыксыз, күңел кайтаргыч булып күренә торгандыр? Ул чакта әйттем исә кайттым...

Бер дуңгызны алла гүзәл диме, бизәк диме, аны ашау харам, ди. Нигә? Имештер, ул фәлән нәрсәләрне ашый әле. Хуш... ә тавык? Тавык фәлән нәрсә өстенә тагын фәлән-фәлән нәрсәләрне ашый түгелме соң? Селәүчән, ак корт, юеш таракан, тирес тараканы тавыкның иң яраткан ашлары... Бу исәптән, без мөселманнарга әнә тавыкны да тыярга иде. Аннары җиләк-җимешне, бодайны, арышны, һәртөрле үсемлек азыкны. Борын-борыннан бөтенесе ат, сыер, сарык һәм шул ук дуңгыз тиресе белән тукланып үсә бит!

Хайваннар турында тагын бер очы очка ялганмаган урын бар. «Нур» сүрәсенең 44—45 аятьләренең әйтүенә караганда, имештер, хайваннарның кайсы ике, кайсы дүрт аяк белән йөри, кайсы корсагы белән. Ә кырыгаяк, таракан ничә аяк белән йөри? Кысла, үрмәкүч, балык, әкәм-төкәм? Югарыдан түбәнгә караганда, бәлкем, алланың үзенә шулай күренәдер, тормышта исә корсак белән бер хайван да йөрми. Әйе, селәүчән белән елан да. Алар бөтен гәүдәләре белән җыерылып-сузылып йөриләр.

Ары киттек. Дөнья булганчы, андый куркыныч юк иде әле. Хәзер исә, карангыда ялгыш берәр нәрсәгә килеп бәрелүең бик мөмкин икән ич. Була бирсен!.. Алла бер дә аптырап калмый, тота да якты ясый.

Белдем, күккә Кояш элеп куя, диярсез. Юк шул. Күк үзе дә юк бит әле. Ә якты дигән нәрсәне алла бик ансат әмәлли. Теге боламык сыман матдәдә җир, күк, су булган кебек, ходайның рәхмәте, караңгы эчендә якты да бар икән. Әйе, әйе, менә дигән якты!.. Шул, караңгыдан яктыны аера да ала. Дөнья гөлт итә. Рәхәтләнеп йөр!

Туа мөгез чыкмый, тора мөгез чыга. Кара, бераздан, дөньяны төзеп бетереп, кеше ясагач, миңа көн белән төн дигән нәрсәләр дә кирәк булачак икән лабаса, ди алла. Ә аны без менә болай итәбез... Алла яктыны янәдән караңгыга куша, — менә сиңа төн; аерып ала, менә сиңа менә дигән көн!..

*(Коръән, «Фәрештәләр» сүрәсе, 14; «Гыймран» сүрәсе, 26 һ. б. күп сүрәләр, бик күп аятьләр.)*

Чыннан да, бик әйбәт булды бит әле бу. Тагын шунысы: бер атуда ике куян!..

Шулай әйбәт кенә килгәндә, алла әкиятнең кызыгын җибәрә дә куя:

«Без төн белән көнне тигез итеп (уникешәр сәгать итеп — Г. Г.) бүлдек», ди ул.

Ә бит чынлыкта, мәсәлән, безнең якларда төн җәй айларында 4—5 кенә сәгать була түгелме? Котыпта исә төн тоташтан 5—6 ай дәвам итә.

Бәлкем, күзгеләребез тагын дөрес күрсәтми торгандыр... Инде дөрес күрсәтә икән, бу Коръәннең наданлыгы булу белән бергә, алланың бик зур гаделсезлеге дә. Ник дисәң, алла «Балкортлары» сүрәсендә: «Без төнне йоклар өчен яраттык»,— ди. Димәк, котып кешесе 5—6 ай йоклап ятарга, аннары айлар буена йокламаска тиеш була.

Менә тагын бер гаделсезлек. Һәр мөселман рамазан аенда көндез ураза тотарга тиеш бит. Ә Котыпта көндезнең бөтенләй булмавы мөмкин, димәк, анда кеше ураза тотмаска, яки тоташтан алты ай буе ураза тотарга тиеш!

Төн ясаганнан соң алла теге боламык сыман нәрсәдән аерып алган күкне, гөмбәз кебек ярымтүгәрәк итеп, җир өстенә каплап куя. Я, кайсыгыз начар дияр? Әнә нинди матур бит ул, карап туйгысыз... Гомерлеккә бит, булган-булсын, нык матдәдән **җиде кат итеп түши** алла күкне.

*(Коръән, «Каф» сүрәсе, 6 аять.)*

Күкне? **Җиде кат** итеп? Бәлкем, җиде кат диюе алланың шагыйрәнә тасвирлап әйтүе генәдер? Түгел. Шунысына кадәр язылган. Беренче катын яшел зөбәрҗәттән түши алла, икенче катын энҗедән, өченчесен кызыл якуттан, дүртенчесен көмештән, бишенчесен кызыл алтыннан, алтынчысын сары алтыннан, җиденчесен нурдан түши. Аннан һәр катына һәйбәтләп капкалар уеп чыга [1]. Уя да тагын бер кәррә мактанып куя:

«...Без эшләгән әйбернең килмәгән җире булмас, әнә кара, җиде кат җирнең берсендә бер ярык таба алмассың».

*(Коръән, «Төркемнәр» сүрәсе, 63 аять, «Патшалык» сүрәсе, 3 аять, «Кассас-эл-әнбия», 6—7 битләр.)*



[1] Имештер, без кылган догалар аллага әнә шул капкалар аша үтеп менә. Берәр нәрсә үтенеп кылган догаң кабул булмаганда мулла абзыйлар шул җиде капкага сылтаучан: «Догаң күк капугысы ябык чакка туры килгән, мелла кем... Шул сәбәпле аллаһ тәгалә хозурына барып җитмәгән... Син фәлән сәгатьләрдә фәлән доганы укып кара әле, анысы, шәт, иншалла җитми калмас...»

Шуннан килеп, алла күкнең аскы катын йолдызлар белән бизәп чыга.

Биредә алла шулай ук бер атуда ике куянга тидерә. Бу йолдызлар күк бизәге булып кына калмый. Дөнья төзелеп беткәч, алланың гарешенә, ягъни тәхетенә якын килгән шайтаннарны, пәри-җеннәрне куып җибәрү өчен дә ярап куячак.

Ышанмыйсызмы? Менә үзегез укып карагыз:

«...Чынлыкта без аскы кат күкне матур йолдызлар белән бизәдек. Төрле фетнәче шайтаннар, фәрештәләрнең сөйләшкәннәрен тыңларга дип, күккә менә башласалар, без аларга шул киртләч читле ялкыннарны ыргытачакбыз...».

*(Коръән, «Сафтагылар» сүрәсе, 5—10 аятьләр, «Патшалык» сүрәсе, 5 аять.)*

Бу мәсьәләдә әле тагын шунысы хикмәтле. Күк шундый авыр һәм каты әйбердән ясалса да, бер терәүсез тора, ишелеп төшеп, җирне чәлпәрәмә китерми, аның өстендәге җан ияләрен изеп ташламый. Һәм бу эше белән алла янәдән бер мактанып куя:

«Үзегез дә күреп торасыз, җидесенә бер терәү юк бит, җидесенә бер терәү... Ә шулай да ишелеп төшми».

***(Коръән, «Күк күкрәү» сүрәсе, 2 аять.)***

Әйтергә кирәк, алла гомумән мактанырга ярата. Берәр яңа нәрсә ясаган саен мактанмый калмый. Хәер, табигате шундый икән, мактанырлыгы бар икән, мактана бирсен, аннан безгә ни зыян! Ләкин алла соңгы очракта урынсызрак мактанып ташламады микән? Терәүсез дә ишелми, дигәнен онытып, «Хаҗ» сүрәсенең 64 аятендә күкне һәрвакыт үз куллары белән тотып торганын әйтеп ташлый. Тагын каршылык. Һәм бу каршылык безнең кызыксынуны көчәйтә. Без ары китәбез.

2

## МЕСКЕН КОЯШ. АЙ НИГӘ КИРӘК? ҖИР ТҮГӘРӘК ДИГӘН ӨЧЕН...

Йолдызлардан соң алла Кояш белән Айны эмәлләп куя.

Яктылык караңгылык эченнән аерып алына торган булгач, көн дә төннән алына торган булгач, Кояш белән Ай нигә кирәк? — диярсез. Кирәк икән шул. Алла Айны күкнең нуры итеп элеп куя, Кояш лампа хезмәтен үти.

*(Коръән, «Нух» сүрәсе, 15 аять.)*

Биредә тагын бер атуда — ике куян. Дөнья төзелеп бетеп, җир йөзендә тереклек башлангач, кешеләр Айга карап вакытны, ягъни көннәрне белеп торачак, Хаҗның кайчан буласын беләчәк.

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 185 аять.)*

Ул Ай әле тагын хатын-кызларның күрем күрү мөддәтләрен әйтеп тору өчен дә кирәк булачак.

*(«Тәфсир Ногмани», 43 бит.)*

Ничек итеп? Аннары хатын-кыз ул кадәресен Айга карамыйча да белә бит. Изге китапның бу сүзен, күрәсең, болай аңларга кирәктер: Ул Шайтан тозакларына ышаныч юк, мөддәтләре тулганны синнән яшереп йөрүләре мөмкин. Ә Ай булгач, син күтәрелеп карыйсың да беләсең... әлеге дә баягы ничек беләсең? Изге китап, кызганычка каршы, иң кирәклесен әйтмәгән.

Шуннан соң алла бу «лампа» белән «нур»ны үзенә буйсындыра, һәр икесенең маршрутларын билгели. Шул көннән башлап алар һәркайсы алла тарафыннан билгеләнгән урынга йөреп торалар.

*(Коръән, «Локман» сүрәсе, 28 аять.)*

Ярый, алар шулай йөри торсын, сезнең белән без бераз тыныш ясап алыйк. Әгәр хәзерге заманда үтә динле, шул ук вакытта табигать белеме белән дә бераз таныш бер агайга, **кояш тәңренең бирмеш көне җир читендәге сасы суга төшеп байый** икән дисәк, сезнеңчә ничек, агай ышаныр идеме?.. Көләр генә иде, әйе бит? Яки барып чыккансың икән син, энем, дип тизрәк яныңнан таю ягын карар иде. Ә шул сүзне Коръән әйтә дисәк? — Коръәнне мыскыл итәсез, дип безне пыр туздырып сүгәр иде. Ә инде үзенә Коръәндәге «Мәгарә» сүрәсенең 84 аятен укып бирсәк? Анда болай диелгән:

«Кайчан Зөлкарнәйн Кояш баешына килеп җитте, **Кояшның бер сасы чишмәгә төшеп батканын күрде.** Бу чишмә янында кешеләр дә бар иде».

Хәзер агай ышану гына түгел, башта ышанмаганы өчен калебе тәмам пакьланганчыга кадәр тәүбә итәр иде.

Ә Ай нишли? Ул да шулай бер сасы суга төшеп батамы? Юк. Аның язмышы тагын да кызыграк. Ай һәр ай ахырында пальма агачының бөгелеп килгән иске ботагы кебек кенә булып кала.

*(Коръән, «Ясин» сүрәсе, 39 аять.)*

Заман ахры булгач, Ай сүнәчәк, сүнгәч, Кояш белән бергә килеп кушылачак. Әйтергә кирәк, бу дөнья бетеп, теге дөнья башлангач, Җир белән күк тә бетәргә тиеш. Алла Җирне сул кулына алачак, җиде кат күкне дә, җиде табак кәгазьне бөтереп төргән төсле төреп алып, уң кулына тотачак.

Анысын ахыр заман җиткәч күрербез... Ә хәзер алланың көн тәртибендәге эшләре белән танышыйк. Шулай итеп, аллача алты көн дигәндә, безнеңчә 6 мең яки 300 мең ел дигәндә Җир булды, суы булды, әнәтерә күге дә. Шуннан соң алла Җир белән җиде кат күккә хитап итеп:

«...Минем яныма килегез, үз ихтыярыгыз белән килсәгез дә ярый, ирексездән килсәгез дә сүз әйтмим», — ди. Һәм Җир белән җиде кат күк: «Үз ихтыярыбыз белән киләбез», — диләр. Алла аларның икесенә дә бурычлар йөкли.

*(Коръән, «Ачыклау» сүрәсе, 10—11 аятьләр.)*

Кызганычка каршы, ул бурычларның безгә мәгълүм ителгәннәре шулар гына:

Алла Җиргә су чыгарып торырга, болыннар үстерергә куша. Ә күккә көн саен бер тапкыр төн ясау, иртән таң аттыру бурычын йөкли.

*(Коръән, «Полкып случы» сүрәсе, 27—31 аятьләр.)*

Баш өсте, бөтенесе эшләнер, ди җир белән күк. Һәм икесе дә шунда ук үз вазифаларын үтәргә керешә...

Алла дөньяны әнә шул рәвешчә юктан бар итә.

Әйдәгез, юри генә ышанган булыйк. Ләкин тфү, тфү... тәүбә эстәгъфирулла... Ышанасың икән, юри генә ярамый, ихлас күңелдән ышанырга кирәк. Бөтенесенә, бөтен Коръәнгә, һәрбер хәрефенә бертигез ышанырга кирәк. Шикләнеп сөйләшергә димим, шигеңне күңелеңә дә китерергә ярамый. Ул чакта син кяфер, урының мәңге җәһәннәм төбендә. Мәңгенең нәрсә икәнен әйттем, җәһәннәмнең нәрсә икәнен алдарак белерсез. Ләкин шунысы куанычлы: алла җәза бирүче генә түгел, ихлас күңелдән тәүбә итсәң, «гафуррәхим» дә, безнеңчә әйтсәк, гөнаһларны гафу итүче дә. Әйдәгез шуңар исәп тотып, алланың үзе биргән акыл белән алда бәян ителгәннәр турында бераз фикер йөртеп алыйк.

Фән бик тиз алга бара. Фән түшәмнән алынган 7565 не хәзер бик ансат инкарь итә. Крестьян, атның тешенә карап, яшен әйтә белгән кебек, сугымчы бер караудa сыерның үлчәвен әйтә алган кебек, хәзер фән Җирнең «Әнба-эл-әнбия»дә әйтелгәнгә караганда миллион тапкырлар

картрак икәнен, аның 6 миллиард 500 миллион яшьләрдә икәнен бик күп, бик ачык мисаллар нигезендә әз-мәз генә булса да укыган кеше төшенерлек итеп исбат итеп бирде. Җирнең Тәүрат, «Әнба-эл-әнбия»-ләрдә, Коръәндә әйтелгәнчә, бишек кебек дигәнен, анысын «онытып», палас кебек яссы дигәнен 2500 ел элек бөек Пифагор, аңардан 200 ел соң яшәгән бөек Аристотель үк инде инкарь итеп, аның түгәрәк икәнен исбат иткәннәр. Шуны ук исбат иткән өчен Флоренция галиме Чекко д Асколине яндырып үтергәннәр. Обсерватория салган өчен үзбәк ханы Олуг Бәкне ерткычларча җәзалап үтергәннәр. Ләкин галимнәр аңар карап өрекмәгәннәр. Бөек поляк астрономы Коперник, бу мәсьәләдә тагын да алгарак китеп, 1543 елда Җирнең бернинди дә таулар белән кадакланып куелмаган икәнен, аның үз «күчәрендә» туктаусыз әйләнеп торуын, төн белән көннең алмашынып торуы шуңардан килүен, шул ук вакытта Җирнең бертуктаусыз Кояш тирәсендә әйләнеп йөрүен һәм елга бер тапкыр Кояш тирәли әйләнеп чыгуын исбат иткән.

Бу — гаҗәп зур гыйльми ачыш. Моңар баштарак хәтта галимнәр дә бик үк ышанып бетми. Шул ук вакытта бу динчеләр өчен тиңдәше булмаган зур югалту, бөтен диннәрнең, шул җөмләдән ислам диненең тамырына балта чабу иде. Аңар каршы бөтен дин әһелләре, дөньядагы бөтен динчеләр күтәрелеп чыкты.

Җир түгәрәк?! Карбыз кебек?! Әлгаязе билләһи... Карбыз кебек булгач, аның менә бу төшендәге кешеләр ничек егылып төшми?! Кеше чебен түгел ләбаса. Ә өйләр... сулар?..

Коперник тарафдарларын эзәрлекләү башлана. Мәчет, чиркәү, синагогларда бу мөртәт исеменә бәддога укыйлар. Коперник ачышын халыкка таратып йөргән өчен Италиянең бөек акыл иясе Джордано Бруноны 1600 нче елда Рим мәйданына алып чыгып, халык алдында яндырып үтерәләр.

Хәзерге көндә инде бөек Коперник ачышын динчеләр үзләре дә инкарь итә алмый. Соңгы елларда самолетлар Җир шарын аркылы-торкылы әйләнеп чыккач, бигрәк тә Гагариннар ракеталарда Җирне берничә кабат әйләнеп төшкәч, иң кара эчле, иң надан мулла-монтагайлар да Җирнең палас кебек булуына, диаметры 12.500 километрлы, әйләнәсе 40.000 километрлы, өске мәйданы 510 миллион квадрат километрлы бу гигант шарның үгез мөгезендә торуына ышанмыйлар булса кирәк.

3

## ӘНӘ ГЕНӘ БИТ УЛ. ТЕЛӘСӘ НӘРСӘ БЕЛӘН АНТ ИТ, ЫШАНДЫ ЮК.

Инде алланың күк хакында биргән мәгълүматлары турында бераз фикер йөртеп алыйк.

Күкнең Җирдән ничә километрда икәне Коръәндә анык итеп әйтелмәгән. «Тау» сүрәсенең 38 нче аятенә караганда, әллә ни биек булмаска тиеш. Бу аятьтә алла шайтаннарның фәрештәләр сөйләшкәнне тыңлап торыр өчен күккә менәрлек баскычлары булмаганын әйтә. Бәс, сүз күккә менә торган баскычның булуы-булмавы турында бара икән, димәк бик биек булмаска тиеш. Моңа тагын бер дәлил: Вавилон кешеләре күккә манара ясап менә башлагач, алла боларның манараларын чәлпәрәмә китереп ташлый.

Бу ике аять, бигрәк тә соңгысы, бернинди техникасы булмаган Вавилон халкының, алла юл куеп торса, күккә җитәрлек баскыч яки манара ясарлыгы булганны сөйли түгелме? Бәхәссез, шуны сөйли.

Бу аятьләрнең Җирнең үгез мөгезендә торуы кебек үк бер әкият икәнен фән мең еллар элек исбат иткән булса да, «кара халык» арасында

шуларга ышану озак яшәп килә әле. Һәм бу гаҗәп тә түгел. Чыннан да, әнә генә төсле бит ул күк.

Ләкин кеше акылы иҗат иткән самолетлар уннарча километрларга күтәрелгәч, күкнең «әнә генә» булуына, баскыч яки манара ясап менәрлек якын булуына ышану какшый башлый. Ә инде Гагариннарның 200—300 километрга күтәрелгәннәрен күргәч, күкнең манара ясап менәрлек кенә, «әнә генә» булуына, белмим, ышанучы калды микән...

Ә Гагариннар күкнең Коръәндә әйтелгән «беренче катына» да менмәде бит әле. Хәтта Кояшка хәтле генә дә күтәрелмәде. Ә Кояш белән Җир арасы 150 миллион километр. Йолдызларның исә безгә иң якын дигәне — Кояшка караганда 270 мең тапкыр ераграк. Арада шундыйлары бар, нурлары безнең Җиргә ун мең ел килә. Аның никадәр еракта икәнен әйтү өчен кешеләр куллана торган гади саннар җитми. 150 миллион километрдагы Кояш нурларының җиргә нибары 8 минут 18 секунд килгәнен хәтерләсәк, ул йолдызларның кайларда икәнен берникадәр күз алдына китереп булыр.

Күрше галактикалар турындагы мәгълүматлар бөтенләй хәйран калырлык. 1963 елның маенда «Известия» газетасы совет астрономнарының күктә моңарчы билгеле булмаган йолдыз күреп фотога төшереп алулары турында хәбәр итте. Галимнәр мотлака берничә көн эчендә бу иң яшь йолдызның ераклыгын, күләмен, энергиясен билгеләделәр. Аның яктысы һәм кызуы безнең Кояшныкына караганда 25 миллион тапкыр көчлерәк, бу йолдызның галимнәр бүген күреп алган нуры моннан 30 миллион ел элек юлга чыккан! Ягъни йолдыздан ядро энергиясе бәреп чыккан вакыттагы ялкын яктысы безгә 30 миллион елдан килеп җиткән!

Әйтәсем килгәне: бәс, шулай икән, алла ул «җир бизәкләрен» нигә дип шул хәтле биек менгереп элгән? Аларның Җир өчен бернинди бизәк була алмауларына фәкать көчле телескоплар аша гына күрергә мөмкин икәнлекләрен дә өстәсәк, бу гаҗәпләнү бездә тагын да артыр.

Күк әнә шундый биек. Вавилон кешеләре манараларын, алла тора торган җиденче кат күккә димим, әнә шул иң якын йолдызга хәтле генә сузарга теләсәләр дә, бертуктаусыз берничә мең миллиард еллар буена эшләргә тиеш булырлар иде. Ә анлык төзү материалы? Ул хәтле материалны казып алу өчен безнеке кебек берничә миллиард Җир кирәк булыр иде. Бәлкем, алар бу эшкә белмичә, «әнә генә» дип керешкәннәрдер? Шулай да булсын. Ә соң алла? Аларның менеп җитәлмәсләрен ничек белмәгән ул, белгән сурәттә манараларын ни дип җимереп ташлаган? Менә бу сорауга нә Коръәндә, нә дин әһелләрендә җавап юк... Инде менделәр дә ди. Менеп нишли ала соң алар? Алла нигә аларның менүләреннән шулкадәр курка? Моңар да җавап юк.

Инде алланың яктыны караңгыдан аерып алуына, күкнең көн белән төн ясап торуына килик. Без борынгы кешенең бу әкияткә ышанып йөрүенә шулай ук гаҗәпләнмибез. Элегрәк хәтта фән ияләре дә, Кояшны Коръәндә әйтелгәнчә, лампа кебек бер яктырткыч кына дип уйлаганнар. Яктылыкның чыганагы Кояш икәнне белмәгәннәр. Хакыйкатьне, беренче булып, 1675 елны Дания астрономы Оле Ремер ача. Ул Җир шарын яктыртып торучының нәкъ Кояш икәнен исбат итә. Шулай итеп Коръәннең табигать күренешләре турындагы тагын бер ялгышы фаш ителә: Кояш чыга — көн була, бата — төн була. Алланың «Кояш сасы суга төшеп байый» дигәне дә тавыклар көләрлек бер мәзәк әкият кенә. Җир йөзендә Кояш төшеп батарлык су юк һәм була да алмый. Безгә җиз поднос хәтле генә булып күренгән Кояш җиргә караганда бер миллион өч йөз мең мәртәбә зуррак. Чебен карынына фил сыймаган күк, җирдәге бер болганчык суның да Кояшны үз эченә сыйдырыр чамасы юк.

Күп кенә дини китаплар, риваятьнамәләр Кояш баюны әле тагын

болай дип аңлаталар. Имештер, Кояш күк читенә төшеп җиткәч, фәрештәләр аны иплән кенә тотып алып, җир эче буйлап көнчыгыш якка йөгерәләр һәм иртәнчәк күккә меңгезеп җибәрәләр... Монысын да тузга язмаган әкият икәнен фаш итү өчен алдагы дәлилебез җитсә кирәк.

Әйтергә кирәк, биредә «байый» яки «бата» сүзе үзе дә хилаф сүз. Без Кояш бата сүзен хәзер туры мәгънәсендә кулланмыйбыз. Чынлыкта Кояш беркая да батмый. Ягъни ул бер секундка да күк йөзеннән төшеп тормый. Җир әйләнгәнлектән Кояш безгә, мәсәлән, Казан шәһәрендә баткан кебек күренә, ә бу вакытта Мәскәүдә ул әле рәхәтләнеп Кремль өстенә карап елмаеп тора. Ә Америкада? Америкага җиде-сигез сәгатьтән соң да әле үзенең нурларын коячак. Бераз үтүгә безнең Сахалин өстенә килеп чыгачак.

Коръәннең «Ай һәр ай азагында кәкрәеп килгән иске пальма ботагы кебек булып кала» дигәненә борынгы кешенең ышануы шулай ук бер дә гаҗәп түгел. Кеше үзе дә Айның азакка таба кечерәеп баруы хакында бик күп әкиятләр чыгарган. Мәсәлән, Хуҗа Насретдиннан: «Яңа ай тугач искесен кая куялар?» — дип сорыйлар. Бу: «Турап йолдыз ясыйлар»,— дип җавап бирә. Бүгенге көндә аның тузга язмаган бер әкият икәнен исбат итеп тору кирәкме? Инде килеп, безнең спутниклар Айның кире ягының фоторәсемен дә алып төшеп күрсәткәч [1], өстенә безнең кешеләр вымпел да кадап куйгач, якын киләчәктә анда кешеләр менәргә җыенганы мәгълүм булгач, Коръән әкиятенә иң надан, иң кара муллаМонтагай да эченнән генә булса да шикләнеп карый башлаган булса кирәк.

Коръәндәге һәр әкият кебек Ай әкияте дә, әлбәттә, безне алланың кодрәтенә шаккатыру максаты белән язылган. Ләкин без шаккатмыйбыз, көләбез генә. Чөнки әкият Коръәннең табигать белемнәреннән хәбәрдар түгеллеген фаш итү булып чыккан. «Ясин» сүрәсенең 40 нчы аятендә әйтелгәнчә, Кояшның Айны куып җитә алмавына карата да шуңардан җылы сүз әйтеп булмый. Ничек куып җитсен?! Кояш бит, алла уйлаганча, Ай артыннан йөрми. Гомумән, йөрми Кояш. Ә Ай, башка планеталар кебек, туктаусыз аның әйләнәсендә әйләнеп йөри!..

Коръәннең йолдызлар турында биргән мәгълүматларын шулай ук фән янына китерерлек түгел. Беренчедән, йолдызлар, Коръәндә әйтелгәнчә, берьюлы барлыкка килмәгән. Урманда агачлар бер яшьтә булмаган кебек, йолдызлар да бер яшьтә түгел. Кайберләре инде берничә миллиард яшьләре белән баралар, кайберләренә әле миллион да тулмаган. Монысы әле «вак» мәсьәлә. Зурысы менә кайда. Имештер, алла йолдызларны күк йөзен бизәр өчен элеп куйган, тәхетенә шайтаннар, җеннәр якын килә башласа, алла, арадан берәр йолдызны алып, шалт башларына!.. Бу бит, алланың Мюнхаузенны бөтенләй бетереп ташлый торган чираттагы мәзәге! Инде алла моны, чыннан да, җитди мәгълүмат димәкче була икән, гафу итсен, без тагын көлмичә булдыра алмыйбыз. Менә уйлап карагыз: чагыштырмача юк кына бер Җир шарын бизәр өчен «элеп куелган» йолдызларның астрономнар тарафыннан фоторәсемгә төшереп алынганнары гына да бер миллиардка җитә. Ә җәмгысе (безнең галактикадагылары гына) 120 миллиард! Инде зурлыкларын күз алдына китерегез. Кояш Җирдән бер миллион 300 мең тапкыр зуррак. Үлчәве Җир, Ай, Меркурий, Плутон һ. б. планеталардан 750 тапкыр авыррак. Ә шул искитмәле зур Кояш кайбер йолдызлар белән чагыштырганда дөя янындагы төймә кебек кенә булып кала. Имештер, алла шайтаннарны куар өчен шул хәтле күп, шул хәтле зур йолдызлар әзерләп куйган!..

---

[1] Бу вакыйга Айның безгә нәкъ пальма ботагы кебек булып калган көннәрендә була, ә спутник төшереп алган рәсемдә ул үзенең ундүртенче кичәсендәге кебек түп-түгәрәк иде.

Үпкәләсә үпкәләр, алланың бу сүзенә дә ышана алмыйбыз. Алла чыпчык башы тикле таш ыргытса да, шайтаннар тамталлар арасына мәтәлеп барып төшәчәк бит! Таш ыргытмыйча, «киләсе булма!» — дип бер нәгърә орса да, шайтан дигәнең күккә ике аягының берсен атлаячак түгел.

Инде йолдызларның җирне бизәр өчен эленгән булуы турында. Чамадан тыш бай патша булып, аллача эшләсә, ягъни бер өен яктырту өчен өеннән миллиард мәртәбә зур лампалар эшләтеп, миллиард километр биеккә менгереп элеп куйса, аның турында нәрсә уйларлар иде икән?

Әгәр алланы чыннанда бар дип белсәк, без аңар болай дияр идек. Юк, син биредә юкка шул хәтле материал исраф иткәнсең. Хәзерге төзүчеләр белән киңәш итәргә иде сиңа, алар йолдызлар санын миллион тапкыр гына булса да кимрәк ясарга, ичмаса, берничә миллиард тапкыр кечерәк итеп ясарга, берничә миллиард тапкыр түбәнрәк төшереп эләргә киңәш бирерләр иде. Аннары ул йолдызларны ул кадәр кызу итмәсәң дә була, диярләр иде безнең төзүчеләр. Чыннан да, кайберсенең кызуы миллион градусларга җитә бит. Тотып алып ыргытканда димим, Казан белән Мәскәү арасы кадәр якын килсәң дә кулың белән бергә үзең дә көеп үлмәле. Хәтта нурына гына да түзә торган түгел. Нурларының Кояш нурына караганда 300 мең тапкыр көчлерәкләре бар. Алла әйткәнчә, чите киртләч тә түгел ул йолдызларның. Самолетта очканда шәһәр утлары безгә киртләч читле булып күренәме, бу да шулай. Укучыга тагын шунысы мәгълүм булсын: нуры шундый көчле, температурасы шундый кызу булса да, йолдыз каты әйбер түгел, үзенә бер төсле тыгыз газ гына. Ягъни тотып алып ыргыта торган түгел.

Аннары, Ай белән Кояш батмаган кебек, йолдызлар да беркайчан батмыйлар. Ә алла аларның батуы турында Коръәндә берничә тапкыр әйтә. Хәтта аларның бата торган җирләре белән ант итә.

«Йолдызлар төшеп бата торган җирләр белән ант итәм», — ди ул.

Шул ук вакытта алла моның тегенди-мондый гына ант булмавын кисәтеп куя: «Беләсегез килсә, бу бөек ант».

*(Коръән, «Төшүчеләр» сурәсе, 74 аять.)*

Теләсәң нәрсә белән ант ит, алла! Ә без йолдызларның батуына ышана алмыйбыз, аларның кирегә хәрәкәт итүләренә дә ышанмыйбыз. Җир таулар белән кадаклап куелган, Ай да Кояш кебек бер яктырткыч, дигәнгә дә ышанмыйбыз хәзер без. Ай — Җир кебек үк суык бер түгәрәк нәрсә, күләме кояштан 5.200.000 мәртәбә кечерәк, ди фән. Әлбәттә, фән белән бертөрле дә алыш-биреше булмаган кешене моңар ышандыру кыен. Андый кеше әле Коръәнгә ышана. Беренчедән, алла сүзе дип белгәнгә, икенчедән, күрер күзгә дә шулай ич. Икесе дә якты, икесенең дә күләме бер, бер үк биеклектә. Ә шул ук фән казанышларын үз күзе белән күрә башлагач, кешенең карашы уңай якка үзгәрә. Фән, 10—20—30 елдан фәлән сәгатьтә, фәлән минутта, фәлән секундта кояш тотыла, ди. Нәкъ шулай була. Фән Мәскәүдәге Май бәйрәмен, яисә Америкада негрлар демонстрациясен шул ук мизгелдә безнең өебезгә китереп күрсәтә, чәчми-түкми сүзләрен алып килә. Фән кешене әллә ничә йөз километрларга күтәреп, Җир әйләнәсендә очырып йөртә, фән кешенең күктә очып йөргәнен безнең өебезгә кертеп күрсәтә, тавышын ишеттерә, җирдәге фән күктә очып йөргән кешенең йөрәк тибешен саный, температурасын үлчи. Тиздән планетадан планетага, самолет белән шәһәрдән шәһәргә йөргән кебек йөри башлаячакбыз. Бу нәрсәләр кешенең күзенә күренеп килә. Шуңар күрә кеше, хәтта бөтенләй надан булса да, моңар ышанмый булдыра алмый. Ә дин әһелләре койрыкларын кыса.

Соңгысы. Заман ахыры булгач, алланың Җирне бер кулына алуына, шул кадәр йолдызлары белән бергә күкне табаклы кәгазь урынына

төреп, икенче кулына тотуына юри генә ышандык та ди. Бәс, чикләнмәгән кодрәт иясе икән, бөтенесен юктан бар итә алган икән, анысын гына эшләр дә диик. Ә менә Ай белән Кояшны бергә китереп кушуы?.. Соң, бу бит биеклеге биш километрлы Эльбрус тавына бүрек хәтле бер кырмыска түмгәген китереп кушу була түгелме? Шуны кушу дип әйтеп буламы? Тагын шунысы бар: Ай Җир кебек үк бер салкын әйбер. Ә Кояшның кызуы 6 мең градус! Кояш Айны, үзенә кушу түгел, миллион километрдан да кызган табага төшкән кар бөртеге урнына күз ачып йомганчы көйдереп бер уч көл итеп калдырачак бит!

Күк җиде кат булып, Җир белән Кояшның берәр генә булуына да ышанмыйбыз без хәзер. Безнең Кояш системасында гына берәр алар. Ә галәм киңлегендә безнең Җиргә, үсемлекләргә, барчабызга тереклек бирә торган Кояш кебек кояшлар берничә миллиард! Һәм безнең Җир безнең Кояш тирәсендә әйләнгән кебек, ул кояшлар тирәсендә дә миллиард җирләр әйләнеп йөрүе, аларда да безнең кебекме, бүтән төрлеме, кешеләр яшәве дә гаҗәп түгел.

Алла, үзенең кодрәтен күрсәтеп, безне шаккатыру максаты белән Коръәнгә әкиятләрне дыңгычлап тутырган. Ләкин без аларны укып, алланың кодрәтенә түгел, фәкать Мюнхаузенлык сәләтенә шаккатабыз.

Дин китаплары исә шаккатыризм мәсьәләсендә алланың үзеннән дә уздырып җибәрәләр. «Алла — диләр алар, — галәм киңлегендәге бөтен әйберләрне, Кояш, Ай, йолдызларны, җиде кат Җирне, җиде кат күкне, хайваннарны, кешеләрне — бөтенесен бер чикләвек кабыгына бөтереп тыга ала. «Рисаләи газизә» дигән дини китап тагын да күпертә төшә. Бу китапның раславынча, алла, әгәр теләсә, әйберләрнең күләмнәрен кечерәйтмичә дә чикләвек кабыгына тыгып куя ала, анда да чикләвек кабыгының бөтен эченә түгел, бер читенә генә!.. Алайса чикләвек кабыгын бихисап зурайта торгандыр дип уйлый күрмәгез. Киресенчә, кечерәйтә әле!..

Тагын бер мисал. Коръәннең Җирне җиде кат диюеннән илһам алып, «Рисаләи газизә», «Фазаил шөһүр», «Алты бармак», Рабгузи китаплары шундый тузга язмаган әкият уйлап чыгаралар.

«Җирнең һәрбер кат белән кат арасы 500 еллык юл. Икенче катында җеннәр, өченчесендә адәм чырайлы, эт затлы, үгез аяклы кешеләр яши. Дүртенче каты — җәһәннәмгә керәчәк кешеләрне газаплар өчен әзерләнеп куелган күкерт. Бишенче катында елан — чаян. Һәрберсе дөя хәтлеләр. Эчләрендә 160 төрле агу бар. Җир йөзенә бер тамчысы тамды исә, бөтен җан ияләре һәлак була. Алтынчы катта җәһәннәм еланнары. Җиденчесендә — Иблис. «Тәхетенә менеп утырмыштыр. Тирә-ягында атлы һәм җәяүле гаскәре йөреп тормыштыр. Җәмгы барчасы Иблис ләгыйнгә табынмактыр...»

Хәзерге заманда тузга язмаган бу әкиятләргә мулла-монтагай үзе дә ышанмый, әлбәттә, бары ышанган булып кылана гына.

Коръәннең табигать турындагы мәгълүматлары гомумән сабыйларча беркатлы. Мәсәлән, аның диңгезләр турында бөтен белгәне ике — өч аятькә сыеп беткән. «Ике диңгез бер-берсенә охшамаган, берсенең суы эчәргә тәмле, рәхәт, җиңел, икенчесенең тозлы, әрем әчеле...»

*(Коръән, «Фәрештәләр» сүрәсе, 13 аять.)*

Алла ике диңгезне бер-берсенә кушылдырмый, араларында киртә бар. Икесеннән дә энҗе белән мәрҗән чыга.

*(Коръән, «Фәрештәләр» сүрәсе, 13 аять, «Рахман» сүрәсе, 19—22 аятьләр.)*

Коръәнне язучы, күрәсең, үзе күргән-белгән Гарәп диңгезе белән Кызыл диңгезне яки Персия култыгын күздә тоткан. Ә бит дөньяда әле

тагын дистэлэрчэ диңгезлэр һәм 5 океан бар, алары Коръән авторы өчен генә юк. Сабый өчен дә үзе яшәгән шәһәр яки авыл белән тирә-юньдәге берничә авылдан гайри авыллар булмый бит.

Коръәнчә, диңгездә энҗе-мәрҗән дә балык кына бар. Ә анда, санап карасаң, 150 мең төрле «җан иясе» яши, 10 мең төрле үсемлек үсә.

Диңгез искиткеч бай. Мәсәлән, кобальт дигән мәгъдән запасы бөтен коры җирдә 1 миллион тонна исәпләнә, ә диңгез төпләрендә ул 2 миллиард тонна булып, кеше кайчан төшеп алыр икән дип көтеп ята.

Алланың диңгезләрнең берсе тозлы, берсе тозсыз диюе дә хилаф сүз. Күрәсең, ул ялкау хатыннар шикелле, ясаганда тәмен татып карамаган, ә соңыннан Коръәнгә язарга кирәк булгач, берәр дельта читенә ятып эчеп карау белән чикләнгән. Дельтада, дөрес, суның тозсыз булуы табигый. Ә аллага диңгезнең эченәрәк кереп, тирәнрәк төшеп эчеп карарга иде... Диңгез суының иң тозсыз дигәнендә дә тоз 8 процент тәшкил итә. Кызыл диңгез суында исә тоз 40 процент!..

Алланың ике диңгез арасына куйган «киртәсе» коры җир булса кирәк. Анысы ярый, образлы итеп әйтергә тырышкан. Ләкин ул киртәне җимерелмәслек итеп ясадым дию коры шапырыну түгел микән? Ник дисәң, Урта диңгез белән шул ук Кызыл диңгез арасында да, тагын Тын океан белән Атлантик океан арасында да, тагын Идел белән Дон арасында да андый «киртәләр» бар иде. Кешеләр килеп җимереп аттылар да бик әйбәт су юллары ачтылар. Кирәк тапсалар, әлбәттә, алла әйткән ике диңгез арасындагы «киртәне» дә җимереп ташлап, берәр нәрсә әмәлләп куярга күп алмаслар.

Чү, бу инде фикер йөртү генә түгел, алла белән бәхәскә керү, алланың бөтен эшен юкка чыгару булып китте түгелме соң? Тәүбәгә килик, алдыбызга Коръәнне ачып салыйк.

## 4

## АЛЛА КЕМ ТӨСЛЕ? АЛЛАНЫҢ СУДТА БУЛУЫ. ҖИРНЕҢ ЧИТ-ЧИТЕН КИСЕП ЙӨРҮЕ һ. Б. ӘКӘМӘТЛӘР.

Җирне, һаваны, суны, хайваннарны юктан бар иткәннән соң, алла, ниһаять, җиденче көнне тәхетенә менеп утыра.

*(Коръән, «Сәҗдә» сүрәсе, 3 аять.)*

Һәм бу безгә аның үзе белән бераз танышып алыр өчен иң җайлы вакыт. Бер карасаң, чикләнмәгән кодрәт иясе, бер карасаң, фән белән әз генә дә алышы-бирешe булмаган, бөтен әйткәне фән әйтүләренә каршы килеп торган зат үзе ни кыяфәтле соң?

Инҗилдә бу мәсьәлә бик ачык: «Алла кешене үзенә охшашлы итеп ясады» диелгән. Коръәндә бу юк, әдәби китаплардагы кебек ясап куйган портреты юк. Аның рәвеше турында дин әһелләре хәтта уйларга да кушмыйлар. Аны күз алдына китерергә мөмкин дә түгел, диләр. Ә безнең беләсебез килә һәм, актарына торгач, Коръәннең сүз арасында гына әйтеп киткәннәреннән чыгып, берникадәр күз алдына китерү бәхетенә ирешәбез.

Күкне алла баганалар белән терәтеп куймадым, үзем тотып торам диде бит. Димәк, куллары бар. Алла үзенең куллары бар икәнен кат-кат әйтә:

«Без күкне үзебезнең кулларыбыз белән ясадык», — ди.

*(Коръән, «Таркатучылар» сүрәсе, 47 аять.)*

Ничәшәр икәне генә әйтелмәгән, бармаклары да бар һәм алла аларга бик сәер эш йөкләгән: «Кешенең күңеле алланың бармаклары арасындадыр».

*(220 нче хәдис.)* [1]

Ә аяк?

«Менә кодрәт иясе (алла — Г. Г.) иң биек офык читенә килеп басты, якынайды...»

*(Коръән, «Йолдыз» сүрәсе, 6—7 аятьләр.)*

Кирәк булганда йөгерә дә:

«Алла әйтәдер: әгәр бер бәндә миңа атлап килсә, мин аның каршысына йөгереп барырмын, дип».

*(589 нчы хәдис.)*

Димәк, аякны да юк дип әйтеп булмый.

Тагын күрми дип белмәгез, күрә, ләкин каравы бик сәер: ул безне һәрдәм **посып күзәтеп тора.**

*(Коръән, «Таң» сүрәсе, 13 аять.)*

«Алла кеше белән вәхи аша яки чаршау артында торып сөйләшә».

*(Коръән, «Киңәш» сүрәсе, 50 аять.)*

Димәк, һәм күзе, һәм колагы, һәм теле бар булып чыкты! Менә әле генә тәхетенә менеп утырды, димәк, утыра торган җире дә бар. Ни өчен утыралар?.. Арганга. Ә ул утыра торган җир тагын нигә кирәк?.. Түбәндәге аятьләр бу сорауларны ачыклый төшә:

«Мин кешеләрнең миңа бирәр төрле өлеш чыгаруларын, **мине ашатып-эчертеп торуларын теләмим.** Алла үзе сезне ашатучы, үзе сезне ризыкландыручы».

*(Коръән, «Таркатучылар» сүрәсе, 57—58 аятьләр.)*

Күрдегез, миңа өлеш кирәкми, дими, ашарга кирәкми, дими... Моннан соң алланың ашказаны, эчәкләре юк дип әйтеп буламы? Дөресрәге, кеше ашаучы түгел дип әйтеп буламы алланы? Әйе, әйе, кеше ашаучы түгел дип... Коръән әнә нәрсә ди бит:

«...Алла әгәр теләсә (теләмәсен генә инде...), **сезнең белән бергә җирнең бер өлешен кабып кына йотар иде».**

*(Коръән, «Исраил балалары» сүрәсе, 70 аять.)*

Ә түбәндәге аятьтән соң аның тагын кайбер әгъзалары юк дип әйтергә урын каламы?

«...Аллага бала кайдан килсен? Аның хатыны юк бит».

*(Коръән, «Хайван» сүрәсе, 101 аять.)*

Дин әһелләре маташтырганча, алла үзе турында, мин өйләнү кебек түбән гамәлләргә мохтаҗ түгел дими, хатыным юк кына ди! Димәк, югарыдагы аятьтән күренгәнчә, булырга да мөмкин, шулай ич?

Түбәндәге ике аятьне укыгач исә, без аның турында чын-чынлап өйләнеп, бала-чагалар үрчетеп ята бит бу мут дигән уйга килми кала алмыйбыз:

«Әллә сезнең аллагыз бер сезгә генә ир балалар биреп, үзенә хатынкыз фәрештәләр алганмы? Чынлыкта сез көфер сүз сөйлисез бит».

«Әллә кешеләрнең балалары ир булып, алланыкы кыз балалар дип беләсезме?»

*(Коръән, «Исраил балалары» сүрәсе, 42 аять, «Тау» сүрәсе, 39 аять.)*

---

[1] Хәдисләр бик күп, калын-калын берничә китаптан гыйбарәт. Аларны дин әһелләре безгә Мөхәммәт пәйгамбәр сүзләре дип тәкъдим итә. Бу хәдис һәм алда китереләчәк хәдисләр барчасы «Мең дә бер хәдис» исемле китаптан.

Ничек кенә боргалама, алланың баласы бар булып чыга, шулай түгелме? Берничәү һәм барысы да ир балалар!.. Бер үк, балаларын кыз дип кенә кимсетә күрмә, ачуын китерерсең.

Шул рәвешчә, төрле сүрә һәм аятьләрдән корыштыра торгач, алла безнең алга нәкъ безнең кебек кеше булып килеп баса. Бездә бар әгъзаларның бөтенесе бар. Димәк, аларның һәрберсе аңар кирәк. Димәк, ул аларсыз яши алмый һәм бу хәл аның чикләнмәгән кодрәт иясе булуын күз ачып йомганчы юкка чыгара. Кинаяләп, бутап әйтүе генә бар, нәкъ шул Инҗил алласы, христианнар алласы. Аерма тик шунда: христианча, алланың гәүдәсе безнеке чамасы. Коръәндәгенең — коточкыч зур... Без моны әле генә менеп утырган тәхетенә карап беләбез. Күкнең күләмен хәтерләгез. Алланың тәхете әнә шул күк хәтле, плюс безнең җир хәтле.

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 256 аять.)*

Бәс, тәхете шул хәтле икән, аның мөбарәк утыра торган җире ни хәтле була ди инде? Ә бөтен гәүдәсе?

Шундый мәһабәт гәүдәле затның куллары белән күкне тотып торуына хәзер инде кимрәк гаҗәпләнсәк тә ярый торгандыр. Ләкин монда анысыннан да шаккатыргыч нәрсә килеп чыкты. Алла күкне тотып тору өстенә, егылып төшмәсеннәр өчен, һавадагы һәрбер кош-кортны да үз куллары белән тотып очыра, тагын, бөтен хайваннарның ялларыннан тотып тора икән әле.

*(Коръән, «Һуд» сүрәсе, 59 аять.)*

Тик ялы юкларның, мәсәлән, ишәкнең, кай җиреннән тотып торганын әйтмәгән. Кызганыч, алай картина тулырак булыр иде. Хәер, анысы «вак» мәсьәлә. Монда бер сорау туа, ул һавадагы кош-кортларның, җирдәге хайваннарның бөтенесен тотып торырга кулы ничек җитә? Бәлкем, куллары күптер? Кайбер халыклар уйлап чыгарган аллаларның шулай бит. Юк, моның нибары ике кул. Нәкъ ике:

«Яһүдләр әйтә: алланың кулы бәйләнгән. Юк, аларның үзләренеке бәйләнгән, алланың ике кулы да як-якка җәелгән».

*(Коръән, «Ризык» сүрәсе, 69 аять.)*

Моннан 1100 ел элек яшәгән таҗик шагыйре бөек Әбелхәсән Рудакый Коръәннең мондый экиятләрен күздә тотып, безгә шундый киңәш бирә:

«Акыл күзе белән кара дөньяга син,
Маңгай күзе белән генә йөрмә карап».

Әйдәгез, бу бөек кешенең киңәшен тотып, маңгай күзе белән түгел, күңел күзе белән карап карыйк. Мәсәлән, шундый зур гәүдәле алланың без яши торган җиргә төшеп йөрүе мөмкинме?

Моңар ышану фил хәтле филнең кырмыска өстендә йөрүенә ышанудан да мәгънәсезрәк бер мәгънәсезлек булыр иде. Ә бәлки алла җиргә төшмәгәндер? Юк, төшкән. Менә үз сүзләре:

«Әллә күргәннәре юкмы, без бу җирдә булабыз һәм чит-читләрен кисеп йөрибез».

*(Коръән, «Күк күкрәү» сүрәсе, 41 аять.)*

Аны, алланы, борынгы кешеләр хәтта суд залларында да очрата булганнар, хәтта аның белән бергә, бер эскәмиягә утырып, судьяларның хөкем иткәннәрен карап торганнар. Тагын ышанмыйсызмы? Менә алланың үз сүзләре:

«Давыт белән Сөләйман игеннәрне таптаган хайваннарның хуҗаларын хөкем иткән судта без дә бар идек».

*(Коръән, «Пәйгамбәрләр» сүрәсе, 78 аять.)*

Менә, ичмасам, күңелле заманнар булган. Син утырасың, бу урын бушмы дип, үзенең күк хәтле плюс җир хәтле арты белән синең яндагы урынга алла агай килеп утыра!..

Коръән, алланың рәвешен шулай сурәтләп килә-килә дә, мин нишләдем, нәкъ кеше төсле килеп чыкты бит дип, аны бөтенләй күз алдына китереп булмый торган кыяфәткә кертә:

«Алла — күкләрнең һәм җирнең яктысы, — ди хәзер Коръән, — анын яктысы стенадагы куыш кебек. Куышта лампа. Лампа пыяла куык эчендә. Куык — энҗе йолдызы кебек. Ул көнчыгышта да, көнбатышта да булмый торган фатихалы зәйтүн агачын бер-берсенә ышку юлы белән яна. Анын мае ут төртмәс борын ук кабынып китәргә тора. Нур өстенә нур!»

*(Коръән, «Нур» сүрәсе, 35 аять.)*

Бутарга икән, бутарга!.. Хәзер алланың торагы да җиденче кат күктә түгел, «кеше белән анын йөрәге арасында». (??)

*(Коръән, «Табыш» сүрәсе, 24 аять.)*

Инде алланың дөньяны ярату эшендәге кайбер очы-очка килмәгән урыннар турында. Алдарак алланың башта «җирне, аннары күкне яратканын әйткән идек. «Йолкып алучылар» сүрәсенең 27—30 аятьләре моның киресен сөйли:

«Кеше ясау читенме, күкнеме? Күкне алла ясады, анын гөмбәзен корды. Шуннан соң җирне җәеп салды».

Коръән күкне җиде кат, Җирне бер дигән иде бит әле. Икенче бер битендә алла безгә болай ди: «Без җиде күк яраттык, шуның хәтле үк җир яраттык».

*(Коръән, «Талак» сүрәсе, 12 аять.)*

Хәтерләсәгез, алла бер урында тереклекне су белән тәэмин итеп торуны күккә йөкләгән иде. Хәзер бу бурычны җирнең үзенә йөкли.

«Без җиргә су чыгарып торырга, болыннар үстерергә куштык».

*(Коръән, «Йолкып алучы» сүрәсе, 31 аять.)*

Бу каршылыкны фаш итү белән бергә, Җиргә рәхмәт әйтергә онытмыйк. Алла сүзен тыңлап, бер су гына чыгарып торса, без нәрсә ашар идек? Аэроплан, телефон, телеграф, кино, телевидение кебекләрне әйтмим дә. Җир күмеребез, нефтебез, газыбыз, ташыбыз, мәгъдәннәребез булмас иде. Димәк, сука белән тимерле арбабыз гына да булмас иде! Рәхмәт төшсен сиңа Җир! Безне ризыкландырып торучы да, бөтен кирәк-яраклар белән тәэмин итүче дә, алла әйткәнчә, күк түгел, ә шул Җир! Җир!! Түбәнчелек белән алдында баш иик. Рәхмәт төшсен сиңа, Җир!

Кояшка да рәхмәт. Алла кушканча, яктырткыч булып кына калмаган, бөтен дөньяга тереклек биреп торуны үз өстенә алган, Җирдән башка тереклек була алмаган кебек, Кояштан башка да тереклек юк! Рәхмәт төшсен сиңа, Кояш!

Гаҗәп хәйран. Табигать, гомумән, һичкайчан алла боерыгын тыңламый. Мәсәлән, алла «Балкортлары» сүрәсенең 1—2 аятьләрендә Кояш белән Айны, йолдызларны, тагын көн белән төнне кешеләргә буйсынырга куштым, ди. Ләкин, һәркемгә мәгълүм булганча, бүгенгә кадәр боларның берсе дә кешегә буйсынырга җыенмый әле... Безгә калса, без буйсынмауларын хәерле күрәбез. Югыйсә, төрлебез төрле якка тарткалап, ул Кояш, Ай, йолдызларны әллә кайчан эштән чыгарып бетергән булыр идек. Ә төн белән көн?.. Яңа өйләнешкәннәр, төнне озайтырга тырышып, йокысызлык белән интеккән карт-коры тизрәк таң аттырырга маташып табигатьнең бу гүзәл күренешләрен әллә ни кыйландырып бетергән булырлар иде.

Алланың башта хайваннар яратып, аннары үсемлек үстерүе, шуннан соң гына Кояшны яратуы — тавыклар көләрлек көлке. Хайван ашамый тора алмый. Димәк, башта үсемлек кирәк.

Табигать хакында Коръәндә мәгълүмат бик күп. Ләкин аларның бөтенесе әнә шундый көлке. Имеш, яшен ул болыт белән болыт, яки җир белән болыт арасында хасил була торган табигать күренеше түгел, электр разряды түгел. «Алла сезгә яшенне куркыту өчен, яки өмет кабызу өчен күрсәтә... Алла яшенне үзенә каршы килүчеләргә җибәрә. Чөнки алла сугышта көчле».

*(Коръән, «Күк күкрәү» сүрәсе, 13—14.)*

Коръәнчә, күк күкрәү дә яшен нәтиҗәсендә килеп чыккан күренеш түгел, «күктә фәрештәләр шулай чыбыркы шартлатып, пәри-җен куып йөри». Ә салават күпере — «хәзрәте Гали кылычыннан төшкән нур. Кояш тотылу — алланың ачыйгысы чыгу билгесе...»

*(«Кырык сөәл» китабы.)*

Алда без әле андый мәзәкләрне күп очратырбыз. Хәзергә тагын бер генә үрнәк: бер заман алла, иман китермәүчеләргә хитап итеп, болай ди:

«Эчә торган суыгызны күргәнегез бармы сезнең? Аны болыттан төшерүче сезме, әллә безме? Әгәр теләсәк, **без ул суны тозлы итәр идек».**

*(Коръән, «Төшүчеләр» сүрәсе, 67—70 аятьләр.)*

Һәм болай дию белән алла тагын бер кәррә үзенең белеме бик тә чамалы икәнен фаш итә. Яңгыр суында тоз бар гына түгел, кайчак кирәгеннән артык күп булучан. Мәсәлән, Урта Азиянең көнчыгышындагы туфракта иген үсмәү сәбәпләреннән иң зур сәбәп — анда яуган яңгырның кирәгеннән артык тозлы булуында! Вахш үзәнендә ява торган иң саф диган яңгыр суының да литрында 180 миллиграмм тоз бар! Менә тагын шундыйрак бер төгәлсезлек. «Форкан» сүрәсенең 2 аятендә алла: «Без һәрнәрсәне кирәк кадәренчә яраттык» — ди бит. Гамәлдә исә күбесенчә моның киресе. Мәсәлән, бер Африкада гына да һичкемгә хаҗәте булмаган ком сахрасы 25 Германия илен сыйдырырлык җирне тәшкил итә. Ә ул очсыз-кырыйсыз сазлыклар!..

Җитәр, күпкә китте. Алла әле бит яңа гына җирне, күкне ясап бетереп, тәхетенә менеп утырды; ял итә торсын. Коръәннең эченәрәк керү алдыннан без дә бераз тынып алыйк.

5

## ФӘРЕШТӘЛӘРНЕҢ ДӘ ХӘЛ ШӘПТӘН ТҮГЕЛ. ҖИР ҺӘМ ТАУЛАР АЛЛА СҮЗЕН ТЫҢЛАМЫЙ. ҺАРУТ БЕЛӘН МАРУТКА ДА ЭЛӘГӘ.

Алланың кодрәтенә хәйран калмаска мөмкинме? Караңгы бушлыкта тик ятканда да, дөньяны юктан бар итеп, искитмәле эшләр башкарганда да тирә-юнендә берничди ярдәмчесе, берничди җан иясе юк иде; тәхетенә менеп утырганда да күренмәде. Ни арада ясап өлгергәндер дә, ничек эш рәтенә төшенеп җиткәннәрдер, күз ачып йомганчы бөтен галәм фәрештә белән тулган, ләббәйке дип, алланың боерыкларын үтәп йөриләр, дүртәвесе алла утырган мөбарәк тәхетне күтәргән.

Тик шунысы бик сәер. Алла хәтле алланың тәхете үзлегеннән тормый, күтәреп торырга кирәк. Ә фәрештәләргә басып торырга җир-мазарның хаҗәте юк, һич нәрсәгә басмаганнар, тотынмаганнар да, әйтерсең, һавадагы болыт... Бәлкем, алар чыннан да болыт кебек җиңел затлардыр? Эшләре турында сөйләүгә керешкәнче, әйдәгез, алайса, башта

килеш-килбәтләрен чамалыйк. Чамалыйк дим, чөнки Коръәндә алланың үзенең анык әдәби портреты булмаган кебек, фәрештәләрнең дә портретлары тулы түгел. Безгә фәкать шул кадәресе генә билгеле: фәрештәләрне алла җир белән күкне ясаган кебек юктан бар итми, саф уттан ясый.

*(Коръән, «Сат» сурәсе, 77 аять.)*

Күп кенә риваятьләргә караганда, барысы да бер төсле түгел, сыер кебекләре, ат, аю кыяфәтлеләре бар. Күбесе кешегә тартым. Бөтенесенең уртак сыйфаты: канат. Канатсызы бер дә юк. Ләкин ул да төрлесендә төрлечә. Кайсында ике, кайсында дүрт. Җабраил исемлесенең — җитмеш. Бу да чик түгел. Йөз канатлылар, хәтта меңлеләр очрый. Гәүдә шулай ук барсының бер тигез түгел. Кеше иңбашына кунып йөрерлекләре булган кебек, коточкыч зурлары да бар. Мәсәлән, «Җабраил фәрештә каты куәт ияседер. Күкләрне һәм җирләрне сыңар кулы белән күтәрергә кадир торыр».

*(«Тәфсир сурәсе», Нәҗем, 101 бит.)*

Изге «Мөхәммәдия» китабындагы бер риваятьтә бу фәрештә турында болай диелгән:

...Бер тапкыр, алланың бер йомышын йомышларга дип, бик тә ашыгып очып барганда, хикмәти хода, канатының очы белән ялгыш айга орынып китте. Беләсезме, ай нишли ул чак? Селкенә. Әйе, әйе, дер селкенә. Зур гына өлеше җимерелеп тә төшә әле. Анысы-анысы, элек кояш кебек якты булган аебыз, әнә ничек тоныкланып кала, өстенә таплар бәреп чыга. Игътибар итегез, канат очы гына тиеп китүдән бит! Ә Ай, ничаклы кечкенә дисәң дә, диаметры дүрт мең километр, әйләнәсе ун мең!.. Ярый әле, Җабраил фәрештә кулы яки аягы белән орынмаган, буласы икән хәлләр!..

Ләкин Җабраил — фәрештәләрнең иң зурысы түгел әле. Икенче бер риваятькә караганда — ышансаң ышан, ышанмасаң — юк, — Мөхәммәт пәйгамбәр алла янына менгәч, үз күзе белән күреп төшкән, — өченче кат күктә менә нindиләре бар: ике күз арасын атлап үтәргә уйласаң, 70 мен көн кирәк булыр иде. Ә җиденче кат күк берсе-берсе мең җир буе фәрештәләр белән тулган. Һәрберсе 700 мең башлы, әйе, 700 мең, бер дә ким түгел. Нинди гүзәл, нинди күркәм, нинди мөбарәк затлар, җанашларым!..

Саннары турында Коръәндә бер генә мәгълүмат бар. Соңынтын, Мөхәммәт пәйгамбәр заманында дин өчен барган Бәдер сугышы вакытында алла мөселманнарга ярдәмгә өч мең фәрештә җибәрә, кирәк тапса, биш меңен дә кызганмаячагын вәгъдә итә.

*(Коръән, «Гыймран» сурәсе, 120—121 аятьләр.)*

Риваятьләргә караганда, фәрештәләрнең гомуми саны: һәрбер сафы 70 меңнән торган 70 мең саф булырга тиеш. Ягъни 4 миллиард 900 миллион. Бу сан әченә алланың иң-иң якын 8 фәрештәсе керми.

Күпме? Юк, бу бик аз. Менә үзегез исәпләп карагыз. Хәзер җирдә өч миллиард кеше яши; шуларның һәркайсын (мөселманын, кяферен) үзләренә күренми генә икешәр фәрештә саклап йөри.

«Алла үзенең җирдәге колларына сакчылар (фәрештәләр) җибәрә. Алар сезнең һәркайсыгызны үлгәнче саклап йөриләр, һәрбер эшегезне гадел күзәтеп торалар».

Шулай ук кешенең һәр нә кылганын язып баралар.

«Ә сезнең сакчыларыгыз бар бит, хөрмәтле писарьләрегез бар. Алар сезнең нишләгәнегезне күреп-белеп торалар».

*(Коръән, «Яру» сурәсе, 10—12 аятьләр.)*

«Менә ике сакчы фәрештә кешене күзәтеп тора. Берсе уң иңбашында утыра, берсе сул иңбашында. Кеше, сакчылар ишетмәслек итеп, бер сүз дә әйтә алмый»:

*(Коръән, «Каф» сурәсе, 16—17 аятьләр.)*

Хәер, бу кадәресен сез мулла-монтагайдан, әби-бабаларыгыздан ишетеп тә беләсез. Сез белмәгәне, искитмәлесе менә кайда: кешенең генә түгел, һәр җан иясенең сакчы фәрештәләре бар.

*(Коръән, «Төнлә килүче» сурәсе, 4 аять.)*

Ә җан иясенә, мәгълүм булганча, кәҗә белән сарык кына түгел, кит балыгы, мамонт, аю-бүреләрдән алып, күзгә чак күренә торган бөҗәкләр дә керә. Димәк, аларны да, баканы, кыргаяк, юеш таракан кебекләрне дә алланың фәрештәләре саклап йөри булып чыга! Ә кемнән саклыйлар фәрештәләр ул ерткычларны, ул хәшәрәтләрне? Анысы Коръәндә юк. Тик фараз кылырга гына мөмкин. Әйтик, крестьянның актык азыгын һәлак итү максаты белән амбар астында күсе бала чыгара. Күсене, бу изге эшкә рухландырып, фәрештәләре саклап тора!.. Балалары туу белән аларны да саклап йөрергә күктән сакчы фәрештәләр төшеп җитәчәк!.. Болында адашып елап йөргән сабыйны чагып үтерергә кара елан ысылдап килә. Еланны бу «изге эшкә» шулай ук фәрештәләр саклап бара!.. Тик биредә шунысының очына чыгу кыен. Сабыйның да сакчы фәрештәләре бар бит. Бу вакытта алар нишләргә тиеш? Кара еланның сабыйны чакканын карап торыргамы? Ул чагында нинди сакчы ди алар?! Еланны куып җибәрергәме? Алай дисәң, бу вакыт елан фәрештәләре нишләргә тиеш? Бәс, сакчы икән, еланны яклап чыгарга тиеш, шулай түгелме? Ә бу инде елан фәрештәләре белән сабый фәрештәләре арасында сугыш хәрәкәтләре башланып китте дигән сүз. Шул форсаттан файдаланып, сабыйны елан чагып үтерде дигән сүз! Бәс, шулай булгач, сабыйга сакчы фәрештәләре булудан ни файда? Гомумән, кешегә иңбашында фәрештәләр булудан ни файда?

Читкә кителде. Фәрештәләрнең санын белеп бетермәдек. Кешеләрне, күселәрне, һәртөрле хәшәрәтләрне саклап йөрү — бу бит әле фәрештәләр өстенә йөкләтелгән бурычларның меңнән бере генә. Җиргә төшеп, хак дин таратып йөрергә генә дә әзме фәрештә кирәктер дисез? Без генә күрмибез икән, ә алла аларны җиргә бер туктаусыз җибәреп тора икән:

«Барыгыз, кешеләргә төшеп әйтегез, — ди алла «Балкортлары» сурәсенең 2 нче аятендә, — бер миңа гына сәҗдә кылсыннар, бер миннән генә куркып торсыннар».

Тик менә безне шунысы уйга калдыра. Җиденче кат күктән димим, 1963 нче елның маенда ачылган үтә яңа йолдыз янынннан гына төшсәләр дә, нур тизлеге белән, ягъни секундына 300 мең километр тизлек белән төшсәләр дә, ул фәрештәләргә Җиргә төшеп җитәр өчен 30 миллион ел кирәк булыр иде. Алла, әйтик, бер фәрештәгә 40 яшьлек кешене дингә өндәп менәргә боерды ди, бу кешенең гомере 80 ел ди. Фәрештә җиргә төшеп җиткәндә аның үлгәненә инде 29 миллион 999 мең 960 ел үткән була түгелме соң! Инде, ходайның рәхмәте белән, бу кеше фәрештәнең төшкәнен көтеп тора алса, фәрештә төшеп җиткәндә кеше 30 миллион да 41 нче яшенә чыккан була түгелме? Ә бит ул фәрештәләр, беләсегез килсә, алла янына баскычтан менеп-төшеп йөриләр.

*(Коръән, «Баскычлар» сурәсе, 3—4 аятьләр.)*

Ә баскычтан, табигый ки, нур тизлеге белән йөреп булмый!..

Монысы бер хәл. Биредә без, барыннан да элек, алла алдына шундый сорау куярга хаклы: ни өчен син ул фәрештәләрне, канатлары була торып, баскычтан йөртәсең? Бу бит, җир мисалына күчереп әйткәндә,

сәгатенә мең километр оча торган самолетың була торып, кешеләрне командировкага, мәсәлән, Сахалинга, ташбакага атландырып җибәрү кебек тинтәклек. Кыйссадан хисса: яки күк белән җир арасында синен бернинди баскычың юк, яки фәрештәләреңнең канатлары юк...

Җиргә төшеп-менеп йөрүче, җан иәләрен саклап йөрүче, тәхет күтәреп йөрүчеләрдән гайри күкне саклап ятучы шундый-шундый кыяфәтле фәрештәләр бар бит әле. Ә сез аларның нигә шундый кыяфәтле икәннәренә, нигә берсе-берсе 700 мең башлы икәннәренә төшендегезме? Безнеңчә, алла аларны шундый кыяфәттә ясавы белән үзенең кодрәтен, маһирлыгын күрсәтүне максат итеп куйган булса кирәк. Тагын үзенә мәдхия укытып, мактатып тору өчен. Ә мәдхия уку өчен фәрештәнең 700 мең башлы булуы нигә кирәк диярсез? Кирәк икән шул. Һәм хәзер үзегез дә минем белән килешерсез. Ул 700 мең башның һәрберсенең 700 мең авызы бар бит. Һәр авызының мең теле бар. Син бер тел белән укып кара мәдхияне, 700 мең×700 мең×700 мең тел белән укып кара. Кайсы көчлерәк яңгырар? Алай гына да түгел бит әле. Шул чаклы телнең һәркайсы 7 мең телдән укый аллага мәдхияне!!!

Мактаганны кем яратмый. Ә алла үзен мактатуга аеруча хирес. Ул әле югарыда әйтелгән фәрештәләр өстенә тәхете әйләнәсендә әллә нихәтле мәдхия укучы махсус фәрештә асрый. Болары безнең кебек бер башлы, бер авызлы, бер телле. Ләкин алар да шулай ук көн-төн бер туктаусыз алла исеменә мәдхия укып торалар.

*(«Күк күкрәү» сүрәсе, 14 аять; «Пәйгамбәрләр» сүрәсе, 20 аять; «Киртәләр» сүрәсе, 205 аять һ. б.)*

Фәрештәләр генәме соң!..

«Күктәге һәм җирдәге әйберләр, хәтта аларның күләгәләре дә иртәкич үз ирекләре белән һәм ихтыярсыздан аллага табыналар».

«Әллә синең күргәнең юкмы? Аллага җир белән күктәге һәр нәрсә: кояш, ай, йолдызлар, таулар, агачлар гыйбадәт кыла, кешеләр дә, хайваннар да гыйбадәт кыла».

*(Коръән, «Күк күкрәү» сүрәсе, 16 аять, «Хаҗ», 18, «Рахман», 4—5 аятьләр.)*

**Хайваннар да...** Бу бит алда телгә алынган һәм алынмаган меңнәрчә төрле хәшәрәтләр дә аллага гыйбадәт кыла дигән сүз!.. Ләкин алла бу урында бераз төтен җибәрә төсле. «Төркемнәр» сүрәсенең 72 аятендә ул, ахыр чиктә зарланып:

«Күкләргә, җирләргә, тауларга без иман китерергә тәкъдим иттек. Ләкин алар курыктылар (?), безнең тәкъдимне кабул итмәделәр», — ди.

Кычкырып торган каршылык, әйе бит? Ләкин анысы «вак мәсьәлә». Монда бик кызык бер нәрсә ачыла. Димәк, без гәнә белми йөргәнбез, күкләр, җир һәм таулар сөйләшә беләләр икән. Хәтта алла белән бәхәсләшеп торыр чамалары бар икән... Алла иман китерергә тәкъдим итә, болар төкереп тә бирми...

Чү, тәүбә, тәүбә... Артык тирән кереп киткәнбез ич...

Фәрештәләр турында сүзебез бетмәде бит әле. Фәрештәләр дөньясының безнекенә охшаган бер җире бар. Истән чыкканчы хәзер шул турыда. Берәүләренең җилкә кашырга да вакытлары юк, икенчеләре тик түшәмгә төкереп ята. Мәсәлән, теге 70 канатлы Җабраил дигәннәре. Дөрес, гөнаһсына кермик, пәйгамбәрләр заманында эше булмаган түгел. Пәйгамбәрләргә алланың боерыкларын ташып йөргән. Коръән һәм башка дин китапларын да җиргә ул алып төшеп тапшырган. Ә хәзер? Ни эше бар аның хәзер? Исрафил дигәннәренең эше булмаган да, юк та. Кыямәт көне, быргы уйнап, бөтен мәетләрне (шул исәптән синең белән мине) кабердән кубарачак. Бөтен эше менә шул. Шуңынчы кендереген кояшка кыздырып тик ята.

Шул ук вакытта Коръән битләрен актарганда фәрештәләрнең кайберләрен ихлас күңелдән кызганмый үтеп китә алмыйсың. Мисалга җырчы фәрештәләрне генә алыйк. Безнең филармония артистлары кебек икеөчне җырлады да көчле алкышлар астында сәхнәдән чыгып китте түгел бит! Бер ук сүзне бер ук көйгә көн-төн акырып тор әле син, җуләркәй!..

Өч фәрештәнең эшен мин аеруча җаваплы һәм катлаулы дияр идем. Боларның берсе Газраил, — җан алучы. Үз үлемең белән үлдеңме, суга баттыңмы, атып үтерделәрме, үзең атылдыңмы — бередә Газраилсез бер нишли алмыйсың. Ягъни, ул пычагын тыгып чыгармаса, үлә алмыйсың. Элек, кеше азрак заманнарда, эше алай күп булмагандыр, билгеле. Ә хәзер дөньяда көненә 150.000 кеше үлә, секунд саен 2 мәет дигән сүз. Син шуларның һәркайсының җанын алырга өлгер әле, агай! Ә сугыш вакытында? Хиросимада Америка зобанилары ташлаган атом бомбасыннан күз ачып йомганчы 180.000 кеше мәет булды түгелме! Бар, өлгереп кара шуларның барысына да!.. Ходай үзе куәт бирсен, диген инде.

Өчнең икесе — Мөнкир белән Нәкир. Бу бичараларга тагын да тызракка килә, Газраил әле ул, ни әйтсәң дә, берәңә пычак тыгып чыгара да, икенчеңне егып сала. Ә болар, кешеләр мәетне күмеп кырык адым җир китүгә, аның каберенә кереп, сорау алырга тиеш.

«Кяферме сән, мөселманмы сән? — ди Мөнкир белән Нәкир. «Әлхәмделилла, мөселман бән» — ди мәет, торып утырып. «Сәнең мөселманлыгында бәнем шәкем бар» — ди фәрештәләр. «Сәнең шәкең улса, бәнем шаһитләрем бар» — ди мәет. «Шаһитең нәдер?» — ди Мөнкир белән Нәкир. Мәет, хак мөселман булса, монысына да чатлатып җавап бирә.

Шуннан бу ике фәрештә мәетнең җанын җәннәткә илтеп куярга тиеш!.. Инде мәет, мөселманлыгы керделе-чыктылы гына булып, иманын әйтә алмаса, өстәвенә, дөньядагы кебек, алдашып та маташса, Мөнкирләргә эш тагын да күбәя. Җәһәннәмгә илтеп тыгудан элек алар гөрзи белән мәетнең арт сабагын укытырга тиеш булалар.

Ә кяферләр белән эш ничек тора? — Аларның да җаннарын шул ук Газраил ала. Әмма мөселманныкын алган күк кенә итми инде...

«Мөселманныкын иплэп кенә ала. Ә кяфернекен йолкып». Бу аять кергән сүрәнең исеме дә шундый: «Йолкып алучылар».

Тагын менә нәрсә эшләтә әле Газраил кяферне:

«А-а, син фәрештәләрнең кяфер җанын алганнарын күрсәң икән!.. Фәрештәләр аларны тотып яңаклыйлар, сыртларын дөмбәслиләр».

Каберләрендә дә Мөнкир белән Нәкир кяферләргә шул ук хөрмәтне күрсәтә.

*(Коръән, «Табыш» сүрәсе, 52 аять; «Мөхәммәт» сүрәсе, 29 аять.)*

Безне күзәтеп, безне саклап йөрүчеләргә дә алла үзе күркәм сабырлык бирсен, дим мин. Без туганнан алып үлгәнчегә хәтле иңбашыбызда бит алар. Ашаганда-эчкәндә дә, башкасын эшләгәндә дә һәм башка, һәм башка гамәлләр вакытында да... Өстәвенә шул эшләрнең һәрберсен язып барырга кирәк бит әле!.. Изге эшне язарга үзенә бер дәфтәр, бозык эшкә үзенә бер.

Бередә мин бу икенең берсен, гөнаһларыбызны язып бара торганын, аерым бер кызгану белән кызганмый үтеп китә алмыйм. Син әз генә кыек юлга кереп киттеңме, — аңар эш. Ә аның каравы тегесенә, савап язучыга, безнең заманда шактый җиңелгә китте.

Дөрес, карт-карчык әле намазын укый, уразасын да калдырмый. Ләкин тәңренең бирмеш көне кимендә 77 гөнаһ эшли дә тора. Йорты сурәт белән тулган. Ә дөньяда сурәт хәтле көфер нәрсә бармы? Сурәткә күбрәк карап торсаң, иманыңның синнән чыгып, шул сурәткә кереп киткәнен көт тә тор!.. Сурәт турында гамәл дәфтәренең кайсына язсыннар? Әлбәттә, гөнаһныкына. Хәзер карт-коры киногa барып яки телевизордан

сурэтлэрнең кыйланып йөргэннэрен, шул җөмлэдэн, ярым шэрэ калып биегэннэрен карап утырырга яраталар. Билгеле, монысына да савап дэфтэрендэ урын юк. Э урыс кэпэче? Э хатын-кызның йөзен ачып йөрүе? Аларның тубыктан югары, белэзектэн ары җирлэре бөтенесе нэмэхрэм бит. Димэк, тагын гөнаһ язып баручы фэрештэгэ эш! Кайсы кортка күкрэкчэ кия хэзер? Кайсысы ирлэрдэн тел яшереп тора? Савапка язып буламы боларның берэрсен? Димэк, тагын гөнаһ язучы фэрештэгэ эш!

Э инде кяферлэргэ беркетелгэн фэрештэлэрне кызганырлык сүзне кайдан алырга да белгэн юк. Бер сүз белэн эйткэндэ, андый фэрештэ урынында булудан алла үзе сакласын! Кяфернең гамэл дэфтэре җиде кат җир астында бит.

*(Коръэн, «Ким үлчэүчелэр» сурэсе, 7 аять.)*

Кяфергэ беркетелгэн фэрештэлэр аның һэр гөнаһсын, һэр савабын шунда төшеп язып менэргэ тиешлэр.

Фэрештэлэр турында укырга кызык. Лэкин, безнеңчэ, алла фэрештэлэрне яратып бик тэ ялгышкан. Үзегез уйлап карагыз. Шуңарчы нинди шома бара иде бит. Җир-су, күк, Ай, Кояш, йолдызлар, җир тулы терлек, кош-корт. Һэм шуларның бөтенесен бер үзе юктан бар итте... Фэннең гаҗэеп ачышларыннан хэбэрдар булмаган кеше яки аның казанышларына күз йомган кеше, алланың бу эшлэрен күреп, аны эле һаман чиклэнмэгэн кодрэт иясе дип белер иде. Э хэзер? Хэзер алланы чиклэнмэгэн кодрэт иясе дип буламы? Караңгы төндэ җир астында йөргэн бихисап күп кырмыскаларның һэрберсен, һэрберсенең һэрбер кыймылдаганын күреп торуына ышанып буламы? Аларны җиде кат күктэн карап күрер кодрэте булгач, нигэ кешенең дөньяда ни кылганын күрерлек кодрэте юк? Нигэ кеше саен ике фэрештэ? Нигэ хайван саен, күсе, тычкан, бет, кырыгаяк саен фэрештэ?.. Үзлегеннэн генэ мэетнең «мөселманмы сэн, кяферме сэн» икэнен дэ белми бит. Шуның өстенэ эле кыямэт көн фэрештэлэр алып менеп биргэн гамэл дэфтэрлэрен үлчэүгэ салып үлчэп караячак! Бер ягына савап язылганны, икенче ягына гөнаһ эшлэр язылганны салып. Биредэ алланың үзенэ шундый сорау бирэсе килэ: язылганны белү өчен ансатрак ысул бар бит — уку. Нигэ укып кына чыкмыйсың соң син? Ул үлчэүгэ салып, дэфтэр эчендэ нэрсэ язылганны һич кенэ дэ белү эмэле юк бит! Дөрес, күп язылганына кара күбрэк сенгэн була. Һэм чиктэн тыш сизгер үлчэүнең моны сизүе дэ мөмкин. Лэкин бит кайчак эз савапны язар өчен дэ күп сүз кирэк була, кешене нахакка җэһэннэмгэ хөкем итүең, гомеренэ шайтани юлда йөргэн бэндэне җэннэткэ кертеп җибэрүең мөмкин бит синең.

Хэер, хикмэт анда түгел, хикмэт менэ кайда: шул тикле фэрештэ ярдэменэ мохтаҗ икэнеңне күргэннэн соң сине чиклэнмэгэн кодрэт иясе дип, җир астында кырмыска йөргэнне күреп тора дип, берничек тэ эйтеп булмый шул. Бигайбэ.

Э ул тэхетеңне фэрештэлэрдэн күтэртеп йөртүең нэрсэ тагын? Кыямэт көн аларның санын дүрттэн сигезгэ житкерэм дисең бит эле син.

*(Коръэн, «Котылгысыз» сурэсе, 17 аять.)*

Үзең эйтмешли, «бул!» дию белэн һэр нэрсэне булдыра ала торып та, үзеңне фэрештэлэрдэн күтэртеп йөртэсең икэн, бу фэрештэлэрне мыскыл итү, урынсызга интектерү булып чыга түгелме соң? Аннан ул фэрештэлэрнең ире, хатыны юк, женси дэрт алар өчен ят нэрсэ дип, соңыннан киресен эйтеп, үзеңне тагын бер тапкыр уңайсыз хэлгэ куясың түгелме?

Эйткэнем юк дисең? Ул чакта хэтереңэ төшерим. Үзеңэ иман китермэүчелэргэ, ягъни кяферлэргэ нэгърэ орып кычкырганда эйттең син аны:

«Эллэ сез мине сезгэ генэ ир балалар үстереп биреп, үземэ хатынлыкка берэр фэрештэ кызын алган дип белэсезме?» — дидең син. Онып-

кан булсаң, Коръәнеңне ал да «Исраил балалары»ның 42 аятен укып кара.

Исеңә төштеме инде? Димәк, фәрештәләрнең бала-чагалары юк түгел? Димәк, тик ятмыйлар. Ә Тәуратында бу хакта тагын да ачыграк. Менә нәрсә дисең син анда.

«Җирдә кешеләр үрчи башлагач, аларның кызлары булды. Фәрештәләр кеше кызларының матур идекләрен күрделәр, үзләренә сайлап алдылар».

*(Тәурат, «Яшәеш», 6 бүлек, 1—2 җөмләләр.)*

Бәлкем, эш шул сайлап алудан узмагандыр?.. Һа-а, ничек кенә узган әле!.. «Бу вакыт җирдә гыйфритләр таралды. Алар бигрәк тә фәрештәләр **кеше кызлары янына кереп йөри башлагач** ишәйделәр».

*(Тәурат, «Яшәеш», 6 бүлек, 3—4 җөмләләр.)*

Дөрес, соңыннан син үзең дә бу эшнең ярамаган эш икәненә төшенәсен. Моның өчен син фәрештәләрнең кирәкләрен бирәсең, янәдән җиргә төшеп, кызлар белән мутланып йөрерлекләрен калдырмыйсың, бөтенесен печеп чыгасың. Ләкин мәсьәлә андамыни?!. Үрчиләр, безнең ысул белән үрчиләр! Менә кайда мәсьәлә.

Хәзер кайбер акыллы башларның, Тәурат — Коръән түгел әле ул, диюләре ихтимал. Бу хакта алда зур әңгәмә булыр. Хәзергә ике генә сүз. Алла Тәуратка Коръәнгә ышанган кебек үк ышанырга әйтә:

«...Кешеләргә житәкчелек итү өчен без Тәурат белән Инҗилне индердек, — ди ул, — соңра шушы Коръәнне. Алланың бу китапларына ышанмаучыларга җәза яман каты булачак».

*(Коръән, Гыймран сурәсе, 2—3 аятьләр.)*

Ары киттек. Борынгы дин башлыклары фәрештәләрнең җиргә төшеп шулай мутланып йөрүләре турында, Коръән белән Тәураттан илһам алып, менә нинди әкият уйлап чыгарганнар. Имештер, шундый оятсыз эштән читтә калган Марут белән Һарут исемле ике фәрештә соңынтын кем очрады шуңар: без андый түгел, без тәүфикълы, алла безне печми, дип мактанып йөриләр. Алла моны ишетеп кала да, бер йомыш кушкан булып, боларның үзләрен җиргә төшереп җибәрә. Болар (алла йомышын йомышлап тору кайда ул!..) икесе берьюлы Зөһрә исемле бер бик чибәр җир кызына гашыйк булалар.

«Тәфсир Ногмани» үзенең 1 нче җөзьә, 23 нче битендә бу хакта безгә түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Бу ике фәрештә адәм сурәтенә керделәр. Аллаһы тәгалә бунларга шәһвәт бирде (!), бунлар Зөһрә исемле бер хатын илән яман эш кыйлдылар». Ә алла, менә, масаймыйлар аны! — дип, боларның шәһвәтләрен кире алды».

Шуннан алла Зөһрә кызны күккә күтәрә. Исемен үзгәртми кызның, җисемен үзгәртә. Аны йолдыз итеп күктә калдыра. Без күреп соклана торган, җырларыбызда мактап җырлый торган якты йолдыз, Зөһрә йолдызы, имештер, шул үзе инде...

Изге фәрештәләр белән безгә күп очрашырга туры килер әле. Мәзәкмәзәк эшләрен күрергә туры килер. Анысы алдарак. Хәзер аллабызны нәүбәттәге эшләр көтә.

6

## ӘҮВӘЛЕ — ҖЕН, АННАРЫ — СИНЕҢ БЕЛӘН МИН. АЛЛА ҖЕННӘР БЕЛӘН СУГЫША. КАЙДА СОҢ СЕЗ, ҖЕННӘР?

Бөтенесе булды. Җир. Җирдә мал-туар, кош-корт. Урман. Урманда киек-җәнлек. Су. Суда балык. Күк. Күктә кояш, ай, йолдыз, һәр нә боерсаң, ләббәйке дип торучы фәрештәләр... Инде алланың кеше яки ке-

шеләр ясап, җиргә төшереп җибәрәсе генә калды... Һәр укучының алла хәзер шул эшкә керешә, дип уйлавы мөмкин. Әтиләр мәчеттән шулай ишетеп кайткан, әбиләр безгә шулай сөйләгән. Ләкин украиннар әйтмешли, вперед батьки в пекло не лезь!.. Җирдә, әүвәл башлап, җен халкы яшәп карасын әле!..

Аптырап калдың шикелле, укучым. Чыны шулай, сүз әле бүгенгә тикле күпләрнең котын алып килгән «җен кебек явыз», «җен кебек көчле», «җен кебек зәхмәтле», «җен кебек иләмсез» җеннәр турында бара. Әкиятләрдә сөйләнгән, җырларга кергән, иләмсез мәкаль булып йөргән җеннәр турында.

Әйе, кем генә, ничек кенә каһәрләмәгән аларны, нәрсәдә генә гаепләмәгән!.. Берәрсенең баласы ямьсез туса: «Әбәү, мәхәббәтсез, җен алмаштыргандыр, бер дә бүтән түгел...» Ана баласыннан туйса: «Җен дә алмады үзен!..» Аты сукасын өстерәп алып китә алмый торса: «У-у, җен суккыры!»

Җен дип, кеше караңгы төндә өеннән чыгарга куркып яткан. Йокларга ятар алдыннан, җен кермәсен дип, колһуалла укып, ишек-тәрәзәләрен куш кулы белән сыпырып чыккан. Җен зәхмәтеннән саклану өчен кеше нинди генә чаралар күрмәгән! Әүвәл башлап, бөти яздырып таккан. Кеше күп кенә сырхауны җен зәхмәте дип белгән. Үз чире тоткан яки котырып авырган кеше турында «Аңар җен зәхмәте кагылган», дигәннәр.

Җирдә йөрергә өлгерербез әле, әйдәгез, янәдән бер күккә менеп төшик.

...Шулай итеп, алла кешедән элек җен халкын ярата:

«Без кешедән алда җеннәрне яраттык, аларны самум утыннан яраттык».

*(Коръән, «Хиҗр» сүрәсе, 27 аять.)*

Шунысы кызык, монда да алла, әллә инде бер тапкыр яратканын оныта, әллә кыяфәтләрен охшатып бетерми, җеннәрне икенче кабат ярата. Бу юлы инде фәрештәләрне яраткан материалдан — «саф уттан».

*(Коръән, «Әррәхман» сүрәсе, 14 аять.)*

Шуңар күрәдерме, җеннәр күп кенә яклары белән фәрештәләргә тартым. Мәсәлән, йөзләп, меңләп булмаса да, һәрберсенең икешәр данә канаты бар. Теләсәң көнчыгышка оч, теләсәң көнбатышка... Тик күккә генә менә алмыйлар җеннәр... Менәрләр иде дә, теге сакчы фәрештәләр, әллә кайдан күреп алып, йолдызлар атып, куарга керешәләр...

Җеннәрнең фәрештәләр белән тагын ике уртак сыйфатлары бар. Берсе — күзгә күренми йөри белү, икенчесе — фәрештәләр кебек, бөтенесеннән үк булмаса да, киләчәк турында кайбер нәрсәләрдән хәбәрдар булып тору.

Башка яклары белән җеннәр безгә охшый төшәләр. Алда әйткәнемчә, безнең кебек үк җирдә яшиләр. Ашыйлар, эчәләр. Безнең кебек үк ирләре-хатыннары бар. Дөбердәттереп торып, туйлар ясап, өйләнешәләр, теттереп үрчиләр. Мал-туарга муллык. Җир-су күп, болар дөньяга килгәнче алла бөтенесен үзе булдырып куйган. Теләсәң җәяү йөр, юл әзер. Теләсәң, атланып чап, дөясе әзер, ишек төбендә ишәге көтеп тора. Теләсәң, әнә кораб дигәне тора диңгез читендә әкрен чайкалып...

Бер сүз белән әйткәндә, кешегә ни, боларга шул. Алла үзләрен хак дингә өндәп, фәрештәләр җибәрә. Хәтта үз араларыннан пәйгамбәрләр билгели.

*(Коръән, «Хайван» сүрәсе, 130 аять.)*

Нәкъ кешеләрдәгечә: бәгъзеләре иман китерә, бәгъзеләре көфер юлда калып, кяфер булып яши. Бу турыда Коръәндә женнәрнең үз белдерүләре дә урнаштырылган:

«Безнең арада аллага бирелгәннәребез бар, алладан йөз чөерүчеләребез дә бар».

*(Коръән, «Женнәр» сүрәсе, 14 аять.)*

Кешегә охшаган яклары тагын шунда. Кешене рәхәткә чыдамый, михнәткә чыдый, диләр бит. Боларга да шул сыйфат тулысы белән хас... Тора-бара үзара талаш-кычкырыш китә. Көнчелек, үчлек, үтереш, талаш... Азу-тузу, бозыклык хәттин аша. Алла түзә. Көферлекнең чигенә чыгалар, кыямәт көнгә, үлгәннән соң терелүгә ышанмас булалар.

*(Коръән, «Женнәр» сүрәсе, 7 аять.)*

Монысына да түзә алла.

Ниһаять, болар аллага каршы баш күтәрәләр. Бөтенләй санга сукмас булалар алланы... Менә монысына инде алла түзеп тора алмый. Ах, әле сез шулаймы? Миңа шөкрана итүегез шулмы сезнең, бәдбәхетләр!.. Алла фәрештәләрдән зур гына гаскәр туплап, женнәргә каршы сугыш ача. Бу әле Иблиснең (Шайтан да диләр) күз өстендә кара каш чагы. Гаскәр башлыгы итеп алла шул Иблисне билгели.

— Иблис ләгыйнне фәрештәләргә гаскәр башлыгы итеп?.. Ялгышмыйсыңмы, язучы?

Юк, ялгышмыйм. Исемен ишетү белән күз алдыбызга жөнтәс тәнле, бозау койрыклы, ярык тояклы, кечтек кенә мөгезле, ялт-йолт хәйләкәр күзле булып килеп баса торган Иблис үзе дә элек фәрештә була, тик хәзер бу хакта сөйләүне безнең мулла абзыйлар гына өнәп бетерми...

Иблис кылычыннан ничә женнең жаны жәһәннәмгә киткән, ничә фәрештә шәһит булган, — бу хакта нә Коръәндә, нә риваятьләрдә мәгълүм түгел. Шунысы бик ачык: женнәр яман күп кырыла. Исән калганнары тау-таш араларына, калын урманнарга кереп поса. Иблис алла хозурына данга күмелеп кайта.

Билгеле, женнәр баш күтәрүләре өчен үкенеп бетә алмыйлар. Еглыйеглый тәүбәгә киләләр. Ләкин күктән рәхим-шәфкать юк.

— Инде нишлибез?

— Ничек тә аллаһ тәгаләнең үзен күреп карарга иде безгә...

Күкләрне саклаучы фәрештәләрнең ваемсызрак чакларына туры килгән булсалар кирәк, болар күкнең ничәнчедер катына менеп тә житәләр. Ләкин, кызганычка каршы, тәки алланың үзен күрә алмый төшәргә мәжбүр булалар.

Коръәндә женнәрнең бу хакта яман ачынып сөйләгән сүзләре дә бар:

«Без күккә чаклы менеп життек. Күк көчле сак белән вә һәм дә көйдереп ала торган факеллар белән (?) тулган иде. Урындыкларга утырып, сакчы фәрештәләрнең сүзләрен тыңларга керешүебезгә без факеллар һөжүменә дучар булдык... Без хәзер беләбез; буйсынмау белән дә, качып йөрү белән дә алланың кодрәтен какшатырга мөмкин түгел икән».

*(Коръән, «Женнәр» сүрәсе, 8—12 аятьләр.)*

Тагын тәүбә, көн тәүбә, төн тәүбә... Ләкин, ачыйгысы хәттин ашкан алла женнәрне гафу итәргә уйламый да. Кабул да итми ул аларны. Тәмам өметләрен өзгән жен токымы янәдән жиргә очып төшә, янәдән кара урманнарга, тау-таш араларына кереп поса...

Кызганычка каршы, жир йөзендә үзебезгә хәтле тереклек иткән бу жен токымының шуннан соңгы тормышы турында безгә бик аз нәрсә мәгълүм. Күк саклаучы фәрештәләр куып төшергәч, сәждәдән башларын

күтәрмиләр. Мең еллар үткәч, Сөләйман дигән пәйгамбәргә диңгездән энҗе-мәрҗән чыгаручы булып хезмәт итәләр. Бик азларыннан гайриләре ислам диненә керә. Бу турыда да Коръәндә аларның үз белдерүләре бар:

«Без тугры юлга өндәүче искитмәле Коръәнне тыңлап тордык. Шуңар күрә хәзер без аңар ышанабыз, үзебезнең аллабызның шәрикләре, тиңнәре бар дигәнгә һич кенә дә ышанасыбыз юк».

*(Коръән, «Җеннәр» сурәсе, 1—2 аятьләр.)*

Я, әйтегез, кем шуннан соң бу җеннәрне җен дияр! Юк, мөселман гына дисәң дә әз булыр кебек. Менә дигән изге җаннар, җан кисәкләрем!..

Ләкин алла аларның гөнаһларын барыбер ярлыкамый, гафу итми. Һәм алар урынына, җиң сызганып, кешене, безнең ерак бабабыз булачак беренче кешене ясарга керешә.

Керешкәч, шәт, башкарып та чыгар. Ул кадәресенә безнең иманыбыз камил. Безне хәзергә әле җеннәр мәсьәләсе кызыксындыра. Ә кайда соң ул җеннәр яши торган кара урман? Тау-таш аралары кайда?

— Каф тавы артында?

Әкият. Юк андый җир. Кеше белмәгән Каф таулары түгел, кеше аяк басмаган, кеше кулы җитмәгән бер атлам җир юк хәзер дөнья йөзендә.

Әлбәттә, дин әһелләре моңар каршы:

— Җеннәрнең күзгә күренми йөрү хасыятьләре бар, — дип Коръәнне якларга керешәчәк.

Ярый, үзләре күзгә күренми дә йөри алдылар ди... Ә соң кеше кебек яши булгач, тормыш кирәк-яракларын кайдан алалар? Ашый-эчә булгач, ризык ничек юнәтәләр? Иген чәчәләр, мал-туар асрыйлар дияр идең, әлеге дә баягы — кеше исәпкә алмаган, кеше белмәгән бер атлам җир калмады бит хәзер. Бер күренмәсәләр, бер күренеп китәр иде. Яши торган җирләре дә, мал-туарлары да күзгә күренми торгандыр дияр идең, алла ул җеннәр өчен күзгә күренми торган махсус җирләр яратмады ич.

Кайда соң сез, җен дуслар?! Ничек тереклек итәсез? Тавышыгызны ишеттерегез әле бер!..

Менә шулай, хак тәгаләнең бер хикмәтенә таң калырга өлгермисең, Коръән битләреннән, риваятьнамәләрдән икенчеләре калкып килеп чыга.

7

## АДӘМ БЕЛӘН ХАВА ӘКИЯТЕ. ФӘРЕШТӘЛӘРНЕҢ АЛЛА БЕЛӘН ТЕЛГӘ КИЛҮЛӘРЕ. ЧЫН ЕГЕТ ИКӘНСЕҢ СИН.

Кеше! Бу инде сиңа җирләр, күкләр ясау эше генә түгел, фәрештәләр яки җеннәр генә түгел. Монысы аерата кызык, үтә күңелле булырга тиеш. Шулай, әлбәттә, сүз һәрберебезнең ерак әби-бабасы турында, атабыз Адәм белән анабыз Хава турында бара бит.

Ләкин, иң элек шуны әйтеп китик: монысы тегеләре кебек шома гына узмый, аллаһ тәгалә, эшкә керешкәнче үк, каршылыкка очрый. Беләсезме, кем каршы килә? — Фәрештәләр. Әйе, әйе. Моңарчы алланың бөтен боерыкларын үтәп, ни кушса да, ләббәйкә дип торган, көн-төн бертуктаусыз үзенә мәдхия укып яткан фәрештәләр.

«Менә алла фәрештәләргә әйтте: «Мин Җиргә идарә итүче вәкил куям, диде».

Шул чак фәрештәләр, ризасызлык белдереп, тагын ни җитми инде сиңа, дигән кебегрәк итеп:

«Без сиңа гел мәдхия укып, сине олылап торабыз, шулай ук син ул җиргә бозыклыклар эшләп, гөнаһ кылып, кан түгеп ятучыны үзеңнең вәкилең итәрсеңмени? — диделәр.

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 28 аять.)*

Биредә без, әүвәл башлап, фәрештәләрнең белемнәренә, зирәклекләренә таң калырга тиешбез. Кешене күрмәгәннәр әле. Ә инде аның нинди буласын, бозыклыклар эшләп, кан коеп ятасын белеп торалар!.. Шуннан соң инде без фәрештәләргә алла хәтле аллага ризасызлык белдереп, безнең бабабызны ясатмый калырга йөрүләре өчен, нәтиҗәдә безне дөньяга китерми калырга йөрүләре өчен үзебезнең кискен протестыбызны белдерергә тиешбез.

Ярый әле, алла аларга карамый.

«Мин сез белмәгәннәрне беләм» ди дә җиң сызганып эшкә керешә.

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 28 аять.)*

— Бар, Җабраил, җирдән туфрак алып мен...

Ләкин, менә бәла, кеше ясауга фәрештәләр генә түгел, Җир дә каршы икән, туфрак бирми. Алла күктән тагын бер фәрештә төшереп карый, тагын, тагын... Җир туфрак бирмәскә ант итә. Шуннан алла Газраилне төшерә, җан алучы фәрештәне. Монысы тегеләре кебек җебеп тормый. Мәсьәләне кабыргасы белән куя. Синең антың зурракмы, алланың хөкемеме?! Я, тиз бул!.. Шунда гына Җир аллага кеше ясау өчен бер уч туфрак биреп җибәрә.

*(Рабгузи, Кассас-эл-әнбия, 10 бит.)*

Ләкин кая китте ул элеккеге кодрәт, илһам, илаһи көч кая китте!.. Монысын мин сезгә аңлатып бирүдән гаҗизмен! Җирен, күген, ай-кояшын, миллиардларча йолдызларын, миллион төрле үсемлекләрен, мең вә мең төрле хайваннарын, мең вә мең төрле кош-кортларын нибары алты көн эчендә юктан бар иткән алла берданә кеше белән 120 ел буена интегә! Юк, бу әле ясап куйганнан соң интегүен әйтүем түгел. (И-и, анда күрәчәк әле ул кеше белән!..) Биредә сүз фәкать ясаганда интегүе турында бара. Мөхәммәт пәйгамбәрнең якыннарыннан берсе булган хәзрәте Габбас җәнапләренең риваятенә таянып, ислам диненең мәшһүр галиме Таҗетдин әфәнде бу вакыйганы менә ничек тасвирлый:

«Аллаһ тәгалә Адәм галәйһиссәләмне туфрактан сурәт кылып, Мәккә белән Таиф шәһәрләре арасына куйды. Сурәт кырык ел шунда торды. Аллаһ тәгалә ул сурәткә кырык ел ягмур яудырды. Кояш кырык ел кыздырды. Өстенә җилләр истерде. Йөз егерме ел дигәндә сурәт утта янган чүлмәк кебек шыңгырдап тора иде. Шуннан соң алла бу сурәткә җан өрде».

*(«Тәфсире Таҗетдин», 267 бит.)*

Ә ул җан дигәннәре каян килде әле? — Анысын алла элек ясап куйган була. Адәмнекен генә түгел, синеке белән минекен дә, бөтен кешеләрнекен. Алар барысы да башта кырмыска кыяфәтендә булалар. Барысы да мөселман. Яратылуларына аллага сәҗдә кылалар. Тик, гөнаһ шомлыгына каршы, безнең тәннәргә кереп урнашкач, кяфер булып әверeләләр.

...Шулай итеп, алла беренче кеше белән 120 ел чыләнгәннән соң, аңар җан өрә.

Юк, чиләнә дию генә дә аз монда. Тәмам башы әйләнеп, зиһене чуалып бетә алланың. Шуңар күрә ул, күпмедер вакыттан соң Коръәнне язганда адәмне нәрсәдән ясаганын да төгәл хәтерләми, биш урында биш төрле итеп әйтә. «Гыймран» сүрәсенең 52 аятендә: туфрактан ясадым,

ди. «Әррәхман» сүрәсенең 13 аятендә: «чүлмәк ясаучыларныкы кебек шыңгырдап торган кызыл балчыктан», «Мөхәммәт» сүрәсенең 12 аятендә «Кызыл балчык серкәсеннән (?!)»

Бу кадәресе бер хәл әле. Ни әйтсәң дә, бер төрлерәк материал. Ә менә «Нух» сүрәсенең 16 аятендә: «Без кешене кыяклы үсемлек үстергән төсле җирдән үстердек», диюе белән безне тәмам аптырашта калдыра. Инде дә килеп, «Фөркан» сүрәсенең 56 аятендә: «Алла — шулдыр кем, кайсы кешеләр токымын судан яратты» дигәч, без халәтебезне аңлату өчен сүзләр таба алмаслык хәлгә киләбез. Юк, бутавы өчен генә түгел, материалистларчарак карашка басуы өчен. Чыннан да, һәр җан иясенеке кебек, кешенең дә башлангычы су бит! Ләкин судан дию белән бергә ул суны 40 ел яңгыр астында тотуы, аннары кырык ел кояшка, җилгә алып чыгып киптерүе белән алла янәдән үзенең идеалистлыгына кайтып төшә. Һәм без, никадәр әдәп сакларга теләсәк тә, бу урынны елмаймый үтеп китә алмыйбыз.

Без — шулай. Ә динле кеше боларның кайсын дөрес дип белергә тиеш соң? — Әлеге дә баягы — бөтенесен.

Әгәр син хак мөселман икәнсең, алланың кешене туфрактан ясадым дигәненә дә, бер үк вакытта «чүлмәкче балчыгы кебек шыңгырдап торган кызыл балчыктан» дигәненә дә, судан дигәненә дә, бүтәннәренә дә ышанырга тиешсең. Көлке? Әйе, көлке. Аның каравы алла кушканча.

Ә дөресе ничек соң?

Кешенең ничек, кайчан барлыкка килүе хәзерге фән өчен сер түгел. Фән бу серне, җир катламнарын тирән казып кереп, иң борынгы кешеләрнең сөякләрен, эш коралларын өйрәнү юлы белән, шулай ук иң борынгы бабаларыбыздан алда яшәгән төрле мәхлукларның калдыкларын өйрәнү юлы белән ачты. Җир шарының төрле нокталарында иҗат итүче галимнәрнең уртак фикере шундый: җирдә безнең кебек кешеләр яши башлаганга Тәүрат, Инҗил, Коръән һәм башка дини китаплар әйткәнчә, 7.565 ел түгел, кимендә 500 мең ел! Фән ияләренең тагын бер уртак фикерләре шуңардан гыйбарәт: безнең ерак бабаларыбызны агачта да үстермәгәннәр, чүлмәк ясаган кебек балчыктан да әвәләмәгәннәр. Алар бик примитив рәвештә башланып киткән хезмәтнең тәрәккъыяте нәтиҗәсендә, моннан берничә миллион ел элек Азия, Африка, Европа урманнарында яшәгән дриопитик дигән маймыл сымак мәхлуктан камилләшкәннәр. Шимпанзе, горилла, орангутан кебек хәзерге заман маймыллары да шулардан таралган. Бу маймыллар белән безнең борынгы әби-бабаларыбыз арасында тән төзелеше ягыннан аерма бөтенләй юк диярлек. Хәзерге көндә дә фәкать тәннәрен йон каплаган булу, әшли, сөйләшә белмәү, ике аяклап йөри белмәүләре белән аерылып торалар. Койрыклары юк, ми төзелешләре безнекенә охшаган, алгы аякларында бишәр бармак, безнеке шикелле үк яссы тырнак. Кан составлары безнекенә тартым. Хәтта тешләре дә безнекечә: 32 теш. Кайбер маймыллар белән хәзерге кешенең уртак билгеләре йөзгә тула. Алар син күрсәткәнгә тиз төшенәләр, балалар кебек синең арттан кабатларга яраталар, хәтер бик яхшы. Һәрнәрсәне күрергә, белергә һәвәсләр. Һәрнәрсәнең серенә төшәргә омтылалар. Бу төр маймылларга шатлык, ачу, сагыш, кайгы хисләре дә ят түгел. Көлә беләләр, елыйлар. Кыскасы: бу төр маймылларны безнең чыбык очы туганнарыбыз дияргә була.

Табигый ки, укучының башында, ул дриопитик маймыллар үзләре каян килгән соң? дигән сорау туачак. Фән өчен монысы да сер түгел. Аларның нәселләре еракка киткән саен, түбәннән түбәнгә төшә барып, примитивлаша барып, суда яшәүче арка сөяксез мәхлукларга барып тоташа.

Коръән гомумән оригиналь булмаган кебек, аның кешене ярату турындагы әкияте дә оригиналь түгел. Ул Коръәнгә кадәр алты-җиде йөз

ел элек «иңгән» Инҗилдә дә шулай, аңар кадәр мең ел элек «иңгән» Тәүратта да нәкъ шулай. Ә төп чыганаклары берничә мең еллар элек билгеле булган халык әкиятләренә барып тоташа. Бу әкиятләр диннәр барлыкка килү белән илаһилаша, дини канунга әйләнә. Бәгъзе диннәр, алла кешене таш чүкеп ясаган, ди, бәгъзеләре — агач юынып. Мысыр халыклары арасында, алла кешене чүлмәкче чүлмәк ясаган кебек кызыл балчыктан ясап җан өргән, дигән әкият таралган була. Бу әкият шул хәлендә борынгы яһүд диненә килеп керә. Аннан Тәүрат, Забур, Инҗилләр аша — Коръәнгә.

Ләкин без хәзергә бу кадәресен онытып торыйк. Ничек ясаган, нәрсәдән? — Анысы, ахыр чиктә, ул хәтле әһәмиятле дә түгел. Ясаган — рәхмәт. Моның өчен фәрештәләргә кушылып, бер мәдхия укыйк та, ары таба атлыйк.

Шулай итеп, кеше булды.

Биредә шунысы хикмәтле: атабыз Адәм безнең рәвештә анадан тумаган кебек, имчәк тә имеп маташмый, биләүдә дә ятмый, мүкәләп тә йөрми. Гомумән, сабыйлык чорында тукталып тормастан, дәррәү житлеккән егет була. Бөтен җире килгән. Тик менә ялгыз. Хайваннар, җәнлекләр төркем-төркем, кош-кортлар көтү-көтү, бу — бер ялгыз. Аннан бар да парлы-парлы, селәүчән, бака, юеш тараканга хәтле парлы-парлы. Бу гына моңлы-зарлы.

Ниһаять, күпмедер вакыттан соң алла үзе белепме, ничекме, безнең ерак бабабыз булачак кешене җәмәгатьле итәргә була.

— Ничек?

— Шулай.

Кешене яман да каты йокыга талдыра, үзе шул арада моның бер кабыргасын шытырдатып сындырып ала. Ерак бабабыз булачак кеше, уянып китсә, бер кабырга юк, аның каравы каршысында менә дигән яшь кыз басып тора. Ерак бабабыз чамаларында, тәмам өлгереп житкән, бер килмәгән җире юк. Тик шунысы: анадан тума, оят җирен дә томаламаган. Хәер, ул чак ерак бабабыз үзе дә шундый хәлдә була әле... Ә кем шундый түгел, әнә хайваннар да, фәрештәләр дә шәп-шәрә ич...

Ерак әбиебезнең дөньяга килүен бер ислам дине генә түгел, христиан, яһүд һәм кайбер бүтән диннәр дә шул рәвешчә аңлата. Һәм бу хәл кабырга әкиятенең бер диннән икенчесенә күчә килүе турында сөйли. Ул кадәресе бәхәссез. Бу уңай белән бездә бер сорау туа: анабыз Хаваны ясауга киткән кабырга урынына алла атабыз Адәмгә бүтән кабырга ябыштырамы, әллә атабыз Адәм бер кабыргасы ким килеш яшәгәнме? Коръән бу хакта әйтми. Христиан дине әһелләре исә, атабыз Адәмнең генә түгел, аңардан таралган һәрбер ир кешенең бер кабыргасы ким, дип ышандырып киләләр. Фәкать 1540 елда гына Вязалий дигән атаклы галим анатомия дәлилендә моның ялган икәнен фаш итә. Котырынган инквизиторлар галимне асып үтерергә хөкем итәләр.

Атабыз Адәм белән анабыз Хавага кайтыйк.

Ике яшь, ул чак әле оят дигәнне белмәгәннәре хәлдә, бер-берсенә сокланышып карап торалар.

Коръән бу хакта күп әйтми. «Кассас-эл-әнбия» китабы яхшы ук тасвирлап бәян кыла:

«Адәм Хаваны күрүенә гашыйк булды. Шунда булган Җабраил фәрештәдән дә оялмыйча: «Хаваны күрде ирсә, миңа якын кил»,— диде.

Хава да әле яңа гына кабыргадан яратылуына карамастан, бик үк тыйнаклардан булып чыкмый.

«Хава әйтте: әгәр син мине теләсәң, үзең якын кил, диде. Адәм галәйһиссәләм торды, Хава янына килде, кулын суза башлады...»

Ә, юк инде, беренче күрешүгә шул кадәресе җитеп торыр...

«Җабраил фәрештә Адәмнең кулын тотып алды».

Адәмнең моңар кәефе китә.

«Ник тиясең, ул минем өчен яратылды ич», — ди.
Җабраил ачыклык кертә:
«Әйе, синең өчен, ләкин никахсыз кул сузмак дөрес түгел, — диде,— әнә башта алладан хәләл җефетлеккә (хатынлыкка) сора, диде».

*(«Кассас-эл-әнбия», беренче җөзьә, 14 бит.)*

Шуннан алла әйтә:
«Менә бу синең хәләл җефетең була инде», — ди.
Һәр икесе тәшәккердән гаҗиз.
— Инде ярыймы?..
— Кара җаен...
Адәм белән Хава бер-берсенең кочагына ташланалар...
Ләкин яшьләргә озак кияүләп ятарга туры килми... Күңелсезлек диик микән, мәшәкать кенә диикме, — акыл ирешмәслек бер хәл килеп чыга. Кеше ясыйм, дигәч, фәрештәләр аллага ризасызлык белдергәннәр иде бит әле, — шуның өчен җәза тәртибендә булса кирәк, алла боларга әйтә: «Я, соң, үзегезне хаклы дип белсәгез, җир йөзендәге әйберләрнең, җан ияләренең исемнәрен әйтеп бирегез хәзер», ди.
Фәрештәләр:
«Дан сиңа! Син бөек акыл иясе, син бөтенесен белүче. Ә без син өйрәткәннәрне генә беләбез шул» — дип җавап бирәләр.
Шуннан соң алла Адәмгә эндәшә:
— Адәм, я, әйтеп күрсәт әле шуларга...
Адәм, ходаның рәхмәте, бер ялгышмыйча, бөтенесенең исемнәрен әйтә дә бирә.

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 29—30 аятьләр.)*

Бөтенесенең бит: миллион төрле хайванның, кош-кортларның, бөҗәкләрнең, балыкларның, үсемлекләрнең, җирдә тереклек башлангач без пешереп ашаячак ризыкларның, без киячәк кием-салымнарның, савыт-саба һәм башка, һәм башкаларның!..
Сизеп торам, бәйләнчегрәкләрегез әйтер, бу акыл ирешмәслек эш бит, дияр. Фәрештә хәтле фәрештәләр, бөтен дөньяның, күкләрнең серләрен белеп торган фәрештәләр, хәтта кеше үзе ясалганчы ук аның бозык юлда йөриячәген, аның аллага буйсынмаячагын белеп торган фәрештәләр, шул җөмләдән бер-берсе 70 мең башлы фәрештәләр, әйтә алмады, безнең төсле бер мескен адәми зат, әле кайчан гына балчыктан әвәләп куелган бер мескен, әйтте дә бирде, дияр...
Мин дә башта шул рәвешчә уйлаган идем. Ләкин алла, үз сүзләре белән әйтсәк, «хәйләкәрнең дә хәйләкәре» булган алла, беләсез нинди хәйлә кора? — Башта фәрештәләргә сиздерми генә, Адәмгә бөтен-бөтен нәрсәләрнең исемнәрен өйрәтеп куя. Ә моңарчы һәр нәрсәне белеп-күреп торган фәрештәләр, ходаның рәхмәте, бу турыда бөтенләй белми дә калалар...

*(Коръән, «Табыш» сүрәсе, 30 аять, «Сыер» сүрәсе, 29, 31 аять.)*

Ничек өйрәтте икән соң алла ерак бабабызны?
Коръәндә бу вакыйга ачык итеп бәян кылынмаган, ә безнең ничек-ничек өйрәткәнен беләсебез килә. Без фараз кылырга керешәбез. Мәсәлән, алланың болай иткән булуы мөмкин: Адәмне җиргә алып төшә дә һәр хайванның, һәр үсемлекнең исемнәрен әйтә-әйтә күрсәтеп йөри. Диңгез читенә алып төшеп утыра да, балыкларны берәм-берәм чакырып чыгарып, исемнәрен әйтә. Аннан Идел, Дон, Нил һәм меңнәрчә бүтән елга буйларында йөртеп, шул елгаларның үзләренә генә хас балык исемнәрен өйрәтеп чыга. Кош-кортларның исемнәрен әйтә-әйтә, Адәмне үзе белән бергә һавада очырып йөртә.

Ләкин монысының мәшәкате күп. Аннан, болай иткән тәкъдирдә, ак аюлар, моржлар күрсәтү өчен атабыз Адәмне боз диңгезенә алып барырга кирәк булыр иде. Ә анда, үзегезгә мәгълүм: кич-иртә 70—80 градус суык, Адәмнең исә, кышкы кием димим, трусигы гына да юк әле! Болай атабыз Адәмнең үпкәсенә суык тидереп, аяк сузуы, анабыз Хаванның яшьли тол калуы мөмкин.

Юк, мөгаен, болай булгандыр. Башта атабыз Адәмне үзе генә белә торган берәр яшерен җиргә, әйтик, берәр урман кырыена алып килә. Бөтен җан ияләренә шунда килергә боерык бирә.

Киләләр.

Әнә теге фил булыр, ди алла, каушавы белән борын очына кыстырып килгән бүрәнәсен дә ташларга онытып, ух-пух басып торган филне күрсәтеп. Ә тегесе ана фил. Аермаларын күрдеңме? Бутама. Тегесе, аркасын имән кәүсәсенә ышкып торганы — аю, аның янында чуалганы — ана аю. Зинһар, бутый күрмә, Адәм...

— Ярый. Абау, тегесе нинди бәләкәй... Нәрсә ул, ә? — ди Адәм чебенне төртеп күрсәтеп.

— О-о, кечкенә булса да төш кенә ул,— ди алла.— Зрә дә хикмәтле итеп ясадым мин аны. Мәсәлән, кеше балык тотып алып кайтып килә. Балыкчыларча итеп әйткәндә: моның хәтле... Бу шуның башына кунып әә итә. Кечкенә генә, инә күзе чаклы гына. Кеше өенә алып кайтып казанга салыйм дисә, тоткан чагында авыз суларыңны китереп торган балыктан бәдрәф исләре килә, эче тулы мыж корт...

Тәҗрибәсез Адәм, алланың елмайганына карап, чебенне кеше файдасына тырышкан дип белә. Күздән югалганчы, ягымлы күзләре белән озатып кала.

— Ә тегесе нәрсә?

— Күбәләк.

— Нинди матур!..

— Анысын мин тагын да хикмәтлерәк итеп яраттым,— ди алла.— Әйтик, син еллар буе бакча үстерәсең, алма бакчасы. Бу синең бакчанда канатларын әнә шулай җилпеп очып йөри. Бөтенегез аны яратасыз, аны мактап җырлар җырлыйсыз. Шигырьләр әйтәсез. Ә ул синең алмагач ботакларына кунып әә итә. Бер көн өеңнән торып чыксаң, алмаларың шып-шып җиргә коела. Эчләрендә корт, ха-ха-ха...

Тәҗрибәсез Адәм бу юлы да аллага кушылып елмая, күбәләк өерен күзләре талганчы озатып калганы хәлдә, башында күбәләк турында шигырьнең беренче юллары туа башлый. Ләкин күбәләкләр арты арсланнар килеп чыга ыжгырып. Адәм берсенең мыегын тотып карамакчы. Алла, вакытында күреп алып, моның кулына суга.

Әлбәттә, болай да бик озакка китә. Дөрес, кошларга әллә ни вакыт кирәкми. Ә менә чүлләрдән дөяләр, ишәкләр, котыптан ак аю белән морж, Сахалиннан селедка, Швеция ярларыннан треска, Африкадан көнгерә, Азиядән чаян, ташбака, Европадан кырыгаяк белән сычкан һ. б. һ. б. миллион төрле хайваннар, кош-кортлар килеп житкәнче, алар ходаның нинди дер рәхмәте белән күккә күтәрелгәнче астрономик санлы еллар үтәргә тиеш бит.

Ләкин шуннан гайри юл юк. Һәм монысы колакка да ятышлы. Әйдәгез, алла Адәмгә шул юл белән сабак биргән дип фараз кылыйк та җәннәт мәйданына, Адәмнең алла һәм фәрештәләр алдында имтихан тоткан урынга килик. Төркем-төркем җан ияләре уза. Ничәмә-ничә төрле йорт хайваны, кош-корт, җәнлек, балыклар... Маймыллар уза мәтәлчек атынып, тараканнар уза кереп калырга ярык-мазар күзәтеп, бетләр үтә Адәм тәненә сырышып калырга чамалап. Күселәр, сычканнар иген амбарларын күрүгә күзләрен ялтырата башлыйлар. Алла аларга бармак яный. Тегеләр җиргә сеңеп, корсаклары белән шуышып

үтеп китәләр. Тавык-чебешләр уза бер гамьсез. Алла этәч. Әлбәттә, ул әле әнә теге, сары тунлы, көлтә койрыклы, мәзин күзле, матур мәхлукның төннәрдән бер төн, кетәккә кереп, бөтен гаиләсен буып чыгачагын белми... Адәм исә, алла өйрәткәнчә, берсен бер бутамыйча, бөтенесенең исемен тәгәл әйтеп тора.

— Әйе, әйтерең бармы, бездән уздырды бу Адәм дигән зат, — диләр фәрештәләр.

— Уздырды, уңган егет икән...

Ләкин... Ләкине бераз алдарак...

## 8

## ШАЙТАН БЕЛӘН АЛЛА БӘХӘСЕ. ИБЛИС ЛӘГЫЙН МӘКЕРЕ. АДӘМ БЕЛӘН ХАВАНЫ НӘРСӘ ХАРАП ИТТЕ?

«...Шуннан соң, — ди алла, — без фәрештәләргә Адәмгә сәҗдә кылырга куштык. Иблистән (Шайтаннан) гайриләре бөтенесе сәҗдә кылды. Без Иблискә: «Нигә син Адәмгә сәҗдә кылмадың?» — дидек. Ул әйтте: «Мин аннан әйбәтрәк, син мине уттан яраттың, ә аны кызыл балчыктан», — диде.

*(Коръән, «Киртәләр» сүрәсе, 10—11 аятьләр.)*

Бу күңелсез бәхәс, күрәсең, байтак вакыт дәвам итә. Без дә аңа тулырак тукталырга булдык. Алла дәшми торгач, Иблис аны хурлауга кадәр барып җитә:

«...Синең ул кызыл балчыктан әвәләгән кешеңә сәҗдә кыламмы соң мин!..» — ди ул.

Алла монысына да түзә. Шуннан Иблис тагын да чәнечкелерәк сүзләр сайлый:

«Әллә үзең күрмисеңме, аның кай җире миннән артык. Миңа караганда аңа күбрәк хөрмәт күрсәттең бит син».

*(Коръән, «Исраил балалары» сүрәсе, 63—64 аятьләр.)*

Ниһаять, алла түземен җуя:

«Без әйттек: кит моннан, югыйсә үзеңне ташлар атып куарга әйтермен, дидек. Кыямәт көнгәчә сиңа миннән бәддога дидек. Күземнән югал, хәзер синең монда һаваланып йөрерлегең калмады».

*(Коръән, «Әлхиҗр» сүрәсе, 34—35 аятьләр, «Киртәләр», 12 аять.)*

Иблис әйтте: «Алайса, минем гомеремне озайт, кеше үлеп терелгәнчегә кадәр (ягъни: кыямәт көнгә кадәр — Г. Г.) мине үтермә, диде».

«Без әйттек: син озын гомерлеләр арасында каласың, дидек».

«Иблис әйтте: **син мине туры юлдан яздырган өчен** мин дә кешеләрне синең юлыңнан дүндәреп йөрермен, аларга алдан да, арттан да, уңнан да, сулдан да һөҗүм итеп торырмын, диде. Күр дә тор, аларның күбесе сиңа буйсынмас, диде».

«Без әйттек: чыгып кит моннан, оятсыз. Сиңа иярүчеләрнең бөтенесен җәһәннәмгә олактырачакбыз, дидек. Ә син, Адәм, җәмагатең белән бергә шушы җәннәттә яши бир, — дидек».

*(Коръән, «Киртәләр» сүрәсе, 12—18 аятьләр.)*

Ә бит кешене ясаганда алла аны җиргә вәкил итеп куям, дигән иде ич, онытты микәнни? Болай булгач, җир нигә кирәк? Андагы хайваннар нигә? Бигрәк тә йорт хайваннары, тавык-чебеш, каз-үрдәк? Бөтенесе аю-бүрегә, төлке — җиһан корткычка азык булу өченмени? Чыннан да, синең хикмәтләреңә төшенеп җиту кыен була башлады, алла агай!

...Ничек булса да булгандыр, Адәм белән Хава җәннәттә! Бүленеп торган баллы айларын дәвам итәләр.

Ул ризык, ул хәмер!.. Җаның ни тели, күпме тели!..

Ерак әби-бабаларыбызның шундый бәхеткә ирешкәннәрен күреп, сөенергәме безгә, көенергәме? Минемчә, Адәм белән Хава бу хәлгә никадәр генә шатланмасыннар, эчтән үзләре дә уңайсызланган булса кирәк. Ник дисәң, бу бәхеткә хәләл юл белән ирешмәделәр бит, икенчедән, Иблис шулар аркасында гына алла белән ачыгышлы булды, нәтиҗәдә алланың дәргяһыннан сөрелде.

Дөрес, Адәмнең фәрештәләргә караганда бер өстенлеге бар. Фәрештәләр, безнең заман теле белән әйтсәк, штамп ысулы белән генә барлыкка килде. «Бул!» дию белән бөтенесе берьюлы булды да куйды. Мәгълүм булганча, Иблис тә фәкать шуларның берсе бит. Ә кеше? Кешене алла 120 ел ясады. Тагын нинди 120 дер әле: безнеңчәдерме, алланың үзенекедерме? Аллача булган тәкъдирдә, оһо-һо!.. Һәрбер көне 50 мең елдан исәпләп кара үзең. 2 миллиард 690 миллион ел ясаган килеп чыга түгелме?!

Шулай да (ерак бабабыз булуына карамастан, үзара тәнкыйть тәртибендә әйтим әле) бу Адәмдәге бердән бер өстенлек. Дөрес, Тәуратта бераз башкачарак. Анда Адәмгә исемнәрне алла өйрәтеп куймый, Адәм үзе белеп куша. Ләкин моны барыбер Адәмнең зур хезмәте димәс идем мин. Ул бу эшкә нинди дер иҗади юл белән ирешми бит. Алла моның күңеленә сала, бу шуны тутый кош кебек кабатлап кына чыга. Ә бит алла күңеленә салса, фәрештә дә шуны ук эшләгән булыр иде. Фәрештә түгел, теләсә нинди мәхлук, хәтта юлда аунап яткан таш та шуны ук эшләр иде.

Инде Иблиснең өстенлекләрен күздән кичерик. Иблис, ни әйтсәң дә, фәрештә. Беренчедән, материалы ниндидер балчык түгел, менә дигән саф ут. Икенчедән, фәрештә кыяматкәчә үлми, ә канаты? Буй-сыны? Кеше күзенә күренми йөри белүе? Алланың иң якын хезмәтчесе булуы? Алда ниләр буласын белеп торуы? Бигрәк тә шунысы: җеннәр баш күтәргән заманда алла фәрештәләр гаскәренә баш итеп җибәргән икән, ул Иблис — фәрештәнең дә ни җитте генәсе түгел булып чыга бит әле!.. Сүз юк, безнең заман түрәләре арасында үз кул астындагыларның олтанына да яраксызлары әз очрамый. Ләкин Иблисне без алай дип кимсетә алмыйбыз. Гаскәр башлыгы буларак, алланың ышанычын тулысы белән аклап чыкты. Юлдан язган җен халкын аның шанлы гаскәре әнә ничек тар-мар итеп кайтты!.. Алла, чыннан да, булып, безнең белән күрешеп сөйләшүдән кимсенмәгән тәкъдирдә, без аңар шундый бер гыйбрәтле мисал сөйләп оялтыр идек: укытучы үзенең яраткан укучысына шыпырт кына, шуннан шунда тикле өйрәнеп кил, иртәгә сорармын, ди. Икенче бер балага, үчлесенә, әйтми. Әйтми, ә башлап шуңардан сорый... Турысын гына әйткәндә, синең дә шулайрак булып чыккан бит, алла бабай, фәрештәләргә карата шундыйрак бер этлек эшләвең булган бит бу, дияр идек без. Килешми, дускай, синең кебек илаһи затка бер генә дә килешми дияр идек. Коръән язылып таралгач, фәрештәләр синең бу этлегеңне, әлбәттә, күргәннәрдер һәм, сиңа моның өчен рәхмәт әйтмәгәннәрдер, дияр идек...

Ә синең, хөрмәтле укучым, моңар әллә ни исең китмәсен. Алла әле алда моңардан мең өлеш кәттәрәк мәзәкләр китереп чыгарачак. Хәзергә мин сезне шундыйларның берсе белән генә таныштырып үтәм.

Җәннәткә керткәч, алла безнең әби-баба булачак кешеләргә:
«Һәр икегез нәрсә телисез, шуны ашагыз, тик менә бу агачка гына якын килә күрмәгез, ялгышкан булырсыз», — ди.

*(Коръән, «Киртәләр» сүрәсе, 18 аять.)*

Ә бу Иблиснең шул бер Адәм аркасында хурлыкка төшкәнен оныта алмый йөргән көннәре. Ул бу хакта ишеткәч, өстәл сугып кычкыра: «Үч алырга! Адәмчектән үч алырга»! — ди ул. Ә үч алу аның өчен чүп тә түгел!.. Иблис шул максат белән җәннәткә йөгерә. Ләкин капка төбендә елан:

— Алланың рөхсәте юк...— ди.

— Аның булмаса, минем бар, — ди Иблис мәзәк көлеп.

— Ничек?

— Шулай...

Эш шунда ки, Шайтан, фәрештә затыннан буларак, теләсә нәрсәгә әверелеп, теләсә нишләп йөри ала бит. Тели икән, кешенең кан тамырларына кереп оялый. Берәр кеше эченә кереп оялап, аны теләсә нәрсә сөйләндереп, теләсә нәрсә кыйландырып йөртү — Шайтанның иң яраткан мәзәге. Әлбәттә, авызыңны бисмилла әйтеп йомсаң, якын да килә алмый, инде ачык авызланып торган чагыңны туры китереп, бер кереп алса, син үзеңә хуҗа түгел. Мәсәлән, Гайсә пәйгамбәр заманында шундый хәл була. Тәкъвә дигәндә дә тәкъвә бер кеше Гайсә пәйгамбәрне мөбарәк сакалыннан эләктереп алып, җиде бабасына җитеп, сүгәргә керешә. Әмма Гайсә, пәйгамбәр буларак, эшнең нәрсәдә икәнен шундук сизеп алып:

— Чык, явыз! — дип бер кәррә кычкырып салуы була, Шайтан теге кешенең эченнән сыра бөкесе кебек пылт итеп атылып килеп чыга. Кеше пәйгамбәрнең сакалын җибәрә, сүгенүдән туктый, ә Шайтан, әллә ничәгә бүленеп, дуңгызлар эченә кереп оялый. Хәзер дуңгызлар дуңгызча оят сүзләр әйтеп сүгенергә керешәләр... Һәм, Шайтан авызларыннан чыгуга, оятларыннан үз-үзләрен диңгез ярыннан ташлап батып үләләр.

Үзенең шул хасиятеннән файдаланып, Шайтан хәзер дә шундый бер мәзәк эш кыла. Җәннәт бакчасын саклаучы елан капкадан кертмәгәч, моның үзенең эченә кереп оялый. Ә елан бакчага кергәч, авыз эченнән атылып чыгып, Адәм белән Хаваны эзләп таба. Таба да теге вакыт алла тыйган агачны мактарга керешә: «...Бу агачның җимешен авыз иткән җан иясе фәрештәгә әйләнә, мәңге үлмәс була, ди, аның җимешен ашаудан алла сезне шуңар күрә генә тыйды бит, ди, ә сез курыкмагыз, ашый бирегез, ант итеп әйтәм, бу — минем сезгә яхшылык теләвем», ди.

*(Коръән, «Киртәләр» сүрәсе, 19—20 аятьләр.)*

Кеше булып, фани дөньяда берничә ел яшәүгә караганда мәңге үлмәс җанга әйләнү, фәрештәгә әйләнеп, алданиләр буласын белеп тору, үзең теләгән җирләргә очып йөрү!.. — Шыр тиле генә кызыкмас моңар!..

— Әйдә ашыйк, Адәм җаным.

— Аллага тапшырдык, Хава бәгырем...

Һәм болар алла тыйган җимешкә ябырылалар.

— Ах, нинди тәмле!..

Чәйнәп йотарга да өлгермиләр, фәрештәгә үк әверелмәсәләр дә, шундук кайбер уңай сыйфатларга ирешәләр. Мәсәлән, үзләренең анадан тума икәннәрен, болай йөрү оят икәнен беләләр. Шайтан хаклы: алланың тыюы да шуның өчен булган, үзе кебек һәрнәрсәне белүче булып китүләреннән курыккан, хәзер йөгереп килеп, Адәм белән Хаваның кулларына суга. Һәм шуның белән ул үзенең берсеннән берсе начар ике сыйфатын: көнчелек белән эгоистлыгын фаш итә. Юк, бер дә арттырып әйтүем түгел. Уйлап карагыз. Без бит үзебез белгәнне балаларыбызга белдерү өчен мәктәпләргә җыеп укытабыз, бала укытучысын уздырып җибәрә,

шул рәвешчә, дөньяда гыйлемлек арта. — Ә алла?.. Юк, үзе белгәнне безнең ерак әби-бабаларыбыздан яшереп яткыруы белән алла тагын безнең гайрәтне чигереп җибәрде әле...

Ярый, хәзергә бу бәхәсне калдырып торыйк.

«Адәм белән Хава тыелган агач биргән белем ярдәмендә шундук җәннәт агачларыннан берничә яфрак өзеп алып (материясе булмаса да, инәсе-җебе булган тагын, ходаның хикмәте — Г. Г.), үзләренә кием тегәргә керештеләр».

Шуннан алла боларны чакырып китереп арт сабакларын укыта:

«Мин сезгә бу агачның җимешен ашамагыз, дигән идем түгелме?!»

Адәм белән Хава калтырап төшәләр:

«Иблиснең сезнең иң явыз дошманыгыз икәнен әйткән идем түгелме?»

Хава хушсыз, Адәм дә берникадәр вакыттан гына телгә килә:

«Әй, алла! Без харап булдык. Әгәр син безне гафу итмәсәң, ярлыкамасаң, без мәңге үзебезгә зыян итүчеләр булачакбыз», — ди.

*(Коръән, «Киртәләр» сурәсе, 21—22 аятьләр.)*

Алла аларның үкенгәннәрен күреп кызгана. Чөнки ул үкенүчеләрне кызганучан, андыйларга шәфкатьле.

Шулай да бу шәфкатьле алла боларны җәннәттә калдыра алмый:

«Күземнән югалыгыз! Берләрегез икенчеләрегезгә дошман (?). Вакытлыча сезнең урыныгыз Җир йөзендә булыр. Шунда яшәрсез, шунда үләрсез, бер көн янәдән терелеп, монда килерсез».

*(Коръән, «Киртәләр» сурәсе, 23—24 аятьләр.)*

Менә ничек кызык итә алла үзләрен!..

*(Дәвамы бар.)*

*Касыйм Фәсәхов*

## Мин—пионер хәзер

*Тукай-Кырлай, Яңа Кенәр һәм Этнә мәктәпләре пионерларына багышлыйм.*

Бәйләдегез миңа ал галстук,
Рәхмәт сезгә, нәни дусларым.
Күз алдыма килде кырык бернең
Ачы җилле салкын кышлары.

Пионерга кердем мин шул елны,
Тик галстук бәйли алмадым.
Сез белмисез инде ул елларның
Бездән барысын тартып алганын.

Дәфтәр иттек иске китапларны,
Уныбызга — ике дәреслек.
Алабута безгә ризык булды,
Шундый иде, дуслар, дөреслек.

Сез бәйләгәч миңа ал галстук,
Шул авыр чак килде хәтергә.
Шуңа күрә күзгә яшь төелде,
Көч җитмәде рәхмәт әйтергә.

Карыймын да сезгә сокланам мин,
— Эх, яшәрсәң иде, — дип куям.
Тик үкенү түгел, куану бу —
Үземне гел үсмер күк тоям.

## Этнә кызларына

*(Шаяру)*

Үен-көлке көңелле дә,
Тик хәлләр яман әле:
Сездән киткәч нишләрмен дип,
Утларда янам әле.

Бүгенгә кадәр Этнәгә
Нигә килмәдем икән?
Сездә — иң мөлаем йөзләр,
Ничек белмәдем икән?

Китәм инде гашыйк булып
Этнә гүзәлләренә.
Күңелләрем сездә кала...
Ничек түзәргә миңа?

Әллә, кызлар, минем хәлгә
Үзегез керерсезме?
Ара-тирә сәлам хатлар
Язып җибәрерсезме?

Бары «әйе»не ишетәм,
«Юк» диеп әйтмәгез дә.
Онытмагыз: йөрәгемне
Калдырам Этнәгездә.

# ФАТИХ ӘМИРХАН ХАТЛАРЫ

*Соңгы еллар матбугатында Фатих Әмирханның төрле елларда язылган һәм төрле кешеләргә адресланган байтак хатлары басылды. «Казан утлары» журналының бу санында күренекле язучыбызның тагын берничә хатын игълан итәбез. Ул хатларда Ф. Әмирханның фикри үсеше һәм иҗтимагый эшләр белән яшьтән үк кызыксынуы, моннан ярты гасыр элек татар матбугатының хәле, беренче спектакльләрнең мәйданга килүе, татар яшь интеллигенциясенең рухи кичерешләре чагыла.*

*Ф. Әмирхан М. Гафуриның Октябрьга чаклы язылган күп кенә әсәрләрен тәнкыйть иткән иде. Октябрьдан соңгы чорда М. Гафуриның иҗаты нык чәчәк атты, ул чын мәгънәсендә революция трибуны булды. Ф. Әмирханның Гафурига җибәргән котлау хатында аның иҗатындагы шул уңышны нык төшенгәнлек, тәкъдир иткәнлек ачык сизелә.*

*Биредә игълан ителгән хатларның берсе дә моңа кадәр тулы килеш матбугатта чыкмаган. Тик Ф. Әмирхан иҗаты турындагы хезмәтләрдә һәм мәкаләләрдә кайбер хатлардан аерым өземтәләр һәм фактлар гына файдаланылган. Хатлар СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты архивында (16 фонд, 3 опись, саклану берәмлекләре 1 һәм 4) саклана. М. Гафури исеменә язылган хат яңа стильдә бирелә. Калган барлык хатларның язылу вакытлары иске стиль белән күрсәтелгән.*

*Ф. Әмирханның әле совет матбугатында һәм гомумән матбугатта игълан ителмәгән хатлары, төрле вакытта, төрле уңай белән язган истәлекләре күп. Болар да киләчәктә матбугатка чыгарлар дип уйлыйбыз.*

*Х. ХИСМӘТУЛЛИН.*

1904 ел, 20 февраль.

**Мөхтәрәм дустым Р. Алуши [1],**
**әс-сәламе галәйкем!**

**Затыныңызның мәктүбе юлкарак, бик мәмнүн улдым [2].**

**Мәдрәсә ихтилале [3] исә игъдадия [4] сыйныфы арасында уларак, програмсыз улдыктан, мәдрәсә ислахына [5] хезмәте булмады, диярлек дәрәҗәдә аз улды. Хәтта рәисләре улан, исереклек илә башы череп беткән касим уларак, дамеллага ихтилалның сәбәбе берсе игъдадиягә мәнтыйк [6] укытмаганлыктан, әгәр мәнтыйк керсә туктыйбыз диярәк, бөтен игъдадия өчен мәнтыйк илтизам итмеш [7] иде. Хәзер, әлхәмделиллаһ, ул малай галия җәмгыяте [8] тарафыннан бирелгән прошениедә күрсәтелгән ифсаде мәдрәсәсе [9] өчен милләт мәҗлесе тарафыннан куылды.**

**Бу ихтилалның фаидәсе [10] уларак, мәдрәсә идарәсе өчен хәлфәләрдән мөрәккәп [11] бер милләт мәҗлесе [12] ясаларак, дамелланың истикъләле тәмамән сәлеб иделде [13].**

**Хәзердә бөтен мәдрәсә шәкертләреннән мөрәккәп бер җәмгыять тәшкил ителде. Хәзер дә 75 кадәр әгъзасы бардыр. (Яшерен тотылсын.)**

**Студентлар вә гимназисткалар илә үткән ел башында татар лисанында [14] ике уен уйнадык [15]. Берсе — «Кызганыч бала», берсе — «Гыйшык бәласы». Мин «Кызганыч бала»да Хәлил булып уйнадым, «Гыйшык бәласы»нда Габдес-Самат әфәнде булып уйнадым. Халык тарафыннан шаян тәхсин улынды [16]. Бәйрәмнең өченче көнендә дәхи ике уен уйныйбыз, ин шаә аллаһ.**

Бакый садакать [17].

Фатих.

---

[1] Ризван Ибраһимов (Алуши) — Ф. Әмирханның мәдрәсәдә бергә укыган иптәше. Совет чорында Уфада Комвузда укыта, 1938 елда үлә.

[2] Хатыгызны алуга бик шатландым.

[3] Чуалышы.
[4] Элекке мәдрәсәләрдә ибтидаи (башлангыч), рөшди, игъдади, гали дип атала торган баскычлар була иде.
[5] Укыту эшләрен яхшыртуга.
[6] Логика.
[7] Йөкләгән.
[8] 4 нче баскыч сыйныфларында укучылар.
[9] Мәдрәсәне бозу, таркату.
[10] Файдасы.
[11] Төзелгән.
[12] Укытучылар советы.
[13] Баш мулланың мөстәкыйль эш итү хокукы бетерелде.
[14] Телендә.
[15] Спектакль куйдык.
[16] Яратып каралды.
[17] Дуслыкка турылык теләп калучы.

1906 ел, 24 октябрь, Москва

**Газиз дустым Ризван, сиңа сәламнәр улсын!**

**Бәндәң 22 ндә октябрь Москвая[1] килдем вә мәгъһүд ишә[2] башладым. Казанда вакытта синнән бер мәктүп (акчалы) вә бер телеграмма аларак, үзем дә туйга[3] бер тәбрик карточкасы күндермеш идем, фәкать 5 нче октябрь тарихлы дәхи ачык бер мәктүбеңне аларак, у[4] карточканың ирешмәдекен белеп тәәссеф иттем[5]. Шуңа күрә сине вә Фәрханә ханымны яңа мәгыйшәт[6] вә бер-береңезә муафикъ иптәшлекеңез илә тәбрик итдекеми вә һәр икеңези шат вә бәхетле күрмәк мәкъсат вә амалемнең[7] берсе идекекене гарыз итәм.**

**Мәктәпнең интизамлы[8] бардыкы вә кызлар кыйсьме[9] дә вөҗүдә килдеке[10] хәбәр мине дәхи артык шатландырды. Тырыш, кардәшем, тырыш, тырышуда гына сәгадәт[11].**

**Москвая килдекемә ике көн улды. Заһид әфәнде[12] саясендә[13] вакыт бик рәхәт уздырыла. Заһид әфәнденең истикьбаль[14] вә мөгаләмәләреннән типичный редактор бюрократ түгел, бәлки башка иптәшләр кеби бер күңелле иптәш идеке күренмәктәдер. Хәзер Москваның иң әгъла[15] бер урамында (Петровка) Мәрьям Шамил[16] квартирында бер гостиницада икамәт итәм[17].**

**Казанда син киткәч әллә нинди ят вакыйгалар булмады, яхут булса да хәтеремдә калмаганнар, шуңа күрә мин китәр алдыннан гына булган хәл вә хиссиятларымны гына язмакчы булам: октябрь уннарыннан соң матди җәһәт бик начарланган вә әти берлә арамыз кямилән[18] суыгаеп җиткән иде. Хәтта китәр көнне әтинең миңа кылган һәр хәрәкәтеннән бер суыклык вә син бездән бөтенләйгә аерылып чыгасың, бәдбәхет, дигән кеби бер шәй[19] аңлана вә һәр минуты мине өюдән суыта вә ерагайта иде. Икенче тарафтан, әнинең мөшфиканә[20] вә мадиранә[21] мөгамәләсе вә китәр алдында, күзләре яшьләнгән хәлдә, «углым, син безгә ачуланма вә хат яз» — дигән сүзләре минем дә күземә яшьләр китерә вә аналарның балага булган мөнәсәбәтләрен миңа бик ачык аңлата иде. Әлхасыйль, бер яктан, өйгә якын да җибәрми торган чәнечкеләр, вә бер яктан да, бик нык тарта торган җепләр мине бик уңайсыз бер халәткә куялар иде. Шулай итеп, өемнән аерылдым, вә җомга вакытында (20 октябрь) вокзалга килдем. Миңа кадәр озатырга төшкән иптәшләр килеп җиткәннәр иде, истикъбаль иттеләр[22]. Сөйләштек, кайгырыштык, куаныштык, поездның китәр вакытлары җитте, иптәшләр актык сүзләрен әйттеләр вә үбештек, вә китеп тә бардым. Хакыйкатән агыр[23] моментны, үземнең ялгызайганымны хис иттем.**

**Бер сәгать урынымнан кузгалмый барырга вә кальбемдә[24] хиссиятемне үземә аңлатырга мәҗбүр улдым ки, хасыйл бөйлә[25] чыкты: иптәшләремнән аерылам, дөньяда мине иң якын күрә торган бер йөрәккә яра салам — агыр. Казаннан вә аның татарларыннан[26] котылам — шатлык. Эш башлыйм, үземнең истигъдатымны[27] күрәм — изтыйрап вә мәҗһүлият[28].**

**Поезд киткәч, берадәрем Ибраһимнең[29] әйткән сүзе миңа тагы бер мәҗһүл халәт вә гаҗземне[30] хис итүне килтерә иде. Аның сүзе бу иде: «Абый, мине онытма, беләсең әтинең могамәләсен, син киткәч, миңа тагы да унайсызрак улыр!»[31]**

**Бәхетемә каршы, юлда студентлар вә курсисткалар туры киләрәк, алар илә белешләнеп барып, бер вакытка булса авыр хисләр онытылып тордылар.**

Аитов Исмәгыйль[32] бу соң көннәрдә миңа бик суыгайган иде; сәбәбе исә бөйлә эшсез йөрү вә әхлак бозу ярамаганлыгын сөйләү. Башка нә языйм, кардәшем. Рәсемнәр җибәрәчәгеңне вәгъдә итмешсең, бик интизар илә[33] көтәм. Үземнекен һәм күндеререм, ушбу көннәрдә сниматься итәргә торам.

Фәрханә ханымга миннән сәлам сөйләп, догаларың үтен.

II

Әгәр дә «Тәрбиятел-этфаль»гә мөштәриләр[34] табылыр дип уйласаң, абунә[35] дәфтәре җибәрермез. Йөзгә 10 микъдары хезмәт мөкяфәте[36] бирермез. Ваклап сатарга алдырырга мөмкин. Журналның әүвәлге нумирәсе (нәмүнә[37]) декабрь башына кадәр чыгачак. Январь башыннан тәртип берлә чыга башлаячак. Еллык бәһасы 5 сум. Һәр айга ике журнал. Берничә педагогический листоклар вә календарь, вә башка берничә шәйләр[38] һәдия[39] ителәчәк.

Редакциянең адресы: Москва, Цветной бул. д. Байбекова, ред. татарского журнала «Тербиял-этфаль».

Миңа мәктүп яздык та: «Фатихел-Әмирхания махсус» кайден[40] арттырырсың. Мәктүп көтәм.

Бакый мәхәббәт
Фатихел-Әмирхани.

---

[1] Мәскәүгә.
[2] Әлеге эшкә (журналда секретарьлык эшенә).
[3] Фәрханә белән Ризван туе. Фәрханә озак еллар Себер мәктәпләрендә укытучы булып эшли, 1958 елда Уфада үлә.
[4] Ул (төрекчә форма).
[5] Үкендем.
[6] Тормыш.
[7] **Теләгемнең.**
[8] Тәртипле.
[9] Бүлеге.
[10] Ачылуы.
[11] **Бәхет.**
[12] Заһид Шамил — XIX гасырда Дагстанда азатлык хәрәкәтенә җитәкчелек иткән Шәех Шамилның улы, «Тәрбиятел-этфаль» исемле балалар журналының (1907 ел январь-апрель) редакторы.
[13] Аркасында.
[14] Каршы алу.
[15] Иң шәп.
[16] Мәрьям Шамил — Заһид Шамилнең кыз кардәше.
[17] Яшим.
[18] Бөтенләй.
[19] Бер нәрсә.
[20] Шәфкатьле.
[21] Аналарча.
[22] Каршы алдылар.
[23] Чын-чыннан авыр.
[24] Күңелемдә.
[25] Болай.
[26] Ф. Әмирханны үз тирәсен чолгап алган искелек, ирексезлек нык туйдырган була.
[27] Сәләтемне, булдыклылык дәрәҗәмне.
[28] Дулкынлану һәм билгесезлек.
[29] Ибраһим — Ф. Әмирханның энесе; 1918 елда Коммунистлар партиясенә керә, шәхес культы елларында кулга алынган.
[30] Билгесез хәл һәм көчсезлегемне.
[31] Бу сүзләр Ф. Әмирханның «Яшьләр» (1909) пьесасындагы Газиз һәм Йосыф хәлен искә төшерәләр.
[32] Исмәгыйль Аитов (1888—1930) — Сөләйман Аитовның улы. Икенче бер хатында Ф. Әмирхан аны «типкеч бер бай малае» дип атый.
[33] Теләп.
[34] Язылып алучылар (подписчиклар).
[35] Акча алу.

[36] Җыелган акчаның 10% кадәр хезмәт хакы.
[37] Үрнәге.
[38] Нәрсәләр.
[39] Бүләк. Ул елларда журналларны язылып (подписчик булып) алучыларга бүләк итеп төрле китап һәм башка нәрсәләр җибәрү гадәте бар иде.
[40] Өстәмәсен.

1906 ел, 9 декабрь, Москва

**Кардәшем Ризван! Многоуважаемая Фарханя ханум!**
**Сезләрә сәламнәрем!**

**Җибәргән һәдия — карточканы алдым, һәр икенезгә халис тәшәккеремне гарыз итәм [1]. Карточка хави булдыгы [2] нурлы йөзләр белән хакыйкатән һәркемнең дикъкатене җәлеп итәрлектер. Фәкать кавалерларда азлык күренә, яңадан бер кавалер арттырылган булса, эффект кямил хасыйль булыр иде. Карточкага юмор кабиленнән генә бер тәнкыйть ясамакчы булам. Әүвәлән: Ризванның мендәр өстенә утырып төшүе миңа Хувалин өязендәге авыл муллаларны тәхтыйр итәдер [3]. Әллә, Ризван, син дә шул тарафтанмы? Саниян: Фәрханә ханымның муенында синең кулыңны күреп, гаҗәп дәрәҗәдә курыктым (чорт возьми), әллә Ризван Фәрханә ханымны бумакчы булганмы? Салисән: передайте многоуважаемой m!!e Александре Виницкой, что она на карточке очень хорошо изображает фельдшерицу, наблюдающую пульс Фарханы ханум [4].**

**Ризван, хәтереңә китер әле Фатыйма Кулиеваны; Рәхимә туташны мин әүвәл мәртәбә караганда, «тәмам бу Фатыйма булырга кирәк» — дип уйлый яздым. Рабиган: ничек һәммәгез дә, гомерегездә фотограф күрмәгән шикелле, аңар карап төштегез?**

**Ха, ха, ха!**

**Но это шутка.**

**Миңа карточкада бик ошаган бернәрсә бар: ул да — һәммәңезнең простой киемнәрдә, демократ сурәттә булуңыздыр.**

**Хатыңыздан бик мәмнүн [5] була торган хәбәрләр белгәнемә күрә, бу хат минем өчен бик кадерле иде: Фәрханә ханым белән табигатьләреңезнең болай килешүе икеңезнең дә сәгадәтеңезне тәэмин иткән нәрсәдер.**

**Җәнабе хакъ (?) дәвамене насыйп итсен!**

**Хәер, мин әүвәлдән дә шулай булыр дип уйлаган идем. Чөнки, әүвәлән, син әхлаксыз кеше түгел. Вә саниян дә — Фәрханә ханымның карточкасы миңа күрсәткән нәрсә кямилән хәлиметтабгы [6] улачагыны белдертә иде.**

**Да, милые, вы счастливые люди [7]!**

**Ризван, син миңа «карточка дикъкатьне җәлеп итәчәк булмаса да...» дип язгансың. Совершенно напрасно: минем генә түгел, бәлки бөтен редакциядәге кешеләрнең дикъкатене җәлеп итте.**

**Москвадагы мәгыйшәтем:**

**Москвадагы татар вә хәтта рус аристократларыннан, хәтта бюрократларыннан әллә никадәр гаиләләр белән таныштым. Һәр кич дип әйтерлек вечерларда, балларда йөрергә тугры килә... Как это все отвратительно... [8] Вакытлардан бер вакытта Шамилләрдә вечерда бер генерал кызы — яшь кенә бер барышня белән белештем. Аның белән бераз танцевать иттек, сөйләштек... и так далее. Менә бер вакыт боларның үзләрендә кунакта булдык. Бу кыз мине бер бүлмәгә чакырып, шундый сөаль кыла: «Мин Сездән бернәрсә сорасам, гаеп итмәссезме? Һәм дөрес җавап бирерсезме? Мин дә бик аристократический вид белән: «Пожалуйста» [9], — дип җавап бирдем. (Хәзер яхшы тыңла!) «Миңа әйттеләр, сез будто-бы социалист? Дөресме шул сүз, юкмы? Мин өмит итәм: ялгандыр!» Мин җавап бирәм: «Да, соверш. верно». Кыз куркып китә. Бераздан соң: «Соң сез шундый мәхәббәтле вә һич куркыныч түгел бит». Мин: «Разве Вы думаете, что социалисты все страшны?» [10] Ул: «Это несомненно» [11]. Менә шушы рухта ярты сәгать сөйләшеп көчкә аңлаттым ки, социалист очраган бер кешене үтерә торган кеше түгеллекне.**

**Хәзер үзең уйлап кара, миңа нинди җәмгыятьләрдә йөрергә тугры килә. Шундый вакытлар була ки, шул аристократка вә аристократларның кыланышларыннан (извини за выраж.) косасылары килә... Әммә Заһид әфәнде, менә ул единственный мин аңлый торган кеше. Ул — как товарищ һәм мөтәрәккый [12].**

Тормыш монда кыйммәт. Хәзер 60 сумнар акча табам. Шул аристократлар арасында торганга күрә, һәммәсе тотылып бетә.

Хәзер инде ул вечер-балларны ташлап, чынлап укырга тотынам! Сез миннән карточка сорагансыз.

Вскором врем. я Вам пришлю свою карточку [13]. Ләкин бер шарт бар: сез дә тәнкыйть язып җибәрерсез.

Әнемнән хат алам. Исмәгыйльдән алгаладым. Әмма Айтугановтан [14] һичбер хәбәр алганым юк.

Бүген Кулиевтән [15] хат алдым. Между прочим, ул яза: сигезенче декабрьда, әгәр губернатор рөхсәт итсә, «Новый клуб»та «Өч хатын белән тормыш»ны уйныйбыз, ди. Һәм бу ел уйнаучы кызлар икенчеләр, ди. Интересно, откуда они появились [16].

Журналның әүвәлге номерусы 15 декабрьда чыга.

Мофәссаль [17] хат көтәм! Ишетәмсең?

Ну пока до следующего письма.

*Фатих Әмирхан.*

---

[1] Чын күңелдән рәхмәт белдерәм.
[2] Әчендәге.
[3] Искә төшерә.
[4] Өченчедән — хөрмәтле Александра Виницкаяга әйтегез: Фәрханә ханымның йөрәк тибешен тикшерүче фельдшерицаны карточкада ул бик уңышлы күрсәтә.
[5] Шат.
[6] Тәмам йомшак табигатьле.
[7] Әйе, кадерлеләрем, сез бәхетле кешеләр.
[8] Болар никадәр җирәнгеч.
[9] Рәхим итегез.
[10] Сез барлык социалистлар куркыныч дип уйлыйсызмыни?
[11] Бу — һичшиксез.
[12] Прогрессист, яңалык яклы.
[13] Озакламый мин сезгә карточкамны җибәрермен.
[14] Айтуганов Ибраһим — сәүдәгәр Исмәгыйль Айтугановның улы, яшьләр арасына катнашып йөрсә дә, файдалы эш күрсәтмәгән.
[15] Кулиев Ибраһим — журналист, Ф. Әмирханның яшьлек иптәшләреннән. 1885 елда туган, шәхес культы елларында кулга алынып, төрмәдә үлә.
[16] Кызык, кайдан килделәр икән?
[17] Озын.

1907 ел, 8 апрель, Москва.

Кардәшем Ризван!

Март 18 ндә язылган мәктүбеңне өченче көн алып, бүген хат язарга ашыгам.

Казанда торган вакытта талигъның [1] золеме белән читкә атылган дусларымның хәлләрен бик накыйс [2] уйлаган иканлегемне фәкать хәзер үзем шулар халәтенә төшкәч кенә бихаккыйһи [3] тәкъдир итә ала башладым [4]. Һәр хат, һәр кечкенә генә хәбәр, шул тарафтан искән һәр җил бик кадерле була икән, шуңа күрә дә синең мәктүбеңдә: «Сагындым, Казанга кайтырга вә көрәшергә ихтыяҗ зур» дигән сүзләр хәзер минем өчен бик аңлана торган җөмләләрдән.

Вакыйган [5], үткән көннәрне хәтергә китерсәң, арасында нинди рәхәт вә сафа [6] белән үткәрелгән вә вакытында бихаккыйһи тәкъдир ителмәгән көннәр, кичләр, төннәр тугры киләдер. Ничек без Кулиев Ибраһимга Осланга барып шаяра идек. Ничек ул безне җимеш белән ачытылган куас белән сыйлый иде. Ничек син аның хатыны [7] белән рәхәттә торганына габта итеп [8] Фәрханәне тәзәккер итә [9] идең?

Ничек без җыелып, Айтовлар дачасында иртәнге 4—5 кә кадәр сүгешдәге мәһарәтебездә мөсабәка итеп [10] карыйдыр идек; ничек Айтуган Ибраһим безгә һәртөрле дивертисментлар күрсәтә иде. Ничек без җыелып Казанкага коенырга төшә идек...

Әлхасыйль [11], кызык-кызык вакыт уздыра идек! Казанга мин 10 апрельдә кайтам, әгәр сез дә кайтсагыз, ул вакытта җәмгыятебез бөтен әгъзалары белән булып, китек җире калмас иде. Язуларына күрә бу ел Казан дәхи дә кызыграк булачагын вәгъдә итеп тора икән.

Исмәгыйль күптән түгел Москва аркылы Ялтага сәфәр итте. Майның уннарында Казанга кайтачак.

Фәрханә ханым мин (ем) мәкаләләрне укый икән. Ләкин мин мәкаләләремне күбрәк имзасыз җибәрәм. Шунлыктан, монда кайсылар минем мәкалә булдыгын сөйләмәкче булам.

Беренче нумерудә — «Идарәдән»; «Истамбул шәһәре»; «Күктә күренә торган нәрсәләр»; «Гаяз».

Икенче нумерудә— «Идарәдән» (ләкин кирәкле җирләре төшерелеп калдырылган).

Өченче нумерудә — «Идарәдән»; «Күктә күренә торган нәрсәләр».

Дүртенче нумерудә — «Идарәдән» (кирәкле җирләре төшерелгән); «Москва шәһәре»; «Галимәтел-бәнат»; «Менделеев»; «Зилзилә» [12].

Бишенче нумерудә — «Идарәдән» (кирәкле җирләре калдырылып); «Петербург шәһәре»; «Гөл агачы» (тәрҗемә); «Күктә күренә торган нәрсәләр»; «Дума ачылды» (иң кирәкле җирләре калдырылып). Моннан соңгы нумерләрдә бәгъзы мәкаләләремне имза белән язмакчы булам.

Күптән түгел генә Ибраһимнан хат алдым. Казанда мине бик көтәләр (?), имеш. Һич көтмәгәндә, Фатыйма Юнысовадан [13] да бер хат алдым. «Гаҗәп сагындык. Казанга кайтыгыз» — дип яза. (Менә гаҗәп!). Киләчәк хатыңны Казанга яз!

Фәрханә ханымга сәламемне сөйләп, догаларын үтен!

Бакый мәхәббәт вә интизар.

*Фатих.*

Бүген алтынчы хат язам инде, арып беттем.

---

[1] Язмышның.
[2] Кимчелекле, ялгыш.
[3] Чын-чыннан.
[4] Ф. Әмирхан Мәскәүгә китүе уңае белән язган хатында Казаннан котылуына бик шатланганын белдергән иде.
[5] Чыннан да.
[6] Күңелле.
[7] Сүз Фатыйма Кулиева турында бара. Бу ханым хәзер дә Казанда яши.
[8] Кызыгып.
[9] Исенә төшерә.
[10] Осталыкта узышып.
[11] Кыскасы.
[12] Җир тетрәү.
[13] Фатыйма Юнысова—зур сәүдәгәр һәм җир хуҗасы Мөхәммәтрәхим Юнысовның кызы. Демократик интеллигенция тирәсендә чуалып йөрү ул чактагы бай кызлары арасында модада була.

1908 ел, 17 апрель, Казан.

**Газизем Ризван!**

Синең алдыңда мең мәртәбә гөнаһлымын. Мин — хат язарга бик иренә торган кеше. Бу хакыйкать сиңа да күптән мәгълүм булырга кирәк. Ялкаулык бер мәраз [1], диләр. Шуңар күрә аның өчен кешене гаепләргә түгел, бәлки кызганырга тиештер. Сиңа хат язарга уйлаганыма бик аз дигәндә, ай ярым бар инде. Ә тәкъдир җитмәгәч, бер эш эшләр хәл юк! Журнал нәшере тугрысында киңәш сорыйсың. Ул тугрыда минем ике елгы тәҗрибәм белән хасыйль иткән фикерем шушы: 1) кирәк газета, кирәк журнал әүвәлге ике елда мотлак [2] зарар күрә. Фәкать аннан соң гына үз-үзен илетә алырлык дәрәҗәгә җитсә җитә ала. 2) Әгәр газета вә журнал киләчәктә бер ашатып яткырырлык нәрсә булсын дигәндә, баштан бик аз дигәндә 3—5 мең сум акчаң кулда булырга тиештер. 3) Нәшер итә башлаганда, мотлак көздән башларга тиештер. Чөнки январь башыннан гына башланганда, халык мәсләген [3] вә ышанычын белмичә, иштира итми [4]. Шулай итеп, яз җитә. Ул вакытта халыкта газета вә журнал һәвәсе калмый.

Шулай, берадәр!

Күрәмсең, хәзер «Яңа тормыш» [5] нинди матур гына туктап куйды? Риваятьләргә [6] күрә, шул аз арада да мең сум зарар итеп өлгергән, имеш.

Алай да, әгәр инде нашир вә мөхәррир булырга бик дәртең төшкән булса, мин үз тарафымнан бер эш гарыз итә [7] алам: «Әлислах» идарәсе июль башларында көлке

журналы нәшер итә башларга уйлаган иде. Шуны мин сиңа уступать иттерермен. Хәзер файда ителәторган бер журнал булса, ул да көлке журналы булырга гына мөмкин.

Гыйбрәт өчен мин сиңа «Әлислах» хәленнән бер кыйсем[8] языйм. «Әлислах» октябрь башыннан апрель башына кадәр, ягъни ярым ел микъдары вакытта 1400 сум расход тоткан. Бу җөмләдән — мөхәррирләр вә редакция тотуга барысы 400 сум тотылган. Димәкки, мөхәррирләргә бер дә түләми диярлек дәрәҗәдә вә начар гына фатирда торганда да никадәр расход кирәк буладыр. Хәзер «Әлислах» фатир өчен түли 20 сум;

Секретариатка .... 20 сум;
Мөхәрриренә .... 15 сум;
Вак расходлар .... 12—13 сум
микъдарында.

Без нәшер итә башларга уйлаганыбыз 15 көнлек көлке журналына анык редакция вә анык мохәррирләр өстенә, елына 1200 сум расход кирәк буладыр. Әгәр елына ике сум абунә бәһасы тәгъин ителгәндә, 600 мөштәри[9] лазим буладыр. Хәзер көлке журналына, хосусан, «Әлислах» исеменнән нәшер итә башлаганда, ул микъдар гына мөштәри табып булыр дип уйлыйбыз. Менә, берадәр, шундый, шундый хәлләр. «Әлислах» ул журналны сиңа уступать итсә, аз бәһа белән редакциясендә бер почмак уступать итәр. Ул вакытларга бераз буш мөшарәкәт иткәләүчеләр[10] дә табылгалар. Әгәр мин җәйгә вә кышка Казанда калсам, мин дә кулымнан килгән ярдәмне кылышырмын. Аның өстенә Казанда башка эшләр дә эшли алуыңа ышансаң, бәлки, бара торгач, чибәр генә урнашып китәргә дә мөмкин булыр.

Әгәр шулай итәргә касдың була торган булса, тизлектә кайтып, рөхсәт сорап гариза бирергә мәҗбүрсең.

Фәрханәгә сәлам. Тизрәк терелсә иде дип, биш вакыт намаз артыннан дога кылам.

Бакый кардәшең

*Фатих.*

Хәлем алда[11].

Бик тиз бөтен хәлеңне язып җибәр!

---

[1] Авыру.
[2] Һәрвакыт.
[3] Тоткан юлын (политик линиясен).
[4] Язылмый, сатып алмый.
[5] Уральскида «Фикер» газетасы тукталгач, шуның урынына 1907 елда чыга башлаган газета.
[6] Сөйләүләренә.
[7] Тәкъдим итә.
[8] Бүлек.
[9] Сатып алучы, подписчик.
[10] Катнашу (язышу)чылар.
[11] Бу чакта Ф. Әмирхан аяксыз калып, шуннан дәваланган һәм сәламәтлеге алга барган чор. «Хәлем алда», сүзе шул турыда.

1908 ел, 26 октябрь, Казан.

Дускай![1]

Моңарчы мин сиңа әллә ничә хат язарга тиеш булып та, хәзергә хәтле бер хат та язмаганлыгым өчен мин синең алда зур гаепле инде. Ләкин минем бу гаебем бер синең алда гына түгел, иптәшләремнең һәркайсы алдында бик мәгълүм вә бик иске инде: «Лән йослихел-гаттаре ма әфсәдәһен-нәһәр»[2], — диләр гарәпләр.

Әүвәл мин сиңа үз хәлләремнән яза башлыйм: ниһаять дәрәҗәдә акчасызлык, уртача, чибәр генә дәресләр белән шөгыльләнү, бераз язу, һәркөнне редакциядә булу, әдәбият мәҗлесләре сылтавы белән атна саен кунакта булу, Ш. К.[3] туташны күрсәм,

куану — минә хәлләрнең иҗмале [4]. Сәламәтлек акрын алга бара. Впрочем, акча юклыктан бик күп вакыты җиткән дәваларны кылмый торырга туры килә. Син язасың (хат № 1), «Әлислах»ны ташла да, акча эшләп, дәвалана башла, дип [5]. Җаным, минем бөтен удовольствием дә хәзер шул көн саен редакциягә чыгудан гына гыйбарәт бит: ял итү дә шул, гомер итү дә шул. Минә шуны син хәтереңнән чыгарма.

Хәзер «Әлислах» хәленә килик: акчасы юк, төрле хәйләләр иткәләргә туры килә (сер тотарга).

Иптәшләр хәленә: Каюм Коләхметовны [6] өченче көн арестовать иттеләр. Тизлектә Сембер шәһәренә сөреләчәк. Әгәр таба алсаң, бераз иганә [7] җыештырып җибәр (редакция адресына мөмкин). «Казак» [8] укый, тырыша, бу көннәрдә яңа тужурка тектереп җибәрде. Газиз [9] бу көннәрдә солдатка каралды, бик нәзеклек белән калды, ул да укый, тырыша, бер көн укыган нәрсәсен икенче көн сүз арасына кыстырып-кыстырып, ят кешеләр күбрәк җирдә рассказать итеп чыга. Габдел-Кадири дә бу арада күбрәк сөйләшә башлап тора иде. Солтан [10] тоже чибәр генә укый бугай, ләкин «Мин кая барам» [11]нан да калмый, диләр. Агиев [12] үзен шагыйрь дип уйлап бик куанып йөри башлады. «Хәзер сез минем шигырьләрне тәкъдир итмәсәгез, тарих тәкъдир итә аны» — дип, чынлап үзе ышанып, кешене дә ышандырырга теләп сөйли. Хәзер Гарифлар [13] белән дә катыша башладык, гаетнең дүртенче көнендә мине үзләренә чакырганнар иде, барып, озак утырып кайттым.

Әдәбият кичәсенә килсәк: ул «Әлислах»ка бары сигез сум файда китерде, чөнки шул ук кичне клуб залында Закир Сәедзадә [14], толчокчы вә күтләкләрдән бер труппа тәшкил итеп, спектакль куйган иде. Хәер, үзе дә кызык булды. 47 сум бөтен сборы булган. Ул кичне бөтен молодежь безнең вечерда булдылар. Закирларда танца игълан ителгән булса да, итүчеләр булмау сәбәпле, булмый калган.

Безнең «Әдәбият кичә»сендә Тукаевның «Кисекбашы» укылды (үзе укыды). Халыкның көлә-көлә эчләре катты һәм Тукаевны да бүлә-бүлә кул чабулар белән сыйладылар. Кичнең ахырына таба үзе «мин кая барам» иде, кичәдә әллә нинди кызыклар да булды: бер приказчик (әүвәл Агафуровлар [15]да торган, хәзер Казанда тора), битенә инлекләр сөртеп, пудралар ягынып килеп, шундый бер бию белән биеде ки, гарәпләр әйтмешли, «Ләм йәра гайнез-замани мисләһү» [16]. Затына мөнасип бер сыйфат белән әллә генә ничек итеп җыерылып үз эченә үзе кереп бетә дә, шуннан аяк-кулларын чыгарып селти. Бөтен кешенең күзе анда гына булды. Бу — бер. Икенчесе — бер карт кына, озын буйлы татар танцевать иткән кызларны канфетти белән тозлады: танцевать итә торган парочканы күрәме — хәзер яннарына килә дә, өч кенә данә канфетти алып, кызның башына салып җибәрә. Ник бер генә данәсен җиргә төшерсенлә. Потеха была!

«Әдәбият кружогы» хәзер тәртипле дәвам итә. Укыла торган нәрсәләр шулкадәр күп була ки, күп мәҗлесләрдә вакыт җитми кала. Мөзәкәрәләр [17] дә бик кызыклы булалар. Габдулла Гыйсмәти [18] белән моназира [19] тәмам булганы юк әле. Егет үзе дә шиккә төшә башлаганга охшый.

Богданова Гайшәләрнең йортлары янды. Үзләре көчкә тәрәзә(дән) чыгып өлгергәннәр. «Оренбургская газета»да Казан татар уеннарында мөшәрәкәт итүче [20] кызларны тәхкыйрь итеп [21] язган кешенең кем икәне билгеле булса, аны татар газеталарына язып бик нык сүгәргә кирәк иде. Берәр шарлатандыр инде. Касим Уралец [22] дигән бер шарлатан Казанда рус газеталарына әллә нәрсәләр язып яткан иде, бу да шундый бер татар приказчигыннан аякка баскан нәрсәдер, шикелле. Сезгә протест язу, әлбәттә, фарыз булмаса, ояты синең белән Борһан [23] башына төшәчәк. Ә «мәшһүр вә зур мохәррирләремездән» Ярулла әл-Вәлинең [24] безгә биргән ләкабеннән бик мәмнүн [25] булдык. Солдатта мулла булып йөргән вакытында татарларга идеальный татарча намаз укытырга гына мәләкәләнеп [26] кайтканмы дип уйлый идем, татарча исем кушарга да өйрәнгән икән. Әгәр азанны да татарчага переводить итсә, аннан соң тәмам зур мохәррирлекнең кәмаленә ирешкән булыр иде. Шулай да, андый наивный самоучка татар солдатлары милләт өчен бик файдалы булалар. Чөнки милләт балаларына көләргә бернәрсә артык була. Синең хаттан соң, мин дә аның белән белешергә бик кызыгып киттем әле (әгәр теләсә). Безнең гаибанә белешлегебезнең мокаддимәсе буларак, минем исемнән тәшәккерән [27] шушы сүзләрне передать итә аласың: «Суконным рылом в калачный ряд не лезут».

**Әгәр бер кеше шулай лезать итсә, аңар замечание ясаучы гаепле булмый. Борһанга сәлам сөйлә. Минем өчен кулын кыс. Аннан соң хат язмыйча озак торган өчен бик нык орыш!**

Ну, җаным, хәзергә хуш!
Хат яз.
*Фатих.*

Ибраһим һәр хаты саен сиңа сәлам яза. Сафия туташтан бик еш хат алам. Ул рождествога кайтып китә.

---

[1] Исмәгыйль Аитов.
[2] Заман, тормыш бозганны хушбуй сатучы төзәтә алмый.
[3] Шәмсениса Камалова — Ф. Әмирханның сөйгән кызы, 1918 елда Казанда үлә.
[4] Кыскачасы.
[5] Исмәгыйль Аитов үзенең 27/IX 1908 елдагы хатында «Әлислах»ны ташларга, дәваланырга һәм укырга киңәш бирә.
[6] Драматург Гафур Коләхметовның энесе, яшьләй үлә.
[7] Ярдәм акчасы.
[8] Язучы Кәбир Бәкер (1880—1921).
[9] Газиз Гобәйдуллин (1887—1938).
[10] Солтан Рахманколый (1888—1916).
[11] Исерткеч сатыла торган кибет.
[12] Фәхрел-Ислам Агиев — язучы, журналист (1887—1938).
[13] Укытучы һәм драматург Гариф Богданов күздә тотыла булса кирәк. Совет чорында мәктәпләрдә эшли, соңгы елларда гына үлде.
[14] Учитель һәм язучы, 1918 елда Астраханьда аклар тарафыннан үтерелгән.
[15] Екатеринбург шәһәрендә зур сәүдәгәр.
[16] Бу заманда моның кебекнең күренгәне юк иде.
[17] Бәхәсләр, фикер алышулар.
[18] Журналист.
[19] Бәхәсләшү.
[20] Катнашучы.
[21] Хурлап.
[22] Бу турыда Ф. Әмирханның махсус мәкаләсе чыкты. Кара: Ф. Әмирхан, әсәрләр, II т. 288—290 битләр.
[23] Журналист Борһан Шәрәф, тел галиме Г. Шәрәфнең туганы.
[24] Язучы.
[25] Шат.
[26] Күнегеп.
[27] «Рәхмәт» белдереп.

1909 ел. 27 апрель.

**Исмәгыйль!**

**Менә сиңа хат. Нәрсәдән башлап языйм? Тукта, таптым. Казанда су бу ел бик начар килә. Шуңа күрә бөтен аяклы кешеләрнең борыны сына, көймәләрдә йөри алмыйлар, ишкәкләр ялтырамый, гармуннар яңгырамый! Кичә синең соңгы ачык хатың белән бергә, Борһаннан бер озын хат алдым. Закирә туташка [1] предложение ясаганын белеп, никтер, чын күңелемнән рәхәтләндем. Вакыт бик җиткән иде. Среда да бик удачно сайланган. Әлхасыйль, чиләгенә — капкачы. Син миңа «Закирә туташ кем?» дигән сөальгә бик мофассал [2] җавап язарсың дип уйлыйм. Ягъни синдә нинди впечатление калдырды? Борһан аягы сиңа да җиңел булса иде! Амин! Казанда син уйлаган кызыкларның берсе дә юк. Һәркем имтиханга хәзерләнә, имтихансыз кешеләр акча юклыктан борыннарын салындырып йөриләр.**

**Җәнабе галием бу көннәрдә «Алмашыну көннәрендә» [3] не язып бетерәм. «Татар кызы» [4] исемле бер рассказ яздым; хәзер бастырырга җибәрәм.**

**«Әлислах» хәзер яңадан терелеп тора. Акчага бик мохтаҗ, син, зинһар, кайдан да булса табып, үзеңнән дә тиешле акчаны [5] бу хатны алу белән җибәрә күр! Әгәр таба алсаң, иганә дә җыеп җибәрсәң, бик рәхмәтләр укыр идек.**

**Ибраһимнан [6] хат алдым. Акчаларны алган, хәзер бик һәйбәт торам, дип яза. Миңа үз мәктәпләренең рәсеме белән открыткалар җибәрә. Кстати, син җибәргән «Мәдрәсәи хан» [7] рәсеме мине әллә нинди размышлениеләргә төшерде. Тагы шундый кызыклырак видлар булса, җибәр.**

Ризваннан [8] хат алдым. Әллә нәрсәләр язып бетергән: гафу үтенгән, сүгенгән, үпкәләгән, иләх... Теге Хәкимҗан безне алдалады, ахры. Хәзергә кадәр һич тавыштыны да чыкмый. Байбәтчәдән шуннан башка нәрсә булыр дип көтәргә кирәк.

Вәли Апанай [9], бик зурдан кубып, иген җыям, он җыям дип йөри. Үзен эшкә тотынган хисаплый. Бер аллага мәгълүм.

Хуканд хәлләреңне тәфсыйль итеп, бер дә иренми генә бер хат яз. «Туташ» [10] терелде, шуңа күрә мине тәбрик итәргә можешь!

Солтан [11], үз выражениесенчә, «все время пьян». Хәзер үзе монда минем янда, сиңа сәлам укый. Тукаев та минем өстәл буенда яңагына таянып утыра, сиңа сәлам әйтми.

Солтан хәзер үзе әйтеп яздырган сүзгә үзе үкенә. Шуңар күрә мин дә ул сүзне язмаганга хисаплыйм.

Хәзергә тәмам. Хат яз!

*Фатих.*

---

[1] Закирә Шәрәф — Борһан Шәрәфнең тормыш иптәше, Фатих Кәриминең сеңелесе. Әле исән.
[2] Озын, тулы.
[3] Ф. Әмирханның «Яшьләр» исемле пьесасы.
[4] Ф. Әмирханның шул исемдәге әсәре.
[5] И. Аитов «Әлислах»ка ярдәм йөзеннән 50 сум акча вәгъдә иткән була. Сүз шул турыда булса кирәк.
[6] Ф. Әмирханның энесе. Бәйрүттә укыган чагы.
[7] Хуканд мәдрәсәсе.
[8] Ф. Әмирхан «Милләт тәрәккый иттерү» исемле әсәрен язгач, шундагы мишәр шәкерте образында үзеннән көлү дип, Ризван Алушиның бик хәтере кала.
[9] Вәли Апанаев — музыкант, мандолинчы. Татарда беренче кыллы оркестр оештыручылардан.
[10] Сүз Шәмсениса Камалова турында булса кирәк.
[11] Солтан Рахманколый.

1923 ел, 6 июнь, Казан.

**Мәҗит иптәш, Сезгә сәлам!**

Мин авырып урын өстендә ятам. Шуңа күрә Сезнең әдәби хезмәтегезгә егерме ел тулу вакыйгасын әле бары кичәге көн, 5 июньдә, ягъни юбилей көненнән ике тәүлек соң ишетеп белдем. Менә инде бер ай газеталар кулыма ала алмыйм, бөтен дөнья әхваленнән гафил ятам. Бүген бераз кәефем яхшырудан истифадә итеп [1], «көч булса да һәм улмас» [2] дигән төрек мәкаленә буйсынып, Сезгә шушы мәктүпне язарга утырдым. Башым аз эшли, мәктүп буталчык һәм кытыршы булыр. Ләкин зарар юк, мин бары бу мәктүп белән Сезгә үземнең сәлам һәм тәбригемне юллап, егерме еллык әдәби хезмәтегезне тәкъдир итүчеләрнең берсе икәнемне генә язып калырга телим.

Егерме ел диегез! Безнең кыска гомерле, 35—40 та үлеп бетә торган буын өчен аз түгел.

Мин әле хәтерлим, Сезнең «Мәдрәсәи мөхәммәдия»дә әүвәлге шигырьләрегезнең нинди сөелеп укылганын. Гомергә әйләнеп карасаң, күз ачып-йому шикелле. Шул әүвәлге шигырьләрнең укылуына егерме ел да үтеп киткән. Ә бит инде:

«Ак катыш чуар бер нәрсәгә әйләнде баш». Әйе, чуар бернәрсәгә әйләнде инде, ә әле күптәнме соң ул башлар Сезнеке кап-кара, минеке коңгырт иде!

Сез соңгы елларда шактый күп нәрсә язып өлгердегез. Бу — шагыйрь өчен зур бәхет. Менә мин һаман әле гомеремнең шул дәверенә килеп чыга алмыйм. Бары соңгы елларда гына үземнең «амплуамны» табып алдым, соңгы елларның соңгы көннәрендә генә чын-чынлап яза башлау дәверемне башлап китәм бугай. Ә бит минем дә «Яза башлавыма унҗиде тулып киткән икән инде». Бүген уйлап чыгардым әле аны. Менә мин хәзер арыдым да: мин плеврит белән авырыйм, хәзер инде терелеп киләм. Миңа, терелеп җитү белән, кымыз эчәргә барырга туры килә. Шуңа күрә дә мин 18—20

**майда[3] Уфага барып чыгып, анда кымыз эчү мәсьәләсен караячакмын. Өмит итәм: Уфага баргач, анда Сезне күрермен һәм шул вакытта Сезнең белән озак бер мосахәбә итәрбез.**

**Хәзергә яңадан бер кат Сезне әдәби хезмәтегезнең егерме еллык бәйрәме белән тәбрик итеп, яңадан озак елларга шул хезмәтегезнең дәвам итүен теләп калам.**

Сәлам һәм хөрмәт белән,
Фатих Зариф углы Әмирхан.
*(Фатих Әмирхан).*

---

[1] Файдаланып.

[2] Кичегү бер дә булмаудан яхшырак.

[3] Ф. Әмирхан авыру булу һәм, үзе әйткәнчә, хатны язганда арып китүе сәбәпле, бу урында «июнь» сүзе урынына «май» дип куйган булса кирәк. Ф. Әмирхан 1923 елда Уфага кымыз эчәргә бара алмаган булса кирәк. Чөнки архивтан шушы хатны тапкач, 1962 елда мин шагыйрь Сәйфи Кудаш иптәшкә махсус хат белән мөрәҗәгать иттем. Ул 1962 елның 18 февралендә миңа язган хатында Ф. Әмирханның Уфага 1924 елда килгәнлеген, Чишмә районы Күчем авылында кымыз эчкәнлеген, Башкортстан партия һәм хөкүмәт житәкчеләре белән очрашуын, Луначарский исемендәге бакчада Газиз Әлмөхәммәдов һәм Солтан Габәшиләр куйган концертта булганлыгын әйтеп, җавап язды.

■ ■ ■

*Шәриф Байчура*

# ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ХӘРӘКӘТЕ ҺӘМ ФАТИХ ӘМИРХАН

*(Истәлекләр буенча)*

Татар мәктәпләрен ислах итү, мәктәп-мәдрәсәләргә реформа кертү мәсьәләсе халкыбызның алдынгы вәкилләрен күптән борчып килде. Узган йөзнең соңгы елларында бу эш, бик чикләнгән рәвештә генә булса да, гамәлгә дә куела башлаган иде инде. «Мөхәммәдия» (Казан), «Хөсәения» (Оренбург), «Буби» (Әгерҗе), «Рәсүлия» (Троицк) һәм башка кайбер мәдрәсәләрдә элекке схоластика шактый киметелде, тарих, география, математика кебек дөньяви фәннәр кертелде, хәтта аз гына русча да укытыла башлады. Әмма белемгә омтылган алдынгы карашлы яшьләрне өстән кертелгән мондый аз-маз үзгәрешләр генә канәгатьләндерә алмады. Бөтен ил күләмендә барган гомум революцион хәрәкәт белән бәйләнешле рәвештә, егерменче йөзнең беренче елларында демократик рухтагы татар яшьләре хәрәкәте тагын да көчәеп, күтәрелеп китте. Бу хәрәкәт, берьяктан, алдынгырак мәдрәсә шәкертләре арасында дөньяви фәннәрне укытуны, рус телен өйрәнүне тормышка ашыру өчен көрәш рәвешендә, икенче яктан, хөкүмәт мәктәпләрендә укучы татар яшьләренең яшәп килүче стройга каршы чыгышлары төсендә барды.

1905 ел революциясе демократик рухтагы яшьләргә, бигрәк тә шәкертләр хәрәкәтенә, яңа рух өрә, яңа дәрт бирә. Электә бер мәдрәсә икенчесенә дошман булып килсә, хәзер инде уртак интереслары өчен көрәш алып бару Казан мәдрәсәләрен үзара якынайта, дуслаштыра. Төрле мәдрәсә шәкертләренең уртак җыелышларын уздыру матур бер традициягә әйләнеп китә. Әнә шул үзара киңәшүләр, сөйләшүләр нәтиҗәсендә Казан шәкертләренең «Мәркәз әлислах комитеты» исемле яшерен бер оешмасы да барлыкка килә. Фатих Әмирхан шул комитетка башлык итеп сайлана. Хәзерге көндә Уфада яшәүче 81 яшьлек пенсионер Гарифҗан Мостафин яшерен «Мәркәз әлислах комитеты»ның члены һәм секретаре була. Бу комитетның составы һәм башкарган эшләре турында ул болай сөйли:

«Ул комитет составына катнашучы шәкертләрнең байтагының исемнәре хәтердә калмаган. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсеннән Фатих Әмирхан, Ризван Ибраһимов (Алуши), Ибраһим Әмирхан, Вафа Бәхтияров, Габдрахман Мостафин, Нургали Мамин, Гарифҗан Мостафин, шагыйрь Миргазиз Укмасый, Кашшаф Патиев, Хәлил Әбелханов һәм башкалар бар иде. Комитет, урта Россия һәм Себер шәһәрләрендәге мәдрәсәләр белән элемтә алып бару өчен, вәкилләр (агентлар) билгеләде. Шундый вәкилләрдән исемдә калганнары: Себер шәһәрләрендәге мәдрәсәләр белән элемтә өчен Ризван Ибраһимов, Казан мәдрәсәләре өчен күл буе мәдрәсәсе шәкерте Хәмит иптәшләр (бусының фамилиясе хәтердә калмаган) билгеләнгәннәр иде».

Ислах комитеты татар мәктәп-мәдрәсәләрендә уку-укыту эшләрен баштанаяк үзгәртеп кору өчен көрәшә, шәкертләр арасында тәрбия-аңлату эшләре алып бара. Комитет шәкертләрне уку-укыту эшләрен яхшырту, мәдрәсәләрне үзгәртеп кору өчен даими рәвештә көрәш алып барырга, әгәр дә мәдрәсә идарәләре аларның урынлы таләпләрен

кабул итмәсәләр, андый мәдрәсәләргә бойкот игълан итеп, аларны ташлап чыгарга чакыра. Шул максатларын тормышка ашыру өчен, комитет 1905 елның 29 ноябреннан Фатих Әмирхан редакторлыгында «Әлислах» исемле атналык яшерен газета чыгара башлый. «Беренче садә», «Икенче садә» исемле шигырьләр беренче башлап шушы газетада чыга[1]. Бу газета шәкертләрне уянырга, революцион хәрәкәтләргә кушылырга чакырып язылган прокламацияләр дә бастыра. Яшерен «Әлислах» газетасы, шулай ук гектографта бастырылган шигырь һәм прокламацияләр, Казанның үзендә генә калмыйча, урта Россия һәм Себер мәдрәсәләренә дә җибәрелә торган була.

1906 елда шәкертләр хәрәкәте иң көчле ноктага җитә. Алар инде, мәдрәсә тәртипләрен үзгәртү, яңа уку программалары булдыру белән генә чикләнмичә, самодержавиенең үзен бәреп төшерү турында да сүз кузгаталар. Шәкертләр арасында «Инсан улан өстенә даг төшсә дә хәүф итмәсен, батинан хәүф итсә итсен, заһирән белгертмәсен...» (кеше өстенә тау төшсә дә курыкмасын, эчтән курыкса да тыштан белгертмәсен...) дип башлана торган шигырь бик популяр булып китә. Аның әле «Бөйлә золмың даим улса и, Николай, аңлагыл! Күрәчәгең күрсәтерләр балалары татарын» дигән юллары да бар. («Мөхәммәдия» хәлфәләреннән Ә. Мостафин тарафыннан язылган бу шигырьне хәзер тулысынча белүче юк, тик әнә шул өзекләрне генә хәтерләүчеләр бар.)

Шул ук елның февраль аенда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең 82 шәкерте, ислах турындагы таләпләре кабул ителмәү сәбәпле, бойкот ясап, мәдрәсәне ташлап чыга. «Мөхәммәдия»не ташлап чыккан шәкертләрне квартираларга урнаштыру, өйләренә кайтып китәргә теләгән шәкертләргә ярдәм күрсәтүне дә ислах комитеты алып бара. Моның өчен мәдрәсәдә калган шәкертләрдән һәм аңлы приказчиклардан акча җыела. Чыккан шәкертләргә квартиралар алына, икмәк-күмәч илтү эшләре оештырыла.

Мәдрәсә ташлап чыккан 82 шәкертнең берсе — Мирза Гозәеров ахырдан озак вакытлар Казанның 13 нче татар урта мәктәбендә укыту бүлеге мөдире булып эшләде. Моннан ике ел элек, үләр алдыннан гына, М. Гозәеров иптәш бу вакыйга турында безгә түбәндәгеләрне сөйләгән иде: «Мәдрәсәне ташлап чыгучылардан бер төркем шәкертләр Арча кырындагы искерәк агач йортка урнаштырылды. Минем мәдрәсәдәге урындашым Кәрим Тинчурин да шунда иде. Без урнашкан йортның капка төбендә һәрвакыт бер полицейский тора. Мин узганда ул, ачу белән, «бунтовщик малай» дип кычкырып кала иде. Аның белән очрашмас өчен, күбрәк йортның икенче ягыннан, биек койма аша чыгып йөри идем». Иптәш Гозәеров алар урнашкан квартирага Фатих Әмирханның һәм башка җитәкче шәкертләрнең еш кына килеп йөргәнлекләрен, һәрвакытта күңел күтәрә торган сүзләр сөйләгәнлекләрен әйтте.

Мәдрәсә ташлап чыккан шәкертләрнең акчасы азая башлагач, ислах комитеты газеталар аркылы халыкка мөрәҗәгать итә. Татар халкының алдынгы вәкилләре арасында бу чакыру кайнар теләктәшлек таба, һәркем, хәленнән килгәнчә, ярлы шәкертләргә ярдәм кулын суза.

Хәзерге көндә Ташкентта яшәүче 82 яшьлек пенсионер Шакир Мөхәммәдьяров бу турыда шулай сөйләгән иде:

«...«Мөхәммәдия» шәкертләренең мәдрәсәне ташлап чыгулары үз вакытында Казанда зур шау-шу тудырды... Көннәрнең берендә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең ябылуы турында хәбәр таралгач, «шәкертләргә материаль ярдәм күрсәтү өчен халык арасында акча җыю, подписка ачу кирәк» дип, «Казан мөхбире» газетасына хат язып, беренче взносны керткән идем...

Шул юл белән җыелган акчага теләгән шәкертләрне русча укыту оештырылды. Ул елларда (1905—06 елларда — Ш. Б.) Татарская учительская школа укучылары белән мәдрәсә шәкертләре арасында контакт бик киңәйгән иде. 1901 нче елдан соң Учительская школага күп кенә мәдрәсә шәкертләре керде. Алар күбәйгәч, аңарчы Уфаның мирза балалары белән тулган бу школа гади рус бурсалыгыннан (дин мәктәплегеннән) чыгып, революция учагына әверелде».

Шәкертләргә материаль ярдәм күрсәтүгә рус яшьләре дә актив катнаша. «Шәкертләр мәдрәсәне ташлап чыккан көннәрдә Казан университеты студентлары шәкертләргә ярдәм итү өчен үз араларында акча җыйганнар. Шул акчаны тапшыру өчен, алар комитеттан вәкилләр җибәрүне үтенгәннәр. Бу хәбәрне алгач, Фатих Әмирхан белән

[1] «Беренче садә»не Г. Мостафин, «Икенче садә»не М. Бәдигый язган.

мин билгеләнгән вакытка Лядской бакчага бардык. Аллеяларның берсендә безгә ике студент очрап 50 сум акча тапшырдылар һәм тагын да акча җыячакларын вәгъдә итеп, шәкертләргә үз юлларында нык булырга киңәш бирделәр», — дип сөйләгән иде безгә Вафа Бәхтияров.

Мәдрәсә ташлап чыккан шәкертләр, бер төрле урнашып алгач, яңа дәрт, яңа энергия белән укырга, белем алырга тотыналар. Кайберләре югары уку йортларына (университет һәм институтларга) керү өчен өлгерү аттестатына хәзерләнә башлыйлар, икенчеләре исә Учительская школага керәләр (Хәлил Әбелханов, Гариф Богданов, Зәкәрия Бәхтияров һәм Габдрахман Дәүләткилдиевләр шул төркемгә керә). Шәкертләрнең зур гына өлеше ул вакытта инде төрле урыннарда ачыла башлаган тәртипле мәктәпләргә мөгаллим — укытучы булып китә.

«Мөхәммәдия» шәкертләренең бу адымы башка мәдрәсәләрне дә кузгата. Казан, Оренбург, Уфа һәм башка шәһәрләрдә, көчле бер дулкын булып, шәкертләр хәрәкәте күтәрелеп китә. Байкот ясап, мәдрәсә ташлап чыгулар гомуми төс ала. 1908 елда, мәсәлән, «Галия» шәкертләренең бөтен бер сыйныфы мәдрәсә ташлап чыга, һәм бу хәрәкәтне оештыручы, шул эшнең башында торучыларның берсе Галимҗан Ибраһимов була. Шул ук елда «Хөсәения»нең дә 33 шәкерте мәдрәсә ташлап чыга.

1906 елның 10—15 майларында, «Ислах комитеты» инициативасы белән, Казанда Россия татар шәкертләренең беренче съезды үткәрелә. Яшерен рәвештә үткәрелгән бу съездга Казан, Уфа, Оренбург, Астрахань, Буби, Троицк, Самара һәм Сибирия мәдрәсәләреннән 25—30 лап вәкил катнаша. «Бу съездны ислах комитеты җыя. Ләкин бөтен программасы, докладлары, шул җөмләдән мәдрәсәләрне ислах турындагы доклад һәммәсе Фатихның (Фатих Әмирханның — Ш. Б.) үзе тарафыннан, яки аның юл күрсәтүе буенча эшләнәләр. Съездның рәисе, рухы Фатих була» [1].

Россия татар шәкертләренең бу беренче съезды Аркадия бакчасыннан ерак түгел җирдә, Кабан күле өстендә көймәләрдә уздырыла. Власть органнарының күзен томалау өчен, съездга шәкертләрнең хозурга (күңел ачуга) чыгулары төсе бирелә. Съездда түбәндәге мәсьәләләр карала: I. Ислах комитетының үткәргән эшләре турында информация; II. Мәдрәсәләрне ислах турында доклад; III. Съездның экономик ягын тәэмин итү. Ахырда съездга катнашучылар җыелышып рәсемгә төшәләр.

Уртада, ялан баш килеш, Фатих Әмирхан утырган. Аның тирә-ягында озын казакидән һәм каләпүштән 20 дән артык шәкерт тезелгән. Бу рәсемне мин революциядән элек Гарифҗан Мостафин өендә күргән идем, ләкин ул бу рәсемне югалткан. Фатих Әмирханның туганнары да ул рәсемнең кайда саклануы турында берни дә әйтә алмадылар.

Ислах комитетының барлык әйберләре Н. Мамин квартирасында саклана торган була. 1906 елның июль аенда Нургали Мамин квартирасында Казан жандармериясе тарафыннан тентү ясала. Комитетның барлык материаллары, печате һәм башка әсбаплары конфисковать ителә, Нургали Мамин үзе кулга алына. Шулай итеп, яшерен «Мәркәз әлислах комитеты» һәм аның органы булган «Әлислах» газетасы яшәүдән туктый. 1907 елда оешма членнары легаль «Әлислах» газетасын оештыру эшенә керешәләр. «Әле һаман дәвам иткән шәкертләр хәрәкәтен, мәдрәсәләргә реформа кертү мәсьәләләрен яктырту өчен, татар телендә легаль газета чыгарырга рөхсәт сорап, Казан губернаторы исеменә гариза яздыру өчен, Хәлил Әбелханов белән берлектә, без хәзерге Тукай урамы 79 йорттагы балалар приютында рус теле укытучы Мөхетдин абый Корбангалиевка бардык. Ул безгә гариза язып бирде һәм шуннан соң губернатор тарафыннан рөхсәт бирелгәч, газетаны чыгарырга керештек», — ди В. Бәхтияров.

«Әлислах» газетасының редакциясе хәзерге Тукай урамы 63 нче йортта (элекке Апаковлар йортында) урнаша. Габдулла Тукай үзенең «Яңа Кисекбаш» исемле поэмасында:

Калды уң якта «Китаплар ханәсе»
Сулда — «Әлислах» идарә ханәсе, —

дип, бу газета редакциясенең, Тукай урамы буйлап Вахитов заводына таба барганда, урамның сул ягында калуын күрсәтә.

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасы, 1926 ел, 12 март.

Легаль «Әлислах»ның рәсми редакторы Вафа Бәхтияров булса да, фактта исә газетаның бөтен җаны, үзәге, аңа идея юнәлеше бирүче Фатих Әмирхан иде.

«Әлислах» газетасы, үзенең барлык саннарында диярлек, мәдрәсәләрне ислах итү, мәктәп һәм мәдрәсәләрдә рус теле, татар тел һәм әдәбияты укыту, уку-укытуга бәйләнешле башка мәсьәләләр буенча мәкаләләр һәм хәбәрләр урнаштырып килә. «Мөхәммәдия», «Хөсәения», «Галия» кебек зуррак мәдрәсәләрнең эчке хәлләре, уңышлары һәм җитешсезлекләре газетада системалы рәвештә яктыртылып бара.

1907 елның октябреннан 1909 елның 23 июленә кадәр, ягъни шул газета чыгудан тукталганга чаклы, Ф. Әмирхан «Әлислах» белән турыдан-туры җитәкчелек итә. Халык шагыйре Габдулла Тукай да бу газетага актив язышучыларның берсе була, үзенең шул чорда язган шигырьләрен һәм проза әсәрләрен ул «Әлислах»та бастыра. Искелеккә каршы көрәшкә өндәве, яңалыкка, яктылыкка чакыруы белән газета үз тирәсенә татарның күп кенә прогрессив көчләрен туплый. Мәгълүм булганча, Галимҗан Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән хикәясе, Фатих Әмирханның турыдан-туры булышлыгы белән, шул газетаның күп кенә саннарында басылып бара. Галиәсгар Камал, Сәгыйт Рәмиев, М. Укмасый, Кәбир Бәкер, Ш. Әхмеров, И. Биккулов, С. Рахманкулов, Хуҗа Бәдигый һәм башка күп кенә язучылар, шагыйрьләр һәм журналистлар бу газетада актив катнашалар. Культурабызны, әдәбиятыбызны үстерүгә, матбугат эшен яхшыртуга Ф. Әмирхан җитәкчелегендәге «Әлислах» газетасы зур өлеш кертә.

1907 елда Казанда татар шәкертләренең икенче съезды үткәрелә. «Кызыл Татарстан» газетасы 1926 елның 12 мартында чыккан санында: «1907 елда Казанда җыелган икенче Бөтенроссия шәкертләре съездына үзе (Фатих Әмирхан — Ш. Б.) катнашмаса да, һаман юлларын күрсәтеп, ярдәмләшеп торды», — дип яза. 84 яшендәге пенсионер, карт коммунист Фәрит ага Хәсәнев тә 1907 елның җәендә Казанда татар шәкертләренең икенче съезды булып үткәнлеген раслый. Иптәш Ф. Хәсәнев шәкертләрнең икенче съездының, полиция эзәрлекләүләре сәбәпле, рәтләп эшли алмавын, Казаннан Зөя каласына күчеп, аннан кире Казанга кайтып йөрүен, ахырда аның таралып китүен сөйли.

Татар халкының иҗтимагый тормышында 1905—1907 еллар революциясе дулкыннары белән кузгалган демократик культура хәрәкәте, уку-укыту, матбугат-әдәбият һәм театр өлкәсендәге башлангыч адымнар моннан соң килгән кара реакция елларында да акрынлап алга атлады, революция чәчеп калдырган бәрәкәтле орлыклар тишелеп чыгып үсүдә дәвам иттеләр. Бу барыш, әлбәттә, шома гына, тигез генә булмады. Яңа тип мәктәпләр ачуга каршы, берьяктан, самодержавие вәкилләре, миссионерлар көрәш алып барсалар, икенче яктан, реакцион татар руханилары, һәртөрле сатлык җаннар бу культура хәрәкәтләре турында патша властьларына төрле ялган, пычрак донослар ясап тордылар. Нәтиҗәдә, күп җирләрдә мәктәп-мәдрәсәләр ябылды, укытучылар сөргенгә җибәрелде. 1910—11 елларда, Буби мәдрәсәсе ябылып, аның җитәкчеләрен, укытучыларын төрмәләргә яптылар. Тәтеш шәһәрендә русча-татарча мәктәп укытучылары Исхак Казаков һәм Фатих Шәмсетдиновны да, донос буенча кулга алып, төрмәдә яткырганнан соң, сөргенгә җибәрделәр. Күп җирләрдә тентүләр, кулга алулар, мәктәп, мәдрәсәләрне ябулар дәвам итте. Реакция елларындагы бу кысынкылыклар байтак кешеләрне пессимизмга төшерде, бишенче ел революциясе идеалларына хыянәт итү очраклары да күренгәләде. Ләкин татар демократик укымышлыларының зур күпчелеге киң халык массасына хезмәт итү юлында турылыклы булып калды. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә реакция елларында да айга ике яки өч тапкыр «Әдәбият кичәләре» үткәрелеп килә. Ул кичәләрдә, төрле кинаяләр рәвешендә генә булса да, илдәге политик хәлләрне тикшерү дә дәвам итә. Минем хәтеремдә: 1907 елның көзендә мәдрәсәнең дәресханә дип йөртелгән зур залында шундый бер мәҗлес уздырылган иде. Бервакыт тышта сакта торган бер шәкерт кереп мәдрәсәгә жандарм отряды килде, дип игълан итте. Җыелышның җитәкчеләре тарафыннан ясалган ишарә буенча, без, бер-ике яшь шәкерт, Хөсәен Ямашов белән Гафур Коләхметовны дәресханә залының арт ишегеннән күрше йорт ишек алдына озатып җибәрдек. Бу җыелышларга әнә шул иптәшләрнең катнашып йөрүләре аларның нindирәк характерда баруларын ачык күрсәтсә кирәк.

II

1903—04 елларда, шәкертләр арасында барган ислах хәрәкәте белән параллель рәвештә, рус мәктәпләрендә укучы татар яшьләренең культура хәрәкәте шактый киң төс ала. Бу хәрәкәт 1904 ел башында «Шимбә» исемендәге түгәрәк оештырылу белән башланып китә. «Шимбә» түгәрәгенең оештыру җыелышы Шаһбазгәрәй Әхмеров йортында (хәзерге Муса Җәлил урамы, 16 йорт) уздырыла. Җыелышта Әминә Терегулова, Суфия, Сара, Ильяс Әхмеровлар, Зәйнәп Габитова, Гайшә Богданова, Нәби һәм Мулланур Вахитовлар, Фатимаи-Зөһрә, Зәйнәп, Солтан Саиновлар, Әхнәф Мамлиев [1], Сөләйман Чанышевлар катнаша [2]. Мәдрәсә шәкертләреннән Фатих Әмирхан белән Гыймад Нугайбеков та була. Югарыда исемнәре аталган кешеләрдән Әминә Терегулова, Суфия һәм Сара Әхмеровалар, Гайшә Богданова, Зөһрә һәм Зәйнәп Саиновалар гимназиядә, Ильяс Әхмеров, Мулланур Вахитов, Солтан Саинов реальное училищедә, Нәби Вахитов художество мәктәбендә, Әхнәф Мамлиев университетта, Сөләйман Чанышев ветеринария институтында укыйлар. Тора-бара «Шимбә» түгәрәге членнары 39 кешегә җитә, алар арасында шәкертләр саны да күбәя төшә. Түгәрәкнең җыелышлары гадәттә Ибраһим Терегулов, Шаһбазгәрәй Әхмеров, Габитовлар һәм Саиновлар кебек, үз йортлары булган гаиләләрдә үткәрелгән; түгәрәк җыелышларында, рус һәм көнчыгыш классикларының әсәрләрен өйрәнү белән бергә, яңа татар әдәбияты әсәрләрен укып өйрәнүгә дә зур игътибар бирелгән. Габитовларның иң кечесе, хәзерге вакытта бу фамилиядән бердәнбер исән кеше, Рабига ханым Габитованың сөйләвенә караганда, түгәрәктә беренче башлап укылган татар әсәре Заһир Бигиевнең «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә» романы булган.



«Шимбә» түгәрәге членнарыннан бер төркем.

Гарифҗан Мостафин «Шимбә» түгәрәгенә катнашучы шәкертләр белән рус мәктәпләрендә укучылар арасында бер-берсенә шефлык итү практикасы яшәп килгәнен сөйли. Шәкерт рус мәктәбендә укучы иптәшен татарча уку-язуга өйрәтсә, тегесе аны русча укыта. Мәсәлән, Гарифҗан Мостафин Мулланур Вахитовка, Габдулла Сөләйманов Зәйнәп Терегулова-Габитовага беркетелгән булган. Гарифҗан Мостафин, Мулланур Вахитовка барып, аннан русча өйрәнеп һәм үзе аны татарча укытып йөргән.

[1] Әхнәф Мамлиев М. Вахитов белән берлектә Петербург политехника институтында укып, озак еллар инженер булып эшли. 1961 елның февралендә Мәскәүдә үлә.
[2] Сөләйман Чанышев беренче дөнья сугышына офицер булып катнаша, 1915 елда фронтта үлә.

Күпмедер тынып торганнан соң, 1906 елда «Шимбә» түгәрәгенең эше тагын җанланып китә. Бу елларда аны марксизм әдәбиятын өйрәнү түгәрәге итәргә тырышыла, бу эшнең башында Мулланур Вахитов тора. Түгәрәккә барысы 7—8 кеше катнаша. Мулланур Вахитов өендә түгәрәкнең бер-ике утырышы да була. Ул, җитәкче буларак, темалар билгели, әдәбият күрсәтә. Ләкин бу җыелышларны полиция сизеп ала, һәм түгәрәк тарала.

Педагог Солтан Саинов[1] «Шимбә» түгәрәге утырышларының берсе Хөсәен Ямашев квартирасында булганлыгын сөйләгән иде. Ямашев, социал-демократларның Казан комитеты члены буларак, шәкертләр хәрәкәте белән, аерым алганда, үзе укып чыккан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре белән якын элемтәдә тора. Шул чорда мәдрәсәнең подвалында урнашкан ашханәсендә, Хөсәен Ямашевның тәкъдиме һәм аның катнашы белән, бер митинг та үткәрелгән. Ул анда шәкертләр массасын большевиклар партиясенә якынаюга чакырып чыгыш ясаган. Яңа Бистәдәге Каюм мулла мәдрәсәсендә дә шундый ук митинг билгеләнгән була, ләкин жандарм килү сәбәпле, митинг үткәрелми кала.

«Шимбә» түгәрәгенең актив членнарыннан берсе, хәзер Ленинградта яшәүче пенсионер Гайшә ханым Богданова-Ибраһимова болай яза:

«Шимбә» түгәрәген алдынгы татар яшьләре төзеде... Түгәрәк үзенең эшен нык конспиратив (яшерен) рәвештә алып барды, чөнки патша хөкүмәте татар яшьләренең нәрсә эшләүләрен өзлексез күзәтеп тора иде. Түгәрәк революцион эш алып бара, аның мәкъсуды татар массасының аңын күтәрү һәм аңа революция идеяләре кертү булды. Мулланур Вахитов бу түгәрәкне төзүчеләрнең, татар яшьләренә революция рухы өрүчеләрнең берсе булды. Аннары ул Петербург политехника институты студенты булган вакытында башкаладан үзенең туган шәһәренә (Казанга) кайтып, безне Петербург түгәрәкләренең эшләре белән таныштыра һәм андагы революцион хәрәкәтнең барышы турында безнең белән бүлешә иде... Бу чорда язучы Фатих Әмирхан һәм атаклы большевик Х. Ямашев иптәшләр дә күренекле роль уйнадылар. «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» шәкертләре ул елларда алдынгылардан саналалар иде. Алар татар яшьләрен революциягә әзерләүдә зур хезмәт күрсәттеләр».

«Шимбә» түгәрәгенең тагын бер әһәмиятле инициативасы — татарча өй спектакльләре оештыру. Бу турыда Гарифҗан Мостафин түбәндәгеләрне искә төшерә: «...1904 нче ел башында түгәрәк членнарыннан Фатих Әмирхан, мин һәм Габдулла Сөләйманов, мөселман бәйрәме мөнәсәбәте белән, Габитовларга чәй мәҗлесенә бардык. Безне өй хуҗалары Гафифә ханым Габитова, гимназиядә укучы кече кызы Рабига, олы кызы Зәйнәп Габитова (Терегулова) каршы алдылар. Без анда утырган вакытта реальный училище укучылары формасында киенгән 17—18 яшьләрендә ике егет килеп керде. Аларның Габитовлар семьясында электән үз, таныш кешеләр икәне күренеп тора иде. Буйга озынрак, сары чәчлесе Мулланур Вахитов иде. Чәй мәҗлесендә сүз күбрәк татарча өй спектакльләре кую турында барды. Сүзгә Мулланур да катнашып, ул бу матур эшне мәдрәсә шәкертләре башлап җибәрергә, алар бу турыда үрнәк күрсәтергә тиешләр», диде.

Шуннан соң өй спектакльләре куюга әзерлек башлана. Бу спектакльләр, гадәттә, рождество бәйрәме көннәрендә, хөкүмәт мәктәпләрендә укучыларның кышкы ял вакытында үткәрелә. Башта берничә тапкыр рус телендә спектакль куела, аннары татарчага күчәләр. Татар телендә беренче өй спектакле 1905 елда[2] хәзерге Ульянов урамы 31 номерлы йортта (элекке Суханов йортында) Габитовлар квартирасында була. Беренче башлап Галиәсгар Камалның төрекчәдән тәрҗемә иткән «Кызганыч бала» пьесасы һәм «Гыйшык бәласе» комедиясе уйнала.

Пенсионер Рабига Габитова иптәшнең «Шимбә» түгәрәге һәм аның тарафыннан куелган өй спектакльләре турында 1951 елда Татарстан дәүләт музеена язып биргән истәлегендә уенга катнашучылардан Әминә Терегулова (Гириева), Зәйнәп Габитова-Терегулова (Солтанова), Шакир Мөхәммәдъяров (Бузурҗомһиров), Газиз Сәйфелмө-

---

[1] Солтан Саинов 1962 елның март аенда Казанда үлде.

[2] 1904 елда Р. Алушига язган хатында Ф. Әмирхан татарча өй спектакльләренең 1903 елда ук куелуын әйтә. *Ред.*

леков (Газизов), Әбүбәкер Терегулов (Юнусов), Шәриф Сөнчәләев (Субаев), Гафур Коләхметов (Ширгали), Суфия Коләхметова (Морадова), Габдрахман Мостафиннарны (Алмазов) санап чыгыла. Җәя эчендә һәвәскәр артистларның театр кушаматлары күрсәтелгән. Суфлерлык хезмәтен һәрвакытта Гыймад Нугайбек үтәгәнлеге әйтелә. Әминә ханым Терегулова әйтүенчә, бу спектакльләрдә Солтан Рахманкулов та катнашып килгән.

Ф. Әмирхан татар театрының ун еллыгы уңае белән язылган «Сәхнәбезнең ун яше мөнәсәбәте белән» исемле мәкаләсендә «Шимбә» түгәрәгенең эше турында түбәндәгечә яза:

«Бу түгәрәкнең әүвәлге татарча уены Гафифә ханым Габитованың Первая Гора урамындагы квартирасында булды. Хәтеремдә ялгыш калмаган булса, уйналган нәрсә «Кызганыч бала» иде...

Татар сәхнәсенең бу дәвере сөйләнгәндә Габитовлар гаиләсен гомумән, Ибраһим абзый Терегулов гаиләсен һәм мәрхүм Шаһбазгәрәй Әхмеров балаларын әүвәлге мәшариклар (катнашучылар — Ш. Б.) вә әүвәлге күңелле уенчылар буларак зикер итми (телгә алмый — Ш. Б.) китәргә мөмкин түгелдер». (Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. II том, 481—83 битләр.)

Ф. Әмирханның «татар сәхнәсенең бу дәвере сөйләнгәндә Габитовлар гаиләсен гомумән... зикер итми китәргә мөмкин түгелдер» дип, бу семьяга аерым басым ясап әйтүе шактый әһәмиятле момент. Без сөйләгән чорда бу семьяның башлыгы Шәрәфетдин Габитов инде үлгән була. Ул Кытайның Синь-Цзян өлкәсендә (Кытай Төркстанында) Гулҗә (Кульджа) шәһәрендәге Россия илчелегендә озак еллар хезмәт иткән; үзе яхшы укыган кеше булып, күп кенә көнчыгыш телләрендә сөйләшә алган. Ул үлгәч, семьясы Россиягә, Казанга кайтып яшәгән. Монда, җәяләр эченә генә алып булса да, тагын бер әһәмиятле әйбергә тукталып үтәсе килә. 1906—09 елларда Ф. Әмирхан кайнаган тормыш, ул белгән, аралашкан, йөрешкән кешеләр ахырдан аның әдәби әсәрләрендә дә шактый ачык һәм тулы чагыла.

«Фәтхулла хәзрәт» повестенда Фәтхулла хәзрәтнең прототибы итеп үзенең надан-лыгы, фанатиклыгы белән мәшһүр ахун Йосыф Сәгыйтовны алганлыгы ул замандагы Казан җәмәгатьчелегенә ачык мәгълүм иде. «Яшьләр»дә аталар һәм балалар арасындагы көрәш шул вакытта Казандагы берничә семья эчендә барган тартышны, шул исәптән, авторның үз тормышындагы хәлләрне дә күз алдына китереп бастыра. Ф. Әмирхан әсәрләрендә очрый торган гимназисткалар, курсисткалар, студентлар, аттестатниклар һәм башка укымышлылар югарыда «Шимбә» кичәләрендә күренгән шәхесләрне искә төшерәләр. Язылa башлап та тәмамланмый калган «Урталыкта» исемле романында бу нәрсә аеруча нык сизелә.

Фатих Әмирхан Рабига ханым Габитовага бер роман язуын, аның геройлары арасында «Шимбә»челәр дә булуын, Рабига ханымның үзен Нәсимә исемле гимназистка итеп алуын сөйләгән. Романда бу семьяның Сөләймановлар дип алынуының да бер хикмәте бар икән: Гафифә ханым Габитованың кыз вакытында фамилиясе Сөләйманова булган. Берничә дистә кеше катнаша торган бу романдагы барлык геройларның прототипларын эзләп табып булмас, әлбәттә. Шулай да, тагын бер геройны әйтеп китәргә кирәк: романның төп герое булган Хәсән Арслановның учителе Сергей Николаевич исемле студент «озын буйлы, озын борынлы, сап-сары озын чәчле 29—30 яшьлек бер студент иде» дип күрсәтелә. Бу геройның тышкы күренеше Фатих Әмирханны, Габдрахман Мостафинны һәм тагын берничә шәкертне (шул исәптән соңыннан татарлардан беренче тарих профессоры булган Газиз Гобәйдуллинны) өлгерү аттестатына хәзерләгән большевик-студент Сергей Николаевич Гассарга нәкъ туры килә. Күрәсез, монда геройның прототипка охшавы, исеме һәм атасы исеменә кадәр туры килә. Мен битләр тирәсендә итеп язылырга уйланган бу роман, үкенечкә каршы, тик башланып кына калган һәм шул сәбәпле татар халкының культура тарихында гаять әһәмиятле урын тоткан бу чор матур әдәбиятта тулысынча чагыла алмаган.

Архив материаллары күрсәтүенчә, Габитовларда Казан жандармериясе тарафыннан тентүләр ясалган. Шулай ук алар яшәгән квартираның йорт хуҗалары Сухановларда да тентү булганлыгы мәгълүм. Бу аңлашыла да. Сухановлар үзләре дә революцион настроениедәге кешеләр булалар, Сухановаларның берсе атаклы большевиклардан Абрам Комлевка тормышка чыга.

* * *

Беренче рус революциясе чорында Казан демократик яшьләре хәрәкәте (мәдрәсә шәкертләре һәм башка укучылар хәрәкәте) нигездә, социал-демократлар ориентациясендә бара. Бу мәсьәлә турында Фатих Әмирхан үлүенә карата язылган мәкаләдә[1] болай диелә:

«1906 нчы елның башларында социал-демократлар партиясенең Биниамин Әхтәмов кул астында Казанда татар группасы төзелгән иде. Фатих (Фатих Әмирхан — Ш. Б.) монда да әгъза булып, күбрәк прокламацияләр язу вазифасын үти иде. Шушы группаның инициативасы белән май аенда Казанда беренче мәртәбә татарча ачык (публичный) театр куелып, Фатих шунда иң баш рольләрне үтәде». Аннары, сызык астына төшереп, бу социал-демократлар группасы әгъзалары: Әхтәмов, Сара Әхмерова, Габдрахман Мостафин, Зариф Садыйков, Фатих Әмирхан, Ибраһим Камал, Муллахмәт Бәдигый, Ибраһим Биккулов иде, дип өстәп куела.

Казан мәдрәсәләрендә укучы шәкертләрнең, башлыча «Мөхәммәдия» шәкертләренең, 1905—07 еллар революциясе чорында социал-демократ большевиклар йогынтысы астында булулары 1905 елның 19 һәм 20 октябрьларында, полицияне коралсызландырып, аның урынына халык милициясе төзүдә актив катнашуларында да күренә. Мәгълүм ки, бу вакытта Казанда власть берничә көн буена халык милициясе кулында тора. «Мөхәммәдия» шәкертләреннән Гарифҗан Мостафин, Баязит Борнай, Мөхәммәд Яушев иптәшләр күрсәтүенчә, күнелле булып язылган милиция работниклары арасында «Мөхәммәдия» шәкертләреннән Ибраһим Килдиев, Закир Шакиров, Нургали Мамин, Г. Мостафин, Ибраһим Әмирхан һәм башкалар булганлыгын күрәбез. 19—20 октябрь көннәрендә полицияне коралсызландыруга һәм аннары халык милициясе төзүгә катнашкан шәкертләргә җитәкчелек итүдә атаклы язучы Галиәсгар Камал зур активлык күрсәткән. Бу вакытта халык милициясенең баш штабы хәзерге шәһәр Советы бинасында урнашкан булган. Хәзерге Тукай урамы 37 йортта (ул вакытта Бәдерттин Апанаев йорты булып, аннары Кәримовларга сатылган йортта) штабның филиалы төзелгән. Шәкерт-милиционерлар кичен атларын «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ишек алдына алып кайта торган булганнар. Беренче татар большевигы, Казан социал-демократлар комитеты члены Хөсәен Ямашев, югарыда әйтелгәнчә, шәкертләр белән якын элемтә алып бара. Шәкертләр хәрәкәте җитәкчеләреннән Фатих Әмирхан, Габдрахман



Ф. Әмирхан журналистлар арасында. 1921 ел.

[1] «Кызыл Татарстан», 12 март, 1926 ел.

Мостафин[1] һәм башкалар большевик-студент Сергей Николаевич Гассардан университетка керү өчен өлгерү аттестатына хәзерләнәләр. Гассар, гимназия программасы буенча укыту өстенә, аларга идеология ягыннан да зур йогынты ясый. «Кызыл Татарстан» газетасының югарыда китерелгән мәкаләсендә: «Гассар ул вакытта аттестатка хәзерләнүче байтак татар шәкертләрен укыта һәм аларга сәяси, иҗтимагый тәрбия дә бирә иде (шуның тәэсире белән булырга кирәк, 1905 ел революциясендә мәдрәсәи «Мөхәммәдия» шәкертләре С. Д. лар ориентациясендә иделәр)», диелә.

Юкка гына демократик татар яшьләре һәм алдынгы фикерле күренекле язучыларыбыз патша жандармериясенең даими күзәтүе астында яшәмәгәннәр бит. Аларның һәр эшендә, һәр адымында полиция агентлары яшәп килүче стройга куркыныч күргәннәр. Алар, бөтен көчләрен куеп, татар халкының алдынгы вәкилләрен большевиклар йогынтысыннан сакларга тырышканнар. Г. Камал, Г. Ибраһимов кебек, Ф. Әмирхан да патша охранкасының даими күзәтүе астында яши. Казан жандармерия идарәсендәге материалларның күрсәтүенчә, мондый күзәтү астындагы прогрессив язучылар, журналистлар һәм укучы яшьләрнең барысына да гомуми бер тамга — панисламист, пантюркист дигән мөһер басылган. Түбәндә Казан губернаторының Казан жандармерия начальнигына Фатих Әмирхан турында язган документының копиясе китерелә[2].

Бөтенләй яшерен

*Эчке эшләр министрлыгы*

*Казан Губернаторы канцелярия буенча 15 декабрь 1914 ел № 14982 Казан шәһәре*

*Казан Губерниясе жандармерия начальнигы әфәндегә*

*Кереш № 18509 18 дек. 1914 ел эш № 26*

*Шушы елның 26 ноябрендәге 15944 номерлы эш кәгазенә (җавап итеп), үзенең пантюркизм идеяләре белән атаклы Фатих Әмирханның эшчәнлеге артыннан бик игътибарлы һәм өзлексез күзәтү оештырылуын, шушының белән бергә, минем тарафтан Казан Полицийместерына боерык бирелүен Сез Галиҗәнапларга белдерәм.*

*Патша хәзрәтләре Сараеның баш начальнигы Камергер* *(имза)*
*Канцелярия мөдире* *(имза)*
*Канцелярия башлыгы ярдәмчесе өчен* *(имза)*

Казан жандармерия идарәсенең Ф. Әмирхан турындагы икенче бер документында аяклары параличланган булу сәбәпле, өеннән бик сирәк чыгып йөрсә дә, ул үз тирәсенә җирле тар милләтче яшьләрне туплый торган бер үзәк булып тора, диелә.

Жандармерия материаллары күрсәтүенчә, Казан университеты студенты Әбдрахман Мостафинның земство чакыруы буенча Златоуст һәм Эстәрлетамак өязләрендә авыл халкына гигиена буенча лекцияләр уку өчен Уфа губернасына киткәнлеге әйтелеп, аның артыннан да күзәтү оештыру турында боерык бирелә. Атаклы татар большевигы Хөсәен Ямашевның якын иптәшләреннән берсе булган Ә. Мостафин, шулай ук революциягә чаклы журналист, революциядән соң озак еллар Татарстан АССР Мәгариф комиссары булып эшләгән карт коммунист Шәһит Әхмәдиев иптәш тә охранка материалларында «панисламист-пантюркист» итеп күрсәтелә.

Патша жандармериясе, аның сатлык агентлары татар халкының алдынгы вәкилләрен күпме генә кысмасыннар, күпме генә җәберләмәсеннәр, алар үзләренең идеалларына турылыклы булып калдылар, үз халкына хезмәт итү юлыннан читкә тайпылмадылар. 1905 еллар мәктәбен узган алдынгы кешеләребез Октябрь революциясен зур шатлык һәм күтәренкелек белән каршылады. Аларның күбесе, җиң сызганып, яңа җәмгыять төзү эшендә катнашты.

Классик язучыларыбыздан Фатих Әмирхан да, революциядән соң «Кызыл Армия» һәм «Татарстан» газеталарында актив катнашып, татар демократ укымышлыларын совет властена һәм Коммунистлар партиясенә нык бирелеп эшләргә чакырган ялкынлы мәкаләләр белән күп тапкырлар чыгышлар ясады һәм ахыр гомеренә кадәр шул позициядә торып эш итте.

---

[1] «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең Әхмәтҗан хәлфә Мостафин улы. Ул Х. Ямашев белән якын мөнәсәбәттә була. Беренче империалистик сугышка врач буларак катнаша, 1915 нче елда фронтта үлә.

[2] Татарстан дәүләт архивы. 199 ф., 1 опись, 3620 эш, 185 бит.

# БАРЫСЫ ДА ХӘТЕРДӘ

Казанга килү, андагы күренекле язучыларны, культура әһелләрен күреп сөйләшү күптәнге хыялым иде. Бу миңа Октябрь революциясеннән соң гына насыйп булды. 1918 елда, гаскәри хезмәттән кайтып Мамадышта эшли башлауга, газета чыгару өчен татарча хәрефләр табарга һәм мөгаллимнәр курсында укытыр өчен педагоглар алып кайтырга дип, мине Казанга командировкага җибәрделәр. Эзләнә, төпченә торгач, үзем ишетеп белгән һәм бик күрәсем килгән язучыларның күбесенең Казанда юклыгын белдем, кайсы кая таралып беткәннәр икән. Фатих Әмирхан Казанда, диделәр. Менә шулай, һичбер чакырусыз-нисез, искәртми-нитми генә чит кешегә барып керү килешмәгәнлеген бик яхшы аңласам да, Ф. Әмирханның кайда торуын, өй адресын белү өчен, тәвәккәлләп, Яңа Бистәгә киттем. Байтак вакыт сорашкалап, эзләп йөри торгач, миңа Яңа Бистәдәге Зариф хәзрәт йортын күрсәттеләр. Кыяр-кыймас кына барып ишек кактым. Тавышка ишектән бер ханым чыкты. Күпмедер вакыт минем өс-башка, кыяфәткә сәерсенебрәк карап торганнан соң, ул, ниһаять:

— Сезгә кем кирәк иде? — дип сорады.

— Зинһар әйтсәгез лә, Ф. Әмирхан шушында торамы? — дидем мин, түбәнчелек белән генә.

— Әйе...

— Ул хәзер өйдәме?

— Өйдә...

— Аны күрергә мөмкин булмасмы икән?

— Сез кем буласыз соң?

— Мамадыштан килгән бер юлаучы. Мәхмүт Бөдәйли.

Ханымның шулай кырысрак, теләмичәрәк сөйләшүе мине инде шиккә дә төшергән иде. Ни булыр икән, ничек каршы алыр икән, сүзне кайдан башлармын икән дип борчылып торганда, теге ханым әйләнеп тә чыкты:

— Рәхим итегез! Ул сезне керсен, диде.

Ханым күрсәткән бүлмә ишеген ачуга, тәгәрмәчле урындыкта утырган кеше, әллә кайчангы танышы, дусты белән очрашкандай, елмаеп каршы алды һәм бик җылы итеп кул бирде.

— Әйдүк, Мәхмүт әфәнде, мәрхәбә, рәхим итегез, хуш килдегез! Шунда ук бер кочак сораулар белән күмеп ташлады:

— Фронттан исән-сау кайттыгызмы? Кайчан кайттыгыз? Хәзер кайда эшлисез?..

Якын күреп, үз итеп, синең турында ихлас бер кайгыртучанлык белән бирелгән бу сөальләр миндәге шик-шөбһәләрне, юып алгандай, тиз генә юкка да чыгарды. Ятсыну да, каушау да онытылды, аның һәр соравына тәмам канәгать булырлык итеп җаваплар тездем. Күпмедер вакыттан соң мине ишек төбендә каршы алган ханым бүлмәгә чәй әзерләп кертте. Фатих Әмирхан аны:

— Менә син курыккан комиссар Бөдәйли шушы инде,— дип, көлдереп тә алды. Бая, гаскәри киемдәге ят кеше килеп, Фатих Әмирханны сорагач, ул, чыннан да, бик нык курыккан булган икән.

Безнең чәй мәҗлесе озакка тартылды, күп нәрсәләр турында гәпләштек. Ул миңа газета чыгару буенча кыйммәтле киңәшләр бирде. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, күбрәк революция, илне торгызу, яңа җәмгыять төзү турында сөйләштек. Тагын шунысы хәтердә калган, яңа җәмгыять турында сүз барганда, Ф. Әмирхан марксизм-ленинизм классикларыннан мул итеп цитаталар китереп сөйләде. Маркс, Ленин тәгълиматын нык өйрәнү кирәклегенә аеруча нык басым ясады.

Дөресен әйтергә кирәк, мондый рухтагы әңгәмә мине бераз сәерсендерде дә. Янәсе, Ф. Әмирхан бу сүзләрне «комиссар» алдында аклану, үзен совет яклы кеше итеп күрсәтү өчен генә сөйләмиме?.. Нигә яшереп торырга, ул елларда без яшьләр Фатих Әмирхан кебек борынгы «милләт хадимнәренә» үткән заман кешеләре, революциягә кадәрге мәсләк кешеләре дип карарга гадәтләнә башлаган идек инде. Кем белә, Ф. Әмирхан, бәлки, үзе кебек кешеләргә безнең әнә шундый мөнәсәбәтне сизә, шуңа борчыла да торган булгандыр... Ләкин, ни генә булмасын, беренче очрашуда ук Ф. Әмирхан миңа марксизм-ленинизм тәгълиматы буенча күп сабак бирде, һәм аның сүзләре бик дөрес, бик урынлы иде.

Иртәгесен ул мине үзе белән сабан туе карарга чакырды. Мин килгәндә ат җигүле, кучер малай кабалана-кабалана, тирләп-пешеп чәй эчеп утыра, ә Ф. Әмирхан, чыгып, арбага утырган иде инде. Ат башына әлеге кучер малай утырса да, дилбегәне Ф. Әмирхан үзе тотты. Без барып җиткәндә халык байтак җыелган, түземсезләнеп уеннар башлануын көтәләр иде. Ф. Әмирханны шунда ук танышлары, дус-ишләре сырып алды, күрешүләр, хәл-әхвәл сорашулар башланды. Мине нык гаҗәпләндергәне шул булды, аның танышларының иң күбесе партия-совет аппаратларында югары постларда эшләүче югары дәрәҗәдәге работниклар иде: Дулат Али, Каспранский, Шәһит Әхмәдиев, Брындуков, Әминә Мөхетдинова, Мәстүрә Фәйзуллина, Гали Касыймов, Губанов... Менә шунда инде мин Ф. Әмирханның «комиссарлар» арасында үз кеше булуына, аны якын итүләренә, аның белән санашуларына ышандым. Димәк, кичәге сүзләр яхшыатлану, «кызыл булып» күренергә тырышу өчен генә сөйләнмәгән икән.

Ул елларда мин Казанга еш килә идем, һәм килгән саен Фатих Әмирхан янына кереп чыгарга тырыштым. Ә 1922 елда без бөтенләй Казанга күчеп килдек.

Шул вакыттан башлап 1926 елга, ягъни Фатих аганың вафат булуына кадәр, без якын дуслардан саналдык.

Ул гаять культуралы, эчкерсез самими утырдаш, менә дигән мәҗлес кешесе иде. Ф. Әмирхан катнашкан мәҗлесләр бик күңелле һәм кызыклы үтә. Җырласалар, ул, әлбәттә, кушыла, мәгънәсез сөйләнүләр башланса, зур осталык һәм такт белән, мәҗлесне кирәкле һәм кызыклы темага борып җибәрә белә. Ф. Әмирхан теләсә нинди темага мавыктыргыч, һәркем тыңларлык итеп сөйли ала, тирән эрудицияле бу кеше, төрекчә, гарәпчә бик яхшы белү өстенә, французчадан да яхшы ук хәбәрдар иде.

Ялгышмасам, Ф. Әмирханның бервакытта да аяксыз калуы турында зарланганын ишетмәдем. Үзенең тәгәрмәчле урындыгы белән аны еш кына театрларда һәм зур җыелышларда очратасың.

Бервакыт килгәндә Фатих ага янында Гаяз Максудов белән Кәрим Тинчурин да бар иде. Бераз сөйләшеп утыргач, ул «Сибгатулла абзый» дигән сатирик хикәя язганын һәм, вакытыбыз булса, укып чыгачагын әйтте. Ф. Әмирхан каләме генә тасвирлый алырлык зур осталык белән язылган бу хикәянең эчтәлеге болайрак иде. «Дини фанатизм»ның аяклы мисалы итеп йөртерлек Сибгатулла дигән бер кеше булган. Укый да, яза да белми үзе. Диннең әсаси нәрсәләрен, фарыз вәҗабын, хәрам-хәләлен ишеткәне дә юктыр, бәлки. Дин турындагы барлык мәгълүматы ата-бабасыннан, мулладан ишеткән юк-барга нигезләнгән. Аның каравы, Сибгатулла абзый шул ишеткән кадәресен искиткеч бер үҗәтлек һәм төгәллек белән үти. Ишектән ул уң аягын гына атлап керер, бисмилласыз бер эшкә дә тотынмас. Ике аяк арасы кулъяссуы кадәр микән дип, намаз укыганда кулын куеп, үлчәп карар. Рикугга киткәч, аркасына сулы савыт куйдырып карый, янәсе, аркасы тигез торамы. Сибгатулла абзый һичбер вакыт ачулана, сүгенә белмәс. Ат куганда да: «Һәй, рәхмәт төшкере, әйдә!» дип кенә суга. Ул татар дөньясында булуы мөмкин булган ырымнарның берсен дә калдырмый. Кыз бала туса аңа изге ана, ягъни хәзрәти Гайшә, яки Фатимаи-Зөһрә, ир баласына хәзрәти Гали яки Хөсәен дип исем куша. Киез эшләпәсенең бер читен кисеп, ерык ясап кия. Кяферләр эшләпәсенә охшамасын, янәсе... Төшендә хайван күрсә, торгач шундый хайванның йонын яндырып исни...

Ниһаять, еллар үтеп, картая башлагач семьясына:

— Мин сезне тәрбияләдем, туйдырдым, үстердем. Инде үземне кайгыртыр вакыт җитте. Мин хаҗга барам. Үлсәм-нитсәм дә сөягем изге җирләрдә калсын, — дип, котомкасын күтәреп хаҗ сәфәренә чыгып китә.

Хикәяне без әчләребез катып көлә-көлә, рәхәтләнеп тыңладык. Безне таң калдыр-

ган бу хикәя менә хәзер бер җирдә дә күренми, бер җыентыгында да юк. Шулай ук ул да дөнья күрми югалды микәнни?..

Икенче бер барганда:

— Теге вакытта сез танышкан Сибгатулла абзыйның энесе туды бит әле,— ди бу миңа.

— Энесе дә шундый ук сукыр фанатикмы? — дим.

— Агасыннан да сукыррак. Моңысы марксизмны дингә, тышкы йолаларга әйләндерә.

Сибгатулла абзыйның «энесе» Сөнгатулла «исемле» иде, бугай. Үткен юмор белән язылган бу икенче хикәя дә Ф. Әмирхан җыентыкларында күренми.

Күбрәк вакыт өйдә утырырга мәҗбүр булганга, Фатих ага Әмирхан дуслары, белеш-танышлары килгәнгә бик шатлана, аларны мөмкин кадәр озаграк утыртырга тырыша. Преферанс уйнарга ярата иде, бер башлагач азарт белән уйный. Шулай бер шимбәдә, эштән кайтышлый, Фатих агаларга кердем. Фатих ага Ибраһим Биккулов, Кәрим Тинчурин, Ибраһим Кулилар белән преферанс уйнап утыра. Андый вакытта ул тагын да үткен телләнеп китә, төрле такмаклар, тапкыр сүзләр агылып кына тора. Тыңлап торсаң, көлеп туя алмыйсың. Ул отса да көлә, оттырса да көлдерә. Көлке сүзгә Тинчурин да, Ибраһим да кесәгә керә торган халык түгел. Берсеннән-берсе элеп алып, ялгап җибәреп, ярыштырып, әкәмәт куптарып утыралар. Мин аерылып китә алмый аларның кызыкларын тыңлап, шактый утырдым. Инде вакыт шактый соң иде, башка кунакларны да үзем белән кайтырга өндәп карадым. Алар миннән көлделәр генә... Якшәмбе көн өйдәге ул-бу эшләр белән үтте. Дүшәмбе көн кич белән тагын Фатих агайга барып кайтырга уйладым. Барып керсәм, ни күзем белән күрим. Өй эче тәмәке төтене, өстәл окуркалар белән тулган. Өстәлдә чынаяклар, ипи, сыр кисәкләре. Шундый «художественный безпорядок» эчендә өченче көн мин калдырып киткән дүрт кешелек компания һаман, көлешә-көлешә, преферанс уйнап утыралар. Мин хәйран калдым. Фатих ага шактый агарган, ләкин һаман шулай кәефле. Мин, Фатих агайны кызганып, аңар бу эшләрнең бик зарарлы булуын сөйләп, уенны туктатырга кирәклеге турында сүз ачкач, Фатих ага, Тукайның шигырен үзенчә үзгәртеп:

«Бозмасын мәҗлес хозурын уйнамас, белмәс кеше,
Измәсен яшьләрне дә күптән яше үткән кеше»,—

дип миннән көлде дә, уеннарын дәвам иттеләр. Мин кайтып киттем.

Кайсы елдадыр, сукыр эчәккә операция ясар өчен, мине больницага салдылар. Барып керсәм, Фатих ага Әмирхан да шунда. Икәвебезгә бер бүлмә. Бик тыныч, бик күңелле. Без анда бер айга якын яттык. Һәркемгә билгеле, лазарет, казарма, төрмә окоп кешеләрне бик якынайта. Борыннан дуслар булсак, хәзер инде без күңелнең тирән почмакларында яшеренеп яткан серләрне уртаклашыр чиктә ышанычлы сердәшләр булып әверелдек. Менә шунда, больница койкасында ятканда, Фатих ага миңа Мәскәүдә узган еллары, яшьлек тормышы турында күп нәрсәләр сөйләде. Мәгълүм булганча, Ф. Әмирхан русчаны танылган революционер Гассардан укый. Үзенең сөйләвенә караганда Гассар аны русча укыту белән генә чикләнмәгән, ничек мәдәни кеше булырга, китапларны ничек укырга, югары обществода үзеңне ничек тотарга, гомумән, кешеләр белән ничек мөгамәлә итәргә, ничек киенергә, өстәл артында ничек утырырга, хәтта, чәнечке, пычаклар белән ничек ашарга кирәклегенә чаклы киңәшләр биргән. Һәм үзе һәр эштә йогынтылы үрнәк булган. «Юкса, мәдрәсә шәкерте андый эшләрне кайдан белсен»,— дип сөйләде Фатих ага.

Үткән гомерләрне искә төшереп, күңеле нечкәргән кичләрнең берсендә Фатих ага:

— Мин, Мәхмүт туган, үземнең үткән тормышымны тасвирлап, яшьләргә гыйбрәт булырдай бер мемуар язарга ниятләнәм әле,— дигән иде. Белмим, вәгъдәсен үти алдымы, юкмы? Һәрхәлдә, андый язма күренмәде. Язарга өлгерә алмагандыр дип уйлыйм. Бик үкенеч.

МӘХМҮТ БӨДӘЙЛИ.

*Рәис Беляев*



# АМЕРИКАДА ЕГЕРМЕ ИКЕ КӨН

## Сайлау алды көннәре


Без — утызга якын совет егетләре һәм кызлары Америка Кушма Штатларына 1964 елның 26 октябрендә Мәскәүдән ТУ—104 самолетына утырып очтык. Шул ук көнне Нью-Йоркка килеп тә төштек. Төнге Нью-Йорк үзенең атаклы небоскреблары, ялт-йолт итеп торган реклама утлары, характерлы шау-шуы белән каршы алды.

Нью-Йорк — Американың капкасы. Шәһәр тирәсе районнарда торучыларны да исәпләгәндә, 11 миллион кеше яши анда. Контрастлар, зур каршылыклар шәһәре ул. Тимер-бетоннан салынган йортлардан гыйбарәт булган үзәк, финанс районы — Уолл-стрит, кечкенә әңгер-меңгердә ничектер шомлы булып күренә. Аннан якында гына бер миллионнан артык негрлар яши торган пычрак Гарлем кварталлары башланып китә. Шулай ук Кытай, Италия, Латин Америкасыннан күчеп килгән халыклар һәм еврейләр яши торган кварталлар да, үзәк белән чагыштырганда, үзләренең пычраклыклары, корамалыклары белән аерылып тора. Шулай булмый мөмкин дә түгел: бу кварталларда финанс магнатлары, булдыклы бизнесменнар, Пентагон генераллары түгел, ә гади хезмәт кешеләре яши.

Нью-Йорк (шулай ук Американың бүтән шәһәрләре дә) — рекламалар шәһәре. Реклама утлары шулкадәр күп — алар күзне чәнчиләр, башны авырттыралар. Кая карама, реклама — кибетләрдә дә реклама, урамнарда да, телевизорда да, кинода да, газета һәм журналларда да. Реклама америкача яшәүнең бөтен якларын характерлый. Рекламачылар сайлау алды вакытларында чын мәгънәсендә котыралар.

Безнең Америкага сәяхәтебез вакытында, анда нәкъ сайлау алды көннәре иде.

Йорт стеналарына Кушма Штатларның флаглары, демократлар һәм республика партияләренең кандидатлары портретлары эленгән. Урамнарда митинглар бара. Гадәттә, трибуна ролен әрҗә кырыйларына плакатлар, лозунглар эленгән йөк машиналары үти. Ә тирә-юньгә төрле төстәге җиңел машиналар тезелгән. Ораторлар җыелган халыкны теге яки бу кандидатка тавыш бирергә өнди. Агитация вертолетлардан да алып барыла. Мотор һәм тавыш көчәйткечләр шау-шуы колакны тондыра. Һәр почмакта президентлыкны дәгъвалаучыларның рәсемнәре төшерелгән значоклар сатып утыралар.



Филадельфия шәһәре күренеше.

Филадельфиядә без Линдон Джонсонны күрдек. Булачак президент туктарга тиешле «Континенталь» отеле тирәсендәге урамнар кичтән халык белән тулы иде. Халыкның яртысы негрлардан гыйбарәт иде. Түбәләренә әйләнә торган фонарьлар куелган полиция машиналары төрле якка өзлексез йөреп торды. Башларына ак каскалар кигән «эмерджենси полис» («гадәттән тыш полиция агентлары») рәте халыкны уртага үткәрмичә тоткарлап тора иде. Полиция вертолеты шул тирәдәге йортларның түбәләрен прожектор белән өзлексез яктырта — Далластагы хәлнең (Кеннединең үтерелүе) тагын кабатлануы мөмкин бит!

Джонсон халык алдында чыгыш ясамады, ул аларны кулын күтәреп сәламләде генә. Аның урынына отель каршындагы йортның тәрәзәсенә куелган тавыш көчәйткеч кенә «сөйләде». «Сөйләде» дию дөрес үк булып бетмәс, аннан бары тик туктаусыз рәвештә демократлар лозунглары гына ишетелеп торды.

Ул сайлауларның Америка халкы язмышы өчен әһәмияте зур иде. Америка халкы алдында гаять зур сораулар тора иде: яңа хөкүмәт авантюристик курсны һаман дәвам итәрме, сугыш конфликтларын китереп чыгару юлыннан барырмы, әллә социалистик илләр белән бәйләнешне көчәйтә торган яңа чаралар эзләү, халыкара киеренкелекне йомшарту, Советлар Союзы белән үзара аңлашуны үстерү, бөтен дөньяда тынычлыкны ныгыту юнәлешендә эш итәрме?

Линдон Джонсон үзенең чыгышларында эчке һәм халыкара проблемаларга җаваплы карарга кирәклекне әйтеп, Америка сайлаучыларына

милли политикада сугышны булдырмауны күз алдында тотачагын белгертте. Нәкъ менә шуның аркасында да котырганнар лидеры Барри Голдуотерны ул җиңеп чыкты да. Ләкин Джонсон сүзендә тормады, халык ышанычын акламады. Америка Кушма Штатларының соңгы еллардагы тышкы политикасы (Көньяк Вьетнамдагы һәм Доминикан республикасындагы агрессияләр һ. б.) — моның ачык мисалы.

Ә ул вакытта телевидение буенча шуны күрсәтәләр иде: караңгы экранда кинәт атом-төш сугышын башлап җибәрү кнопкасы пәйда була; аңа җиңенә сержант билгесе тегелгән бер кул үрелә. Аннары барысы да югала һәм түбәндәге язу барлыкка килә: «Сез бу кнопкада кемнең бармагын — армия сержанты бармагынмы, әллә АКШ президентыныкынмы — күрергә телисез?» Моның, әлбәттә, тәэсире зур иде: азмы-күпме башында аңы булган сайлаучылар ил язмышын котырган сугыш чукмарларына — республикачыларга тапшырырга теләмәделәр. Әмма, соңыннан күренүенчә, демократлар вәкиле Л. Джонсон да алардан ерак китә алмады...

Яшь америкалылар белән очрашканда, без аларның Советлар Союзы һәм Америка Кушма Штатлары арасындагы мөнәсәбәтләрне киләчәктә ничек итеп күз алдына китерүләре турында кызыксындык. Чөнки агрессив курс яклыларның яшьләрне, аларга хас булган сыйфатларны: энергияне, хәрәкәткә омтылучанлыкны үз файдаларына аударырга тырышканлыкларын без яхшы белә идек. Ләкин яшьләрнең зур күпчелеге Голдуотер үткәрергә тырышкан курска каршы тавыш бирде.

Төньяк Каролина башкаласы Роли университеты студентлары белән очрашу хәтердә. Алар сайлау алды көннәрендә Джонсонны яклау буенча комитет оештырганнар. Бу комитет членнары Голдуотерны президентлыкка сайлауның студентларга ни бирәсен бик ачык мисалларда күрсәтеп, берничә мең листовка бастырып таратканнар. Мәсәлән, листовкаларда алар Голдуотер яклы Аризон сенаторының түбәндәге сүзләрен китергәннәр: «Балалар, — дигән ул, — белем алырга хокуклы булмаска тиешләр. Күп очракта алар белемсез дә бик яхшы яшиләр». Комитет членнары сайлау көнне, сайлау участокларына килеп, значоклар һәм «1964 елда Голдуотер сайлану — 1966 елда хәерчелек ул»,—дигән лозунглар язылган листовкалар тараттылар.


Питтсбург университеты студентлары уңнарның программасына карата үз карашларын кискенрәк төстә белдерделәр. Алар, Голдуотер фамилиясе язылган йөзләгән плакатлар сатып алып, фамилия турысына ук рәсеме төшергәннәр һәм җәмагать әҗәтханәләренә ябыштырып куйганнар иде.

Сайлау яшенә җитмәгән егетләр һәм кызлар да бу кампаниядән читтә калмадылар (Американың күпчелек штатларында 21 яшьтән сайлый алалар). Роли шәһәрендә унҗиде яшьлек укучы безгә үз мәктәпләрендә демократлар һәм республикачылар программалары буенча символик сайлаулар үткәрүләре турында сөйләде. Тавыш бирү республикачыларның зур җиңелүен күрсәткән. Ә бу бит иң консерватив штатларның берсе булган Төньяк Каролина штатында.

Америка яшьләре сайлауларда сугышка каршы тавыш бирде. Бу — бик өметле факт. Күп еллар буена аларны барлык чаралар белән политикадан аерырга маташтылар. Шуңа карамастан, Америка егетләрен һәм кызларын читтән күзәтүче роле инде канәгатьләндерми, алар хәрәкәт итәргә тиешлекләрен торган саен тирәнрәк аңлыйлар.

— Сезнең сәяхәт уңышлы булды, — диделәр безгә Америка яшьләре. — Мондый вакыйганы дүрт елга бер генә күрергә туры килә бит.

Сәяхәтебезнең уңышлымы, уңышсызмы булуы турында бәхәсләшергә мөмкин. Ләкин шунысы бәхәссез: мондый вакыйганы гел күреп булмый, дүрт елга бер генә түгел, америкалыларның үзләре әйтүенчә, хәтта киләчәк ун ел дәвамында да мондый хәлләрнең булуы мөмкин түгел икән.



Кеннеди кабере янында.

Гаугалы, астыртын, пычрак яла ягулы мондый сайлау алды кампаниясенең соңгы утыз ел эчендә булганы юк икән әле.

Газеталар һәр көнне Голдуотерның үзенең речьләрендә президент Джонсонны халык интересларына хыянәт итүче, дәүләт акчасын туздыручы итеп, ә аның кабинетын рецидивистлар, булдыксыз һәм бозык кешеләр шайкасы итеп күрсәтүе турында яздылар.

Демократлар, хакимлек итүче партия буларак, республикачыларга карата характеристика биргәндә, тыйнаграк һәм шул ук вакытта төгәлрәк иделәр. Республикачылар вәкиленең ике-өч речен күзәтеп чыгу да «сукыр фанатик, психопат, таш гасыры кешесе» кебек эпитетлар авторының — төшеп калган кандидатның — чын йөзен гәүдәләндерергә җитә иде.

Хәзер инде боларның барысы да — тарих. Матбугатта да, радио, телевидение буенча да пычрак сүз боткасы җитәрлек түгелде. Болар турында күп яздылар. Барри Голдуотер сайлауларда җиңелсә дә, үзенең фашистик карашларын ачыктан-ачык һәм күп мәртәбәләр белдергән бу кешене яклап 26 миллион америкалы тавыш бирде. Әлбәттә, ул вакытта газеталар язганча, 26 миллион кешенең барысы да бу психопат күз алдында тоткан политик курсны якламадылар. Бик күпләр республикачылар кандидаты өчен семья традицияләре буенча гына тавыш бирделәр.

Сайлаулар узды. Линдон Джонсонның президент вазифасын үти башлавына шактый вакыт узды. Ә политика искечә калды. Ләкин Америкада аек карашлы кешеләрнең тавышы торган саен ешрак ишетелә; алар Вьетнамдагы сугышны бетерүне, СССР белән экономик һәм культура мөнәсәбәтләрен киңәйтүне таләп итәләр.

## Доллар хакимлеге

Һәр шәһәргә килгәч, гидлар безне университетларга, колледжларга чакыралар. Әмма, ни өчендер, без кергәндә аларда укулар беткән була иде. Я ял көнгә туры киләбез. Ә безнең, студентларны очратып, иркенләп сөйләшәсе, совет студентларының тормышы, бездәге шартлар турында аларга белдерәсе килә иде. Ләкин без болар турында уку йортларында түгел, мәҗлесләрдә, гостиницаларда гына сөйләшә алдык. СССРда уку йортларында түләүсез уку, студентларның стипендия алулары, уку йортын тәмамлаган һәр кешенең эшкә җибәрелүе турында сөйләгәч, Америка студентлары ышанмадылар.

Әлбәттә, боларга ышану алар өчен кыен! Чөнки Америкада һәр студент югары уку йортында укыган өчен елга 1400 доллар акча түләргә

тиеш. Төньяк Каролина штатындагы университетта безгә уку дәверендә барлык студентларның 40 проценты, укыган өчен түли алмаганга, уку йортыннан чыгарылуы турында сөйләделәр. Америкадагы университетларның 45 процентында (алар аерым кешеләр кулындагы уку йортлары )студентлар стипендия алмыйлар һәм уку йортын тәмамлаганнан соң эшкә алыну-алынмауларын белмиләр. Урта мәктәпне тәмамлаганнарның бары тик 25 проценты гына университетларга, колледжларга кереп укый ала, чөнки уку өчен күп акча кирәк. Мәктәпләрдә уку өчен дә долларга ия булуның әһәмияте зур. Класслар өч группага бүленгән — янәсе укучыларның сәләтләре бертөрле түгел. Иң сәләтлеләр өчен бер группа, уртача сәләтлеләр өчен икенчесе, ә өченче группада — сәләтсезләр.

Укучыларның сәләтләрен болай итеп ничек билгеләүләрен белергә теләдек. Чыннан да, теге яки бу укучының сәләтлеме ул яки сәләтсезме икәнен ничек әйтә аласың?..

Америка гидлары безгә аларда югары квалификацияле эшченең аена 300 доллардан артык хезмәт хакы алуы турында җае килгәндә дә, килмәгәндә дә тукырга тырыштылар. Әмма бу акчаның кайларга китүен саный башлагач, сүзне артык куертырга теләмәделәр. Һәр америкалы квартира өчен айлык хезмәт хакының дүрттән берен түли. Ике бүлмәле квартира өчен анда аена 140—150 доллар түләргә кирәк. Әгәр тешең сызласа, врачка күренеп ничек дәвалану турында консультация алу да 5—10 долларсыз мөмкин түгел.

Бала көткән ата-аналар врачка 300 доллар әзерләп куярга тиешләр. Ә игезәк бала туса, 500 доллар түләргә кирәк. Бу урта америкалы өчен ике айлык хезмәт хакы дигән сүз.

Без Америка Кушма Штатлары буйлап 4 мең километр юл үттек. Юллар — анда штатлар яки аерым кешеләр милке. Һәр машина хуҗасы юлга чыкса, взнос түләргә тиеш. 25 миль юл үтә икән ул, 80 цент түли, мең километр юл үтү өчен 20 доллар түләргә кирәк. Юл йөргәндә туктап тору рөхсәт ителми, һәр тукталыш өчен күпмедер доллар таләп ителә.

## Негрлар хәле

Америкада негрлар аеруча авыр хәлдә яшн. Моннан 100 ел элек үк барлык Америка гражданнарының бер хокукта булулары турында закон чыгарылуга карамастан, негрларның хокукы бик нык чикләнгән. Дәүләт департаментында эшләүчеләр моннан җиде ел элек конгресс каршында гражданлык хокуклары буенча аерым комиссия оештырылуы турында мактанып сөйлиләр. Әмма бу комиссиянең негрларның хокукларын киңәйтү буенча кыл да кыймылдатканы юк.

Америкада 20 миллион негр яши. Хәзер шулардан бары тик 6 миллион негр гына тавыш бирергә хокуклы. Көньяк штатларда бик күп негрлар бу хокуктан мәхрүм. Белем алу да раса билгеләренә бәйле. Аклар һәм негрлар өчен мәктәпләр, театрлар, хәтта су алу колонкаларына кадәр аерым. Негрларны судсыз-нисез җәзалау — линчлау — кешелек дөньясы өчен бу хурлыклы гадәт — Америкада әлегә кадәр дәвам итә. Негрларның күбесе торак мәйданы алырга хокуксыз. Дөрес, Кеннеди хөкүмәте моннан берничә ел элек дәүләт йортларыннан (хөкүмәт акчасына салынган йортлардан) квартираларны, раса билгеләренә карамыйча, барлык гражданнарга тигез бүлү турында закон чыгарган иде. Әмма бу закон кәгазьдә генә. Чөнки Америкада 65 миллион йорт аерым хуҗалар кулында. Бары тик бер миллион йорт кына дәүләткә карый. Бу йортлардан квартира алу негрларга чынбарлыкта бөтенләй мөмкин түгел: моңа рәсми органнар да ирек бирми, торучылар да негр белән күрше булырга теләмиләр.

Негрлар шулай ук иҗтимагый тормышка да катнаштырылмый. Мә-

сәләң, конгресска бары тик алты негр катнаша. 100 сенатор арасында бер генә дә негр юк. Негрның кереме ак тәнле кереме белән чагыштырганда кырык процентка ким. Негрларның һәр тугызынчысы — эшсез.

Әлбәттә, негрларның елдан-ел политик активлыгы үсүе юкка гына түгел. Алар үзләренең гражданлык хокуклары саклануны таләп итәләр. АКШ хөкүмәте «негрлар проблемасын ничек хәл итү» турында торган саен ешрак баш вата. Изү, алдау, вәгъдә белән котылу заманы инде узды. Бөтен прогрессив кешелек дөньясы раса һәм тән төсенә карамыйча, барлык гражданнарга тигез хокук бирүне таләп итә.

## Пропаганда кемгә хезмәт итә?

Кичләрен без кинотеатрларга йөрдек яки телевизор карый идек. Ковбой фильмнары, банк басулар, үтерешләр. Атышлардан, шау-шудан арасын да америкалы күршеңә эндәшәсең:

— Бу фильмнар балалар арасында җинаятьне арттыруга этәргеч бирмиләрме, балалар тәрбиясе өчен алар начар тәэсир ясамыйлармы? — дисең.

— О, юк, — дип елмая америкалы, — һәр кеше, табигате буенча, начар эшкә сәләтле. Мондый фильмнарны күрсәтеп, без яшьләрне начар гадәтләрдән арындырабыз.

Турысын әйтик, кызык «логика»...

Америка студентлары, яшьләре Совет кешеләре тормышы турында бик аз беләләр. Дөньяның бөек язучылары әсәрләрен түгел, хәтта Америка язучылары әсәрләрен дә укымыйлар.

Америка кешеләренә караганда совет кешеләре Америка сәнгате, әдәбияты турында күбрәк беләләр — бездә шундый тәэсир калды.

Вашингтон университетында рус факультеты студентларыннан без нинди совет язучыларының әсәрләрен укулары турында сорадык. Озак кына уйлап тордылар да Достоевский, Толстой, Евтушенко исемнәрен телгә алдылар. Башка юк...

Рәсми пропаганда совет кешеләре турында дөреслеккә бөтенләй якын булмаган ялган тарата. Роли шәһәрендә аерым семьяларда яшәгәндә, безне күрергә тирә-күрше җыела торган иде. Баштан аяк бик җентекләп карыйлар, әйтерсең, без Марстан төшкән. Аннары сораулар яудыралар. Аларны барысы да кызыксындыра: кем булып эшлибез, балаларны ничек тәрбиялибез, белемебез нинди? Америкага ничек килә алдык һ. б., һ. б.

Алар совет чынбарлыгы белән бөтенләй таныш түгел. Хәтта шундый сораулар да бирделәр:

«Партия членнарының партиясезләргә караганда күбрәк хезмәт хакы алып эшләүләре дөресме?» «СССРда ни өчен парламент сайлап куелмый, ә билгеләнә генә?»

Америка яшьләре белән безнең әңгәмәләр һәм очрашулар дуслык атмосферасында үтте. Яшь америкалылар совет кешеләре тормышы белән кызыксыналар. Бу кызыксыну бигрәк тә соңгы елларда үсте. Шулай дигәннән, Төньяк Каролина штаты губернаторы Санфорд әфәндененең сүзләрен искә төшерәсе килә. «Совет кешеләре җибәргән Спутник барлык америкалыларның күзләрен ачты, — дигән иде ул. — Шуннан соң без яхшырак күрә башладык».

Америкада Советлар Союзына каршы пропаганда безнең илебез турында никадәр пычрак ялган таратса да, тормыш моның киресен күрсәтә. Без ышанабыз, килер бер көн, америка халкы әйтер: «Җитәр, — дияр, — яшьләрнең күзенә төтен өрүне туктатыйк, җир шарында тынычлык хакимлек итәргә тиеш, пропаганданың төп темасы — халыклар арасында дуслык булырга тиеш».

Америкадан киткәндә, танышларыбыз белән без түбәндәге сүзләрне әйтеп аерылыштык: «Хәзергә сау булыгыз, без әле очрашырбыз!»

# СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

## ЮЛНЫҢ ДӘВАМЫ ҺӘМ ЗУР ХЫЯЛЛАР

Тормышта күп кешенең йөрәк түрендә саклап килгән олы хыялы була, һәм ул бөтен гомере буена шуңа омтыла, үзенең иң якты уй-хисләрен, теләк-омтылышларын, барлык көчен шул хыялына багышлый. Шул хыял, маяк сыман, кешене киләчәкнең матур иртәсенә чакыра, озын юллар үтәргә, күп кыенлыкларны җиңеп чыгарга аңа көч бирә.

Белмим, ничек алай булгандыр, кем сәбәпчедер: Зәкиядә бик яшьләй, әле авыл мәктәбендә укыганда ук, артистка булу теләге уяна. Әнә шул чаклардан башлап, аның хыялын артистлар тормышы били, ул кайчан да булса үзенең дә сәхнәгә менәсенә ышанып, өметләнеп яши. Җиденче классны тәмамлагач, Зәкия, Казанга килеп, ФЗО мәктәбенә керә һәм беренче көннәрдән үк Вахитов клубы каршындагы драмтүгәрәккә языла. Күп тә үтми, ул үзешчән коллективның иң актив һәвәскәрләреннән берсе булып китә. Шулай бервакыт, драмтүгәрәк җитәкчесе үзе белән Зәкияне дә сәүдә эшчеләре драмколлективы тарафыннан әзерләнгән «Галиябану» спектакленә алып бара.



Матур итеп бизәлгән бәләкәй генә зал халык белән шыгрым тулы. Халык түземсезләнеп пәрдә ачылганны көтә. Башлагыз инде, вакыт җитте бит дигәндәй, вакыт-вакыт дәррәү кул чабып алалар. Ә һәвәскәр артистларның үз кайгылары кайгы: яучы карчыкны уйнарга тиешле кешеләре килмәгән. Кыен хәлдә калган артистлар, ярдәм сорап, кечкенә Зәкиягә мөрәҗәгать итәләр. Тиз арада аңа текст тоттыралар, ябь-яшь, үсмер кызны, карчыклар гримы салып, Бәдегый роленда сәхнәгә чыгаралар. Һәм һич көтелмәгән нәтиҗә! Бу роль спектакльдәге иң уңышлы образларның берсе итеп билгеләнә. Спектакльне карарга килгән комиссия яшь кызның артистлык сәләтен сиземли һәм аңа театр студиясенә керергә тәкъдим итә. Шулай итеп, Зәкия күптәнге хыялын тормышка ашыру юлында беренче уңышлы адым ясый.

Студент еллар! Гомернең яшьлек яме белән шаулап торган кызыклы, күңелле еллары. Кайнап торган тормыш эчендә ул елларның ничек узганын сизми дә каласың. Зәкия дә тиздән артист булачак, алда сәхнә, кызыклы да, мавыктыргыч та тормыш көтә... Мәскәүгә барабыз, анда үткәреләчәк әдәбият һәм сәнгать декадасына катнашабыз дип дәртләнеп, ашкынып йөргән көннәрнең берендә ил өстенә зур афәт килә — сугыш башлана. Бар өметләр, бар хыяллар чәлпәрәмә килеп җимерелгәндәй була.

Сугышның беренче көннәреннән үк Зәкия Кетгут заводына эшкә керә, ә 1942 нче елның май аенда, үз теләге белән, фронтка китә. Снаряд-туплардан җәрәхәтләнгән, бомбалар шартлавыннан зар елаган җир Зәкия Тушиева өчен беренче сәхнә була: ул дивизия клубында артист булып эшли. Бии, җырлый, солдатларга төрле әсәрләрдән өзекләр уйнап күрсәтә.

Фронт оборонадан һөҗүмгә күчкәч, Зәкия, санитарка булып, медсанбатка күчә һәм сугыш беткәнче шунда хезмәт итә. Фронтташларының тормышын саклап калу өчен ул үзенең йөрәк җылысын да, ярдәмен дә, канын да кызганмый. Сугыш еллары Зәкия Тушиева тормышында иң авыр һәм иң озын юллар булдылар. Җиңү таңын аларның гвардия дивизиясе Чехословакиядә каршылый.

Туган Татарстанына Зәкия җиңүче-батыр булып кайта. Аның күкрәгендә Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр балкый. Җиңү шатлыгы, җиңү тантанасы күптәнге теләкләрне кабат яңарта, һәм Зәкия еллар буе хыялланган сәхнәсенә аяк баса. Баштарак ул Республика күчмә һәм Мамадыш колхоз-совхоз театрларында эшли. Ә инде 1951 елдан Әлмәт дәүләт драма театрына күчеп килә. Шулай итеп чын-чынлап сәхнәгә аяк басканда, Зәкия Туишева инде авырлыкларга чыныккан, бай тормыш тәҗрибәсе туплаган кеше иде. Сәнгатькә ул тормышта үз урынын аңлап аяк басты. Бәлки, нәкъ менә шуңа дадыр, бик аз вакыт эчендә ул күренекле сәхнә остасы, үзенчәлекле артист булып формалашты.

Зәкия Туишеваның иҗат почергы ачыкланган. Аның өчен хас сыйфатлар — кыюлык, тирән эзләнү һәм тормыш дөреслеге. Ул иҗат иткән образлар төгәл сызымланган, эчтәлекле һәм хисләргә бай булалар.

Әлмәт театрында эшләү дәверендә Зәкия Туишева татар һәм тугандаш халыклар драматурглары әсәрләреннән дистәләрчә кызыклы образлар иҗат итте. Алар арасында актрисаның биографиясендә аеруча тирән эз калдырган рольләрдән А. Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр» драмасындагы Кручинина һәм Иван Франконың «Урланган бәхет» драмасыннан Анна образлары бар. Башкаручыдан зур көч һәм сәхнә осталыгы таләп итүче мондый образлар белән очрашу һәр актрисаның иҗатында кызыклы һәм күңелле вакыйга. Инде шул рольләрне син еллар буе йөрәгеңдә саклап, аларны уйнарга хәзерләнеп тә йөргәнсең икән, ул чагында шатлык та бермә-бер зуррак була. Кручинина Туишева өчен шундый образлардан берсе иде. Әле студиядә укыганда ук Зәкия бу образны диплом эше итеп хәзерли... Бары тик егерме елдан соң гына аңа образ белән тамашачы алдына чыгу насыйп була.

Зәкия Туишеваның актерлык биографиясен бизи торган образларның тагын берсе — Машенька. А. Афиногеновның «Машенька» пьесасындагы төп героиня Машенька образы белән очрашу бер генә актриса өчен дә эзсез үтә торган вакыйга түгел. Үзенең характеры, сәхнә үзенчәлекләре белән яшүсмер кыз Машенька роле алда телгә алынган образлардан нык кына аерылып тора. Тышкы буяулары тонырак, хәрәкәтләре азрак булган бу героиня артисттан эчке җыйнаклык, төгәллек һәм зур осталык сорый.

Машенька — әле мәктәптә укучы гына. Һәртөрле ялган, каты сүз һәм ачулы карашка да, олыларның кечкенә генә ялгыш адымына да сизгер күңелле бала үз мөнәсәбәтен белдерергә ашыга. Хисләрнең иң нечкә, иң саф, иң чиста чагы, һәм ул барлык кешеләрдән шундый ук сафлыкны, чисталыкны таләп итә. Туишева бу рольдә беркатлы бала булырга гына тырышмады. Бу образның асылын, аның кеше буларак характер үзенчәлеген ачарга тырышты. Безгә яшүсмер кызның ачык һәм юмарт табигатен, көчле ихтыярлы характерын да күрсәтте.

Әлмәт драма театрының соңгы елларда чыгарган спектакльләре арасында Аяз Гыйләҗевның «Яланаяклы кыз» исемле драмасы да бар. Актриса монда Әлфинур образын уйный. Әлфинур бай фикерле, олы җанлы кешеләрнең йөрәк тавышын сизә, матурлыкның кадерен белә торган хатын. Болай тышкы кыяфәте белән ул йомшак табигатьле кешегә бөтенләй охшамаган да, хәрәкәтләре һәм тавышы кискен, энергиясе ташып тора. Тик кызының югалуы исенә төшкән минутларда гына ул, ничектер, таштай катып кала сыман, газета-



З. Туишева Әлфинур ролендә.

журналлар актарганда гына артык кабалана һәм каушый сыман. Ул яктылык-ачыклыкны ярата, хезмәте белән кешеләргә бәхет, шатлык, матурлык китерергә тели. Үз кызы булмавын белә торып, Әлфинур Гөләндәмгә карата аналарча мөнәсәбәт күрсәтә, бу кешенең күңеле киң. Әлфинур иң авыр хәлләрдә, иң кискен очракларда да үз эшенә, фикер һәм идеалларына турылыклы кала. Кешелекле булу өчен юмартлык, яхшы күңеллелек кенә җитми, яхшылык өчен көрәшергә дә кирәк, ди безгә үзенең бу образы белән актриса. Узган сезонда Әлмәт театры Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» әсәрен сәхнәгә куйды. Бу спектакльдә Зәкия Туишева Зәмзәмбану образын иҗат итте. Актриса, беренче чиратта, образның эчтәлеген, Зәмзәмбануны түбәнлеккә төшергән сәбәпләрне ачарга тырышкан. Һәм иң кызыклы ягы шунда: актриса бу образны, кеше буларак, яклап чыга, төп игътибарын аның әйбәт, яхшы якларын күрсәтүгә юнәлдерә. Зәкия Туишева башкаруында Зәмзәмбану караңгылык, наданлык, авыр тормыш шартлары нәтиҗәсендә югалып, томана булып калган хатын булып күз алдына баса.

Әлмәт театры — күчмә театр. Аның эш шартлары шактый кыен һәм үзенчәлекле. Һәркөнне яңа авыл, яңа клуб, яңа сәхнә. Өзлексез юлда булу, гел күченеп йөрү, билгеле, бик җайлы түгел. Шуңа карамастан, бу хезмәтнең үзенең мактаулы ягы, романтикасы бар. Авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә йөргәндә һәркөнне диярлек яңа кешеләр, яңа тамашачы белән очрашасың, аның ихтыяҗлары, омтылышлары белән якыннан аралашасың. Зәкия Туишева — Әлмәт театрының олы патриоты: актрисаның шәхси тормышы театр тормышыннан, аның иҗади эшеннән, көндәлек мәшәкатьләреннән аерылгысыз. Театр коллективы репертуар сайлауда, башка мәсьәләләрдә булсын З. Туишеваның сәләтенә һәм зур тәҗрибәсенә таяна, шул ук вакытта актрисаның иҗади кыялларын тормышка ашыруда ярдәм дә итә.

Хәзерге көндә театрның художество җитәкчесе булып ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, тәҗрибәле режиссер Габдулла ага Юсупов эшли. Ул Зәкия Туишеваның иҗатына югары бәя бирә, аның сәләт көченә, фикер кыюлыгына зур ышаныч белән карый. Соңгы вакытта куелган күп кенә спектакльләрнең режиссер ассистенты итеп ул З. Туишеваны билгеләде. Татарстанның атказанган артисты Зәкия ханым Туишева бүген дә зур иҗат планнары белән яши. Актриса күптән инде күңел түрендә В. Вишневскийның «Оптимистик трагедия»сеннән комиссар образын саклап килә. Кем белә, бәлки, аның бу хыялы да тормышка ашар. Һичшиксез, без аның бу теләгенә кушылабыз һәм үзенең иҗат көченә нык ышанган актриса бу образын да уңышлы гәүдәләндерер дип ышанабыз.

Зәкия Туишева үткән юллар озын. Бөек Ватан сугышы фронтларында ул меңнәрчә километр юл үткән. Хәзер исә республикабызда ул булмаган почмак, ул булмаган җир юктыр. Соңгы сүз итеп шуны гына әйтәсе килә: иҗат юлыгыз озын һәм дәвамлы, уңышларыгыз мул һәм бай булсын!

*Д. ГЫЙМРАНОВА.*

■ ■ ■

# ТӨРЛЕСЕННӘН

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ИСЕМЕ КЕМ?

**Кеше исемнәренең килеп чыгышын, мәгънәсен, кулланылыш-үзгәрешләрен тел белеменең аерым тармагы өйрәнә, һәм аны «антропонимия» дип йөртәләр. Тел белеменең барлык төр ялгызлык исемнәрен тикшерә торган бүлеген исә «ономастика» дип атыйлар.**

**Татар ономастикасы һәм аның бер кисәге булган антропонимиясе — тел белемебезнең бик аз өйрәнелгән өлкәләре әле. Бу тармаклар исә татар телчеләре, этнографлары һәм тарихчыларыннан лингвистик һәм тарих-культура аспектында махсус фәнни тикшеренүләр алып барылуны көтәләр.**

**Ялгызлык исемнәре телнең гомуми сүзлек составының бер өлешен тәшкил итәләр һәм аның аерым катлавын барлыкка китерәләр. Алар мәгънәләре ягыннан уртаклык исемнәренә якын торалар, чөнки күбесенчә шулардан ук ясалалар. Кеше исемнәре, сүзлек хәзинәсенең башка тармаклары кебек, татар халкының тарихи үсешенең төрле чорларына хас иҗтимагый тормыш укладын, культурасын һәм дөньяга карашын шактый тулы чагылдыралар. Бу мәкаләбездә әдипләребезнең исем-фамилияләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча беркадәр фикер йөртмәкче һәм, шул җирлектә, татар антропонимиясен өйрәнүнең әдәбиятыбыз тарихына азмы-күпме өлеш кертә алуы турында берничә сүз әйтмәкче булабыз.**

**Борынгы әдәбият буенча белгеч Ш. Абиловның «Совет әдәбияты» журналының 1958 елгы 11 санында XVII йөз татар шагыйре Мәүла Колый иҗаты турында бер мәкаләсе басылган иде. Ул 1957 елда СССР Фәннәр Академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтының (Ленинград) кулъязмалар бүлегеннән шагыйрьнең ике хикмәтен таба һәм, шуларга таянып, Мәүла Колыйның чын исеме, яшәгән урыны, иҗат иткән заманы турында үзгә фикер йөртә. Шагыйрьнең остазы Мелла Мамайга багышланган хикмәтнең Ленинград нөсхәсендәге:**

Мөхиб[1] дустлар, бу хикмәтне әйтмеш көндә[2]
Сиксән йыл ирде ул көн тарих миндә[3].
Әйтү ады[4] шәһри Болгар кәнтләрендә[5].
Гасый[6] җани Меллагол кол сүзли, дустлар, —

**дигән юлларыннан чыгып, Ш. Абилов түбәндәге нәтиҗәләрне ясый:**

**«1. Шагыйрь Казан — Болгар тирәсендә яшәгән һәм бу әсәрен Болгар шәһәрендә яки бистәләренең берсендә 1669—1670 елларда иҗат иткән.**

**2. Биредә мөһим моментларның берсе тагын шул — без беренче мәртәбә шагыйрьнең чын исеме белән очрашабыз. Моңарчы шагыйрьнең чын исеме дип саналып йөртелгән «Мәүла Колый» сүзләре, хәтта аның псевдонимы да түгел. Ул шагыйрьнең үзен алла колы итеп санаганлыгын гына белдерә. Шигырьдәге «Гасый җани Меллагол кол**

---

[1] Мөхиб — сөекле.
[2] Әйтмеш көндә — сөйләгән вакыты.
[3] Һиҗридән 1080 ел — милади буенча 1669—1670 елларга туры килә.
[4] Әйтү ады — сөйләгән (язган) урын исеме.
[5] Кәнт — шәһәр, бистә.
[6] Гасый — гөнаһлы (сноскаларның аңлатмасы Ш. Абилов тәрҗемә иткәнчә бирелде — Г. С.).

сүзли, дустлар» дигәндәге «Меллагол» сүзе, һичшиксез, шагыйрьнең чын исеме булырга тиеш» (109 бит).

Шушы нәтиҗәләргә ияреп булса кирәк, борынгы татар әдәбияты белгечләре Х. Мөхәммәтов һәм Х. Хисмәтуллин да шагыйрьнең исеме Меллагол дигән карашта торалар [1].

Ш. Абилов ясаган нәтиҗәләрнең дөреслеге, дөрес түгеллеге турында сүз алып барудан элек, укучыга аңлавы җиңел булсын һәм өзекләрне үзара чагыштырып фикер йөртү өчен, Мәүла Колыйның шул ук хикмәтенең проф. Габдрахман Сәгъди игълан иткән юлларын китерик [2]:

Мөхиб дуслар, хикмәтне әймеш көндә
Сиксән сигез ирде тарих ул көн мең дә [3];
Әйтелде шәһре Болгар кәндләрендә [4]
Гасый җаны Мәүла Колый сүзли, дуслар.

«Борынгы татар әдәбияты» китабында исә шул ук шигырьнең Ленинград нөсхәсеннән алынган юллар түбәндәгечә бирелгән:

Мөхип дуслар, бу хикмәтне әймеш көндә
Сиксән ел ирде ул көн тарих мең дә,
Әйтелде шәһәре Болгар көннәтләрендә [5],
Гасый җани Меллагол Кол сүзли, дуслар.

Күрәсез, борынгы кулъязма әсәрләрнең текстлары бездә төрлечә укылалар һәм бастырылалар. Мәсәлән, бер үк өзектә Ш. Абилов: дустлар, әйтмеш, мендә, әйтү ады, шәһри Болгар кәнтләрендә, Меллагол кол дип, ә Х. Хисмәтуллин: дуслар, әймеш, мең дә, әйтелде шәһәре Болгар көннәтләрендә, Меллагол Кол дип бирә. Кыскача әйткәндә, кулъязма әдәби әсәрләребезнең текстологиясе өстендә эшләүгә бик зур игътибар бирергә кирәк әле.

Хәзер Ш. Абиловның югарыда китерелгән нәтиҗәләре турында фикер йөртик. Ленинград нөсхәсеннән аңлашылганча, хикмәт 1669—1670 елларда язылган, ә Г. Сәгъди бастырган юллар 1677 елда иҗат ителүен хәбәр итәләр. 7—8 еллык вакыт аермасы бар. Шагыйрьнең остазына багышлап элек язылган хикмәтен, 7—8 ел үткәннән соң янадан эшкәртүе, камилләштереп язуы бик мөмкин. Шулай булса, бер үк хикмәтнең төрле вариантларына ике төрле дата куелуы аңлашыла. Ләкин Мәүла Колыйның яшәгән һәм иҗат иткән урыны турында Ш. Абиловның кистереп әйткән фикерләре белән килешү кыен. Безнең карашыбызча, бу мәсьәлә тагын да эзләнүне, тикшерүне сорый.

Хикмәтнең «Әйтү ады шәһри Болгар кәнтләрендә» (Ленинград нөсхәсе) дигән юлларыннан чыгып, Ш. Абилов: «Шагыйрь Казан — Болгар тирәсендә яшәгән һәм Болгар шәһәрендә яки бистәләренең берсендә... иҗат иткән», — дигән шактый каршылыклы нәтиҗәгә килә. Казан белән Болгар шәһәре бер-берсеннән 150 километрдан артык ераклыкта урнашканнар. Шулай булгач, географик тирәлекне конкрет күзаллап, Мәүла Колыйның я Казан, я Болгар шәһәре тирәсендә яшәве турында гына сүз алып барырга мөмкин булыр иде. Нәтиҗәдән аңлашылганча, шагыйрь бер урында яшәп, икенче урында иҗат иттеме икән?

Борынгы әдәби әсәрләрдәге архаик сүзләрне бөтен мәгънәләрен күрсәтеп, тәрҗемә итмәү әсәрнең эчтәлеген дөрес итеп аңларга һәм тикшеренүчеләргә фәнни фикер йөртергә, эзләнергә комачаулый. Ш. Абилов «кәнт» сүзен «шәһәр», «бистә» дип тәрҗемә итә һәм, шуңа таянып, Мәүла Колый Болгар шәһәрендә яки бистәләренең берсендә иҗат иткән дигән фикергә килә. «Кәнт» сүзенең «бистә» төшенчәсендә кулланылган булуын әйтүе кыен. Топонимикада моңа мисал таба алмадык. «Татар поэзиясе антологиясе»ндә «кәндләрендә» сүзе (71 бит) «тирәләрендә», «җирләрендә» дип тәрҗемә

[1] Борынгы татар әдәбияты. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1963 ел, 80 һәм 481 битләр.
[2] Татар поэзиясе антологиясе. Таткнигоиздат. Казан, 1956, 71 бит.
[3] Һиҗри белән 1088 ел; милади белән 1677 елга туры килә.
[4] Кәндләрендә — тирәләрендә, җирләрендә.
[5] Көннәтләр — капкалар.

ителгән. Бу тәрҗемәләр «кәнд» сүзенең барлык мәгънәләрен дә биреп бетерәләрме, аның тагын башка мәгънәсе юкмы? 1940 еллардагы мәктәп дәреслекләрендә (Л. Җәләй һәм С. Байков. Әдәбияттан дәреслек-хрестоматия. Казан, 1940, 8 бит) Мәүла Колый хикмәтендә кулланылган «кәндләрендә» сүзе «авылларында» дип тәрҗемә ителгән. В. И. Савинна да «Иран топонимнарының сүз ясалыш типлары турында» дигән хезмәтендә кенд, генд сүзләренең шәһәр һәм авыл мәгънәсендә кулланылуын әйтә һәм шул фикерләрен дәлилләү өчен Аккенд, Эскикенд, Чалекенд, Баг-кенд, Семезкенд, Акчакенд кебек мисаллар китерә. Ул кенднең көнчыгыш Иgranнан килеп чыккан сүз булуы, Согдиананың борынгы топонимнарында очравы һәм төрки халыкларның да бу сүзне кулланылышка алулары турында яза. В. И. Савиннаның бу фикерләрен Урта Азия һәм Казагыстан шәһәрләре һәм кышлак, авыллары ның исемнәре тулысынча раслыйлар: Ташкент, Чимкент, Яркенд, Самар-канд — шәһәрләр; Бабкент (Бохара өлкәсе), Бешкент (Сурхандарья өлкәсе), Сарканд (Алма-Ата өлкәсе), Газелкент, Пскент (Ташкент өлкәсе)—кышлак һәм авыллар. Димәк, «кәнт» сүзе шәһәр мәгънәсендә генә кулланылмаган, бәлки кечерәк торак пункт — авыл, кышлак мәгънәсендә дә кулланылышта йөргән һәм моны җирле топонимнар да раслыйлар. Азербайҗан телендә «кәнд» сүзе хәзер дә авыл мәгънәсендә кулланыла. Боларга таянып, Мәүла Колый хикмәтендә «кәнд» сүзенең авыл төшенчәсендә кулланылган булуы мөмкин, дигән карашка киләбез. Бу карашны тагын ике факт куәтли:

I. XVII гасыр азакларында Болгар шәһәренең хәрабәләр хәлендә булуы һәм «кәнт» сүзенең күплек санында «кәнтләрендә» формасында кулланылуы (Болгар шәһәре бер генә булган, ә берничә түгел) Мәүла Колыйның шәһри Болгарда иҗат итмәгәнлегенә ишарә ясыйлар.

II. Шагыйрьнең «шәһри Болгар» сүз тезмәсен шәһәр төшенчәсендә генә алмыйча, традиция буенча, дәүләт, ил (Хорезм дәүләте, Бохара дәүләте, Рим дәүләте һ. б. кебек) мәгънәсендә кулланган булуы мөмкин. Шулай булганда, «шәһри Болгар кәнтләрендә» тезмәсе турыдан-туры Болгар иле авылларының берсендә дигән мәгънәне белдерә.

Ш. Абиловның икенче нәтиҗәсе белән шулай ук килешеп булмый. Ул Ленинград нөсхәсендәге: «Гасый җани Меллагол кол сүзли, дустлар», дигән юлларга таянып, Мәүла Колый сүзләре хәтта шагыйрьнең псевдонимы да түгел, Меллагол сүзе, һичшиксез, аның чын исеме булырга тиеш, дип икеләнүсез кистереп әйтә дә, шул фикерен ике дәлил китереп расларга тырыша. Бу дәлилләр шагыйрьнең чын исеме Мәүла Колый түгел, бәлки Меллагол дигән фикерне тулысынча раслый алалармы соң? Икенче өлеше кол-гол сүзеннән гыйбарәт булган кушма тамырлы кеше исемнәренең татарлар арасында еш очравы, мондый кеше исемнәренең Хисаметдин Мөслими, К. Насыйри хезмәтләрендә булуы (мәсәлән, Рәхимкол, Җомагол, Сөяргол, Әлемгол Меллагол углы һ. б.) Ш. Абиловның беренче дәлилен тәшкил итә. Моңа тулысынча кушылабыз. Ләкин әле бу исемнәрнең XVII гасырда, аннан элегрәк тә, соң да кулланылышта йөрүләре Мәүла дигән сүзнең дә кеше исеме буларак кулланылуын инкарь итә алмый бит. Ш. Абилов карашынча Мәүла Колый сүзләре бары тик шагыйрьнең үзен аллаколы итеп санаганлыкны гына белдерә, хәтта псевдонимы да түгел. Моннан, табигый, бу сүзләрнең кеше исеме буларак кулланылуы турында әйтеп торасы да юк, дигән фикер ачык аңлашыла. Хәлбуки, Мәүла сүзе һәм аның кушма исем ясаган төрләре татарларда, кеше исеме буларак, кулланылган һәм хәзер дә кулланыла. Бу сүз ирләр (мәсәлән, Мәүли, Мәүла, Мәүлихан, Мәүлиҗан һ. б.) һәм хатын-кыз (Мәүлия, Мәүлиҗиһан, Мәүлиҗамал, Мәүликамал һ. б.) исемнәре ясауда әле актив кулланыла. Кыпчак һәм мең кабиләсе башкортлары шәҗәрәләрендә Мәүләяр, Мәүлеш кебек кеше исемнәре очрый.

Ш. Абилов шагыйрьнең бер үк хикмәтенең икенче вариантында Меллагол кол урынына Мәүла Колый дип язылуны күчерүчеләрнең игътибарсызлыгыннан һәм саксызлыгыннан гына булган дип хисапларга кирәк, ди. Ягъни Ш. Абилов профессор Г. Сәгъди игълан иткән хикмәтләр күчерүчеләрнең игътибарсызлыгы аркасында хата язылган дип уйлый. Хикмәтнең Ленинград нөсхәсен күчерүче игътибарсыз булмаган һәм берниндн дә хата җибәрмәгән дигән гарантия бирә алабызмы соң? Юк,

[1] Башкорт шәҗәрәләре. Башкортстан китап нәшрияты, Уфа, 1960, 66—107 битләр.

әлбәттә. Г. Сәгъди бастырган һәрбер хикмәтнең соңгы юлларында Мәүла Колый сүзләренең кабатланып килүе үзе үк механик хата җибәреп күчерергә урын калдырмый. Чөнки күчереп язучы бер үк сүздә бер-ике хикмәтне күчергәндә хата җибәрсә дә, унынчысы, утыз бишенчесе яки туксан алтынчысында ялгышмас (Мәүла Колыйның туксан алты хикмәте барлыгы билгеле), дөрес язар һәм, алда хата җибәргән булса да, аны табып, һичшиксез, төзәтер иде. Ленинградтагы Көнчыгышны өйрәнү институтында шагыйрьнең ике генә хикмәте табыла. Бу хикмәтне күчереп язучы Мәүла Колый сүзләрен Меллагол кол дип ялгыш күчерергә, бер үк сүзне кат-кат күрә алмаганга, хатасын сизә һәм төзәтә алмавы бик мөмкин бит.

Безнең карашыбызча, Мәүла — шагыйрьнең исеме, ә Колый — туган урыны белән бәйләнешле исме нисби фамилиясе.

Көнчыгыш халыкларының күпчелегендә һәм шул исәптән татарларда да әдәбият, культура һәм фән эшлеклеләре үзләренең фамилияләре итеп, гарәп теленнән алынган — и (-ый) кушымчасын ялгап, туган авылларының һәм шәһәрләренең исемнәрен кулланганнар: Ә. Рудаки (IX йөз), М. Кашгари (XI йөз), Хуҗахәсән Болгари (XIII йөз), Харәзми (XIV йөз), М. Болгари (XIV йөз), Г. Утыз-Имәни (XVIII йөз), Г. Курсави (XIX йөз), Ш. Мәрҗани (XIX йөз), Г. Кандалый (XIX йөз), Г. Чокрый (XIX йөз), Н. Думави, М. Укмаси, З. Ярмәки һ. б. XVII йөз шагыйре Мәүла Колый да шушы традициядән читкә китмәгән булса кирәк. Моңа таянып, Мәүла Колый исемендә кол сүзе булган татар авылларының берсендә туган булырга тиеш дигән фикергә киләбез. Казанда укыганнан соң, шагыйрьнең туган авылына яңадан кайтып яшәве, иҗат итүе һәм шунда үлүе дә мөмкин.

Антропонимия материаллары кол сүзенең кеше исеме буларак үзе генә кулланылмавын, бары тик Коләхмәт, Колбарис, Колхуҗа яки Собханкол, Үлмәскол, Әтнәгол, Мөхәммәткол кебек кушма тамырлы кеше исемнәре составында гына килүен күрсәтәләр. Шуңа Колый шагыйрьнең әтисе яки бабасы исеменнән ясалган патронимик фамилиясе түгел дип әйтә алабыз. Дөрес, Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» драмасында катнашучы бер тарханның исеме — Колый. Бу исем драматург тарафыннан иҗат ителгән булырга тиеш.

Әсәрләрендәге мәгълүматлардан чыгып, кайбер филолог галимнәребез Мәүла Колый Урта Идел буе авылларының берсендә[1] яки, урынын тагын да конкретрак күрсәтеп, борынгы Болгар авылларының берсендә (хәзерге көндә Татарстанның Куйбышев районына туры килә) яшәгән[2] дип саныйлар. Идел елгасының урта агымында, атап әйткәндә, Болгар һәм Казан шәһәрләре тирәлегендә исемендә кол тамыры булган авыллар бармы соң? Бар һәм алар байтак. Борынгы Болгар шәһәре тирәсеннән: Колчура (Куйбышев районы), Колбай (Әлки районы), Коллар һәм Колчык (Апас районы); Казан тирәсеннән: Колкамәр (Питрәч районы), Колсәет (Биектау районы) һ. б. авылларны мисал итеп китерә алабыз.

Шагыйрьнең әсәрләре беренче башлап табылган төбәкне дә истән чыгарырга ярамый. Билгеле булганча, аның хикмәтләре 1925 елда Зәй-Каратай авылында кульязма китап эченнән табыла. Китапны Зәй-Каратай якларына хәзерге Әлмәт районының Сөләй авылында яшәгән Мөхәммәди Вилдан дигән кешенең кызы Гайшә Мөхәммәдиева алып килгән була. Мәүла Колый әсәрләренең Мөхәммәди кулына эләгүе турында ике төрле фикер йөртергә мөмкин. Я Мөхәммәди үзләреннән ерак булмаган, Г. Утыз-Имәнинең борынгы кульязма әсәрләрне туплау һәм күчереп язуга әһәмият бирүе белән билгеле Куакбаш яки Тимәш мәдрәсәсендә укыган һәм Мәүла Колый хикмәтләрен дә шунда кульязма китабына күчереп алган, яисә шагыйрь үзе Сөләй тирәсенең исемендә кол сүзе булган авылларының берсендә туган һәм иҗат иткән. Бу тирәләрдә Колшәрип (Әлмәт районы), Колчан (Бөгелмә районы), Колмәт (Сарман районы), Колеш (Минзәлә районы) дигән авыллар бар. Кульязма китапның шагыйрьнең үз кулы белән язылган булуы һәм соңрак Мөхәммәди кулына килеп керүе дә мөмкин. Югарыда сөйләнгәннәрдән нәтиҗә ясап, шагыйрь өч төбәктәге (Болгар шәһәре, Казан һәм Әлмәт тирәләре) авылларының берсендә туган; җыйнаклык һәм кыскалык өчен туган авылы

[1] М. Гайнуллин, Ш. Әхмәтов. Татар әдәбияты. IX класслар өчен дәреслек. Казан, 1964. 13 бит.

[2] Л. Җәләй һәм С. Байков. Әдәбияттан дәреслек-хрестоматия, Казан, 1940, 8 бит.

исеменең к о л дигән тамырын гына алып, үзенең исме нисби фамилиясен ясаган булса кирәк дип әйтәсе килә.

Биредә антропонимия һәм топонимика мәгълүматларына таянып, Мәүла Колый биографиясенә бәйләнешле берничә фикер әйтергә тырышылды. Дөрес, Мәүла Колый биографиясен төгәл ачыклау өчен әдәбиятчыларыбызга әле бик күп тикшеренергә, күп яклы фәнни эзләнүләр алып барырга кирәк.

Бөек Октябрьдан соң да әдипләребез һәм культура эшлеклеләребез -л ы, -л е һәм рус теленнән алынган -с к и й, -с к а я аффиксларын топонимнарга кушу юлы белән туган җирләрен күрсәтә торган фамилияләр ясауны дәвам иттерделәр: М. Сөндекле, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ф. Сәйфи-Уфалы, Г. Иделле, С. Урайский, Г. Толымбайский, Г. Кайбицкая һ. б.

XX йөз башларыннан алып татар әдипләре фамилияләре функциясендә үз исеменнән соң әйтелүче һәм язылучы әтисе яки бабасы исемен куллану киң урын ала: Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Ш. Камал, Һ. Такташ, М. Җәлил, И. Туктар, М. Әмир һ. б. Патронимик фамилияләр куллану Көнбатыш һәм Көнчыгыш язучылары арасында шулай ук киң таралган: Андре Стиль, Ромен Роллан, Вильям Шекспир, Гафур Голям, Гомәр Хәйям, Мирсәет Миршакар, Сөләйман Рөстәм, Әхмәт Габбас һ. б. Татар әдипләреннән Муса Акъегет задә үзенең патронимик фамилиясен таҗик-фарсы телендә улы төшенчәсендә йөрүче з а д ә сүзен куллану юлы белән ясаган.

XIX йөзнең икенче яртысында татарларда рус теленнән алынган -о в, -е в, -о в а, -е в а, -и н, -и н а аффикслары ярдәмендә фамилия ясау тәмам формалаша һәм әдипләребез арасында киң кулланышка керә бара: З. Бигиев, Ш. Мөхәммәдев, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Ш. Усманов, Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, Н. Арсланов, Ш. Галиев, Г. Ахунов, Л. Ихсанова, С. Сөләйманова һ. б.

Татар телендәге исем-фамилияләрне дөрес әйтү, язу һәм транскрипцияләү мәсьәләләре кичектергесез рәвештә махсус фәнни тикшеренүләр алып баруны сорыйлар. Билгеле, болар язучыларыбызның исем-фамилияләренә дә кагылалар. «Борынгы татар әдәбияты» китабында (74 бит) «Йосыф вә Зөләйха» поэмасы авторының үзен бер урында Г а л и, икенче җирдә К о л Г а л и дип атавы әйтелә. Әдәбиятыбызда һәм матбугатта аның исемен К о л Г а л и дип язу рәсмиләштерелгән. Болай язганда, К о л шагыйрьнең исеме, ә Г а л и патронимик фамилиясе булып аңлашыла һәм укучы аны шулай кабул итә дә. Чынбарлыкта исә, К о л Г а л и Коләхмәт, Колсәет, Колбарис, Колмөхәммәт, Колшәрип һ. б. кебек кушма тамырлы кеше исемнәре тибындагы бер исемне генә белдерә. Димәк, шагыйрьнең исемен К о л г а л и дип кушып әйтү һәм язу дөрес булачак. Тарихи чыганаклар күрсәткәнчә, Колгалинең әтисе Мирхаҗи, ә улы Миргали исемле булган. Бу исемнәр шулай ук ике сүз кушылу юлы белән ясалганнар: Әмир (мир) + хаҗи, Әмир (мир) + гали. Колгали әтисе исемен патронимик фамилия функциясендә кулланса, К о л г а л и М и р х а җ и булырга тиешлеге дә яхшы аңлашыла. Казан шәһәренең 1646 елгы писцовая книгасында Колгали дигән исем «Кулалей» рәвешендә бергә язылган.

Әдипләребезнең исем-фамилияләрен төрлечә язу (Мәүла, Мәүлә; Шамил, Шамиль) һәм русча бирелештә төрлечә транскрипцияләүдә дә (Гали Рагим, Гали Рахим, Галимзян Ибрагимов, Галимжан Ибрагимов һ. б.) еш очрый. Мондый кимчелек һәм чуарлыклардан арыну өчен, якын елларда татар телендәге исем-фамилияләрнең русча транскрипциясе дә күрсәтелгән тулы сүзлеген төзеп бастырырга кирәк. Язучыларыбызга бу сүзлекнең иҗат ителәчәк әсәрләрендәге әдәби образларга исемнәр сайлап алу өчен дә ярдәме булачак.

ГОМӘР САТТАРОВ.

# ЧУВАШ ЖУРНАЛИСТИКАСЫ КАЗАНДА ТУГАН

### («Хыпар» газетасының чыга башлавына 60 ел тулу уңае белән)

*Казан элек-электән культура, фән һәм мәгърифәт үзәге булып килгән. Казанда басылган китаплар, журналлар һәм газеталар Ерак Себергә, Урта Азиягә киткән, Урал таулары һәм Идел буйларында яшәүче җирле халыклар арасында таралган. Мари телендәге беренче календарь, якут, бурят, удмурт телләрендәге әдәбият үрнәкләре башлап шушы шәһәрдә басыла. Чуваш журналистикасы да Казанда туган: моннан 60 ел элек, 1906 елның 8 январенда «Хыпар» («Хәбәр») исемле беренче чуваш газетасы чыга. «Хыпар» 1907 елның 27 маена кадәр яши, һәм шул вакыт эчендә 16 битле бу газетаның 65 саны чыгып өлгерә.*

*Чыга башлавының беренче чорларында газетаның идея йөзе, тоткан кыйбласы шактый буталчык була. Редакция коллективының үз эчендә бер-берсенә капма-каршы ике агым барлыкка килә. «Хыпар» битләрендә бигрәк тә либераль демократизм рухындагы материаллар күп урын ала. Озаклямый газетаның беренче редакторы Николай Васильевич Никольский укытучылар семинариясенә эшкә күчә, редактор булып С. К. Кириллов эшли башлый. Яңа редактор килгәч, «Хыпар» нык аякка баса, газетага Казан большевиклары йогынтысы көчәя. Газета шул чорның актуаль мәсьәләләрен күтәрә, тормыштагы күп төрле җитешсезлекләрне, аларның сәбәпләрен күрсәтә. «Хыпар» битләрендә дингә каршы язылган мәкаләләр, фельетоннарга киң урын бирелә.*

*Билгеле булганча, патша самодержавиесе, Россиядәге төрле милләт халыкларын бер-берсенә каршы котыртып, аларны үзара сугыштыру, дошманлаштыру политикасы алып барды. Газета самодержавиенең бу эшен һәм кабахәт политикасын фаш итү юлында да зур эш башкара. «Русларның, чувашларның, татарларның уртак дошманнары — бер. Әгәр без яшәп килүче тәртипләрне үзгәртергә телибез икән, барыбыз да руслар белән дус булырга һәм авыр көрәш алып бару өчен берләшергә тиешбез», — дип язды газета чираттагы саннарының берсендә.*

*«Хыпар» газетасында катнашучы барлык чуваш язучылары диярлек татарча әдәбәт белгәннәр, үзләренең байтак әсәрләрен турыдан-туры татар газета-журналларында да бастыра торган булганнар. Беренче чуваш шагыйрәсе А. В. Васильева — Итесь үзенең «Чувашлар һәм татарлар» исемле шигырендә татар һәм чуваш халыкларын дус һәм тату яшәргә, берләшеп уртак дошманга каршы көрәшкә күтәрелергә чакырды.*

*Чуваш халкының күп кенә талантлы язучылары башлап «Хыпар»да чыныгалар, шул газетада иҗат тәҗрибәсе алалар. «Хыпар» Т. С. Семеновның (Тайр Тимкки) халыкны кораллы күтәрелешкә чакырган революцион шигырьләрен баса. Т. С. Семенов РСДРПның Казан комитеты членнары белән элемтәдә яши, татар халкының данлыклы улы, күренекле революционер Хөсәен Ямашевның якын дусты була. РСДРП комитетының соравы буенча, «Интернационал», «Эшчеләр марсельезасы», «Варшавянка», «Крестьян марсельезасы» кебек революцион җырларны ул чуваш теленә тәрҗемә итә.*

*Шул ук газетада чуваш халкының икенче бер язучысы — М. Ф. Акимов иҗатына да киң мәйдан бирелә. М. Ф. Акимов үзе дә редакция аппаратында эшли. Килгән материалларны эшкәртә, яшәп килүче стройга каршы юнәлтелгән үткен мәкаләләрен, фельетон, памфлетларын яза. Михаил Акимов чуваш журналистикасында политик юмор һәм сатира жанрын башлап җибәрүчеләрнең берсе булды.*

*«Хыпар» газетасы турында сөйләгәндә, без чуваш журналистикасын, культурасын һәм әдәбиятын үстерергә зур өлеш керткән Н. И. Полоруссов-Шелеби, Т. Абрамов, Д. Демидова, С. И. Игнатьев, П. А. Алексеев, В. И. Иванов, Ф. Н. Николаев һәм башка кулләрнең исемнәрен зур хөрмәт белән искә алырга тиешбез.*

*«Хыпар» милли матбагада беренче карлыгач иде. Ул озак яшәмәде, кара реакция елларында хөр фикерле мондый газета, билгеле, иркенләп, озаклап яши алмады. Әмма, шул кыска бер вакыт эчендә дә, ул милли журналистиканы үстерүгә лаеклы өлеш кертте, файдалы эш башкарды.*

**К. ПЕТРОВ.**

# ТЮРКОЛОГЛАР КИҢӘШМӘСЕ

1956 елдан башлап, ике елга бер мәртәбә, төрки телләр диалектларын өйрәнүче тел белгечләренең региональ киңәшмәләре үткәрелеп килә. Бу эшне СССР Фәннәр академиясе Тел белеме институтының төрки телләр секторы һәм Әзербайҗан ССР Фәннәр академиясенең Низами исемендәге әдәбият һәм тел институтлары башлап җибәргән иде.

Тюркологларның чираттагы V Бөтенсоюз киңәшмәсе узган елның 5—8 октябрендә Баку шәһәрендә үткәрелде. Киңәшмәгә илебезнең төрле почмакларында яшәүче йөзгә якын вәкил килгән иде. Киңәшмә гомумтөрки лингвистик атлас төзү мәсьәләләре турында сөйләшү белән башланды. Докладчылар да, чыгыш ясаучылар да киңәшмәгә куелган проблеманың гаять әһәмиятле, актуаль булуын билгеләп үттеләр. Төрки телләрне һәм аларның диалектларын бер-берсеннән аера торган төп күренешләрнең таралышын күзәтүне төрки халыклары яшәгән бөтен территория күләмендә алып барырга кирәк, диделәр алар. Моның өчен исә гомумтөрки лингвистик атлас кирәк. Бары шундый атлас төзегәндә генә төрки телләр тарихына караган кайбер бәхәсле мәсьәләләрне чишәргә, ул телләрне төркемләргә һәм чагыштырмалы тарихи метод белән өйрәнергә мөмкинлек туачак. Бу атлас төрки халыкларның тарихын өйрәнү өчен дә бай материал бирәчәк.

Киңәшмәдә гомумтөрки лингвистик атласны әзерләү мәсьәләләренә караган докладлар белән күренекле профессорлардан Н. А. Баскаков һәм Э. В. Севортян чыкты. Әзербайҗан, үзбәк, төркмән, чуваш телләренең диалектологик атласларын төзү турында Р. А. Рөстәмов, М. И. Исламов (Баку), Б. Җ. Җураев (Ташкент), Р. Бердыев (Ашхабад) һәм Л. П. Сергеев (Чабаксар) иптәшләр сөйләде.

Атлас төзү Бөтенсоюз күләмендә алып барылырга тиешле эш итеп билгеләнде. Атлас төзүгә әзерлек һәм оештыру эшләрен алып бару өчен Әзербайҗан ССР Фәннәр академиясе академигы М. Ш. Ширалиев председательлегендә оештыру комитеты төзелде. Комитетка күренекле профессорлар һәм төрле өлкәләрдә яшәүче тюркологларның вәкилләре дә кертелде.

Киңәшмәдә тикшерелгән әһәмиятле мәсьәләләрнең икенчесе — төрки телләрнең диалектологик сүзлекләрен төзү.

Филология фәннәре докторы Ф. А. Абдуллаев (Ташкент), К. М. Гасанов, Б. М. Тагиев (Баку), Н. Х. Максутоваларның (Уфа) докладларында диалектологик сүзлек төзү принциплары яктыртылган иде.

Тарихи диалектология мәсьәләләренә караган докладлар белән Төркмәнстан ССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты З. Б. Мухаметова, әзербайҗан тел белгече М. Ш. Рагимов, Г. Ф. Благова (Мәскәү) һәм Х. Д. Данияров (Сәмәрканд), А. А. Дарбееваларның (Мәскәү) төрки тел мәсьәләләренә багышланган докладлары кызыксыну белән тыңланды. Польша Фәннәр академиясе академигы А. А. Зайчонковский, төрки тел истәлеге !Мукаддимат-аладәб» буенча алып барган тарихи эзләнүләре турында сөйләп, киләчәктәге эш планнары белән таныштырды. Венгрия Фәннәр академиясе профессоры Г. А. Хазаи төрек теленең тарихи диалектологиясенә караган мәсьәләләрне яңа, статистик алымнар белән өйрәнү тәҗрибәсенә тукталды.

Киңәшмәдә тагын, төрле республикаларда һәм өлкәләрдә алып барылган диалектологик эшләр һәм аларның фәнни нәтиҗәләре белән уртаклашу тәртибендә, Ә. Ишаев (Ташкент), Д. Амансарыев (Ашхабад), Д. Г. Тумашева (Казан), Ш. Сарыбаев, С. Омарбеков (Алма-Ата), Е. В. Гудиашвили (Тбилиси), Б. П. Тукан (Кишинев), М. С. Воронкин (Якутия), Ц. Б. Цындендамбаев (Улан-Удэ), Х. Д. Данияров (Сәмәрканд), Л. А. Покровская, Э. Р. Тенишев (Мәскәү) чыгышлары тыңланды. Докладлар һәм чыгышлар буенча фикер алышуда Ч. Җафаров, Ю. З. Ширвани (Баку), Е. И. Убрятова (Новосибирск), А. Кичиков (Калмык АССР), А. Җафарлы, (Кировобад) һ. б. катнашты.

Чираттагы VI региональ координацион киңәшмәне 1968 елда Ташкент шәһәрендә чакырырга карар кылынды.

**Д. ТУМАШЕВА,**
**Г. ЯКУПОВА.**




*Шәүкәт Галиев*

# СӨЗГӘК ҮГЕЗ МАҖАРАЛАРЫ

Көлке көлә килә,
Артыннан куа килә.
*Мәкаль*

## МӨГЕЗ ОЧЫ

Килде кене, алыйк кулны
Үгезнең мөгезеннән,
Әйләнсен әле дөньяны
Әйдә бер, үзе генә!

Нинди үгез? Каян килгән?
Үзебезнең якныкы.
Чыкты мөгез, үсте үгез,
Житте сөзәр вакыты!

Чынмы? Тәнкыйть үгеземе?
Баш ватма җавап эзләп,
Кайсы булса да бик усал,
Кайсы булса да — сөзгәк!

Сизәм, мондый үгезләрне
Кайберәүләр яратмый.
Мөгез булып, сөзмәгәч тә,
Нәрсәгә ул, я рабби!

Әйтмәсләр: дуласа аңа
Күренми дип, ак-кара —
Аклык — хаклыкка таянып
Караларны актара.

Үгез ачуының күпләр
Тәмен татыр шикелле,
Минем бурыч футболдагы
Комментатор шикелле...

## БЕРЕНЧЕ ӘКӘМӘТ

Түбән очтан үгез килә,
Килә ул җан-фәрманга.
Бераз алда Хөҗҗәт абзый
Элдертә бар дәрманга;

Әле ярый, шунысы уңай —
Буй яклары тәбәнәк,
Аяклары да күренми,
Килә туптай тәгәрәп.

Авылдашлар төрттереп тә,
Көлешеп тә калалар,
Болай да кызган канына
Мәзәк тозы салалар:

— Моның аяклары махсус
Чабарга көйләнгәндер!
— Алименттан кача-кача
Шулай шәп өйрәнгәндер!

Урам чирәмле чакта ук
Кияү булып таптаган,
Туптай кереп, уктай чыккан
Ул ничәмә капкадан!

Йөри биргән мут мәчедәй
Кәефле мырлап кына,
Кая барса да һаман шул
Бер җырын җырлап кына:

— Үкчәләрең
Кадак сыман,
Күкрәкләрең
Кабак сыман,

Син йөзәсең
Кораб сыман,
Мин йөримен
Карак сыман...

Синсез тормыш
Харап сыман,
Үтик бергә
Пар ат сыман!..

Җырлар иде әле дә ул,
Әгәр сулу капмаса,
Мөгез — сәнәкләрен сузып
Арттан үгез чапмаса...

Хатын саен йөри торгач,
Сукмаклары юл булган;
Эш хакында уйлау кая —
Бар шөгыле шул булган.

Йөргән ятимнәр арттырып,
Булса да башы такыр,
Уллары белән берrәттән
Туй ясый ул да, факыр.

Үгез соң, туйны туздырып
Тикмәгә димсең, куа —
«Гражданин, син минем белән
Ярышма!» — димәк була.

«Болельщиклар бармы?» — дисәк,
Китереп футбол шартын —
«Кайсы капкага керер?..» — дип,
Күзәтә тугыз хатын.

Харәм җефетләре икән,
Ул карап калучылар;
Алучысы алыр инде,
Ни уйлый баручылар?

Үгез аларга, үтешли,
Карый күзен акайтып,
Мөгаен, вәгъдә итәдер
Сөзәргә кире кайтып.

Хөҗҗәт ул, никах яңартып,
Гомер буе йөрмәкче,
Әле чапкан уңайга да
Тагын йортка кермәкче!

Яңа болдыр бикле булгач,
Искесенә тотынды,
Үз хатыны капкасына
Кереп кенә котылды...

Котылды? Котылмый торсын,
Хатын әллә җансызмы —
Уклау белән яра-яра
Кире бора сансызны.

Илле яшьлек яшь кияүгә
Килде бигрәк тыгызга!..
Судья да сызгыртыр инде,
Исәп җитте тугызга!

Болай булгач, имин генә
Котылмас Хөҗҗәт җаный —
Ауната-ауната үгез
Кабыргаларын саный.

Күреп туйдан соң биюен
Шулай мөгез көенә,
Тугыз хатын — тугыз көндәш
Тугыз яктан сөенә!..

## ИКЕНЧЕ ӘКӘМӘТ

Габделәнбәр хәзрәт көн дә
Кунычлы галош кия.
Шул галош, әнә, шәп тә шоп
Чалбар төбенә тия...

Үзе чаба янып-пешеп,
Үзе укый әгузе.
Әгузедән кодрәтлерәк
Бу замана үгезе!

Сүгенсәң шәт аңлар иде,
Каян белсен доганы?
Ә хәзрәт тирги Хөҗҗәтне:
— Ах, син, шайтан туганы!

Синең аркада юлыктым
Мин бу хәлгә, сабакы!
Очрасаң укытыр идем,
Никах түгел, сабакны...

Кычкырмак була үгезгә:
«Куарга бар ни хакың,
Укыдым ич мин Хөҗҗәтнең
Нибары биш никахын...

Мине бар да кыерсыта...
Тилермә, йөзең кара,
Хәлеңнән килсә, син әнә
Парторгны сөзеп кара!

Ул да бит, күргән чакларда
Күрмәмешкә салышты...»
Чү, кинәт хәзрәт ниндидер
Бер баскычкаябышты;

Ә баскыч, турыдан-туры
Күккә үк менә алып!
«Нужәли алла бар?!» диеп
Тора мулла таң калып...

Ни булса да, бу форсатны
Ычкындыру ярамый —
Үрмәләде алла колы
Алны-артны карамый.

Аннан-моннан, тәһарәтсез
Теләсә дә теләкне,
Әллә инде, чынлап торып,
Оҗмахка ук эләкте?..

Әйе, әнә җимешләре,
Пешкән ничек кызарып!
Кәс-кәс атлап бакчасында
Йөриләр хур кызлары!

Җитмешләп кенә дә түгел,
Сиксәнләп булыр мәгәр,
Хөҗҗәт керсә, өлеш чыкмас
Сайлап калмасаң әгәр...

Чү, күзләрем алдашамы —
Монда да машиналар!
Әллә җәннәт сельпосыннан
Продукты ташый алар?!

Әллә кызмача шайтаннар
Күрсәтә буташтырып —
Җәннәтне дә корганнармы
Механикалаштырып?

Тфү, тфү, ни күрәм мин,
Тәүбә әстәгъфирулла —
Ничек оҗмахка эләккән
Коммунист Гарифулла?!

Шунда барлык күренешләр
Гүя әйләнеп баса —
Биектән шулай күренгән
Безнең авыл лабаса!..

Үгез янгын каланчасын
Әнә ничек селкетә...
Һай, бу газиз башкайларны
Нинди афәтләр көтә?

(Аударыр, тәки аударыр,
Армаган, юк, армаган,
Әллә инде быел кыш та
Җилкәсе юкармаган?)

Габделәкбәр үрсәләнә,
Карана як-ягына,
Йолып алчы бәладән дип,
Алласына ялына.

Инде хәзер нишләргә?! — дип,
Тора хәзрәт баш кашып —
Җиргә дә төшәр әмәл юк,
Күккә дә булмый ашып...

Үгез әллә төбеннән үк
Кузгатты каланчаны —
Даң-доң! «Янгын!» дигән кебек
Яңгырап китте чаңы...

Авыл куба, давыл куба,
Бар да урамга чыккан,
Кайсы көрәк, кайсы күлмәк,
Кайсысы башын тоткан!..

Этләр чиный, тавык-үрдәк
Оча юлдан пырылдап,
Күрше авыл машинасы
Килеп җитә тырылдап.

Ни жары, ни пожары юк,
Ник шулчаклы кагалар?!
«Янгынчылар янмыймы?» дип,
Бар да шунда чабалар.

Кабаланып килгән шапка
Аңлашмый торгач әзрәк,
Танып алалар:
— Бәй, хәзрәт,
Ни кылана бу хәсрәт?

— Манараны юксынганмы?
— Ә бит заманасында
Үзе кисешкән иде ич
Мәчет манарасын да!

— Менгәндер ул эче пошып
Дин тотучылар азга!
— Пожар диеп чаң какмаса,
Кем йөрсен соң намазга!

Күккә түгел, җиргә карап
Ялвара Габделәкбәр:
— Унбиш тәүлеккә дә риза,
Чуртсним — аллаһәкбәр;

Тик моннан гына төшим дә,
Тик үгезгә бирмәгез!..
«Акылың алтын икән!» дип,
Көлешәбез җирдә без;

Сизә мулла, котылу юк
Үгезнең хөкеменнән,
Төшкәч тик бер нәрсә сорый
Динсезләр төркеменнән:

— Җәмәгать... чалбарны гына
Чыгыймчы алыштырып,
Тәһарәтне бозып ләгыйн
Куйган бит ялгыштырып...

Үгез үгезлеген итте,
Өркетеп аңын алды,
Элеп алды, селкеп салды,
Хәзрәтнең җанын алды;

Сикертте дә үрле-кырлы,
Йөгертте әрле-бирле,
«Үгезе билләһи...» диеп
Укый ул шуннан бирле!..

...Уяна да иң соңыннан
Янгынчыбыз Мурашов:
— Нигә шаулаштыгыз? — диеп
Йөри шунда сорашып...

## ӨЧЕНЧЕ ӘКӘМӘТ

Бик зарыгып торган идек,
Килче, диеп, кил дә кил —
Ярдәмгә килде колхозга
Иптәш Бәйрәмов Вәкил.

Килү-килүенчә шәпләп
Акыл бирә башлады —
Җыен җыеп кайнар-кайнар
Речьләр сөйләп ташлады.

Җил тегермәне шикелле
Кулларын селкә-селкә,
Мәчеле сәгатьтәй ялт-йолт
Күзләрен йөртә-йөртә,

Ай-һай, малай, чая сөйли,
Авызына карата —
Без тыңларга яратабыз,
Ул сөйләргә ярата:

— «Киңәйтик тә җәелдерик!
Давай, давай, күтәрик!
Оештырыйк та көрәшик!
Давай, давай, үткәрик!»

Күр, ничек ансат икән ич —
Шуңа да баш җитмәгән!
Чакырулар аз булганга
Эш тә алга китмәгән...

Әйдәгез, Вәкил иптәштән
Сорыйк әле баш орып:
Күрсәтсен шәп киңәшләрен
Үзе эшкә ашырып!

Баш итеп сайлыйкчы үзен
Колхозның штабына —
Без дә бер янгырап карыйк
Өлкә масштабында!

Вәкил иптәш калды никтер
Ярты сүздә тотлыгып,
Тып-тын калып көтә идек,
Ник йөгерде ул торып?

Без тыңларга әзер идек,
Күнеккәннәр инде без.
Әллә каян килде-чыкты,
Эшне бозды бит үгез!

Килде-чыкты, куды-китте
Бөтен шартын китереп —
Фамилиясен дә сорамый,
Дөбер-шатыр иттереп!

Аякларың да телең күк
Шома икән, оратор,
Без бүтәнгә борыйк гәпне,
Чатор-чотыр чаба тор!

Очратканың бар идеме
Болай үгез куганын?
Җете кызылны күрдеме —
Җене чыга шул аның.

Әүвәл андый мөгезләләр
Түзә торган иде дә,
Дәрәҗәгә карап кына
Сөзә торган иде дә,

Заманалар үзгәрде шул,
Хәзергеләр бик кыю,
Кабынып киттеме, бетте —
Һич мөмкин түгел тыю!

Сөзсә инде, белеп сөзә,
Сөзә абайлап кына,
Нәкъ мена синең ишене
Арадан сайлап кына...

Портфелең — бозау тиресе,
Ахры шуңа ярсуы —
Мәрхүм малкайларны уйлап
Кабаргандыр ачуы.

Өстәвенә, башыңда да
Сары салам фуражка,
Бир безнең өлешне диме,
Калдыр диме фуражга?

Әллә «Давай!» диюеңнән
Туеп кына куамы,
Гаебе барга качадыр,
Диеп кенә куамы?

Ә без ул сүзне ошаттык,
Шуңа хуплап тик тордык —
Үгез сине сөзгән чакта
«Давай! Давай!» — дип тордык!

## ДҮРТЕНЧЕ ӘКӘМӘТ

Вәкил китте, ак юл аңа,
Шакир аннан ким түгел,
Хәтта Вәкил, бик күп яктан
Үзе аңа тиң түгел.

...Ул чакта бу күркәм сыйфат
Туры килгән бик таман —
Булган ич, сөйләшеп кенә
Яши торган шәп заман!..

Дөнья күргән авылдашлар
Бик зур киләчәк юрап,
Мондый әвәслеге белән
Китәр, дигәннәр, ерак!

Йоклаган чакта да теле
Кыймылдап тора икән,
Сүз әвәләп иреннәре
Мимылдап тора икән.

Шуңа аны күтәргәннәр,
Ә ул тырышып эшләгән:
Су эчкән дә сүз сөйләгән,
Трибунадан төшмәгән.

Ә беркөнне авылыбызны
Шакирсыз калдырганнар,
Безгә бик кулай кадр дип,
Районга алдырганнар.

Анда да озак тормаган,
Анда да тиз танылган,
Казан хәтле Казанга да
Чакыртучы табылган.

Кәнсәләр тормышы бит ул
Туктаусыз кайнап тора,
Шундый телгә осталарны
Өскәрәк сайлап тора...

Ә Казанда нотыгын да
Язып кына биргәннәр.
Цитаталар эзләп вакыт
Әрәм итмә, дигәннәр.

Махсус җирдә дәваланган,
Махсус җирдә яшәгән,
Махсус урында ял иткән,
Махсус төштә ашаган.

Торганнар аны һәрвакыт
Уңайга гына сыйпап,
Гомер иткән ул халыкны
Нотыклар белән сыйлап.

Дөнья — куласа, ул һаман
Әйләнә алга табан.
Җитте, сөйләүдән тыелып,
Эшләп күрсәтер заман!

Ә моңа ул өйрәнмәгән,
Трибуна — бар белгәне;
Техникасы да искергән,
Гел бер тел тегермәне...

Бүтән эшкә күчерделәр,
Булдыралмый — һөнәрсез.
(Тигәнәк сыман ябышып
Яшәгән бит ул әрсез!)

Күчергәләп рәт чыкмагач,
Калмагач бернинди ранг,
Үзебезгә кайтып төште
Әйтерсең лә бумеранг.

Өлкә дә шат, район да шат,
Хәзер алар котылды,
Ә Шапырҗан, иркенәеп,
Инде безгә тотынды.

Әмма дөнья күләмендә
Сайрап күнгән юртак тел,
Кайтып төшкәч авылда да
Табалмады уртак тел.

Халык та бит хәзер шундый,
Дәшми тормыйлар, каһәр,
Берсеннән-берсе чаялар,
Берсеннән-берсе зәһәр.

Ә Шакир, кая куйсаң да,
Үз туксанын туксанлый,
Регламентыңны да белми,
Сөйли бирә, тукталмый.

Тап булсаң хәтта урамда,
Төймәңне бора-бора,
Актыгын өзеп алганчы
Сөйләпме сөйләп тора!

Качыйм дисәң, арттан бара,
Калдырып азрак ара...
Бертуктаусыз ярма яра,
Тавышы колак яра.

Ул ярманы тавыклар да
Бетерә алмас чүпләп!
Ә менә болары, бәлкем,
Өлгерерләр, дип, җөпләп.

Шапырҗанны үрдәкләргә
Мөдир итеп куйдылар;
Бакылдауга ни мәшһүрләр,
Такылдаудан туйдылар!..

Шул рәвешле тагын күпме
Йөрер иде Шапырҗан,
Яңа эшкә күчерергә
Идарәбез чакырган.

Артта калган бер тармакка
Ярдәм дигән формада,
«Сүз бозау имезер», диеп,
Җибәргәннәр фермага.

Эшләп акласын әле бер
Сөйләп алган билетын —
Гомер буе тик ятырга
Түгел бит ул — бюллетень!

Нишләсен, киткән Шапырҗан,
Фермага барып кергән,
Мондыйларны күп күрдек дип,
Үгез сөзеп үтергән...

Күзе — йомык, тәне — суык,
Йөрәк күптән туктаган.
Сәгать теле кебек йөри —
Тик телдән җан чыкмаган!

«Бик вакытлы ычкынды» дип,
Мактагач мактаусын,
Чүт кенә өзелми калды
Озату тантанасы.

Тикмәгә генә селкенеп
Ятмаган икән теле —
«Җыелыш башландымени?» дип,
Сикереп торды тегеi..

Ярсып-ярсып сөйләп китте,
Тәмам үтте үзәккә.
(Бөкрене, ахры, чынлап та,
Кабер генә төзәтә);

Чыга күрмәсен дип тагын
Мондый шәп җирдән торып,
Куйдык бик зур хөрмәт белән
Өстенә таш бастырып.

## БИШЕНЧЕ ӘКӘМӘТ

Быел электр керттеләр —
Бөтен авыл тиенде.
— Ходай уттан аермасын! —
Дип картлар да сөенде.

Лично үзем мыекны да
Электр белән кырам.
Ә кайчак, сакал сыпырып,
Караңгыда утырам.

Бүген менә калдык-куйдык
Бөтенләй утсыз-нисез;
Сузылдык та яттык кичтән,
Сез моңа нәрсә дисез?

Эш бүленде, дип сукранып
Иртә ятсак без шулай,
Беләсеңме, берәүләргә
Караңгылык та уңай;

Туксан литр сөтне эчкән
Ферманың учетчигы.
Ничек эчкән? Сатып эчкән,
Вәт кычыткан чыпчыгы!

Күрше авыл буйдаклары
Кара айгыр җиккәннәр,
Айсылу дип, ялкау Хәйне
Ялгыш урлап киткәннәр...

Ут барда сварщик Каюм
Эретеп ябыштыра,
Хәзер читтә куныл йөри —
Йортларны ялгыштыра.

Күрше врач, теш дип телен
Суырган Сафураның,
Бураныннан котылдым, дип,
Шатлана ире аның.

Төннәр уза, монтер Мөнип
Исереп аунап ята,
Җилтерәтәбез җыйнаулап,
Кабыз дип, яхшы чакта!

Нәрсәдер җитми, ди, мертәт —
Пырубкымы, бөкеме;
Бөке генә өмет итми,
Төшенәбез төлкене...

Мөнип шундый, гадәтенчә
Мең вәгъдәләп мең алдый,
Лаякылда кая акыл —
Баганага меналмый!

Билгеле инде, әйтерсез,
Көн дә эчмәсен, диеп,
Без бит аны эчерәбез
Тизрәк эшләсен, диеп!

Ничек кенә тырышсак та
Һич рәте табылмады,
Монтеры да айнымады,
Уты да кабынмады.

...Беркөн кибет урамыннан
Тәгәрәп чыкты мичкә.
Мичкә икәнен дә аның
Абайлап алдык көчкә.

Мәгълүм түгел бу мичкәнең
Эчләрендә ни бары —
Бәлкем судыр, бәлкем сыра,
Ә бәлкем әле — дары!..

Үзе йөри торган мичкә
Уйлап чыгарганнармы?!
Иһи, салмыш агайларның
Эш җайлана аннары!

Чү, чыннан да, бер ягыннан
Ике аяк күренә,
Кем икәнлеге күренми,
Башын төрткән түренә!

Шул мизгелдә баганага
Бәрелде дә таралды —
Кыршаулары тәгәрәде,
Мөнибе генә калды...

Шешәдән имеп туймагач,
Мичкәгә күчкән икән,
Ятып-ятып эчкән, имеш,
Эченә төшкән икән.

Килеп җитте, үгез икән
Мичкәгә җан кертүче,
Мөнипле мичкәне шулай
Тәгәрәтеп йөртүче.

Мөгезен генә күрсәтте
Ул Мөнип багалмага —
Сизми дә калды монтерың
Менгәнен баганага!

Шаклар каттык, менде-китте
Тиен кебек тиз генә,
Лаякыл диген син аны —
Хәвефне бит сизенә!

Юк иде аягында да
Теге тимер «тырнагы» —
Үз тырнагын батыргандыр,
Ансын сорап тормадык...

Менгәч инде ни хәл итсен —
Бүтән чара калмады,
Мөгезләргә карый-карый
Чыбыкларны ялгады.

Рәхмәт укыйбыз үгезгә
Утка караган саен —
Хөрти иде безнең эшләр,
Ул да тапмаса җаен.

*(Ахыры бар.)*

## УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

# ТАГЫН ДА ЯКТЫРАК ЯНСЫН!

## Укучыларыбыз тәкъдим итә

Киләчәктә «Казан утлары»ның сыйфатын тагын да яхшырту теләге белән, журналның узган елгы тугызынчы санында редакция укучыларга түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итеп, алардан үзләренең журнал турындагы фикерләрен һәм тәкъдимнәрен язып җибәрүләрен үтенгән иде:

1. «Казан утлары»н («Совет әдәбияты»н) күптән укып киләсезме? Журналны яздырып аласызмы, әллә китапханәләрдән алып укыйсызмы?

2. Соңгы ике елда журналда чыккан материаллардан (проза, поэзия, әдәби тәнкыйть, очерклар һ. б.) кайсылары сезгә күбрәк ошады?

3. Нинди әйберләр сезгә ошамады һәм ни өчен?

4. Киләчәктә «Казан утлары» журналы битләрендә нинди материаллар укырга, нинди темалар яктыртылуын күрергә теләр идегез?

5. Журналның сыйфатын яхшырту буенча нинди тәкъдимнәрегез бар?

6. Профессиягез, яшегез.

Иң элек шуны әйтергә кирәк: әлеге сорауларга җавап бирүдә журнал укучылары бик актив катнаштылар, редакциягә йөзләрчә хат килде. Хатлар авторларының барысы да «Казан утлары»н яратып, кызыксынып укуларын әйткәннәр.

«Мин,— дип яза, мәсәлән, Р. НУРИЕВА республикабызның Тәкәнеш районыннан,— «Казан утлары»н бик сагынып, көтеп алам. Ул килер көннәр якынлашкач, сөенеч буласын сизеп, йөрәк алдан ук җилкенеп-җилкенеп тибә башлый. Журнал килгәч, аны, бик зур хәзинәдәй күреп, почта ящигыннан ипләп кенә алам да, күкрәгемә кысып, йөгереп өйгә керәм. Ләкин укырга тотынмыйм әле. Соңыннан мине борчып, фикерләремне бүлдермәсеннәр өчен, башта өйдәге эшләремне тиз-тиз эшләргә тотынам. Шулай итеп «бөтен дөньяга» тынычлык урнаштыргач, журналны кулга алам да анда сурәтләнгән вакыйгалар дөньясына кереп чумам. Моңарчы булган күңелсез уйларым, хәсрәтләрем (дөнья булгач андый вакытлар да була) — барысы да онытыла. Аларга минем башта урын калмый хәзер. Ике-өч көн буена, ягъни журналны башыннан ахырына тикле бер сүзен дә калдырмыйча укып чыкканчы, әнә шундый рәхәт бер дөньяда яшим мин...»

Хатлардан күренгәнчә, безгә язган иптәшләрнең барысы да диярлек «Казан утлары»н үзләре яздырып алалар икән. Редакциягә килгән хатларга тагын бер нәрсә хас: журнал укучыларының күпчелеге А. Расихның «Ике буйдак», Г. Әпсәләмовның

«Ак чәчәкләр» һәм Ш. Маннурның «Муса» романнарын аеруча яратып укуларын хәбәр иткәннәр.

Шул ук вакытта хат авторлары журналның сыйфатын яхшырту һәм аны тагын да кызыклырак итү өчен үзләренең тәкъдимнәрен һәм теләкләрен дә белдергәннәр. М. МАНСУРОВ (Саба районы, Т. Утар авылы), соңгы елларда журналда басылган әсәрләрнең күбесе шәһәр тормышын чагылдыруга багышланган булуын искәртеп үткәч, авыл тормышын, бигрәк тә, колхоз җитәкчеләрен, аларның үз эшләренә, колхозчыларга мөнәсәбәтен ачык һәм тирән итеп сурәтләгән романнарны, повестьларны һәм хикәяләрне күбрәк урнаштырырга тәкъдим итә. Ул хаклы, әлбәттә. Чыннан да, безнең әдипләребезнең берсе дә хәзерге колхоз тормышын һәм кешеләрен калку итеп, бөтен катлаулылыгы белән чагылдырган әсәр язганнары юк әле. Шулай итеп, бу мәсьәләдә эш язучыларга кайтып кала. Әгәр колхоз тормышы турында әйбәт итеп язылган әсәрләр булса — редакция аларны бик теләп басып чыгарырга әзер.

Березники шәһәрендә яшәүче С. ЗӘЙНЕТДИНОВА һәм А. НӘБИУЛЛИН (Кировск шәһәре) журналда сатира һәм юмор әсәрләренең бик аз һәм сирәк басылуы турында язалар. Шул ук фикерне башка укучылар да хәбәр иткәннәр. Зәйнетдинова, Нәбиуллин һәм алар фикеренә кушылучы бик күп укучыларның, шул исәптән редакциянең дә, бу теләген язучыларыбыз искә алырлар, киләчәктә сатира һәм юмор әсәрләрен күбрәк иҗат итәрләр дип ышанасы килә.

Алай бик үк еш булмаса да, редакция журналда драма әсәрләрен дә урнаштырып килә иде. Күрәсең, алар гына укучыларның таләбен канәгатьләндереп җиткерә алмый торгандыр.

«Без,— дип яза СУНИНОВ ГИБАДУЛЛА (Новосибирск өлкәсе, Госман авылы),— Татарстаннан читтә яшибез. Татар китаплары юк бездә, килеп җитми алар монда. Татарча язылган пьесаларны сәхнәдә куярга бик теләсәк тә, китаплар булмагач, аларны һич тә таба алмыйбыз. Шуңа күрә сездән үтенәбез: журналыгызда авыл сәхнәләрендә уйнарлык берәр-икешәр пәрдәле драма әсәрләрен ешрак бастырсагыз икән». Н. МӨБИНОВА (Куйбышев өлкәсе, Ново Бритовка авылы), Х. ШӘЙХЕТДИНОВ (Караганда өлкәсе, Абай шәһәре), И. ЗӘЕТОВ (Караганда өлкәсе, Джезказган шәһәре), Б. ХӨСНЕТДИНОВА (Азнакай районы, Вахитов исемендәге совхоз), И. ГАЛИМОВ (Актаныш районы, Яңа Богады авылы) һәм башка иптәшләр дә журналда кечкенә күләмле драма әсәрләрен күбрәк урнаштырырга тәкъдим итәләр.

М. САЛАХОВ (Буа районы, Мещеряки авылы) рәсем сәнгате һәм Татарстан художниклары турындагы материалларга да киләчәктә күбрәк урын бирелүен үтенә.

Р. ХӘЛИЛОВ (Пермь өлкәсе, Уинск авылы) киләчәктә өлкән язучыларыбызның иҗат практикалары турындагы мәкаләләрне журналда урнаштырып баруны гамәлгә кертергә тәкъдим итә һәм моның укучылар өчен дә, язучылык эшендә каләм сынап караучы яшьләр өчен дә файдалы булачагын әйтә. С. САФИН (Оренбург өлкәсе, Озерки авылы) дингә каршы язылган материалларны, сугыш турындагы истәлекләрне күбрәк урнаштыруны үтенә. Әле соңгы елларда гына генералларыбыздан Г. Сафиуллинның «Җиңү юллары буйлап» Ф. Булатовның «Генерал язмалары» исемле зур күләмле истәлекләре һәм алардан тыш та кайбер сугыш чоры турындагы материалларның журналда басылып чыгуын искә алсак, бу өлкәдә укучыларыбыз үпкәләрлек эш юк кебек. Ә менә диннең асылын ачып салырлык җитди материаллар, чыннан да, журналда моңарчы җитәрлек булмады диярлек. Әнә шул кимчелекне искә алып, редакция журналыбызның шушы санынннан Г. Гобәйнең «Коръән серләре» исемле повестын урнаштыра башлады.

Күп кенә укучылар журналның «Казан утлары» исеме белән басыла башлавын да бик хуп күрәләр һәм, 1965 елда аның аеруча кызыклы, күп төрле материалларга бай булып чыга башлавын билгеләп үтү белән бергә, киләчәктә тагын да яхшыруын телиләр. «Казан утлары» тагын да яктырак янсын! диләр алар.

Укучыларыбыздан килгән хатлардагы игътибарга лаеклы фикерләр нигездә менә шулар, һәм алар эш барышында искә алыныр.

Үзләренең тәкъдимнәрен, журнал турындагы фикерләрен язып җибәргән барлык иптәшләргә дә редакция чын күңелдән рәхмәт белдерә.

# Хатлардан юллар

«Казан утлары»н мин 1932 елдан бирле күзәтеп барам. Кайсы елны яздырып, кайсы елны киосктан яки китапханәләрдән алып укыйм.

Журналны алгач та эчтәлеген карап чыгам. Яраткан авторларымнан Г. Афзал, Ш. Галиев шигырьләрен эзлим. Журналның соңгы номерында яшьләрдән өметлеләре күренә (№ 10).

«Ак чәчәкләр»не үтереп мактыйлар, ә минемчә ул уртача гына тәэсир итә. Әйбәт җире күп, булмаганда ялгана.

Укучы буларак, журнал битләрендә сәнгать турындагы материалның күбрәк бирелүен теләр идем. Сәнгать «Казан утлары»нда болай үги бала булып кына яши төсле. Моның белән килешәсе килми.

Тагын хәзерге вакытта исемнәре югалган авторларның язмышы, әсәрләре турында (Г. Рәхим, С. Сүнчәләй, М. Галәү, «Дим буе»ның авторы һ. б.) искә алып киту дә ярар иде. Алар үз заманында әдәбиятка азмы-күпме хезмәт иткән кешеләр.

Журналда урнаштырыла торган материалларның төрле, бай, бәхәсле булуы да кирәк. Югыйсә бер сызык сызылган — барыла да барыла. Дәверебез дулкын-дулкын, ә әдәби хәрәкәтебез талгынрак тоела.

Авторларның рәсемнәре, тарихи фотолар, художник язмалары, юл язмалары, истәлекләр, хатлар, юмор-сатира битләре күбрәк булсын иде. Кирәк алар.

ХӘЛӘПОВ К.
Әлмәт шәһәре.

* * *

Мин, Сафина Мәрзия, сезнең журналны 1959 елдан бирле яздырып алып, яратып укып киләм. Г. Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше», «Ак чәчәкләр» романнарын, Ф. Хөснинең «Утызынчы ел» романын аеруча яратып укыдым. Ш. Галиев шигырьләре дә бик ошый миңа.

Мин 1941 елдан бирле Казагыстанда яшим, шунлыктан кайбер татар сүзләрен оныта да башлаган идем инде. Ә менә сезнең журналны алып укый башлагач, яңадан тугандай булдым, яңадан саф татарча сөйләшергә өйрәндем. Мин татар укучысы өчен «Казан утлары»ннан яхшырак журнал юктыр дип уйлыйм. Хәер, бер мин генә түгел, минем белән яшәүче, бу хатка кул куючы башка иптәшләрем дә бик яратып укыйлар аны. Мин укып чыккан көнне үк, иптәшләрем аны алып китәләр дә чиратлап, кулдан-кулга йөртеп укырга тотыналар. Безнең якларга татар китаплары килеп җитмәгәнлектән, татарча китап укырга тилмереп торучылар күп монда. Казагыстанда яшәсәк тә, без үзебезнең Татарстан сәнгате һәм культурасы белән кызыксынып барабыз, аның үсешенә сөенәбез, горурланабыз. «Казан утлары»нда басылган әсәрләрне укыганда без үзебезне туганнарыбыз арасында йөргән кебек хис итәбез. Хәзер Ш. Маннурның «Муса» романын бик кызыксынып укыйбыз. Журналның һәр санын түземсезлек белән көтеп алабыз.

САФИНА М.
МУКТЫБАЕВА Н.
НАСИРОВА Н.
АБРАХМАНОВА М.
Целиноград өлкәсе,
Ак Күл станциясе.

* * *

Журналыгызның 1965 елгы 9 нчы санында басылган сорауларны укыгач, мин дә үз уй-фикерләремне язарга булдым.

«Казан утлары»н («Совет әдәбияты»н) мин 1950 елдан бирле укып киләм. 1960 елга кадәр авыл китапханәсеннән алып укый идем, аннары, эшли башлагач, үзем язылып ала башладым.

Дөресен генә әйткәндә, журналда басылып килгән барлык жанр әсәрләре дә ошый миңа. Анда басылган барлык материалларны да бик яратып укыйм. Ләкин минем аеруча яраткан язучым бар. Ул — Әмирхан Еники. Аның әсәрләре мине бик дулкынландыра. Мин аны татар язучылары арасында иң талантлысы дип саныйм. Дөрес, аның зур полотнолы романнар иҗат иткәне юк әле. Әмма ничек әйбәт аның «Рәшә» һәм «Саз чәчәге» исемле повестьлары! Повестьлар язу белән бергә, ул даими рәвештә «Азат хатын» журналында да бик әйбәт хикәяләр бастырып килә. Аның әсәрләренең кайсысын укыганда да күздән яшь чыга, кемнәргәдер каты нәфрәт туа; ә кайберләрен укыганда, авыз колакка җитә. Дөресен әйтим: бик ышандыручан була аның әсәрләре. Аның хикәяләре арасында романга алыштыргысызлары бар! Менә талантлы язучы ичмаса ул!

Мин редакциядән Әмирхан Еники әсәрләрен журналда мөмкин кадәр ешрак бастыруны үтенер идем.

Ф. Хөснинең «Минем тәрәзәләрем» повестен иртә язылган әсәр дип әйтәсем килми, әмма аны Г. Галиевның «Хикәя турында хикәя»се формасындарак язарга иде. Х. Туфанның томанлы (минем өчен) тәрәзәләрен укыйсы иде. Аның иҗат портретын укыганда фаҗигале тормышына шаккаткан идем. Озак көттермәсә ярый инде.

Шагыйрьләрдән һәммәсен дә яратып укыйм. Миңа Ә. Баяновның «Сез аңларсыз мине» исемле поэмасы бик тәэсир итте.

Дөрес, журналны бераз калынайттыгыз, яңадан да калынайтып булмасмы. Моннан укучылар да, язучылар да отар гына иде.

ЗАҺИТОВ Ф.,
Воткинскгэсстрой
механизаторы.


# ЛЕ КОРБЮЗЬЕ ВАФАТ

Шундый кешеләр була: алар синең күңелеңдә тирән хөрмәт, гыйззәтләү тойгысы тудыралар, кадерлисең кидә, аларга бағынасың. Миллиардлаган кешелек дөньясында маяк булып нурланган, үзенә караткан шундый кешеләрнең безнең арада яшәгәнлеге белән горурланасың, алар сине җилкендерә, күңелгә шатлык бирә, аңында ашкыну, кыю өметләр тудыра, үзеңнең дә, шулар кебек үк, кешелеккә, халыкка зур хезмәт күрсәтәсең килә.

Узган ел августның соңгы көннәрендә Парижда вафат булган Ле Корбюзье шундыйлардан иде. XX гасырның беренче чирегендә сынлы сәнгать күгендә калкып, бөтен җир йөзенең төзү-архитектура сәнгатенә олуг йогынты ясаган, үзенең сынлы сәнгать мәйданындагы әсәрләре белән дөнья күләмендә дан тоткан бу останы — кешеләргә уңайлы, матур көнкүреш ясау өчен тыйлыкмастан көрәшкән сәнгатьчене — искә алып китү изге бурычыбыздыр.

Ле Корбюзье кушаматы белән танылган, сәнгатьтәшләре, дуслары арасында үзсенеп, садәләштереп «Корбу» диеп кенә аталган Шарль Эдуард Жаннере 1887 елда Швейцариядә дөньяга килә. 1910 елларда ул Парижга күчеп килә һәм 1924 елда үзенең карендәше Пьер Жаннере белән бер ательеда эшли башлый. Бу ательега Ле Корбюзье җиңел аяк белән керә. Тиздән монда шулай ук бөтен дөньяга танылган алдынгы архитекторлардан Оснар Нимейер һәм Жозе Люи Сертекс тә хезмәт итә башлыйлар. Икесе дә азатлык, халык бәхете өчен көрәшүчеләр: беренчесе 1933 елны Германиядән, Гитлер режимыннан качып котылган; икенчесе Франко Испаниясеннән качып киткән. Боларның әсәрләренә Ле Корбюзье принципларының йогынты ясавы ачык сизелә.

Ле Корбюзьенең төзүчелек сәнгатендә тоткан принциплары, ясаган биналарыннан башка, матбугатта чыккан әсәрләрендә ачыкланган. Шул төп фикерләрен тормышка ашыру өчен ул гомер буе көрәш алып бара. Ле Корбюзьенең ачык, аңлаешлы төзү концепциясе, новаторлыгы тиз арада бөтен җир йөзенә таралып, бигрәк тә, яшь буын төзүчеләрнең мәхәббәтен казана. «Юманите» газетасының Ле Корбюзьенең вафатына багышланган санындагы мәкаләләрнең «Безнең өчен яшь коммунист архитекторлар...» дип башланган берсендә мондый сүзләр бар: «Әгәр без, яшь коммунист архитекторлар, Ле Корбюзьенең доктриналарындагы кайбер кирәгеннән артык күпертелгән урыннарны аера алсак, сәнгатьтә яңалыкны үстерү өчен ул безнең үрнәк итеп тотарлык остазыбыздыр...» һәм, чыннан да, хәзер җир йөзендә Ле Корбюзьенең хезмәтен тәкъдир итмәгән, аның иҗаты белән кызыксынмаган төзүчеләрне уйга китерү мөмкин түгел. Үзебезнең Казаныбызны алсак та, яңа корылышларыбызның төзелешендә Ле Корбюзьенең йогынтысы барлыгын инкарь итеп булмый. Ле Корбюзье, төзелештә гасырлар буе хөкем сөргән борынгы традицияләрне кире кагып, яңа заман, яңа көнкүреш таләпләрен күз алдында тотып, яңа техника байлыклары кушканча яңа төзү рәвешләре эзли, гомер буе эзләнә. Аның шул юлдагы ачыш-табышлары җир йөзенең һәр төшендә эшкәртелә. Ле Корбюзье төзегән биналар дөньяның һәр биш кыйтгасында бар. Мәскәүдәге ЦСУ бинасы шундыйларның берсе, аны «Корбюзье өе» дип йөртәләр. Ул безнең илдә кору техникасы бик рудиментар заманда, 1930 елларда салынган. Шул ук заманнарда «Советлар сарае»на проект ясау өчен дөньякүләм конкурс үткәрелеп, Ле Корбюзье проекты өстен чыга, беренчелекне ала. Ләкин «культ дәверендә» төзелеш борынгы традицияләргә авыша, неоклассицизм, дөресрәге, псевдоклассицизм алымнары белән ясалган биналар модага керә, бер кавымга Корбюзье онытылып кала.



Нью-Йорк. Ле Корбюзье проекты буенча салынган БМО бинасы.

Ләкин тимер-бетон һәм пыяла заманы яңа техника һәм формалар таләп итте. Бу юлда Ле Корбюзьенең эзләнүләре, базык фикер һәм иҗади кыюлык белән ясаган проектлары кайвакыт хәйран калырлык табышлар белән нәтиҗәләнде. Аның шәкертләреннән берсе Роланд Добруль: «Ул иске тузанны безнең аңыбыздан сыпырып төкте», — ди. Добрульнең «иске тузан» дигәне — хәзерге заман шартлары белән исәпләшмәстән, гасырлар буенча традиция, йола булып килгән борынгы грек храмнарын, борынгы рома сарайларын үрнәк итеп ясалган төзелеш рәвеше, архитектура стиле. Бу борынгы төзү сәнгате архитектура академияләрендә схоластик рәвештә укытылып килде. Парижның уртасында, Франциянең нәфис сәнгать академиясендә иске фикерле, иске йолалы төзүче академиклар үзләренең авторитетлары белән һәртөрле яңа карашны, новаторлыкны басып торган бер заманда Ле Корбюзьегә яшьләрнең аңыннан «искелек тузанын» сыпырып түгү, үзенең радикал принципларын эшкәртүгә юл ачу җиңел булмагандыр. Ләкин Корбюзье, бирешмәс базыклык белән, реакцион ретроградлыкка, схоластикага каршы көрәшә. Ле Корбюзьенең төп фикере — кешенең яшәеше, көнкүреше өчен уңай торак, өй һәм калалар төзү. Кояш, үсемлек-куак, киң аралык — кала төзү өчен нигез материал. «Минем шәһәрләрем — куаклы шәһәрләр», — ди Корбюзье.

Корбюзье гомер буе яшәр өчен уңай, үсемлек-куаклар белән уралган һәм кояш нурлары белән мул нурланган шәһәр кору дәрте белән рухланган һәм үзенең практик хезмәтләрендә шул теләкләрен тормышка ашырырга тырышкан.

XIX гасырның ахырында, XX гасырның башында Корбюзьедән башка да яңа фикерле төзү осталары булган. Шулардан америкалы Франк Ллойд Райтны һәм башкаларны атарга мөмкин. Ләкин Райтның төземнәрендәге романтизм алымнары аның эшләренә иҗтимагый һәм техник проблемаларны эпохабыз кушканча хәл итәргә мөмкинлек бирми. Корбюзьенең реализмы, эпохабыз таләпләренә җавап бирерлек төзү принциплары соңгы 20—30 ел эчендә җир йөзенең күп төшләрендә зәмин таба. Алжирда, Һиндстанда, Стокгольмда, Антверпен, Барселона, Рио-де-Жанейро, Буэнос-Айрес, Нью-Йорк, Мәскәү, Париж һәм башка илләр, олуг калаларда Ле Корбюзье проектлары белән корылган биналарның булуын әйтеп китү житсә кирәк.

Парижны иң соңыннан атадык. Шәмнең нуры төбенә төшми, диләр. Ле Корбюзье дә, Франциядән бигрәк, башка илләрдә игътибар казанган. Олуг останың якын дусларыннан Жан Никола «Юманите» газетасының Ле Корбюзье вафатына багышланган санындагы мәкаләсендә: «Франциянең өлеше кызганыч, күп чит ил университетлары тарафыннан дипломланган, армый-талмый иҗат иткән бу оста Франция тарафыннан иҗади сәләтенә, осталыгына лаек, тиң булган бер эш тапшырылмастан вафат», — дип көенеп язды.

Ле Корбюзье сынлы сәнгатьнең янәшә төрләре белән дә шөгыльләнә. 1961 елны Мәскәүдә үткәрелгән индустрия һәм сәнгать күргәзмәсендә аның эшләреннән берничә келәм һәм декоратив тукымалар бар иде. Архитектура сәнгатендәге кебек үк, аның бу эшләрендә дә классик садәлек һәм ачыклык күренә. 1963 елда җир шарының ике ягында ике күргәзмә үткәрелә. Парижда, беренче мәртәбә буларак, аның бөтен эшлә-

рен җыйган күргәзмә оештырыла. Монда ул төзегән биналарның фотолары, басма әсәрләреннән парчалар, макетлар, картиналар, скульптуралар, декоратив тукымалар, келәмнәр һәм башка әсәрләре җыйналган була. Икенчесе — Нью-Йоркта. Бу күргәзмәдә Корбюзьенең икенче дөнья сугышыннан соң Һиндстан һәм Европада төзегән биналарының бөтен комплексы тулы рәвештә тамашага куела һәм бу зур сәнгатьченең иҗаты бәя ала.

Бу мәкаләчекне илебезнең күренекле архитекторларыннан Н. Коллинең «Правда» газетасында басылган мәкаләсеннән бер өзек белән тәмамлыйсы килә:

«Сокланырлык, әмма катлаулы һәм тигәнәкле-чәнечкеле булды архитектор Ле Корбюзьенең иҗат юлы. Бу юл тирән һәм самими эзләнүләр, кешенең рәхәте өчен иң яхшы төзү чараларын куллану юлы. Ул һәр эшнең кыйммәтен кешегә файдалы булуы белән үлчи иде. Бу юл төзү сәнгате остасының кешелек дөньясы алдындагы җаваплылыгын тулы аңлау, ялланмас принципиальлек, бервакытта да компромисска разый булмаучы оста юлы иде».

Сәнгатьчегә моннан да лаек мактау булуы мөмкин түгел.

*БАКЫЙ УРМАНЧЫ.*
Казан, 10 сентябрь, 1965 ел.

■ ■ ■

# ӘДӘБИЯТ һӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

### В. И. УЛЬЯНОВ-ЛЕНИН ТУРЫНДА ФИЛЬМ

Яшь Ленинның Сембер, Казан һәм Самарадагы тормышын, аның революцион көрәш юлына басуын чагылдырачак яңа фильм эшләнә. Аны Ленинградның фәнни-популяр фильмнар студиясендә режиссер Борис Волкович һәм оператор Юрий Артамонов төшерә. Сценариен кинодраматург Лев Горин язган. Фильм В. И. Ленин тормышының 1886 елдан 1893 елга кадәрге чорын, ягъни гимназиянең 9 нчы классында укыган вакытыннан алып, Петербургка күчүенә кадәрге вакытны үз эченә ала.

Экранда безнең заман яшьләре дә күрсәтелә: Володя Ульянов һәйкәле куелган бакчада Казан студентлары. Станок янында, имтиханда, күңелле кичләрдә — Ленинград яшьләре, Питер пролетариаты варислары.

Әсәрнең бүгенге көн белән элемтәсе аны күңелгә якын итә, юлбашчының үзебез белән бергә һаман да яшәгән төсле хис итәсең.

### ЛЕНИНГРАДТА ӘДӘБИЯТ АТНАЛЫГЫ

Узган елның 21—29 октябрендә Ленинградта татар әдәбияты атналыгы булып узды. Шул уңай белән барган бригада составында язучылардан Мирсәй Әмир, Габдрахман Әпсәләмов, Гариф Гобәй, Әмирхан Еники, шагыйрьләрдән Сибгат Хәким, Әхмәт Ерикәй, Мөхәммәт Садри, Әнвәр Давыдов, С. Сөләйманова, Р. Кутуй, тәнкыйтьчеләр Гази Кашшаф, Рафаэль Мостафин, драматург Риза Ишморат, Татарстанның халык артисткасы Рәнсә Билялова, филармония артисты Эмиль Җәләлетдинов, үзешчән композитор Фәтхерахман Әхмәдиев һәм пианистка Назнинә Сабитовская иптәшләр бар иде.

Татар әдәбияты һәм сәнгате вәкилләрен Ленинград кешеләре һәр очрашу вакытында җылы каршыладылар. Әдәбият сөючеләр үзләренең фикерләрен, теләкләрен, художестволы сүзгә мәхәббәтләрен һәр очрашуда әйтеп калдылар. Безнең язучыларыбызның әсәрләре Ленинград дәүләт филармониясенең концертлар залында, Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәдә, Капранов исемендәге Культура йортында, Киров исемендәге — элекке Путилов заводында, Дзержинский исемендәге Культура йортында һәм башка урыннарда яңгырады. Кронштадт шәһәрендә очрашулар Флот офицерлары йортында һәм хәрби частьта үткәрелде.

М. В. Ломоносов исемендәге китапханәдә уздырылган укучылар конференциясе Г. Әпсәләмов романнарына, М. Ю. Лермонтов исемендәге китапханәдә булган конференция Г. Әпсәләмов әсәрләренә һәм М. Әмирнең «Саф күңел» романына багышланды.

С. Хәким, Р. Мостафин, артистлар белән берлектә, телевидение аша чыгыш ясадылар. Г. Кашшаф 317 нче мәктәп, Г. Гобәй 320 нче мәктәп укучылары белән очраштылар.

Саубуллашу кичәсе Муса Җәлил поэзиясе һәм батырлыгына багышланды.

Язучылар революция шәһәренең күп кенә тарихи урыннарында, шул җөмләдән, Эрмитажда, Рус музеенда, Смольныйда булдылар, Петергоф, Пушкино шәһәрләренә һәм атаклы Разливка барып килделәр.

Әдәби кичәләрдә Ленинград шагыйрьләре һәм язучылары Михаил Дудин, Даниил Гранин, Бронислав Кежун, Леонид Хаустов, Риза Халид, Елена Вечтомова, Олег Шестинский, Ариф Сапаров, Майя Борисова, Глеб Пагирев, Владимир Торопыгин һәм башкалар катнашты.

Ленинградның өлкә һәм шәһәр газеталарында татар шагыйрьләренең рус теленә тәрҗемә ителгән шигырьләре, информация мәкаләләре басылып чыкты.

### АВЫЛДА ОЧРАШУЛАР

Республикабызның Буа районында үткәрелгән әдәбият атналыгы 29 октябрь көнне район Культура йортындагы очрашу белән башланды. Анда А. Расих, А. Әхмәт, Г. Хуҗи, А. Гыйләҗев, Б. Камалов, И. Юзиев, Ш. Галиев, А. Сәләхетдинов, Р. Гатауллин чыгыш ясадылар. Сүз әдәби-

ятыбыз, язучыларның иҗатлары турында барды. Әдипләр үзләренең әсәрләрен укыдылар.

Иртәгесен язучылар, ике төркемгә бүленеп, район колхозларына чыгып киттеләр. А. Расих, А. Әхмәт, Г. Хуҗи, А. Гыйләҗев, Ш. Галиев XXII партсъезд исемендәге, «Искра», «Волга», «Коммунизм», «Татарстан» колхозы членнары белән һәм Иске Шайморза унберьеллык, Иске Тинчәле, Иске Суыксу сигезьеллык, Вахитов исемендәге унберьеллык мәктәп укучылары белән очраштылар.

И. Юзиев, Б. Камалов, А. Сәләхетдинов, Р. Гатауллин Янтуган, Әлших, Кайбыч, КулЧеркен авыл клубларында очрашулар үткәрделәр. Шулай ук Әлших, Кайбыч, Норлат сигезьеллык мәктәпләрендә дә булдылар.

Иске Суыксу авылы клубында 3 ноябрьдә йомгаклау кичәсе үткәрелде. КПСС райкомы секретарьлары Г. Усманов, Ф. Шәмгунов, райбашкарма председателе И. Нестеров, «Татарстан» колхозы рәисе Н. Сабирҗанов, Иске Суыксу мәктәбе директоры Г. Хәмидовлар да катнаштылар. Атналыкта катнашучыларга КПСС райкомы һәм райбашкарма исеменнән мактау язулары тапшырылды. Район газетасы әдәбият һәм сәнгать сәхифәсе бирде. Очрашуларда китап сәүдәсе оештырылып, язучылар автографлар бирделәр.

Очрашуларда укучылар үзләрен кызыксындырган бик күп сорауларга җаваплар алдылар, теләкләрен белдерделәр, кызыклы тәкъдимнәр керттеләр.

## ҖӘЛИЛ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Казандагы Ленин районының 26, 31 нче мәктәпләрендә Җәлил музее оештырылды, ә 26 нчы мәктәп каршында геройга бюст куелды.

Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулу уңае белән, сугыш ветераннары инициативасы буенча, шагыйрь хөрмәтенә Восстание мәйданында декоратив мемориаль-панно эшләнде. Монументның алгы ягында геройның рәсеме, астарак Алтын Йолдыз төшерелгән, сул якта ике кул: берсенең учы ачык, икенчесе нык йомарланган. Бу — дошманга нәфрәт билгесе, ә ачык кул һәм ромашка чәчәге тормышка мәхәббәт символын аңлата.

Аның икенче ягында — Моабит төрмәсендә язылган шигырьләр дәфтәре. Ул чәнечкеле кара тимер белән уратылган.

Декоратив мемориаль-панноның ике ягында да М. Җәлилнең шигырьләреннән өзекләр язылган һәм Ленин премиясе лауреаты медале ясалган. Һәйкәлнең авторлары — Казан художество училищесын тәмамлаган Василь Маликов һәм Рөстәм Кильдибеков.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Балалар язучысы Әминә Бикчәнтәева, Кукмара районына барып, Кукмара, Янил, Ядегәр урта мәктәпләрендә үзенең укучылары белән аңгәмәләр үткәрде, шигырьләрен укыды.

* * *

Шагыйрь Илдар Юзиев, яшь шагыйрьләрдән Касыйм Фәсәхов, Марзия Фәйзуллина, Роберт Әхмәтҗанов, Абдулла Сәләхетдинов Арча районында булдылар. Әдәби кичәләр һәм укучылар белән очрашып сөйләшүләр Арча педагогия училищесында, 2 нче номерлы урта мәктәптә, шулай ук китап магазинында үткәрелде.

* * *

Аяз Гыйләҗев Әлмәт шәһәренә барып кайтты. Анда Әлмәт күчмә театры драматургның «Көзге ачы җилләрдә» исемле пьесасы буенча эшләнгән спектакльнең премьерасын күрсәтте. Автор шул спектакльне карады һәм фикер алышуда катнашты.

Әсәрне Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, режиссер Габдулла Юсупов куйган.

* * *

Казанның Дербышки поселогы Культура сараендагы тематик очрашу «Совет властенең 50 еллыгына — язучылар» дип исемләнгән иде. Очрашуда язучылардан Г. Минский, А. Гумеров, Г. Бакиров, Г. Мөхәммәтшин, Ә. Баянов, М. Шәрифуллин, К. Фәсәхов катнашты. Сүз Дербышки поселогының кичәге көне һәм бүгенгесе, совет халкының рухи һәм материаль тормышында Октябрь социалистик революциясе тудырган тарихи үзгәрешләр, бөек җиңүләр турында барды. Бу хакта Г. Бакиров һәм А. Гумеров иптәшләр чыгыш ясадылар. Аннары лирик шигырьләр, юмористик хикәяләр һәм парчалар укылды.

* * *

Октябрь ахырында Лениногорск һәм Азнакай районнарында яшь һәм башлап язучылар өчен атналык семинар-консультацияләр үткәрелде. Индивидуаль семинарларда нефть ягында яшәүче авторларның хикәя, очерк һәм шигырьләре укып тикшерелде. Ахырдан йомгаклау җыелышлары үткәрелде. Семинарлар белән Әлмәт язучылары Р. Төхфәтуллин һәм Ә. Маликов җитәкчелек итте. Яшь авторларның әсәрләре газета һәм журналлар өчен сайлап алынды.

* * *

Бөгелмәдәге крайны өйрәнү музее, Бөек Октябрь революциясенең 50 еллыгы уңае белән, гражданнар сугышы ветераннарының, Бөгелмә-Әлмәт якларында Совет властен урнаштыруда актив катнашкан карт большевикларның истәлекләрен җыя башлады.

17 сентябрьдә Әлмәт шәһәренең беренче номерлы татар урта мәктәбендә үткәрелгән очрашуда җыелган материалларны тикшерү булды. Пенсионерлардан Шогаеп Рамазанов, Касыйм Насибуллин, Хасимә Мостафина һәм башкалар 1919—20 еллар һәм Әлмәттәге сәнәкчеләр вакыйгасы турында үзләренең язмаларын укыдылар, бик кызыклы фактлар сөйләделәр. Очрашуда Әлмәт

язучыларыннан Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин, Э. Мөэминова, Ә. Маликов катнашты. Алар җыелган материалга карата үзләренең фикерләрен әйттеләр, язмаларны әдәби яктан эшкәртү турында киңәшләр биреп чыгыш ясадылар. Мондый элемтә киләчәктә дәвам итәчәк.

* * *

Башкортстан АССРның Кырмыскалы район китапханәсендәге китап укучылар конференциясенең берсе язучы Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романына багышланды. Чыгыш ясаучылардан Әнисә Сиражетдинова, Мәликә Жданова һәм башка иптәшләр Гөлшәһидә, Әбүзәр абзый, Мансур, Фәтхәттәй кебек үзәк образлар турында, әсәрнең сюжеты һәм теле турында (Ф. Акчурина) сөйләделәр. Конференциядә катнашучылар китапханәче Ф. Ганиева, врач З. Сәгыйтова чыгышларын да яратып тыңладылар.

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР КИҢӘШМӘСЕ

Россия Федерациясенең җитмешкә якын яшь тәнкыйтьчесе күптән түгел Мәскәүнең «Юность» исемле гостиницасына киңәшмәгә җыелды. Аны «Молодая гвардия» журналы һәм РСФСР язучылар союзы правлениесенең тәнкыйть һәм әдәбият белеме комиссиясе оештырган иде. Киңәшмәгә Татарстаннан яшь тәнкыйтьчеләр Ф. Миңнуллин һәм Ф. Мусин барды.

«1963—1965 еллар әдәбиятында яшь замандаш», «Яшь прозаиклар иҗатында төп тенденцияләр», «Хәзерге яшь поэзиянең торышы», «Стиль проблемалары» дигән темаларга докладлар һәм белдерүләр белән тәнкыйтьче һәм әдәбият белгечләре Л. Якименко, Л. Крячков, В. Турбин, Н. Власенко һәм башка иптәшләр чыгыш ясады. Киңәшмә өч көн дәвам итте.

## УЧИЛИЩЕГА 70 ЯШЬ

Россиядәге иң өлкән уку йортларыннан берсе — Казан художество училищесы оештырылуга 70 ел тулды. Атаклы Репин, Суриков, Васнецов, Левитан, Коровин, Фешин, Шишкин һәм башка күренекле осталар башлаган бөек традицияләргә һәрвакыт тугры булган, иҗатта партиялелек һәм халыкчанлык принципларында нык торган бу мәктәп үзенең эшләү чорында бик күп сәләтле художниклар тәрбияләп чыгарды. Аларның күбесе — хәзер Татарстан рәсем, нәкыш сәнгате һәм графикасы вәкилләре. Исемнәре халыкка киң танылган художниклардан РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклеләре, дәүләт премиясе лауреатлары Х. Якупов, Л. Фәттахов, Татарстанның сәнгать эшлеклеләре Н. Кузнецов, С. Лывин, Ә. Нагаев һәм башкалар шул училищены тәмамлаганнар.

Казан шәһәр җәмәгатьчелеге узган елның 13 ноябрендә училище оештырылуга 70 ел тулуны тантаналы төстә билгеләп үтте.

## ЯҢА СИМФОНИЯ

СССРның халык артисты, композитор Нәҗип Җиһанов соңгы вакытта тагын бер зур әсәр — «Симфоник җырлар» исемле симфония иҗат итте. Әсәр алты бүлектән тора — «Рамай», «Авыл көе», «Такмак», «Бишек җыры», «Туган тел» һәм «Финал».

Татар дәүләт опера һәм балет театрында 12 ноябрь көнне Казан дәүләт консерваториясе студентлары оркестры симфонияне беренче тапкыр башкарды. Оркестрга РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Карелия АССРның халык артисты, профессор И. Э. Шерман җитәкчелек итте.

## «ДИМ БУЕНДА» ПРЕМЬЕРАСЫ

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры коллективы тамашачыларга Хөснул Вәлиуллинның драматург Хәй Вахит либреттосы буенча язган «Дим буенда» исемле лирик операсын сәхнәгә куйды. Спектакльнең дирижеры — композитор Алмаз Монасыйпов. Әсәрне театрның баш режиссеры Евгений Кушаков сәхнәләштергән. Декорацияләр ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе художник Әнвәр Нагаев тарафыннан эшләнгән.

Рольләрне башкаруда РСФСРның атказанган артисты В. Жарков, ТАССРның атказанган артисты И. Ишбүләков, артистлар Ф. Тимерова, А. Зайнуллин һәм башкалар катнаша.

## РӘХМӘТ ӘЙТӘЛӘР

Республика Халык иҗаты йортында яшь татар драматурглары семинарын Татарстан АССР Культура министрлыгы һәм Татарстан язучылары союзы правлениесе оештырган иде. Семинарда катнашучылар татар театры сәнгатенең күренекле эшлеклеләре, язучылар белән очраштылар, спектакльләр карадылар һәм алар буенча фикер алыштылар.

Очрашуларда һәм фикер алышуларда катнашкан сәнгать осталары, язучылар һәм драматурглардан Н. Исәнбәт, Б. Гыйззәт, Ш. Сарымсаков, Г. Галиев, А. Гыйләҗев, Х. Вахит, Х. Гобәйдуллин, З. Нури, Ә. Камал, Г. Шамуков, А. Әхмәдуллин, Г. Минский, А. Гумеров иптәшләргә Республика Халык иҗаты йорты дирекциясе рәхмәт белдерде.

## Х. ХИСМӘТУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Күренекле әдәбият галиме, тәнкыйтьче, филология фәннәре кандидаты Хәй Хисмәтуллинга 70 яшь тулды. СССР фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият, тарих институты һәм Татарстан язучылар союзы шул уңай белән әдәби кичә уздырдылар. Утырышка галимнәр, укытучылар, язучылар килгән иде. Алар галимне кайнар котладылар һәм киләчәк иҗатында тагын да зуррак уңышлар теләделәр.

# Зыя Ярмәки

Үзбәкстаннан кайгылы хәбәр алынды: Ферганә өлкәсенең Ташлак районында яшәгән татар шагыйре Зыя Ярмәки үлгән.

Зыя Ярмәкинең исеме һәм әсәрләре бүгенге киң катлау укучыларга аз таныш. Ә ул поэзия өлкәсендә күп еллар эшләгән һәм татар әдәбияты тарихына якты эз калдырган әдипләребездән берсе.

Зыя Шәйхи улы Насыйров (Зыя Ярмәки) 1887 елның 9 январенда элекке Самара губернасы, Богырыслан өлкәсе (хәзерге Куйбышев өлкәсе, Камышлы районы) Иске Ярмәк авылында туып үсә. Башта үз авылы мәктәбендә укыганнан соң, аны Чистай шәһәре мәдрәсәләренең берсенә илтәләр. Монда бераз «гыйлем өстәгәннән соң», ул, схоластика оясының тынчу атмосферасыннан туеп, шәкертләр хәрәкәтенә кушыла, Уфага китеп, андагы «Галия»дә укый башлый. Монда ул әдәбият белән таныша, үзе дә каләм көчен сынап карый. Ләкин тормыш шартлары, экономик кысынкылык аркасында үз авылына кайта һәм балалар укыту белән шөгыльләнә.

1909 елда «Шура» журналында Зыя Ярмәкинең «Өмет бетте!» исемле шигыре басыла. Анарда гади халыкның авыр һәм михнәт белән тулы тормышын үз күзе белән күреп, үз җилкәсендә татыган яшь шагыйрьнең тирән борчылуы гәүдәләнә. Бу шигырь җәмәгатьчелек фикерен үзенә тарта, яшь шагыйрьнең әсәрләре татар газета-журналлары битләрендә ешрак күренә башлый.

Яшь шагыйрь демократик караштагы әдипләр даирәсенә тартыла. 1912 елда басылган бер шигырендә ул:

Кер вә таплардан агардым мин хәзер бер кош кеби,
Ялтырарга уйлыймын күктә матур йолдыз кеби;
Күп авырлыкларга, әпкәй, түзде бәбкәң җилкәсе
Шул ачы яшьләр, әни, итте Тукайның иркәсе, — ди.

Чыннан да, татар шагыйре Тукай Зыя Ярмәкине үз итеп каршы ала.

Татар классик поэзиясен яхшы белгән һәм аның бай традициясендә тәрбияләнгән, халык иҗаты үрнәкләрендә иҗат иткән Зыя Ярмәки әсәрләре бик сирәк басылганнар. 1912 елда аның «Яшьлек дәртләре» һәм «Күрсәтәм», 1913 елда «Әдәбият гөлләре» һәм «Тойгыларым» исемнәре белән дүрт җыентыгы чыккан.

«Татар поэзиясе антологиясе»ндә Зыя Ярмәки иҗатына да урын бирелгән һәм аның әсәрләреннән үрнәк китерелгән. Боларга өстәп Татарстан китап нәшриятының быелгы планында карт шагыйрьнең сайланма шигырьләре җыентыгын чыгару күздә тотылганын әйтергә була.

Зыя Ярмәкинең тормыш юлы җиңел генә бармады. Ул озак вакытлар иҗат эшеннән аерылып та торды.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң ул яңадан укытучылык эшенә кайта һәм 1919—1926 елларда Иске Ярмәк авылында мәктәптә укыта, соңыннан китапханә мөдире, балалар йортында тәрбияче, волость башкарма комитетының загс мөдире булып эшли. 1932 елда ул, Үзбәкстанга күчеп килеп, мамык совхозында идарә секретаре һәм тәрҗемәче була. 1935 елда аны Ферганә өлкәсе, Ташлак районы хезмәт ияләре депутатлары Советына сайлыйлар һәм ул шул Советта 17 ел буе җаваплы секретарь һәм бүлек мөдире булып эшли. Совет аппаратында намус белән эшләвен һәм җирле кадрлар әзерләүдәге тырышлыгын искә алып, Үзбәкстан хөкүмәте Зыя Ярмәкине Үзбәкстан Верховный Советы Почет грамотасы белән бүләкли. Бөек Ватан сугышы елларында фидакарь хезмәтләре өчен ул «Хезмәттәге батырлык өчен» медале һәм Зур Ферганә каналын төзүдәге эшчәнлеге өчен «Зур Ферганә каналы» значогы белән бүләкләнә. 1953 елда ул пенсиягә чыкты һәм әдәби-иҗат эше белән күбрәк шөгыльләнә башлаган иде. Аның соңгы елларда язылган «Муса Җәлил», «Мин постта» һ. б. шигырьләре Зыя ага Ярмәкинең үзен һаман халык белән бергә итеп сизүен һәм иҗат ялкыны белән януын күрсәтәләр.

Яшьләр йөрәгендә тормыш кайный,
Карт йөрәгем шуңа сөенә,

— дип шатланып җырлаган патриот шагыйрь Зыя ага Ярмәкинең якты истәлеге күңелебездә озак еллар сакланыр.

*М. Гайнуллин, Н. Исәнбәт, Х. Туфан, Ә. Исхак, И. Рәми, Х. Хисмәтуллин, Г. Кашшаф, Ә. Еники, А. Шамов, Галә Ходаяров, Г. Әпсәләмов, Г. Минский, А. Гомәр, З. Бурнашева, М. Әмир, С. Хәким, Г. Бәшир, Ш. Маннур, Ә. Юныс, З. Нури, Г. Бакиров.*

## Алдагы саннарда:

*Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулуга багышланган материаллар:*

П. Хузангай, М. Дудин, С. Баттал, Х. Туфан, Х. Камалов, Г. Латыйп **шигырьләре.**

**М. Җәлил турында совет язучылары.**

Н. Юзиев, Г. Кашшаф, Р. Мостафин, Ф. Исхаков, Р. Таһиров, Ә. Кәримуллин мәкаләләре.

Б. Бикбай, Х. Максуд, Х. Салихов, С. Алишев истәлекләре.

*Проза әсәрләре, шигырьләр:*

И. Гази. **Канатланыр чак.** Повесть.

Г. Гобәй. **Корьән серләре.** Повесть.

З. Нури, Г. Хуҗиев **шигырьләре.**

*Очерклар.*

*Әдәби тәнкыйть мәкаләләре.*

*Сатирик һәм юмористик парчалар.*

*Хатлар.*

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев.**

Производствога бирелде 12/XI-1965 ел. Басарга кул куелды 24/XII-1965 ел. ПФ 08169. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн. изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 34300 экз. Заказ Л-1442. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1966 ел.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

*«Казан утлары» редколлегиясе журналны тагын да матуррак чыгару өчен журналның тышкы оформлениесенә ачык конкурс игълан итә. Сездән тышлык рәсемнәре эшләп җибәрүегезне яки теләкләрегез, тәкъдимнәрегез белән катнашуыгызны үтенәбез.*

*Конкурста иң яхшы дип табылган тышлыкка акчалата бүләк биреләчәк.*

*Редакция.*

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс 73210

*Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал*

**КАЗАН УТЛАРЫ**

*(Огни Казани)*

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ